# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Бары купты күк гөмбәзе... *Шигырьләр.* ...3

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА. Юаш. *Повесть.* ...8

Данис ХӘЙРУЛЛИН. Гел тәгәрәп торыр кояшы да... *Шигырьләр.* ...27

Рәдиф СӘГЪДИ. Әлмирәнең хәтере ачыла. *Роман.* ...32

Идият АШИРОВ. Без бу җирнең бары кунаклары. *Шигырьләр.* ...85

Марат КӘБИРОВ. Тик син генә. *Повесть.* ...89

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фәтхулла АБДУЛЛИН. Сәет батыр токымнары. *Повесть*...132

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Абдулҗан АЗНАБАКИЕВ. Салкын һава, тулган айлы йолдызлы төн... *Шигырьләр*... 146

МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татарстаннан – дөнья фәне киңлекләренә. ...149

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Гали РӘХИМ. Шәрык шагыйрьләре. *(Басмага Дания ЗАҺИДУЛЛИНА әзерләде).* ...154

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Мәхкәмәи шәргыянең вәкаләтләре. ...171

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Татар җыры менә шундый була... *(Әхмәт Ерикәйнең тууына – 120 ел).* ...178

Мәхәббәт һәм яшьлек шагыйре *(Мостафа Ногманның тууына – 110 ел).*
*Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ...179

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Ландыш НӘСЫЙХОВА. Алтын төбәгендәге алтын кешеләр. ...180

2022 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге. ...184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 12 (1202) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигъръят, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 278.11.2022, график буенча 28.11.2022, басылып чыгу вакыты 02.12.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3555. Тираж 7535.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Рүзәл Мөхәммәтшин

# БАРЫ КУПТЫ КҮК ГӨМБӘЗЕ...

## Париж

Хемингуэй саташтырды мине.
Көнне, төнне, таңны бутадым.
Парижныкы кебек балкып янды
Тәрәзәдән Казан утлары.

Һәм сөйләдем сиңа онытылып
Монпарнасны,
Күрсәм, ялгышмам:
Менә бусы – «Шекспир һәм Ко» булыр,
Менә бусы – Нотр-дам-де-Шан.

Медичиның болын-бакчасында,
Шәраб исләреннән исереп,
Шундый гөлләр, шундый гөлләр үсә!..
Мин аларның белмим исемен.

Карарымнан хисләр кабарынды.
Тик монда да, ахры, кичектем:
– Син һәрвакыт йөрәгемдә йөргән
Бәйрәм! – дидем ялгыш,
Ничектер.

– Ияр миңа!
Бездән артып калган
Дөнья, – дидем, – узмас тупсадан!
Качыйк, әйдә!
Качыйк!
Һич югында,
Париж куенына булса да.

---

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. «Каралама», «Бүре мин», «Мин дә китәрмен әле» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

Кабаланган,
Өмет тулы караш
Гамьсез елмаюга абынды,
Иренеңне буяп көрсендең син:
– Ә мин диңгез ярын сагындым.

Хемингуэй соңгы битен япты.
Күкне басты шәфәкъ тимгеле.
Һәм чаң какты шәһәр.
Бусы инде
Башка әсәр иде, билгеле...

Чәлпәрәмә килеп төште Париж,
Коткарырга аны казганмам...

Кояш.
Урта диңгез.
Куш күләгә.

Нәрсә әйтим? –
Сәлам Казаннан!

## Экспромт

Ашламасы ару.
Кургаш орлыклары
Тондырыла учлап!..
Укшыта.

Һәм, елмаеп, бала
Пластмасс мылтык ала...

Озакламый уңыш мул шытар.

***

Зәңгәр күк, сары арыш.
Чиксезлекне ера-ера
Эчкәре үтә барыш:
Биш карыш, җиде карыш...

Тәшвишле төшләнүемә
Төшенмичә, баш ватам:
Серкәләнер сәгатендә –
Кан тамчысы башакта...

Сары арыш, зәңгәр күк.
Киемгә сеңгән кызыллык –
Эчкәре атлаган саен –
Җаныма да сеңәр күк...

Йодрык сыман
Йомарланган
Кояш! –
Юк аңа каушау! –
Җиргә батырырдай булып,
Дөп тә дөп суга башка.

Салкынча,
Дымсу рәхәтлек –
Биш карыш, җиде карыш
Эчкәре...

Дөнья – чиксезлек! –
Зәңгәр күк, сары арыш...

## Матч-реванш

Иртә әле безгә башны иеп,
Уен кырын ташлап китәргә.
Без, җан чыкса да, җиңәргә тиеш!
Бүген түгел икән – иртәгә!

Дәррәү кубып күтәрелик кенә,
Көндәшләрнең йөзе агарыр.
Бездән бер гол, бердәнбер гол кирәк!
Без – чемпион! –
Медаль тагарлык.

Кагыйдәгә сыешасы, диеп,
Әллә кемнәр юктан шау ясый.
Ни пычакка андый ярыш безгә,
Ни пычакка андый дөньясы?..

Аяк өчен баш җаваплы түгел! –
Уен кыры – сугыш кыры ул! –
Безнең өлеш – җиңеп, күккә ашу,
Сезнең – җәһәннәмдә кырылу!

Дәррәү кубып күтәрелик кенә,
Дошманнарның тезе йомшарыр.
Бездән бер гол, бердәнбер гол кирәк!
Без – чемпион! –
Безнең туп – Җир шары.

## Dior

Бертуктаусыз нур коела,
Күзгә керә тузаны...
Әллә купты күк гөмбәзе,
Әллә түбә кузгалды.

Җил тисә дә җимерер, дип,
Суларга кыенсынам:
Бу дөнья шундый үз синңа! –
Dior иннеге сыман.

Менә мин – ихтыярыңда,
Барсын ал – җаным, көчем,
Бит очымда ялкын эзе
Кабарып калсын өчен.

Җил тисә дә җимерер, дип,
Суларга кыенсынам:
Бу дөнья шундый үз сиңа! –
Dior иннеге сыман.

Офыкларны югалткандай
Карама ачуланып.
Аңлаешсыз башланса ни! –
Ахыры ачык аның:

Җил тисә дә җимерелми
Калгачтын, җиңел сулап,
Син мине сөртеп алырсың –
Dior иннеге сыман.

Бертуктаусыз нур коела,
Күзгә керә тузаны...
Бары купты күк гөмбәзе,
Бары түбә кузгалды.

Җил тисә дә җимерер, дип,
Суларга кыенсынам:
Бу дөнья шундый үз сиңа,
Бар галәм шундый үз сиңа! –
Dior иннеге сыман.

***

Юк!

Ялганга
Тагы
Ни диярсең,
Ни диярсең? –

Күндермәкче булып,
Бармакларын күзгә батырмакчы:
Яктылык ул, имеш,
Караңгылык!

Юкса,
Төн – төн!
Кояш – кояш, юкса!
Хакыйкать бер һаман –
Элеккечә.

Мүкләк Иблис чут өйрәнәмени –
Төймә-төймә җаннар
Ары күчә...

Мүкләк Иблис
Асыл мәгънәләрне
Җуймаган ла! –
Аңа гөнаһ – савап! –

Юкса, ут – ут!
Афәт – афәт, юкса! –
Алфавитны арттан башласаң да...

«Юк!»тан кала барсы ялган булса,
«Юк!» бәһасе булса – газап, яшьләр,
Хакыйкатьне ярып салыр өчен,
Ни диярсең,
Ни диярсең? –
Дәшмә.

## Анда

Кояш, тәртә буе калып,
Кичке нурын коя.
Анда дөнья – биек, иркен!
Анда – җем-җем дөнья!

Анда –
Тупыл мамыклары,
Җилдә оча-оча,
Төшеп куна –
Кура сытып
Җилемләнгән учка.

Анда –
Рәхәт!
Бәхет!
Анда –
Шат авазлар камый!..

Кем бу, шундый таныш, дисәм,
Мин – ыштансыз сабый.

Көтү кайта...
Көтек булып,
Сандугачны көтәм.
Тиздән мыек шытар миндә
Яңа сауган сөттән.

Тиздән мыек шытар миндә!
Һәм эңгердә эрер
Артта калган таныш тавыш:
– Берүк исән йөре!..

Күкрәк турысына сугып,
Туктатасым килә:
Анда – биге купкан капка...
Ыңгыраша җилдә.

***

Синең җаның –
Хуш гөлләмә икән.
Мин гербарий диеп ялгыштым.
Аңышуга, Иделдәге тапны
Баш очында кояш алышты.

Дулкын бәрде кинәт.
Җир чайкалып,

Авыр шәүләм сиңа авышты.
– Ядрә очкан ераклыктан бире
Якынайма! – дидең.
Кавыштык.

Син – минем иң үкенечсез, татлы
Һәм, һичшиксез,
Дөрес ялгышым.

## Мөртәт

Туфан китеп, мең җилләгәндер җир.
– Күпме гомер, – диеп, – үткән әрәм! –
Пәрәвезне җаннан йолкый-йолкый
Чыккан идек, юкса, мәгарәдән.

Күз камашты таңда. Баш әйләнде.
Кизләүдәге чагылыштан өркеп,
Битне юдык, сүс урадык билгә...
Һәм бөтенләй кешеләштек беркөн.

Иртәнге җил тәме – иренемдә!
Мин ырудан бераз ераклаштым, –
Чәчкә борын төртмәсме дип, читтә
Каурый белән кармаладым ташны.

Сулап тончыгырлык иде һава!
Учак сыман өтте кояш, якты!
Мин, хис тулы, чалкан авып төштем
Кайнар чыкка. Һәм Тәңрене таптым.

Нинди тавыш, кам, ишетәсеңме?
Йөрәк тибешедәй –
Дөп-дөп, дөп-дөп.
Көтү булып калыр өченмени
Без Нух чорын, Һарун чорын үттек?

Күрәсеңме:
Алар, дөңгер ише,
Ике куллап башка бәрә-бәрә,
Җаны туңган, күзе тонган килеш,
Кабат кереп бара мәгарәгә!

Монда – гөлләр, юкса! Монда – сахра!..
Очы сынык каурый төште учтан...
– Артык иркен, – дип сукранды кемдер, –
Ышык җитми. Димәк, ышаныч та.

Артка –
Якты киләчәккә, имеш!
Дөнья балкыш күреп шатланганда
Ыруымның йөзе күләгәле...
Мин беркайчан кире кайтмам анда.

Казык сыман –
Кузгаласым да юк!
Тәңрем, раслап, күзләремә бакчы! –
Ирек! Ирек! –
Соңгы сәгать сугып,
Мәгарәмә кереп урнашканчы.



Нәбирә Гыйматдинова

# ЮАШ

ПОВЕСТЬ

**1**

...Акбүз кушаяклап типкән иде, тояк җиленнән ирләрнең өчесе өч якка «очты»: ичмасам шунда берәрсенең маңгаен да ярмады! Уе, билгеле, әшәке, ләкин боларның гамәле аның белән чагыштырганда, йөз тапкыр әшәкерәк, болар көпә-көндез акыртып, күмәк хуҗалыкны талый иде. Әүвәл терлек-туарның эресен-вагын урладылар, аннары атларга чират җитте. Ачкүз директор барысын да үзе санап-чутлап төяттерде. Атам малы дисә, ал да ычкын дияр идең, иң болгавыр елларда көрәк-сәнәк белән колхоз төпләгән бабайлар дәүләте бит, бабайлар дәүләте!

Ташкичүгә күктән инвестор «иңгәч», өстәгеләр и мактады аны, и мактады. Янәсе, ул авылга шифалы сулыш өрәчәк. Тик аның сулышы агулы иде ахрысы: ике елда он тарттырган борынгы тегермән ябылып, балык үрчеткән күл кибеп, бакчада алмагачлар корып, авылның җелеге суырылгач, көн итмешләре авырайган яшьләр ирексездән шәһәр-калаларга таралды. Эшкә батыр ташкичүлеләргә бер сыйфат хас: алар чәче белән җир себерер, әмма гаделсезлеккә каршы күсәк күтәрмәс, телсез-тешсезгә әйләнер иде. Әнә, меңәрләгән баш терлек асралган каралтыларны бушатканда да дәшмәделәр. Кечкенәдән ат ботына ябышып үскән Сәлим дә авызына су капкан иде дә... йотмады, кире төкерде, чөнки аның Акбүз кушаматлы җан дустына кул суздылар. Егетнең бахбайны минеке дияргә хакы бар иде. Ала биянең соңгы баласы зәгыйфь булып туды. Ферма мөдире Әмәнулла: «Ярты сәгатьтән үлә хайванкай, үләт базына илтеп ташла», – дип, аны егетнең арбасына салгач «тыңлады» күндәм егет, ләкин табылдыгын базга түгел, өенә кайтарды. Атасы Сәйфулла рәешкә генә кигән кайры тунын җәлләмичә мич аралыгына җәйде. Җылыга кинәнсен тай! Әнисе

Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА (1956) – *Татарстанның халык язучысы; «Мәхәббәттә гөнаһ бар», «Икебезгә дә авыр», «Үзем генә беләм» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

күршеләрдән саудырткан ярты чәшке кәҗә сөтен бәләкәй шешәгә тутырып, имезлек каптырды. Башта хайван теләр-теләмәс кенә суырды, инде дә түмен татыгач, тамчысына кадәр эчеп бетерде. Үлмәдеме икән дип, төнлә әллә ничә мәртәбә уянып тикшерде Сәлим. Исән! Салам сыйракларын як-якка таратып, сабый бала кебек изрәп йоклый. Җылы! Тамак тук! Ә иртән Акбүз хәтта ки аякланырга маташты, тик ул әле хәлсез иде, суыкта өшегән төсле дер-дер калтыранды да, атлап китәргә куркып, идәнгә тезләнде.

– Артык иркәләмик, улым, – диде атасы. – Арытабан табигать үзе җайлар. Җә юаштан, җә гайрәтледән әвәләр бахбайны.

Әнисе көлеп кенә әйтеп куйды:

– Хуҗасына охшаса, знамы юаштан әвәләр.

Хуҗасы, әлбәттә, Сәлим иде.

Сәйфулла карт мытырдык карчыгының керпе теленә кадалмады, чөнки аларның нәсел кушаматы Юаш иде. Авылда өч Сәйфулла, кайсысы дип сорасалар, «әнәгенәк Юашы...»

Әтисе:

– Әзрәк тернәкләнгәч, кире фермага илтерсең, безгә хәрәм килешми, улым, – дигәч, егетнең тавышы корыч кебек чыңлады. Юаш юан бау ишәр, ди!

– Илткән сиңа! Акбүз минеке! Аны без терелтәбез!

– Анысын кем исәпләр икән, улым. Таең күрәйсен генә, аранга китереп яп, диярләр. Әмәнулланың ярты чиләк бодай сыешлы халат кесәсендә биш былтыргы амбар кенәгәсе. Кайсы сыер кайчан бозаулаган, кайсы бия кайчан тайлаган – көне-сәгате белән яза, писыр сыңары.

– Зерә шикләнәсең, әти. Акбүз үлгәннәр исемлегендә инде күптән. Оныттылар инде аны.

Чынлап та, ни рәис, ни мөдир тай турында сүз катмады. Ул алар өчен кибәннән җил очырткан салам кисәге генә, миллионер колхозда үрчем-артым чутсыз, мөгезлеләр һәм тояклылар абзарларга сыймый иде.

Табылдык ни хәлдә иде соң? Әйбәт иде аның хәле. Яшәү теләге көчле, ул һич тә юаштан әвәләнми, эчкәне – кәҗә сөте, ялаганы каты бал иде. Тамаксау, күрәя-күрәя, баздагы запас кишерләрне үз итте, түмен татыгач, шакмаклы шикәр кетердәтте, әрсез иде, аралыкны тарсынып, бүлмәгә «күченде», бүлмәдән – ишегалдына... Дөньясы киңәйгән саен киңәеп, болын белән тоташкач, иркенлек тойган бия кызын беркөнне тиз генә куып тота алмады Сәлим. Тай чапты, хуҗа чапты! Икәү озак «ярыштылар». Ачуын кабартса да, егет аңа сукмады. Чыбыркы белән нинди куркыту, ди, чыбык белән дә селтәнмәде. Күрде хуҗалык рәисе Нәҗибулла абзый, һәр терлек санын кенәгәсенә теркәгән мөдир Әмәнулла да күрде: «үлгән» бахбай – терек! Әмма Алланың рәхмәте, ник берсе: «Колхоз милке, кайтар!» – дисен?

Төшке якта авылның сыер көтүен су эчәргә Сөлчә елгасына куалыйлар, мәхлук хайваннар исә аны изеп-таптап куертып бетерә, су төнлә тона, шуңа күрә Сәлим иртән үк атын коендырырга йөртте. Яр битендә көй көйләп, Рухи чишмәсе ага, иренмәгән халык чәйлеккә шунда килә, һәм ул халык дигәннең берсе Хәйрия карчыкта фатирда яшәп, мәктәптә укыткан күрше Шәрбән авылы кызы Әнисә иде. Аның ничек көянтә-чиләген иңнәрендә уйнатып, баскычтан төшкәнен яшерен генә күзәткән

юаш егетне ни-нәрсә кыюлатты икән, ул Акбүзне йөздерә-йөздерә, чишмә турысынарак җитте дә:

– Чиләкләрең авырдыр, апасы, – диде.

Бу кыз турында: «Тәкәббер, яше барса да, һаман сайлана, әкиятләрдәге ак атка атланган патша малаен көтә», – диләр. Сәлимнең дә бахбае ап-ак, тик кызганыч, ул патша малае түгел, гап-гади авыл баласы. Хәер, аңа карап кына кимсенгәне юк.

Тәкәббер кыз чиләген чишмә улагына куеп:

– Авыр шул, – диде. – Хәйрия әбекәй көненә биш-алты тапкыр күмер самавыры кайната. Газ чәйнегенә тиз юшкынлана, ди. Миндә чәй тәмле дип, ахирәтләрен җыя тагы. Аларга суны чишмәдән ташып кына өлгерт.

Мөгаен, Хәйрия әби ахирәтләре белән туктаусыз шапыр-шопыр чәй эчмәгәндер, мөгаен, Акбүзнең дә тәненә катлам-катлам тузан кунмагандыр, шушы ике «хәсрәтле»нең гел бер үк вакытта Сөлчә буенда очрашуы гаҗәп, әйтерсең, алар кичтән үк төгәл сәгатен билгеләгәннәр. Һи, «сәбәбе»н күрегез сез, имеш тәҗел кирәк эшләрен иртән үк башкарырга гадәтләнгәннәр. Кыз – мәктәптә дәресләр башланганчы, егет – елгада су болганганчы...

Әнисә чая иде, беркөнне ул:

– Ялларда Шәрбәнгә кайтасы идем, кичләтә урман аша чыгарга шүрлим, зинһар, озат әле, абыйсы, – дигәч, Сәлимнең аркасына меңләгән кырмыска үрмәләде. Патша малаен гына үзенә тиң санаган асылбикә аңа «озат» дип ялварамы? Озатты анысы егет. Акбүз белән озаттылар.

Мондый «сәфәрләр» атна арты атна кабатланды. Урманда агач саен күз, агач саен колак икән: авыл гайбәтчеләре күргән-ишеткән, тешлесе дә, тешсезе дә, и рәхәтләнде чәйнәп! Үлеп, Сәлимне кызгандылар. «Өйләнсә-нитсә, тәкәббер Әнисә аны санлап яшәмәячәк», имеш. Урман аша озаттыру әле ул нәрсәгәдер өметләндерми иде. Ә кыз бүтәнчәрәк уйлаган бугай, менә ул маңгайга бәреп:

– Син кайсыбызны ныграк яратасың: минеме, атыңнымы? – дигәч, беркатлы Сәлим җан дустының муеныннан сыйпап:

– Акбүзне, кәнишне, – диде.

Бу аның иң зур хатасы иде. Агач тел! Икегезне дә дисә, җә!

Ир-егетләрне күз карашы белән чәнчеп сындырган чибәркәй мондый мәгънәсез җавап көтмәгән иде, җен-убыр өермәсе кузгатып, урман сукмагыннан элдертте. Аның артыннан карап калган Сәлим үзе генә ишетелерлек итеп пышылдады:

– Икегезне дә... икән.

Шөкер, Әнисәнең үпкәсе кояш җылыткан боз-сөңге кебек тиз эреде. Егет хәзер тәкәбберне урман аша гына чыгармый, аңа Шәрбәнгә хәтле озату хокукы бирелде.

Озын аяклы җәй өч-дүрт кенә сикерде дә, көзге елак яңгырлар тотынды һәм кызга турыдан юл бикләнде. Асфальттан биш чакрым урасаң гына, алар авылына эләгергә мөмкин иде.

– Әйдә, абыйсы, йолкыш атыңны җик тә, җәлт кенә мине илтегез, – диде Әнисә.

Бу патша кызының һич карусыз үтәлергә тиеш әмере иде. Үзенә кагылганда, әллә ниткән хурлауларга түзгән Юаш Сәлимне, әйтерсең, корт чакты:

– Акбүз йолкыш түгел, яме, апасы! Ул әле ять-яшь. Үссә дә, мин аңа камыт кигезмим, Сабан туе чабышларына әзерлим, яме!

Әнисә «корт»ка әче дару сиптерде:

– Кайсы гасыр бүкәне син, абыйсы! Ир-атның аты – машина бүген, машина! Чит илнеке, иң шәбе! Әй... – Кыз, сиңа сүз әрәм дигәндәй, нәзек иренен бөрештерде. – Дүрт аяклы хайванга гашыйк икән берәү!

Сәлим теге чактагы кебек аңгыраймады, күкләр ярылырлык көчле тавыш белән:

– Кайсыдыр чибәр кызны да яратабыз әле без! – диде.

«Кайсыдыр чибәр»нең кем икәнен аңлады Әнисә. Алар ярәшелгән тамгасы белән ике ел урман юлын таптап такырайткач өйләнештеләр. Аңа хәтле булачак кияү көйләнде-җайланды: машина алды, төп нигезеннән аерылып, йорт тергезде.

Кәләш беренче көннәрдә үк юаштан бау ишмәкче иде бугай:

– Бияңне әтиеңнәрдә калдыр, – диде.

Калдыра ди сиңа. Кышкы салкыннарда өшемәсен дип, калын-калын бүрәнәләрдән кем өчен җылы абзар төзелде? – Акбүз өчен!

Капкадан беренче Акбүз керде. Ә аннары... башланды. Сабан туендагы ат ярышында җиңгән малкайның муенына бәйләгән чигүле сөлгене диварга элгән иде ир, хатынга бу ошамады, ул аны йолкып атты. Сәлим исә яңадан элде. Шулай бер-берсе белән «көрәшә» торгач, Юаш җиңелде. Юл биреп, дөрес эшләгәндер: чүпрәк өчен талашып ваклану ир-атка килешми. Әмма сөлгедән соң вакланулар ереләнде, «патша кызы» почык борынын кулъяулык белән каплап, кәһ-кәһ йөткерде:

– Фу, өйдә тончыктырырлык ат исе! Фу!

– Ат абзарда бит, – диде Сәлим.

– Өйдә дә ат исе! Синнән дә шул ис аңкый, фу!

– Мин чиста, һәр кич мунчада юынам!

– Күзәнәкләреңә сеңгән синең! – Хатын өй уртасында бомба шартлатты: – Түзәрлегем юк бүтән! Сиңа өч көн срок, сайла: йә мин, йә йолкыш!

Ничек «сайла», ничек?! Сәлимгә аларның икесе дә кадерле, аның йөрәгендә икесенә дә урын бар, кайсысы якынрак дип үлчәсәң – үлчәү тәлинкәләре тип-тигез иде.

Тугач та, чуттан сызылган тайны балаң кебек багып үстергәч кенә, «дүрт ягың кыйбла» дип, урамга ку, имеш. Беләме соң хатын: Акбүз аның бердәнбер хыянәтсез дусты. Беләме соң хатын: Акбүз хуҗасын данлаган батыр чаптар да! Алда әле дистәләгән җиңүләр! Ә син үз кулың белән хыялыңның тамырына балта чап!

Әнисә дә бердәнбере... Тәкәббер кыз белән кушылгач, авыл шаккатты. Юаш кына чыпчык нинди асыл кошлар аулый, янәсе. Үз ихтыяры белән җилкәңә кунган «кош» ауланган саналамы икән? Егет аңа өйләнү турында ым да какмады, авылда «чиләгенә күрә – капкачы» урам саен, ә инде Әнисәнең тел төбендә ниләр ятканын сизгәч, «капкач» ярамаса да, тәвәккәлләде. Кыз аны ярата, димәк! Бәлки әзрәк яратадыр, ләкин ярата кебек тоела иде. Менә хәзер шушы мәхәббәтеңнән ваз кич инде, йа!

«Сайла...»

Әйе, ул сайлады.

– Хәйрия әбиләрдә яшисеңме яки үзегездәме? – дигәч, «патша кызы» чүт аркан аумады. Акылга сыймаслык хәл! Аңардан – ил-көндәге иң чибәр хатыннан баш тарталар!

– Алай икә-ән! – Әнисәнең күзеннән мең төрле төсләргә үзгәреп, зәһәр чаткылар чәчрәде. – Сиңа йолкыш хайван якынрак икә-ән! Нишләп мин сезнең авылда гомер черетим, Шәрбәнем мәктәбендә укытам! Әллә сиңа үлеп-бетеп гашыйк идемме?! Сазаган кыз исеме күтәрмәс өчен генә чыктым мин сиңа, ат колы!

«Юаш шул, хатынын үз кубызында биетмәде», – дип сөйләде авыл. Сөйләсеннәр, тел чүбеннән генә чүмәлә өелми. Ярату ярасы тирән уелды, ул мәңге төзәлмәс шикелле иде, алдагысы куәтлерәк булып, ул аста күмелде.

...Тирә-якларда күмәк хуҗалыкларны исеме телгә ятышсыз агрохолдингларга берләштергәндә, эшле-ашлы ташкичүлеләр пошаманга төште. Аларның кыр-басуларын да саранча көтүе сырмасмы икән? Рәис Нәҗибулла җыелышта халыкны тынычландырды үзе.

– Туганнар, безгә бу афәт янамый, без миллионер колхоз, безнең өс – бөтен, тамак тук, чыга... төтен. Ярар, каян чыкканы сезгә мәгълүм төтеннең, әле без үзебездән артканны дәүләткә дә сатабыз.

Ялгышты рәис абзый, «саранча» уптым илаһи авылга ябырылды. Аларның байлыгы ташыган хуҗалыкка бөтәшкән күрше колхозларны кушкан иттеләр дә Каф таулары артыннан диярсең, килеш-килбәте белән әкиятләрдәге түгәрәк күмәчкә охшаган бер адәмне китерделәр. Хәзер түрә директор дип атала, аңа перси агай яисә перси энем дип эндәшәсе түгел, ул Мөнир Хикмәтович иде. Инвестор дигәнең, моңардан да кәттәрәк кеше, бер дә күзгә-башка чалынмады, Казандагы биек каланчасыннан гына боерык биреп ята, ахрысы.

Элек колхоз капкасы көн-төн шыр ачык, атлы ир-ат арт шәрифләренә йомшак ясап, арба төбенә печәнен-фәләнен түшәсә, җәяүле сыер савучы хатын-кызлар пластик шешәләргә сөт тутырса (үз йортындагы сыерның сөтенә караганда хуҗалыкныкы тәмлерәк!), рәис боларны урлашуга санамады. Ә директор Мөнир өчен бу дәүләт җилкәсен кимерү иде: ул җил аударырлык такта капканы җимертеп, тимердән эшләтте һәм каяндыр читтән җирән сакаллы бер әзмәверне сакка бастырды. Бил каешына әллә чын, әллә уенчык пистолет кыстырган Җирән бик әшәке кыланды: ул ике уч силос өчен ирләрнең чанасын вата-сындыра, хатыннарны исә тентеп җәзалый иде. Өстәргә килмәде инвестор, киметергә килде һәм озакламый исеме үзгәртелгән бай колхоз шома таш кебек таудан аска тәгәрәде. Әкрен генә фермалардан йөзәрләгән-йөзәрләгән сыер-бозаулар кыяклады, амбарлардан каядыр ашлык озатылды, печән кибәннәре урынынннан «күчте». Терлекчеләр, бигрәк тә сыер савучылар, зар елады. Терлек саны азайгач, аларны кыскартырга керештеләр. Экономия! Бишәү башкарасы вазифа бер кешегә генә йөкләнгәч, өч ат караучысының икесе, шул җөмләдән Сәлим дә «артык кашык» булды. Хәер, аның ризыгы киселмәде: ул оялмады-хурланмады, шәхси хуҗалыкларның сыер көтүен көтәргә ялланды. Ярдәмчесе Акбүз белән киң болыннар иңләү дөнья рәхәте бит! Киләчәктә үзенең бизнесын оештырырга хыялланган ир шактый гына мая тупласа да, иш янына куш иде көтүче акчасы. Аннары, Әнисә ташлагач,

буш өйдә күңелсез иде аңа. Әмма хыял канатларын бик җәймәскә икән шул. Беркөнне көтүдән кайтышка капка төбендә аны атасы Сәйфулла көтә иде. Гадәттә, борчылса-нитсә, аның куе кашлары җыерылып, бергә тоташа иде.

– Улым, нишләрсең инде, атыңны ыштубы да безгә тапшырсын ди теге диликтор Мөнир. Бия минем малайныкы, ул колхоз исәбендә юк дигән идем, вәт явыз, кәнсәләр шкафыннан Әмәнулланың амбар дәфтәрен тапкан. Әмәнулла, эт бете, үләт базына ыргыт дисә дә, тәки фәлән елда, фәлән числода тай туды дип теркәгән бит, улым.

Сәлимнең биш бармагы йодрыкка бөкләнде. Әйтерсең, юаш кына башы белән директорның яңак төбенә кундырмакчы иде ул.

– Тапшырган, ди! Акбүз минеке!

– Мәгәр тыңламаса, политсага жалу язабыз, ди. Каракка чыгармакчылар сине, улым.

– Миңа димәгәе, хет Берләшкән Милләтләр Оешмасына язсыннар. – Армиядә хезмәт иткәндә, Сәлим сәяси терминнарны күп ятлаган иде. – Алардан кем шөлләгән, ди, әле монда!

Башта аңа Җирән сакчыны өстерде директор. Ул бәндә котырган эт белән бер иде.

– Давай атны! Ике сөйләттермә! – дип, капканы тупсасына хәтле каерган «кунак» абзарга табан ыргылмакчы иде, ишегалдында кипкән печән әйләндергән хуҗа, көнозын көтү көтеп арса да, ничек җиңел генә аның каршысына атылып, корсагына сәнәген терәде икән? Сукса җиргә сеңдерерлек әзмәвер артка чигенде, чөнки ярсыган ир үз-үзен белештермичә эчен тишеп агызырга мөмкин иде. Үкчәсен ялтыраткан Җирән сакчы капка артыннан гына янады:

– Без сине төрмәгә утыртабыз, ат карагы!

Онык бабасы язмышын кабатлармы икәнни? Алтмышынчы елларда колхоз рәисе: «Безнең алаша», – дип, Сираҗи картның тайдан үстергән атын фермага япкач, бабасы яклау өмет итеп, Мәскәүгә – Хрущёв янына китә. Кертәләрме аны илбашы эргәсенә яки Кызыл Мәйданнан ары уздырмыйлармы? – Алла белсен, әмма ул кемдер сырлаган язу тотып кайта. Шул серле кәгазьне рәиснең борын төбендә селкегәч, тегесе бүтән аңа каныкмый. Ә Сәлим кемгә барып егылсын? Егылган тәкъдирдә аңардан: «Вәт җүләр!» – дип көләчәкләр генә. Сираҗи картлар заманында ат күп балалы гаиләнең төп ярдәмчесе саналган, аның белән бакча сөргәннәр, бәрәңге утыртканнар, болыннан печән, урманнан утын ташыганнар. Бүген һәр йортта техника. Сәлимнең дә гаражында машина, каршында мини-трактор әнә. Ни җитми сиңа, егет, диярләр. Җитми, Сабан туйлары якынлашканда, йөрәкнең җилкенүе җитми! Кулыннан көрәк-сәнәк төшмәгән авыл баласы, елга бер мәртәбә бәйгедә җиңеп, шәхесен таныта икән, моның ни гаебе?! Әнә гәүдәсеннән ун-егерме тапкыр авыррак йөк сөйрәгәндә (әйтик, таракан үләксәсен), кырмыска да үзен фил итеп тоядыр. Акбүз дә бәйрәм алдыннан хуҗасы кебек җилкенә, ул да ярышлар өчен яратылган чаптар икәнен расламакчы.

Урланасы – урланып, таланасы – таланып, фермалар бушады. Ә комсызларга төягәне һаман аз, гүя иң зур майлы калҗа Сәлимнең йортында калган, әгәр шуны чәйнәп йотмасалар, тамаклары туймый иде.

## 2

Өч тапкыр куылганнан соң Җирән сакчы төркем туплап килде. Әрҗәле машинада директор белән өчәү, сиренасын улата-улата, аларны озаткан полиция егетләре икәү, монда инде сәнәк кенә булышмаячак иде. «Кунаклар» килешкә махсус әзерләнгәндәй, Сәлим Акбүзнең ялын тарый иде. Тегеләр шалдыр-шолдыр әрҗәне бигеннән ычкындырып, артына тактадан әтмәлләгән шома баскыч сөяделәр. Директор абзыйның йөзендә тантана иде.

– Кем диик әле сине, җегет? Каракмы, угрымы? Тәки кирегә каттың, җегет. Миннән бер яхшылык: эшне судка җиткермим. Ат – дәүләтнеке, ә дәүләт милкен урлаган кешегә статья чәпиләр. Живо, арбага менгез безнең бияне!

Зур капка шар ачык, атыңа атлан да боларны изеп-таптап чыгып чап! Акбүз дә сигнал биргәндәй, кешнәп җибәрде. И аңардагы сиземләүләр! И аңардагы адәм акылы!

Атланды ир, әмма шул мәлдә үк ике полиция хезмәткәре аны аягыннан тартып төшерде һәм кабыргасын чатнатып, кулын артка каерды. Җирән белән шофёр Акбүзнең тезгененә ябышты. Юкка гына көчәнделәр, кечкенәдән үк ирек тәмен тоеп үскән гайрәтле бия үзенә ят куллар орындырамыни, ул уңга-сулга башын чайкады, чайкаган саен тегеләр су тамчылары кебек читкә «чәчрәде». Сәлим ычкынырга азапланып, алга тартылды, тик «закон сакчылары» селкенмәслек итеп кулын боргычлаган иде шул.

Бу тамашаны кырыйдан гына күзәткән директор ярсыды:

– Икәү бер хайванны җиңәлмисез, камыр батырлар! Аркан бармы, аркан?

– Бар, – диде Җирән.

Сүс арканның очын түгәрәкләп, элмәк ясадылар. Һоп! Циркта аюлар уйнатканмыни, Мөнир элмәкне очырткан иде, ул атның муенына ук чорналды. Өчәүләшеп, аны баскычка сөйрәргә тотындылар. Ә Акбүз карыша, Акбүз хуҗасыннан башка китәргә теләми, көрәшә-көрәшә, аның хәтта муенындагы элмәге дә өзелде.

– Балтагыз кая?! – Мөнир акылдан шашты. – Аягына чабыйк! Барыбер ит комбинатына илтәсе! Балта!

Шунда бия кушаяклап типте дә инде. Типте дә ефәк ялын тузгытып, җан-фәрманга кырга чапты. Аның җәлладлардан котылуына сөенгән Сәлимнең шул мизгелә үк йөрәгенә шом үрмәләде. Ат кырны урталай кисеп, Сөлчә елгасына табан турылый. Мәгәр аръякка йөзеп чыкса, ярты чакрымнан гомер йөзендә кеше аягы басмаган Руша урманы башлана. Элгәреге заманнарда картлар: «Ул зәхмәтле урын дип өркетә, чехлар белән сәнәк сугышы вакытында (алар нәкъ шушы тирәләрдән уза) йөзәрләгән дошман солдатларының мәетен күммичә генә, Рушага ташлаганнар, имеш. Анда җен-пәри оялаган, әгәренки бу урманга керсәң – адашасың, кайту юлын тапкан ни зиһенле атлар да монда бутала, имеш.

– Хи-хи. – Җирән авыз ерды. – Ташкичүләрнең Рушасындагы ач бүреләр өеренә азык бу мәхлук хайван! Өченче ел көтүгә ничек ябырылганнар иде, атаманнарын атып үтергәч кенә шөлләделәр, иеме, Мөнир агай?

Полиция хезмәткәрләре шыпан-шыпан тайгач, ике куштан сыңарлары

– шофёр белән Җирән безнең бурыч үтәлде дигәндәй, машина кабинасына үрмәләмәкче иде, директор:

– Ашыкмагыз? – диде һәм сирәк теш ярыгыннан чекерт-чекерт җиргә төкерде. – Кая чабулыйсыз, мөгезсез үгезләр?! Мин уйлаган нәрсәмә нокта төртмәдем. Хәзер үк ат артыннан барасыз! Хәзер үк, диләр сезгә!

Сакчының ерылган авызы киредән җыелды.

– Ялгыш ишетәмме соң, Мөнир агай? – диде ул сагаюлы тавыш белән. – Саңгырауландыммы соң?

– Дөрес ишетәсең, сарык! Немедля, Рушага элдертегез!

– Шаярма, Мөнир агай. Күперсез елгадан машина белән ничек элдертик, йа?

– Шофёр Рәкыйп кылдырчасын яр буенда калдырсын, ә син йөзеп чык, сарык!

Каерылган кулын угалаган Сәлимне оныттылар. Үзләренеке куәтлерәк иде.

Моңарчы түрәсенең һәр боерыгын баш өсте үтәгән Җирән әллә нишләде. Менә-менә аның өянәге көчәер кебек: күзе акаеп, ирен кырыйлары күбекләнде:

– Минме?!

– Син түгел, мин! – дип үртәде Мөнир.

– Минме?! Рушагамы? Ерткычлардан чәйнәтергәме?! – Сакчы кызарды-бүртенде. – Акылың алтын икән, агай. Боларның колхозын чишендереп, бөтен нәрсәләрен сатып, кесәңә тыкканда, минем белән бүлештеңме, ну? Кукиш миңа! Туган якларга кайтырга өч тиен премия язмадың! Урлаганнарың тамагыңа тыгылсын, бирән! Кузгалдык, Рәкыйп! – Әзмәвер җиргә чүгәләгән Сәлимнең җилкәсенә орынып үтте. – Гафу ит, туган.

Болай кул сыпырып сызланып утырсаң, Акбүздән бөтенләй колак кагуың ихтимал иде, ир этиләренә ашыкты.

– Бия качты, эти! Апкитмәкче иде теге капкорсак директор, качты шуннан!

Атасына ни, үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын!

– Кайгырма, йортка ияләшкән хайван кайта, улым.

– Ничек «кайта»?! Рушага качты бит ул! – дип үкерде Сәлим. – Безнең бабай чеби аулаган тилгәннәрне һавага атып куркыта иде. Чормадамы аның мылтыгы?

Сәйфулла карт сагайды. Юаш бер дә болай казаныннан ташып, дөбер-дөбер кайнамый иде.

– Нәмәгә сиңа мылтык? Син, малай, бандит Мөнир белән көрәшмә! Аларның озын кулын син генә кыскартырсың, ди!

– Мин аның белән көрәшмим! Мылтыкны бир, эти.

– Күгәргән тимер кисәге чуртымамы сиңа! Бабаң үлгәч, кем аны чистартып майлаган әле.

Ир, һич югы бүреләрне чәнчергә монысы да ярый дигәндәй, абзар нүешенә сөялгән сәнәкне эләктерде.

– Акбүз артыннан барам мин, эти!

– Әҗәлеңне эзләпме? Мәрхүм бабаң буранлы кичтә Сөнчәледән ялгышып, Руша ягына борыла. Таңга хәтле урман буенда адашып йөри бабаң. Көчкә ычкына тегеләрдән.

– Нинди «тегеләр», эти?! Бүредән гайре шайтаным да юк анда.

– Бигрәкләр арусыз җир бит, улым, – дип инәлгән атасына кул гына селтәде ир.

Сөлчәдә балык сөзгән өч малай аркасына сәнәк яткырып, арткы ярга йөзгән Сәлимгә иярмәкче иде дә, «батыр» акаеп карагач, курыктылар.

Бүген ул әкият каһарманы, аңарда биниһая көч, ул бүре кыяфәтле диюнең җиде башын да сәнәк кадап өзәчәк. Акбүзне явыздан коткарачак Сәлим. Юк ла, дию кыяфәтле бүренең... Тфү, Руша ягыннан искән җил дә зәхмәтле, ахрысы, әллә ниләр уйлата. Әйтерсең, ир беркатлы сабый яшендә!

Балачакта малай әбисе белән Шәрбән урманында чикләвеккә йөри иде. Карчык урман авызында чирәмгә утырып, башта тузанланган галушын кагып, артка чөеп бәйләгән яулыгын рәтли, аннары пышылдап кына дога укыгач, буйсынган тавыш белән:

– Керергә ярыймы суң? – ди. Янәсе, урман иясеннән рөхсәт сорый. Сәлим көлә. Уйдырма! Ия дигәннәре хет бер тапкыр очрасын иде. Ә хәзер Рушага якынлашканда, бу «уйдырма» чынбарлыкның үзе кебек тоелды. Даң-доң, даң-доң... Күкрәк читлеген җимергәндәй, йөрәк чаң какты. Даң-доң... Урман тирәсен камаган яшь наратлар гүя чех солдатлары, менә алар җанланып ирнең өстенә авар кебек иде. И куркак! Бастырып атла, бастырып. Ниткән солдатлар, ди, болар гасыр бабалары – карт наратларның кысрык куенын тарсынып, кырыйда – иркендә тамыр җәйгән. Аумый алар, куркак, аумый!

Әнә төпләренә кушучлап-кушучлап, каен җиләге сипкәннәр. Сәлим берсен өзеп капмакчы иде, кулы утта пеште. Диндар әбисеннән көлгән иде дә... Ул җиргә тезләнде. Шартын китерергә кирәк... Шартын... Иренен чак кына кыймылдатып, күңеленә сеңгән догасын кабатлагач, тимер чаң күкрәкне авырттырмый иде инде. Шартын китерде...

– Керергә ярыймы суң?

Сәер тынлыкка кемдер өф-өф өргәндәй, кинәт җил кубып, наратларның тубал башын чайкалдырды. Җилкәгә шыбыр-шыбыр күркә малайлары коелды... Эчтә – чытырманлыкта ат кешнәде... Сәнәген тотып шунда ташланган ир яшь наратлар арасыннан җиңел генә йөгерсә, алда аңа юл бикләнгән: аркылы-торкылы ауган гасыр агачлары «урман пәрәвезе» корган, монда җил сызгырырлык тишек тә юк иде хәтта. Йөгергән шәпкә черек төпкә абынып егылган ир уфтанып:

– Керттең дә үзе, – диде.

Бит турысында гына бөгәрләнеп, елан йоклый, мәгәр селкенсә – Сәлим аңа сәнәк белән кадарга әзер иде, бәхеткә хәшәрәт уянмады. Ир бугаз ертылганчы кычкырды:

– Акбү-үз!

– Үс-үс... – Кайтаваз аны үчекли генә иде. – ...Үс-үс...

– Акбү-үз!

– Үс... үс...

**3**

Батыр абыйга иярмәк булган шәрә малайлар ярда ыштаннарын киптерә иде, өчесе дә аны уратып алды.

– Абый, абый, Рушада җеннәр күпме?

– Күп. Агач саен унар.

Ир күлмәген салып сыкты.

– Абый, абый, бүреләр мыжлаганмы?

– Мыжлаган.

– Нишлиләр, абый?

– Җиләк ашыйлар.

– Һи, тиле абый, – диде «балыкчылар»ның иң бәләкәе. – Бүре куян гына ашый ла.

Оланшакның күзе үткен, инә тишегеннән җеп саплый. Кубарылып, Рушага чапканчы башта алардан белешәсе иде аңа.

– Бөркетләр, минем ак атны күрмәдегезме алай-болай?

– Күрдек, күрдек! – диеште малайлар. – Әрәмәлеккә качты синең атың, абый!

– Рәхмәт, бөркетләр! – Сәлим юеш күлмәген кия-кия, шунда чапты. Тик күпме генә чакырса да, Акбүздән «җавап» ишетелмәде. Куаклыкта кыр тавыгы гына тамак төбе белән кыркылдады, күрәсең, ул бала чыгара һәм ирнең тавышы аның йөрәгенә ярамый иде. Һәр җан иясенең үз хәсрәте! Ләкин Сәлим кебек бәгырен утлы кисәү белән өтә-өтә, беркем дә сызланмастыр, беркем дә! Ат кына бит ул диярләр, аңа алмашка йөзләгән чаптар бар, берсен сайла диярләр, ә син шуларга тукы: эт белән ат хәтле тугры җан иясе дөньяда юк, Сираҗ бабасы кырда кибәннән егылып, билен имгәтә, тезгенгә аягын куярга җиңел булсын дип, аты дүрт аягына тезләнә... Ә аларның Сарбай кушаматлы этләре алты яшьлек Сәлим тобада баткач, колагыннан тешләп, ярга сөйрәгән иде. Ахырдан колак авыртты, аның каравы тончыгып үлмәде малай.

...Сөенечле хәбәр көткән атасына ни дисең инде?

– Юк, эти. Җир ярылып, шуның ярыгына чумган, ахры.

– Чуммас, улым, чуммас. – Берәү өметен өзгәндә, икенче берәү аны ялгарга тиеш. Ялгады карт. – Хәтереңдәме, ун ай элек дүрт көнгә югалды Акбүз. Без әнкәң белән бәрәңге казый идек, син и кыбырсыдың, и кыбырсыдың. Урлаганнар, фәлән-фәсмәт. Кайларда браматта йөргән икән хайван ул чакта, җә? Кайтты бит малкай. Бу юлысы да кайта, инша Аллаһ. – Сәйфулланың әйтәселәре шуның белән генә бетмәгән иде. – Сиңа яңалык, улым. Акбүз буаз безнең, корсагы хәттин зурайды.

Сәлим шунда ук этисенең «яңалыгы»н искәртте:

– Солы ашап симерде ул. Сабантуйга хәтле ябыктырасы идем.

– Ай-һай, ашауда гынамы икән хикмәт, – диде атасы. – Яшьтән бирле атлар янында эшләдем. Чамалыйм, кайсы кысыр да, кайсы буаз аның, вәт шул.

– Әй син тагы! – Ир бәхәсләшмәде, эче-тышы янган хәлдә өенә китте. Тормыш төссезләнгән кебек иде. Ул абзар ишеген ачты-япты, ачты-япты. Дивар кадагындагы өзәнне сыйпады, бер тапкыр да биянең муенына кидермәгән камытның тузанын өрде. Акбүз йөк ташыр өчен яратылмаган иде. Аран тагарагындагы солыны буташтырды. Малкайның соңгы тәгаме... «Кайта», – ди атасы. Атларда адәм акылы, әгәр хуҗасына үпкәләсә – капкаңа да орынмас. Үпкәләр дә, Сәлим аны җәлладлардан араламады. «Кулымны каерганнар иде», – дип аклан инде син. Яки бүген башкисәрләр заманы, аларда көч, аларда мәкер, ә синең хуҗаң бер юаш нәрсәкәй дип мескенлән!

Юаш Ташкичүне көтүчесез калдырды. И, усал хатыннар аны тел табасында куырды да соң! «Һа, аты югалган икән! Һа, җир йөзендә бердәнбер ат икән!» Авыл белән җыелышып, шәп кенә айгыр сатып алырлар, көтүен генә ташламасын, янәсе. Сәлим мондый тиргәүләрне колагына да элмәде, аның максаты анык: Акбүзне эзләп табу. Якын-тирәләрне айкагач, ул ерактагы Салагыш урманына турылады. Биштәренә ун шакмак шикәр тыкты. Җан дустын сыйлар! Үзенең ничә тәүлек тамагыннан ризык үтми, әйтерсең, кайгы буып, бугазын нечкәрткән иде.

Ир, урман авызында, икенче мәртәбә шартын китереп, дога укып:

– Керергә ярыймы суң? – дигәндә генә, шатор-шотыр куак ерып, каршысына каравылчы Фәйзрахман чыкты. Бу абзый да «ияләр» кавеменнән, ул да урман хуҗасы, бәлки иң әүвәл аңардан рөхсәт сораргадыр?

– Ни хәл, Фәйзрахман абзый?

– Сорама! Хөрти минем хәлләр, энем. – Каравылчы яшь наратлар армиясенә ымлады. – Әнә, бак, пошилар ничек харап итте боларны. Ун гектар бит! Синең киләп-сарып йөрешме, Сәйфулла малае? Табигатьтә хозурланасыңдыр, шәт?

– Ниткән хозурлану, Фәйзрахман абзый. Югалган атымны эзлим. Матур гына ак бия күрмәдеңме син?

– Минем күзгә агы-карасы күренерлекмени, энем? Җүнсез пошилар наратларның кайрысын кимергән, тәбәнрәкләренең очын ашаган, дим бит, Алла колы! Миллионнар тотылган байлык ие, миллионнар! Сталин чорында мине кәкре каенга терәп аталар ие. Безнең министр атмас, ну, ник сакламадың дип, эшемнән куар. Сакларсың, пычагым! Пошилар хәттин үрчеде.

– Рушада наратлар ип-исән, Фәйзрахман абзый.

Телеңне тешлә, белдекле кыланып, кешенең җен ачуларын кузгатма югыйсә.

– Исән, кәничне! Рушага урман иясе тидертми. Ә минекен сезнең ише җан көекләре куркыта. Йөрмәле чиләктән иләккә су ташып, Сәйфулла малае. Бабаң аучы иде, мылтыгы хуттадыр әле, өч-дүрт поши ат хет. Кышлыкка түшкә-түшкә ит сиңа.

– Рәхмәт, Фәйзрахман абзый, поши итенә әче кайры тәме сеңә! Яшәсен хайваннар, урман тулы агач, тагын утыртырлар, – дигәч, Сәлим сагайды. Каядыр ат кешни! Яңгыратып кешни!

– Минем Акбүз, – диде ул, кай тарафка йөгерергә белмичә.

– Умартачы аты ул, Сәйфулла малае. Бездән өч чакрымдагы аланга ел саен корт оялары куя Шәйхи.

– Акбүзнең кешнәвен аерабыз без, – дип канатланган ирнең аркасын каравылчы чәнечкеле сүзләре белән «пешерде»:

– Җүләр – аягы белән түләр! Әйдә, чап!

Аяк кынамы, гомере белән түләргә риза иде Сәлим. Тик Аллаһы Тәгалә ни аяк, ни гомер белән түләттермәде: түгәрәк аланда күм-күк ат чемченә иде...

Табигать кызганмыйча аркасына бөкре чәпәгән умартачы исә көтелмәгән кунакка аптырамады. Сулуы капкан ир дә аны ерактан гына сәламләде.

– Саумы, агай?! Сиңа алай-болай ак бия очрамадымы?

Хикмәти Хода, бүген халыкның барысы да, сүз куешкандай, Сәлимгә кырыла иде. Менә монысы да бөкресен тигезләгәндәй кагынды да:

– Синең азгын атың гына уемда, ди, бәндәм. Кортларымны кабахәт шөпшәләр урлап ашый. Ходай минем хәсрәтемне сиңа бирмәгәнгә шатлан, – диде.

Әлсерәгән эт төсле көчкә өенә кайтып егылды Сәлим. Ике йорт арасындагы сукмакка тузан кундырмаган пырдымсыз атасы тып итеп килеп тә җитте.

– Тәккә җил куасың, улым. Табылмаса ни кайгы! Мәчет картлары садака акчасына сиңа ат юнәтмәкче. Түлке хуҗалык көтүенә генә алынсын, диләр.

– Миңа бернинди ат та кирәкми! Миңа үземнеке кирәк. – Сәлимнең нерв җепселләре менә-менә шытырдап өзелер кебек иде.

Аксакаллар гозерен аяк астына салып таптаган ирне элеккеге колхоз рәисе Нәҗибулла да үгетләп маташты.

– Нәстә инде син киреләнәсең? Ярты көтү авылга таралган кичә. Тыялмый кеше, синең осталык юк кешедә. Атым дип бетәшмәле, башың исән булсын. Миндә әнә яшь айгыр, сиңа бүләк итәм. Иярлә!

– Миңа үземнеке кирәк! – Бу сүзләр бәгырьгә үк береккән иде. – Дәҗҗал Мөнирдән генә качып ятышы аның, кайта ул беркөн.

– Ишетмәдеңмени, Сәлим? Мөнирнең эше судта, урлаганнарын костыралар.

Әлеге хәбәр күңелнең бер почмагына поскан өмет ялкынын көчәйтте. Чын мәгәр, атларда адәм акылы, сизәр Акбүз, һичшиксез имансыз каракның бүтән зыян китермәячәген сизәр һәм йортына кайтыр.

Атналар буе шушы өмет йөрәкне җылытты. Әмма санаулы көннәр уза-уза аның ялкыны кимеде.

Бер иртәдә, кочагына көлтә-көлтә шатлык тутырганмыни, йөзен балкытып, әтисе килде.

– Улым, хәзер үк барып апкайт! Хәзер үк! – диде карт. – Тимерне кызуында сук, улым!

Акбүз табылган, Акбүз!

– Кайда ул, әти?! Кайда?!

Капкага ыргылган Сәлимне карт җиңеннән каптырды.

– Дулама! Кем ат дигән сиңа! Хатының: «Ирем белән кушылам, килеп апкитсен», – дигән. Кибетче Рокыя аша әйттергән. Чыны-дөресе: шушы дүрт аяк аркасында тормышыгыз ватылды. Атыңны сөймәде килен. Яңадан татулашыгыз, улым. Үзе ялынгач, апкайт!

Сәлим кояш чагылдырган күзен кысып, зәңгәр күк йөзенә текәлде. Тау хәтле ап-ак болыт кадакланган төсле баш очына эленгән һәм ул килеш-килбәте белән аның Акбүзен хәтерләтә, әнә төз аяклары, әнә озын муены, әнә тузгак койрыгы... Менә бия ипләп кенә ишегалдына төшеп басар кебек.

– Әти, сезнең былтыргы каты балыгыз бетмәдеме?

– Саңгырау мәллә син, малай? Хатының Әнисә дим...

– Бетмәсә, Акбүзгә ашатырга бирерсез.

Картның кочагындагы шатлыгы шыбырдап, җилгә коелды:

– Һаман шул бер чүбек чәйнәмә, малай! Атка караганда, хатын кадерлерәк!

– Миңа атым кадерлерәк, эти.

Атаның сабыр савыты тишелде:

– Башыңа тай типте мәллә, малай?! Хатын белән гомер итәсе, хатын белән! Ат егыла да үлә. Синеке дә үлгән, малай! Элдерт килен артыннан! Әнкәң табын көйли, бездә чәйләрсез, – дигән карт, шапылдатып, капканы япканда, Сәлим кычкырды:

– Каткан балыңны Акбүзгә ашатырга бирерсең, эти!

Ир, юк эшен бар итеп, озак кына абзарда бөтерелде. Берәмтекләп, аран идәнен себерде, агач ләгәндәге бүрттергән солы әчегән иде, аны түкте. Хәрәкәтләнгән саен күкрәгеген киереп сулады. Әйдә, аны акыш-макыш дип мыскылласыннар, аның өчен дөньяда иң татлы ис – ат исе иде. Ә бит кемдер Сәлимне җүләргә санамаска тиеш. Ир тиз-тиз генә юынып, киемен алыштырды. Хәтта туйда бер генә тапкыр таккан зәңгәр галстугын муенына бәйләп интекте. Ыспайланды!

Гаражда кыштан бирле кузгатылмаган машинаның ян тәрәзәсендәге тузанын кул арты белән генә сөртте. Шулай да бата! Атасы турларында иде, хәерле юл теләп, кул болгады. «Шөкер, киленне апкайта».

## 4

...Ә чакрымнар гел бүтән якларга әйдәде. Әгәр ул да Акбүзнең югалуын кысыр хәсрәткә тиңләсә? Ул да: «Кем инде үлеп-бетеп, ат ярата, тиле син», – дисә?

Хәтерли әле Сәлим, кечкенә чакта урманда йөргәндә, малай-шалай сусаса, юлдагы бәләкәй чокырчыкка җыелган яңгыр суын эчә, ләкин берсе дә йогышлы чир белән авырмый, чөнки чокырчык шифалы ат тоягы эзеннән хасил иде.

...Сабакташның капкасы бикле иде. Элгәре авыл кешесе ишеген дә таяк белән генә терәтә, таяк – йозактан хәтәррәк кисәтү иде: «Без өйдә юк!» Бүген исә йортларның эче-тышы биктә. Хәер, хуҗа хатын ябасын ябып, томалыйсын томалар, ул бит шыр ялгыз. Кая ашыксын Сәлим, көтә. Кич кайтмаса иртән, иртән дә кайтмаса... барыбер көтә. Лачын абзардамы икән? Хуҗаларның аты аның сызгыруына кинәнеп пошкырыр иде. Якын күрде ул Сәлимне. Ник дигәндә, ир дусларына гел эре тешле тарак кыстырып килер һәм Акбүз белән Лачынны янәшә бастырып, ялларын тарар иде.

Тарак бүген дә үзе белән. Сызгырды Сәлим, нигәдер Лачын пошкырмый. Мөгаен, сабакташ болында айгырның аякларын яздыртадыр. Ярышка әзерләнә: тиздән Сабан туе. Моңарчы беренчелек Акбүздә иде, бәлки быел Лачын җиңәр?

Нәкъ менә кыр бәйрәмендә шушы йортның мәрхүм хуҗасы белән дуслашкан иде Сәлим.

– Минем хатын да Ташкичүнеке. Әйдә, күрештерәм, – дип, Сәйдәш аны үзләренә чакыргач, баш тартырга уңайсызланды ул. Кеше зурлап чакыра! Чынлыкта аның сабакташын бик күрәсе дә килми иде әле. Наҗия белән ул бер партада утырды. Малайларны шук-шаян диләр, ә кыз алардан ун тапкыр әшәкерәк, чәчби аерата Сәлимнең теңкәсенә тия: йә дәфтәрен буйый, йә утыргычына замаска сылый, башлангыч сыйныфтагы бу этлекләре үсә-үсә кимер дисәң, киресенчә, өлкән сыйныфларда сюрпризлар артты гына.

Мәктәптәгесенә күз йомарлык, ә менә кичләрен... Нәҗиянең әтисе Нурәхмәт талчыбыктан аю сыярлык тарантас үрдертеп, шуңа айгыр җигә иде. Җикми ни, колхоз рәисе бит! Сәлимнең әтисе гап-гади ат карауччы, аты да, арбасы да үзе кебек гап-гади иде. Олылар кич өйгә кайткач, бахбайларны фермага балалар илтештән. Менә авылның ике очыннан икеияр кузгала. Берсе – Сәлим, берсе Нәҗия. Колхоз рәисе кызы тәмам шашына: артыннан тузан болыты куба, урамда тавык-чебеш таптала, һаваны «һайт-һайт» дигән әче тавыш яра. Җан-фәрманга айгыр куган кыз әкрен генә атын юырттырган үсмерне юл читенә кысрыклый да, Сәлим аска мәтәлә. И шушы тамашадан көлә Нәҗия, и көлә! Сыптырып егар идең – кыз бала, тырнак белән дә чиертергә ярамый.

Чыгарылыш кичәсендә «без хәзер мөстәкыйль», дисәләр дә, егет-җилән һаман мәктәп күз уңында, лимонад ише татлы сулардан гайре табынга берни куйдыртмаган сыйныф җитәкчесе Сәлимә апа ана каз кебек «бәбкәләр»ен канат астына җыеп тотты. «Сыра исертми бит», – дип, авыз турсайткан малайларны кызлар да якламады, алар укытучыга теләктәш иде. «Ут бөрчәсе» Нәҗия:

– Сәлимә апа, әйдәгез, такмаклар әйтешеп уйныйбыз, – дигәч, кызлар дәррәү егетләрне уратып, түгәрәк ясап басты. Кемнең теле ныграк кычыта? – Шул әрсез Нәҗиянең! Оят аңардан җәяү качкан, ахрысы, ул гел мәхәббәт турында җырлады.

Кил, җаныем, алдымда тор,
Алмалар каптыраем.
Сиңа төшкән мәхәббәткә
Үзем дә аптыраем.

Җырлап кына калса икән, тыпыр-тыпыр биеп, Сәлимнең каршысына килә, егет, кызарып, зур гәүдәле сыйныфташы артына яшеренә, сызгыру, кул чабулар кызны тагын да катырак кыздыра.

Колак алкаларым сынды,
Алырсың микән алка?
Булырсың микән үземә,
Калырсың микән ятка.

Монысы баласы гына, анасы алда икән. Караңгылата иде инде, һава суларга бакчага таралыштылар, Нәҗия һич искәрмәгәндә, алмагач куагы ышыгында Сәлимне кочаклап, ирененнән суырып үпте дә:

– Әй, никләр генә моның кадәр юаш икән син! – диде.

Колхоз рәисе баласы кара эштә караламыни, Нәҗияне Чистайда хисапчыга укыттылар. Җылы кабинетларда саннар гына чүеп уйна! Сәлим армия хезмәтендә чакта үткен-чая кыз танышкан сәгатендә үк Чәтрән авылындагы агроном Сәйдәшкә ияргән икән. Иярсен, хуш! Авылның җаны тынар. Яшь парлар дус-тату яшәгәндер, Нәҗия аерылмады. Максатлар ир белән хатынны мәхәббәттән көчлерәк берләштерә, диләр. Алар да ат яраткан, алар да Сәлим кебек колыннан баһадир үстергән һәм алар да Сабан туйларында алдынгы урыннар яуларбыз дип өметләнгән.

Кияүдәге бичә инде басылгандыр, теге вакыттагы җүләрлекләрен бүтән кабатламас дисә, Наҗия баскычта ук Сәлимнең муенына асылынды:

– Әттәгенәсе! Минем мәктәптәге беренче мәхәббәтем, әттәгенәсе! Саумы, юаш?!

Хуҗа: «Чү, хатын!» – дип, кисәткәндәй тамак кыргач кына, ул кулын ычкындырган иде.

Ел саен Сабан туеннан соң юмарт Сәйдәш аны үзләрендә сыйлады. Ашсуга оста хуҗабикәнең өстәле ризыктан сыгылыр, табынга бәлеш, пылау, тавык ите, майда кыздырылган елга балыгы тезелер һәм ачыккан ирләр күзе шартлаганчы ашагач, атлар янына чыгар, малкайларның да табагы яшелчә белән тулыр, өлгер Наҗия кай арада икесенә дә кишер, кәбестә турап салыр... Атның тамагы туйса – тоягы тузмый, диләр.

Әмма мондый күңелле мизгелләр озакка сузылмады, юктан гына үлде Сәйдәш. Табиблар йөрәге челтәрләнгән дип әйткән. Ир җилкәсе ышыгында яшәп сабырланган Наҗиянең эченә кабат җен-пәриләр ояладымы икән, былтыр ул Сабан туе мәйданында пәйда булды! Җайдак сабакташның киенүе дә ирләрчә иде: киң балаклы кара чалбар, озын җиңле шакмаклы күлмәк (Сәйдәшнеке!), ямьшәйгән кепка... Тач абзарда тирес түккән авыл агае!

Мондый үзгәрешләр ни-нәрсәгә ишарә дисәң, ат чабышларында беренчелекне алу, ягъни Сәлим ишеләрнең борынына чиртү икән. Ә ир гаилә дусты дип кенә җиңдертмәячәк иде. Һа, ел буе дәртләнеп, ярышка әзерләнгән, үзеңдәге азартны Акбүзгә йоктыр, кичтән үк җиңү тәмен тоеп йокларга ят һәм иртәгәсен дуамал Наҗияне алга үткәр!

Старт сызыгында ук көндәшләренә тояк тузаны очыртып кузгалды Сәлим. Ә бит Акбүзне тыеп, әз генә тезгенне тартсаң, арттан «Һайт-һайт» дип кычкырып, атын куалаган хатын Лачынын ике генә сикертәчәк иде, сикерттермәде шул ир.

Ярыш азагында Наҗия йодрыгын йомарлап, аңа ташланыр, һич югы газиз башкайларына әр-битәр яудырыр дигән иде, көтелмәгән хәл: сабакташы дуламады, шауламады, күбеккә баткан Акбүзнең битеннән сыйпагач, кепкасы белән җиңелчә генә Сәлимгә суккалап:

– Сәвсим үк юаш та түгел икән син, – диде.

...Менә хәзер Наҗияләр капкасы төбендә соңлап кына бәгырьне үкенеч көйдерә. Сабакташын уздырасы иде аңа. Нинди зур «ачыш»: юаштан битәр үзенең мәрхәмәтсез зат икәнен таныды ир. Быел Лачын көчле көндәштән котылды, быел – мәйдан аныкы... Шатлансын хатын!

Урам башында велосипед «иярләгән» Наҗия күренде. Аркасына бүктәре белән тал чыбыгы бәйләп аскан. Сәлимгә карап, серле генә елмайды ул. Бу елмаюда ирнең кайгысына (ишеткәндер!) сөенү бар кебек иде. «Әһә, алдагы ярышларда мин җиңәм!» янәсе. Аның:

– Сәлам, кунак егете! – дип исәнләшүе дә мәкерле иде.

– Исәнме... – Ир хатынның аркасындагы бәйләмен салдырды. – Кәҗә ризыгы.

– Әйе, яшел азык. Кәҗәгә тиендем әле. Бәтиләре белән бишәү алар.

Сәлимгә дә чеметергә ярый иде.

– Без үскәндә, ярлы-ябагай асрый иде кәҗә. Сыерга көче җитмәгәч.

– Хәзер, җанашым, киресенчә, байлар кәҗә тота. Чөнки файдалы сөте. Дару ул. Туктале, сиңа савып эчертим. Бәлки яшәреп, икенче кат өйләнерсең.

Хатынның үртәве ачу кибәнен ишә иде. Моңа Акбүз турында сөйләп, тел әрәм итәргәме! Лутчы дәшмә.

– Үзең эч, яме. Китәм, – диде Сәлим коры гына. – Лачын белән хушлашам да.

Наҗия аяк астына аударган талларның иң озынын бөгеп сындырды. Йөзендәге баягы елмаю капылт кына сүрелгән иде.

– Үтүт Лачын, җанашым.

– Ничек «үтүт»?

– Энесе Шакир, «Абый истәлеге» дип, көзен үзенә апкитте. Син кызкатынга нәмәгә ат, ди. Сәйдәш йөрәк белән егылган көнне буран котырып, юлларны кар күмде. Әйдә, Лачынны чанага җигеп, үзәк бүлнискә илтәм дигәч, ирем: «Айгырга кагылма, ул җигәр өчен тумаган», – диде. Энесе әнә... – Нервыланган Наҗия чыбык кисәкләрен учында изә иде. – ...Лачыннан бакча сөрдерткән. Хәзер Лачын эш аты. Быел Сабан туенда Акбүз аны юксыныр инде, дуслар бит.

– Акбүз дә үтүт. – Ачкыч белән бикләнгән тел чылтырап, үзалдына «ачылды». Сәлимнең һәр сүзе саен сабакташының күзеннән мөлдерәп яшь акты.

– Акбүзкәем, бичаракаем, шул кансыз Мөнирдән качкан инде, – дип елаган хатынны ул иңнәреннән кочып юатты.

– Чү, чү, матурым, елама! Кем инде чабышкы атын сукага җигә?! Вәт заразы! Дөмбәслим хәзер үзен!

Чебенгә дә сукмаган Юаш әтәчләнә генә иде.

– Шуңа сугып, кул пычратма сана! – Наҗия чыланган битен яулык чите белән сөртеп корытты. – Елата бит, кызганыч бит Акбүз. Нәрсә инде без, капка төбен такырайтабыз, безнең йортта кунакларны коры авыз белән бормыйлар, әйдә, чәй эчәбез!

Акбүз югалганнан бирле тамагыннан ризык үтмәгән ир ябыкты. Мөгаен, эче суырылып, кабыргасына ябышкандыр, ул кыстатмады. Наҗиянең майда кетердәп пешкән тәбикмәге, парда тәмләгән каз ите, шулпалы бәлеше әле дә авыз суларын китерә иде. Әмма табында коймактан гайре тәгам юк иде. Аның ниләр уйлаганын күзеннән укыды бугай хатын.

– Ялгыз башыма пешермим дә. Күңелем боега. Сәйдәш белән бергә хыяллар да үлде. Банкта акчам череп ята, җәренгә нәселле атлар үрчетәм дигән идең берсендә. Без дә, мәрхүм белән синең сымак болынны татар аргамаклары белән тутырмакчы идек тә... Язмаган Ходай.

– Акбүз табылмаса, минем дә күңел үсмәс андый эшләргә. Акчасы черемәгәе шунда, – диде ир һәм авызын пешерә-пешерә, кайнар чәй эчкәч саубуллашмакчы иде, хуҗабикә арттан килеп, җилкәсенә басты.

– Чү әле, чү! Акбүз исән-сау кайтсын дисәң, нәзер әйт син, сабакташ.

– Ниткән нәзер ул тагы?

Боегам дисә дә, Наҗия, шаяртып, кешедән көләргә ярата иде.

– Күршебез шофёр Наҗар абый сәфәрем уңса, сезгә кәнфит бирәм дип, без – бала-чаганы сөендерә иде. Гайшә әби чирләгәч, терелсәм, сезгә бияләй

бәйлим, дия иде. Безнең әти төпчеге сау-сәламәт туса – сарык чалырмын дигән. Әни корсаклы килеш тыкрыкта бүрәнәгә егылгач, бала гарип туар дип курыккан. Энем Илдус әнә, тап-таза, авылда икенче йорт тергезә.

Сәлим җилкәсен сикертеп, Нәҗиянең кулын кагып төшермәкче иде, хатын бармагын тагын да катырак батырды.

– Үтә, ата-баба йоласын син дә үтә!

– Йола икән, йола, – диде ир, бу мәгънәсез тәкъдим белән килешмәсә дә. – Сарык кынамы, бозау ниятлим. Табылсын гына Акбүз.

Нәҗия җилкәдән кулын алып, өстәлгә таянды.

– И-и җанашым, нәзерең бигрәк бәләкәй инде.

– Өч бозау алайса!

– Барыбер бәләкәй. Беләсеңме нишлә?

– Нишлим?

– Язым-гатаем атымны юлласам – Нәҗиягә өйләнәм, дип әйт!

Мондый ук оятсызлык көтмәгән ирнең миенә кан сауды бугай, чигәсе чатнады. Көлә! Битеннән көлә! Асыл кош йолкыш чыпчык белән оя бүлешә, ди, сиңа!

Ә Нәҗиянең зур, матур күзендә сагыш дәрьясы иде, ул еламсырап:

– Әй, ялгыз башыма авыр ла, – диде. – Аеруча җәйге төннәрдә – яшен яшьнәгәндә, чүт кенә аңымны җуймыйм. Балачакта аягыма яшен аткач, чак үлмәгән идем, шуннан калды курку.

Сәлим:

«Өч кат юрганга төрен», – дип шаяртмакчы иде, хатынның керфек очында җемелдәгән яшь тамчысы күреп тыелды.

– Хәтерлисеңме, теге такмакларны? Чыгарылыш кичәсендә идек. Берсен сиңа атап җырладым бит мин.

Колак алкаларым сынды,
Алырсың микән алка?
Булырсың микән үземә,
Калырсың микән ятка.

Әллә син янәдән Әнисә белән кавышасыңмы, ә, Сәлим?

Җавап шундый да кискен иде.

– Юк!

Капкадан озатканда, Нәҗия отыры әрсезләнде:

– Мин синең нәзерең, онытма!

Юаш борын астыннан гына мыгырданды:

– Булмаганны...

**5**

Килен дә килен дип өтәләнгән атасы турларындагы эскәмиядә йокыга оеп, яшьләрне көтә иде, Сәлим машинасының тәрәзә пыяласын шудыртып, аңа эндәште:

– Әти!

Карт сискәнеп, дерт итте.

– Һе, бик тиз сез, оланнар.

– Мин үзем генә, әти.

– Йа, Ходай җәзасы! Әнисә килен тагы киреләндеме?

– Аңа кем ялынган, ди. Акбүз табылачак, әгәр мин... – «Әгәр мин таш-таулар ишелерлек бер нәзер әйтсәм», – дигән җөмләнең койрыгы өзелде, чөнки атасы урам сасытып ярсыды:

– Тәки шул хайван белән дүрәкләндең, малай! Катының белән гомер чигәсе сиңа! Өй учагын катыннар кабыза! Тормышмы бу, йа? Ничу авылда каңгырап йөрергә! Вәнә дустың Фәнил төнәдән авылда, аның белән фикерләш, бар! Лутчы Фәнилнең киңәшен тот, ул синнән акыллырак!

...Тирләп-пешеп, утын ярган Фәнил балтасын бүкәнгә чапты да баудагы сөлгене җәһәт кенә биленә урады. Ул:

– Әйдә, Юаш, көрәшеп күрешәбез! Син мине балачактагы кебек бәрәлмисең, точно! – дип, аягын җиргә терәгән иде, Сәлим:

– Очынма, куык! Җә шартларсың, – диде. – Шәһәрдән сөрделәрме әллә?

– Отгул минем. Әнинең мунчасына берсәк утын ваклыйм.

Яшьтиләр чирәмгә чүмәште. Аһ-ваһ итәрлек очрашу түгел иде. Фәнил – ончы, тегермән ябылгач, ташкалага тайды. Ул хыялланган акчаларның «теле» кыска иде, ахрысы, ел ярымнан ике кулын селкеп, туган нигезенә кунакка кайтты. Күлмәге белән чалбары да шул ук, хәтта ки чәч бөртекләренә кунган он тузаны да юылмаган төсле иде. Куык бит, сер бирмәде, мактаныпмы мактанды:

– Тулай торакка урнаштым. Душы, бәдрәфе ятажда. Эшем җиңел, базада тауар төйим. Кичләрен бүлмәдә телевизор карыйм. Мал асрап, тирес түгеп пычранмыйм, сөте-каймагы, ипие кибет киштәсендә. Җәннәт, яшьти!

Аннан бирле өч тапкыр ел фасылы алмашынды. Казан Фәнилне баеткандыр, әнә көрәшик дип, көче белән масая.

– Яшәү һаман тулай торактамы? – диде Сәлим, сүз юктан сүз ясап.

– Яхшы әле, вакытында тайдым авылдан. Сиңа алданмадым. Миңа: «Әйдә, уртактан нәселле атлар үрчетәбез, акчага тилмермәссең», – дигән идең, хәтереңдәме? Үрчеттең, пычагым. Бер чаптарыңнан да колак каккансың әле. У-у, миндә үлеш яңалык! Аида исемле кибет директоры белән парлаштык. Әлегә ЗАГСта язылышмадык. Апаң бай. Дүрт бүлмәле квартиры. Суыткыч тулы кызыл балык, уылдык, казылык, ит.

– Хурланмыйча, йортка кергәнсең икән.

Сәлимнең турыдан аткан тәнкыйть уты яшьтинең мин-минлегенә тимәде, куык тагын да өрелеп кабарды:

– Аидага мин бүләк. Кырык тугыз яшьлек хатын япь-яшь егетнең кочагында назлансын әле, шту син! Аның ахирәте Самира тужы ялгыз. Өч катлы йорт, мунча, гараж, чит ил машинасы, кыскасы, череп баеган кәләш! Анысы да: «Яшь, чибәр егет белән танышыр идем», – ди. Авылныкы белән, алар күндәм, ди. Бая әтиең белән фикерләштек. Югалган бияң өчен саргаеп кибәсең икән, яшьти. Әгәр катыны белән никах яңартмаса, малайны Казанга әйдәкләле, ди Сәйфулла абзый. Сразу Самира түтекәйгә шылтыраттым. Иртәгә киявеңне каршыларга әзерлән, мәйтәм. Балда-майда йөздерәчәк сине апаң. Ат димәктән, аны бүреләр ботарлаган инде, яшьти.

Акбүзгә үлем юраган кеше кан дошманы белән бер иде, Сәлим чабылган балтаны каерып алды да, кизәнеп, бүкәнне урталай ярды:

– Эшләсәң – менә шулай батырып эшлә, яме! Иту бай хатыннар күмәчен

ашап, беләгең чүпрәкләнгән. Атым исән, атым үлмәде минем! Хуш, шәһәр куыгы!

Капканы ябар-япмас, ир борылып сорады:

– Нәзер-фәләннәргә ышанасыңмы син?

Фәнил челт-мелт күзен йомды. Юаш яшьтинең акырганын беренче тапкыр күреп, аның акылы таралган иде.

Сөрән сал, күкләр ярылсын! Акбүз исән, Акбүз үлмәгән!

Ир канаты – ат булыр, диләр, ә аның ул канаты сынык! Бүген сынык! Иртәгә аны ялгар өчен тагын юл сабачак Сәлим. Көндез дә, төнлә дә эзләр Акбүзне, урманда кунар, болында кунар, арып егылса – үрмәләр, шуышыр, әмма җан дустын тапмыйча туктамас.

Кичтән үк биштәргә шешә белән су гына тыкты ир. Ашау кайгысымыни! Тизрәк таң атсын иде, тизрәк!

Күзгә йокы эленмәде, Сәлимнең шашынуы табигатькә дә күчкән сыман, йомры ташларын даңгыр-доңгыр тәгәрәтеп, күк күкрәде, укларын кадап, тәрәзә пыяласына сыланган яшен бүлмәләрне яктыртты. Табигать тә, ир дә бер үк халәттә иде. Нажия нишли икән? Гаҗәп, мәктәптә малайлар кыйнап, айгыр хәтле айгырда җилдереп чыныккан башкисәр кыз яшеннән курка, ә! Өендә – түшәктә ятып, ә! «Мин синең нәзерең, онытма», – дигән иде, онытырсың, көт... «Йа, ялгыз хатынның яшеннән куркуы көлкеме сиңа? Мышкылдама, киен, машинаңны кабыз һәм Нажиянең баскычында сакта утыр, тынычлап йокласын сабакташ...»

Сәлим шул уй белән өстенә киенгәндә, ат кешнәде. Бу кешнәү дөбердәгән тавышлардан мең кәррә көчлерәк иде. Җаннан суырылып, колакта зеңгелдәгән авазлар микәнни? Әллә саташуы чамадан арттымы? Кешнәү тагын кабатлангач, ир ишек-капкаларны этеп, урамга атылды.


Капка төбендә, яшен утына коенып, колыны белән Акбүз тора иде.

***

...Атау болынында утлаган ат көтүе арасында и йөгерә, и йөгерә малай. Мал бер ишәйсә, ишәя икән: йөзләгән чаптар фермаларга сыймый. Алла кушып, киләсе елга бу саннарны икеләтә арттырачак Сәлим. Әнә дәвамчысы өч яшьлек Сәйдәш бәләкәйдән үк атларга мөкиббән. Киләчәктә аңа алмаш үсә.

– Баланы таптамасыннар бер үк! – дип өзгәләнде хатын.

– Таптамыйлар, тынычлан, әнисе. Бак, Акбүзнең улы Лачын гел аның янәшәсендә! Маладис, нәни дустын күз карасыдай саклый, – диде ир.



Данис
Хәйруллин

# ГЕЛ ТӘГӘРӘП ТОРЫР КОЯШЫ ДА...

## Җил сурәте

Аягыма урала җил – узыйм, дисәм,
Сулышыма кабына – җыр, сузыйм, дисәм:
Давыл өсте давыл исте өстегездән –
Ә сез әле һаман исән, һаман исән!

Җиде җилнең үзәнендә басып торам,
Җил капканы ябып торам, ачып торам;
Җилнең, телнең тегермәнен тартып торам... –
Мәһәрен дә, каһәрен дә татып торам.

Оча еллар – оча җилләр канатында,
Шыпырт кына шыңшый җаннар кара төндә:
Кайчан кабат уяныр да Тукай рухы,
Казанына кайтыр, диеп, пар атында.

Җил канаты очларында ак болытлар.
Ил басуын басып бара сорыкортлар:
Бөртекләрдә бөреләнеп, өмет йоклый,
Буразнасын табалмаса мәңге йоклар.

Фәрештәләр эзен эзләп исә җилләр,
Йөз елдан соң кабат кайтты Газраилләр[1].
Әйтче, и җил, ник соң болай бу кавемнәр? –
Каберендә боргалана фиргавеннәр!

Җиде җилнең үзәнендә басып торам,
Җил капканы ачып торам, ябып торам:
Кайгыдан да, шатлыктан да шакымагыз –
Бу көннәрдә мин үзем дә ябык торам!

[1] Һ.Такташның 1916 елда язылган «Газраилләр» шигыренә ишарә.

Данис ХӘЙРУЛЛИН (1945) – *шагыйрь, «Хәтер», «Йөрәк тибеше», «Казлар ник көлә?» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Ярлыка!

Гел туры булмый икән ул дөньялыкның юллары.
Буталган чак та булгандыр уңнарым һәм сулларым.
Ашаттым черки-чебенне үрмәкүчкә мул итеп,
Кырмыска өсләреннән дә узгалады күн итек.
Уйнадым, булды яшьлектә, арба тагып шөпшәгә
Һәм менә, исәйгәч күңел салды мине шөбһәгә.
Дөнья бит! – буталган чак та булгандыр уң, сулларым:
Кочкандыр, бәлки, кочарга тыелганны кулларым...
Бар микән ул гел актан кичүче дөнья эчләрен?
Ярлыка, Ходам, аһ, гөнаһ булса кылган эшләрем!

***

Тәңре эргәсендә кем булсаң да,
Син үзеңә – тоткын!
Үзең котыл!
Баткан чагында да
Тик үзеңә тотын!

Гел үзем дип, үзләнеп тә бетмә,
Башкаларга чагыш!

Күрәсеңме, күпме күздә сыкы,
Күпме йөздә сагыш?

Дөнья көтү...
Кайтып килгән мәлем
Көтү көтеп, арып.
...Түрәлекнең түре – бүре икән,
Үрчеп китсә сарык...

## Тәгәрәү

Гел тәгәрәп тора кояшы да,
Гел тәгәрәп тора җире дә.
Игә килмәс илләр генә һаман
Гел тәгәрәп тора кирегә.

Тәгәрәшеп үсә бәндәләре.
Булыр, дисәң, илгә мәртәбә:
Җан ауларга җыеп өйрәтәләр,
Буе җитү белән тәртәгә.

Тәгәрәшеп уза еллар, көннәр.
Сөтен, белмим, кемнәр имезгән:
Маңкорт булып оча мал кортлары
Бабалары корган нигездән.

Гел тәгәрәп торыр кояшы да,
Гел тәгәрәп торыр җире дә,
Тәгәрмәчкә таяк тыгучылар
Бора алмас аны кирегә!
Бора алмас аны кирегә!

## Мизгел

Язларымны көзләр күмеп китте,
Ярсуларым бетте бу көздә;
Әләмемне күккә чөймим хәзер,
Чорнап кына куям мөгезгә...

Бүген! – дисә, мин бүген дә әзер,
Иртәгә дә әле соң булмас...

Газраил ул атап чыкканда да,
Кемгә генә әле сугылмас...

Язларымны көзләр күмеп китте,
Кышларымны күрәм көзгедә:
Җаным тыныч, каным салкын хәзер,
Тик хәтерем генә өзлегә!

## Тәңгәллек

– Гади генә күренәсең,
Каян ул синдә акыл? –
– И хуҗам, акыл иясе
Падишаһ була, йә ...кол!

Икесенә дә бер уй хас,
Һәм хас бер үк хаталар:
Берсе чыгарып аттыра,
Икенчесен аталар!

Ничек үлчәп карасаң да,
Икесе бер бәядә:
Падишаһсыз җәя булмый,
Ә колсыз – ук җәядә.

Падишаһ та кол булгалый,
Кол да падишаһ була.
Аерма шул: «мат» алдыннан
Падишаһка «шах» була.

## Ике язмыш

Ике язмыш: берсе бер дигән, ди,
Икенчесе шәүлә берсенең.
Бер сум өчен берсе интеккәндә,
Бер сәгатьтә эшли берсе – мең.

Ике язмыш: берсе догада, ди,
Ай батса да, кояш чыкса да.
Икенчесе ил буенча йөри,
Акчаларын төреп чыптага...

Берсе тыныч, берсе «ду» китерә
Кыңгыравын алтын дугада.
Берсе беркөн шаулап китеп бара...
Икенчесе – кала догада...

## Бездә шулай

Кем яратсын кемнең Кем булуын –
Яраша, йә бәреп төшерә.
Тары бөртегедәй уңышың да,
Көшел булып керә төшенә.

Бездә шулай, бездә безелдәүче
Өлгеррәк кортның үзеннән.
Бездә шулай, сынап тора сукыр
Югалганчы шәүләң күзеннән.

Кем яратсын кемнең кем булуын –
Яраша, йә сөрә көндәшен.
Бездә шулай – агач утыртмыйлар
Ботак тишегеннән көнләшеп...

## Чарасызлык

Мин – буш урын...Тәнем генә йөри,
Җаным гына йөри каңгырап:
Хыялларны корбан итә теләк,
Теләкләрне – юа яңгыры...

Мин – буш урын... Берни кимемәс тә
Миннән соң да, берни артмас та.
Бушлыгыннан айный алмыйдыр күк
Китеп барганнар да кайтмаска...

Мин – буш урын... Төнне җитәкләгән,
Җаным гына йөри каңгырап;
Сез танырсыз аны, килеп чыкса
Татар бистәсеннән, таң ерып...

***

Кыса-кыса яңа кысаларга,
Ниһаять... дип, дога кылсалар да,
Бетте инде, диеп, имгәнеп:
Миллилек ул бетми – эчтә ята,
Бөгәрләнеп салкын мичтә ята,
Көтеп ята жылы иңгәнен...

***

Кем арбасында баруын һәммәбез сиземли ул:
Акыллы булып кылансаң, юләрлек сизелми ул.

***

Ихатага чыкса хуҗа ябырыла кәҗә, сарык:
– Нигә дип эт үрчетәсең, ә нигә без шундый арык?
– Сезне саклый алар, ахмак! Җиде эткә – алты сарык,
Юкса, койрык чөя-чөя чабышасыз – тәмам гарык!

## Аклану

– Әллә нинди сүзләр йөри синең хакта,
Имеш, сине узып киткән синең хата:
Кергәнсең син кемнәрнеңдер күңеленә,
Күңеленең ишекләрен вата-вата.

– Шулайдыр шул: сәбәп кенә булсын сезгә,
Оста бит ул иске авыз яңа сүзгә:
Ялгыш киткән ялгышны да яфсарта, кем,
Булмаса да кырып салыр җире күзгә.

Гадәтем бар: кайткалыйм, хак, тай чакларга,
Чытлык сүзләр чыгып оча кайчакларда;
Кагынгалап кояшкача менеп китәм,
Куйсалар да, әдәпле дип, ай сакларга.

Бәндәләрнең күңелләре йозак-йозак,
Ачкыч юллап йөрер булсаң озак-озак,
Пәрәвезгә килеп кунган күбәләктәй –
Бетте башың – анда тозак, монда тозак!

Ватмадым мин һичбер күңел ишеген дә,
Ишетәсем килми хәтта исемен дә.
Туры әйткән – туганына ярамаган:
Ярамас ул яранына ишенең дә!

## Вәгазь

Дога кыл син, гел шакып тор Аллаһының ишеген!
Бәлки әле фәрештәләр язып алыр исемең.
Догадан да алданрак нәфесеңне дагала:
Теләнү булса теләгең, дога – нәфес санала!
Искә төшермә Аллаһны авырда, әрдә генә –
Йөрәгеңдә йөрсен дога, булмасын пәрдә генә.
Һәр гамәлең Аллаһыга дога булып ирешер,
Булмасаң үзеңә генә бик кирәкле бер кишер...

## Җан

Күрәсеңме җан иясен – энә очы кадәрле?
Ишеттеңме вирус мең кат ваграк дигән хәбәрне?
Беләсеңме, җаннар җанга яшәгәнен берегеп.
Нәрсә ул җан? Белмисеңме? – Менә сиңа бер үгет:
Табалмассың – эзләмә дә, эзләнмә дә җан, диеп:
Үзен-үзе эзләүче җан үзенә бер җан көек.

Күрәсеңме бу ноктаны: кыймыл-камыл – тере бу!
Нәрсә ул җан? Аллаһының ачылмас бер сере бу!
Җан ул безсез яратылган, белеп безгә иңдсен;
Кат-кат укы Аллаһының Ләм-мим атлы сүрәсен!

## Вакыт белән очрашу

Елап саный идек башта, еллап та саный идек,
Яшь чакта вакыт сурәтен күзеннән таный идек.
Айларга бүлдек аннары көн белән чуалмыйча,
Сәгатькә калгач йөдәдек чутына чыгалмыйча...
Санасаң, санамасаң да, вакыт та бер алҗыта:
Бал җыясы көннәреңне чәчрәп җыяр мал йота.
Йөзгә-йөз килгәч кенә без тәмам аңлаштык канә:
Мин бит – син ул! Син ул – мин – дип тордык ике дивана...

## Озак яшәү сере

Шундый күп ул озак яшәү сере, бетер генә укып.
Укымасаң тыңла, һәр танышың сөйләр сиңа нотык.
Берсе әйтер, ул бит – тамагыңа эчкән судан тора,
Икенчесе әйтер, тәгамеңә күбрәк суган тура!
Өченчесе әйтер, дөрес сулап, дөрес йоклау кирәк,
Төне буе йөрер йөремсәккә һәйбәт уклау кирәк...
Аны кап та, моны йотып җибәр, дияр, дүртенчесе,
Алыштырыр аны чибәр-чибәр илнең дүрт имчесе...
Дүртесе дә күктән төшкән булыр, күрмәгәнен күреп...
Берсе сыйпар йоның уңаена, берсе карар өреп...
.....................................................................................
Котылдым мин андый сердәшләрдән, офыкларга бактым:
Шәфәкъ нурларында буш хыялның бетле тунын яктым.

## Берәүгә

Беләмен мин синең хакта, шактый беләм,
Белгәнемне белдермичә саклый беләм.
Фикер җебен күпме генә чуалтсаң да,
Мантыйгымның энәсенә саплый беләм.

Беләмен мин синнән ашу белгәнемне:
Сүз аралаш кабарткалап beләгеңне,
Төчеләнеп күпме генә сайрасаң да,
Кулларыңнан төшермисең элмәгеңне.

***

Шулкадәр күп эшнең вак-төяге,
И, кубасы килә эредән:
Таңнар атып, күзең ачтың исә,
Яраласың кабат бөредән.

Рәдиф
Сәгъди

# ӘЛМИРӘНЕҢ ХӘТЕРЕ АЧЫЛА

РОМАН[*]

***

Ул патшалар яшәгән калага Яңа ел бәйрәменә хәтле үк килергә тиеш иде. Ләкин табигатьтән үк бирелгән көчле тоемлавы ашыкмавын сорады. «Бер-ике атна сыра-аракы, шампан шәрабларына коенсыннар әле, эчеп миңгерәүләнеп, уяулыкларын югалтсыннар, соңыннан иркенләп, юлга чыгарга да булыр, дип фикер йөртте ул. Ләкин туган шәһәре Казанда да калырга ярамый. Көтмәгәндә килеп чыккан четерекле, болганчык хәлләр шундый итеп китереп терәде ки, гади халыкның яклаучысына да, саклаучысына да әйләнгән иде ул. Кемнеңдер машинасын алып киткәннәр, милиция ярдәм итмәгәч, аңа киләләр. Кемнеңдер эшеннән процентлар түләп торуын таләп итеп басым ясыйлар, хатын-кызларын көчләү белән куркыталар, яныйлар. Шантаждан төн йокылары качкан, йөрәк авыруына сабышкан, аяк-куллары калтыранган эреле-ваклы җитәкчеләр аңа килеп тезләнәләр. «Зинһар, безнең «крыша» бул әле, бигрәк азындылар Түбән очныкылар! Хезмәт хакы түләргә дә сәмәннәребез җитми, күзләренә карарга оялам, харап итмә, энекәш!» – дип, күз яшьләре белән ялынган адәмнәрнең хәленә кереп, ярдәм итте. Андый чакларда Россия киңлекләрендә боксёр буларак даны таралган якын дусты, озын буйлы, кара тут чырайлы Флүр булды Артурның янәшәсендә. Курыкмый торган адәмнәр юк, ләкин иптәше дуслары өчен утка да, суга да керергә әзер иде. Көчле, тәртипле, эчмитартмый торган төркем төзеде алар. Наркотиклар турында сөйләп тә торасы юк, Аллам сакласын! Алар биләмәсендәге урамнарда урнашкан мәктәп коллективлары шуны яхшы белә: балаларны үлем порошогына утырткан бәндәләр Артурлардан куркып, әлеге уку йортларын ерактан ук әйләнеп үтәләр. Күпме ата-ананың кадерле нарасый-сабыен шушы караңгылыкка, тәмуг упкынына кереп китүдән саклап калды алар. Горбачёвның үзгәртеп коруларыннан соң Ельцин дәүләт башына килгәч, күпме завод-фабрикалар таланып, күпме халык эшсез калды. Күпме ата-ананың баласы мохтаҗлыктан җинаять юлына кереп китте, меңнәр шушы сикәлтәле юлда газиз башларын

[*] Журнал варианты

*Ахыры. Башы узган санда*

салды. Анының җан дусты Флүрнең да гомерен өзделәр. Барысы да гап-гади алыш-бирештән башланып киткән иде. Россиянең танылган рецидивисты Сазан яшь сөяркәсе Диләрә белән су юлыннан сәяхәткә чыгып кермәкче булган. Үзенә күрә кечерәк кенә катерлары да бар. Кирәк бит, кемдер аңа, братан, сиңа иске-москыда йөзү килешмәс, яңа яхта юнәтергә кирәк дип, акыл бирә. Ә андый затлы көймәләр Артурлар кулында. Килә Сазан Флүр янына тимер юл базасына. «Миңа да, братан, яңа яхта кирәк иде!» – ди. Флүр аңа барысын да күрсәтеп йөри, бәясен әйтә һәм ун процент өстәмә түләргә кирәклеген дә искәртә. «Мин бит – Сазан, ничек инде ун процент?!» – дип гаҗәпләнә рецидивист. «Үзеңә кара, алсаң – ал, алмасаң – башкалар алыр», – ди егет. Шуннан бәхәс, ызгыш-талаш китә. Иң соңыннан җинаятьчелектә тәҗрибәсе булмаган Флүр, ачуы чыгып, өч хәрефкә озата тегене. Азу тешләре калыккан, амбицияләре көчле булган авторитет аны үлемгә хөкем итә. Нык тетрәнү кичерде ул уң кулын, яшьлек дустын югалткач. Иптәшен җир куенына салгач: «Алар берсе дә исән калмаячак!» – дип, ант эчте. Нәтиҗәдә, бу җинаятьне кылган өч адәмне бер-бер артлы олактыралар. Сазанның үзен органнарда эшләүче дусты аерым камерага утыртып кына саклап кала. Менә шулай итеп, Артур үтерүчегә әйләнде. Сазанның органнардагы кешесе аны эзәрлекли башлады, чөнки белә, Артур исән булганда, инде наркотик сәрхушлегенә бирелгән рецидивистның исән калуы мөмкин түгел. Иртәме-соңмы, барыбер эзләп табачак!

...Ленинградка ул, гомумән, икенче кеше исеме белән килеп төште. Килеп төште дию дә бик үк дөрес булмас, ике станца алданрак чыкты. Саклану чаралары шуны таләп итә иде. Чөнки Казаннан патшалар каласына еш барып йөрүе иминлекне саклау органнарына да күптән билгеле. Артурлар кул астында бөтен диңгез порты, кайбер завод-фабрикаларның «түбәсе» дә алар иде. Вокзалдан егетне Алиев каршы алды. Өч тән сакчысы белән генә килгән Артурга куркасы юк, чөнки биредәге иярченнәренең күбесе Казаннардан торса, бик азы гына – җирле халык. Бөтен операцияләрне татарлар алып бара. Алай дип әйтү дә дөрес үк булмас, чөнки төркемнең яртысы диярлек рус өммәтеннән. Тик аларны милләтләргә бүлмичә, Казаннан булгач, «татарлар» дип кенә йөртәләр.

Артур да бүген большевиклар партиясенең җитәкчесе Ленин бабай кебек «подпольеда». Конспирация кануннарының бөтен шартларына туры китереп, ясалма сакал-мыеклар ябыштырган. Таныrлык та түгел. Ул Казан егетләренә генә таяна, җирле адәмнәр белән сак булырга кирәклеген үз тәҗрибәсеннән чыгып белә. Үткән елны бер сатлык аркасында бик аздан гына суд залына эләкми калды. Вася дигән адәм аның кайчан киләсен органнарга җиткергән, тегеләр поезддан төшүгә тотып та алдылар. Тикшерү изоляторының шыплап тулган чагы, суларга да һава юк! Артур үзенең шулай ахмакларча килеп эләгүенә нык гарьләнде. Кем генә юк иде биредә: кесә караклары да, күз төпләре күгәргән, чырае җимерелгән урам хулиганнары да. Аракы эчеп, хатынын кыйнап эләккәннәр дә җитәрлек! Төрмәгә керәле-чыгалы йөргән рецидивистлар да буа буарлык. Алары бөтен ятакларны үзләренә алганнар, кайберләре ач бүреләр кебек клиентураны күзәтәләр. Берәр ярамаган сүз генә ычкындыр, котырган этләр кебек өстеңә ташланырга торалар. Яхшы киенгән Артурга да сәерсенеп тә, сынап та

карыйлар. Өс-башы күзләрен кыздыра, күрәсең. «Йәле, бераз кысыл, братан!» – дип, ул да аркасы белән сөялерлек урын җайлады. Шулай да биредәге сасы искә ияләнү читен иде. Кемдер коскан, кайсыдыр ыштанын чылаткан, шуларга әле күптән су күрмәгән адәм затларының тән исе, тәмәке төтене дә өстәлеп, тәмуг исләре килә, диярсең. Артур бу хәшәрәтлекне күрмәс өчен күзләрен йомып, уйга чумды. «Нишләргә, ничек ычкынырга икән бу капкыннан?» дип чыгымлады аның башы. Тик бернинди чыгар әмәл күрмәде. Иң соңгы өмете аның белән килгән тән сакчылары Альберт һәм Дамир иде. Алар ни эшли алыр икән соң? Общактан акча алып, ришвәт тәкъдим итеп карасалар гына. Биредәге танышы, диңгезче, беренче ранглы капитан Ибраев та ни майтара алыр бу хәлдә? Өмет иң соңыннан үлә, диләр бит, уйларга кирәк! Казанга депортация ясасалар, бер унбиш-егерме елга озатасыларын көт тә тор. Шулай төрле юлларны күзаллап утырганда, берәү каты гына итеп, җилкәсенә китереп тартты. «Әй, красавчик, сөйләшеп аласы бар! Әйдә, кырыйгарак!» – дип ымлады. «Башланды!» – дип уйлап, Казан егете ашыкмый гына урыныннан торды. Каршысында боз кебек салкын зәңгәр күзле, күптән юылмаган саргылт чәчләре укмашып беткән, аскы иреннәрендә яра эзе калган бер чырайсыз зат басып тора иде.

– Тыңлыйм, хөрмәтлем, – дип, як-ягына каранып алды егет. «Әнә тагын икесе, өчәү икән болар!» дип уйлап куйды.

– Бик әйбәт киенгәнсең, бик затлы, үзеңә генә бик күп түгелме? Әйдә алмашабыз!

– Сез, хөрмәтлеләрем, дөрес адреска эләкмәдегез! Бәлкем, ишеткәнегез бардыр Артур Казанский дигәннәрен?

– Син безне понтка алма, бу, кадерлем, синә Казан түгел! Әнә басурманнарың белән үзегездә идарә итәрсең, чишен тизрәк, – дип ырылдады теге, күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп.

– Мине мыскыл иткәнеңә бик үпкәләмим дә мин, минә мөселманнарга начар сүз әйтүең рәнҗетә!

– Шуннан?!

– Эш шунда! – дип, кискен итеп китереп орды ул бер мизгелдә кяфер кавеменең эченә! Теге «ах» итеп, урталай бөгелде. Ияgenә тезе белән дә менеп төшкәч, аңын югалтып, идәнгә үк тәгәрәде. Иярченнәренә каршы торырга дип борылса, таныш булмаган берәү ул ике мөртәтне дә шул арада бер-бер артлы сугып аударган иде.

– Рәхмәт, теләктәшлек күрсәтүеңә!

– Була торган хәл! Танымыйсыңмы?

– Әбүбәкеровмы әллә?

– Үзе, – дип, кавказ кешесенә тартым әлеге егет аңа нык кулын сузды. Каршысында моннан өч ел элек аның белән бүлешергә стрелкага килгән Дагстан егете басып тора иде. Шул арада Артур сугып аударган адәм аңына килеп:

– Ах, мин хәзер сез Казан кәҗәләрен! – дип мырлый гына башлаган иде, Әбүбәкеров аягын шул якка җилпеде. Аннан камерада утыручыларга: «Алыгыз әле моннан бу парашаны!» – диде. Кемнәрдер урыннарыннан кузгалып, яңа хакимияткә ярарга тырышудандыр инде, теге өч адәмне читкәрәк сөйрәделәр.

– Миңа, Әбүбәкер, моннан ничек тә булса ычкынырга кирәк! Югыйсә шактый срок яный. Ничек минем киләсен белгәннәрдер? Димәк, крот бар, аны да табасы, арт сабагын укытасы иде!

– Берәр фикерең бармы соң үзеңнең?

– Бар!

Тагын бер сәгатьләп вакыт үтмәгәндер, Әбүбәкер һәм биш-алты ристан камерада тавыш куптардылар.

– Әй, сез, чакырыгыз начальникны! Бу нинди вәхшәт?! Бөтен камераны бомжлар белән сасыттыгыз, суларга һава юк, тончыгабыз хәзер! – дип, ишеккә тибәргә тотындылар. Гаугага, башта тимер ишек тәрәзәсен ачып, бер милиционер күз салды. Тоткыннар тагын да ныграк рольгә кереп: «Йә безне, йә сасы бомжларны күчерегез икенче җиргә!» – дип, тавышларын көчәйттеләр. Милиционер: «Туктатыгыз! – дип, акырып-бакырып карады да эшнең барып чыкмаячагын аңлап, ачу белән күзәтү тәрәзәсен шапылдатып япты. Тавыш, оран салу аның саен көчәя генә барды. Бер унбиш минуттан камера ишеге ачылып, аннан бер майор һәм баштанаяк коралланган дүрт ОМОНчы килеп керде. Сасы истән милиция начальнигы «фу» дип чыраен җыерып куйды.

– Нинди тавыш бу? Кем күтәрде ыгы-зыгыны? Отвечайте!

Шунда бер исерегрәк тоткын торып:

– Сулап булмый бит, гражданин начальник, тончыгып үләбез, бу бомжларны икенче җиргә күчерегез, пажалысты! – диде.

– Юк минем бүтән камерам! Юк! – дип акырганнан соң, теге: – Дежурный, бу сасы бәндәләр ни өчен тоткарланды? Нәрсәгә кирәге бар боларның? – дип сорады.

– Соң, төрле сәбәпләр белән инде! Кайсыдыр подъездга кереп, кече йомышын башкарган, кайсыдыр метрода ятып йоклаган, араларында чүпрәк-чапрак урлап тотылучылар да бар, иптәш майор!

– Монда суялар, аталар, көн саен кеше мәетләре, шул җинаятьләрне дә тикшереп бетереп булмый. Ә сез эш күрсәтәбез, план ясыйбыз дип, урам бомжларын җыеп кайтасыз! Куалап чыгарып җибәрегез бу эт кавемен хәзер үк! – дип әмер бирде. Үзе борынын томалап чыгып китте.

Шуннан соң дежурный алты тоткынны тиз генә камерадан урамга озатты. Иртә белән Артур Казанскийны допроска чакырырга дип, камерага килсәләр, аның юкка чыкканлыгы билгеле булды. Айнып, аңына килгән берәү исә өстендәге затлы киемнәренә карап, берни аңламый аптырап утыра иде.

Менә шулай котылып калды ул зинданга эләгүдән. Бу хәл бик сак булырга, кешеләрне төркемгә сынап, тикшереп алырга өйрәтте. Юридик факультетның өченче курсында читтән торып укуы да кануннарны яхшы белергә ярдәм итә иде. Ни кызганыч, качкынлыкта йөрүе генә белем алуын тоткарлады. Кайчагында ул уйланып: «Мин бит яшьлек дустымның гомерен өзгән кабахәтләрдән үчемне генә алдым. Юк өчен үтереп ташладылар бит! Имеш, өч хәрефкә җибәргән! Кемне диген әле? – Татарстанның атказанган рецидивистын! Ә хәзер ментлар куенына сыенып посып ятасыңмы? Миннән үтерүче ясавыңны мәңгегә кичермәячәкмен, Сазан! Зонага гына эләгә күрмә, исән кайтмаячаксың! Ә мин кулымны синең шакшы каныңа пычратасым килми! Ходайның гадел хөкеме барыбер эзләп табачак сине!

Бу юлы да ул фатирга Ленинград читендәге Совет бистәсенә урнашты. Чөнки биредә күбесенчә үзбәк, таҗик, азәрбайҗан, төрекмәннәр яши, татарлар да җитәрлек. Чагыштырмача тынычлык хөкем сөрә. Кечкенәрәк кенә булса да, мәчетләре дә бар. Өстәвенә, конспирациянең дә кирәклеген онытмады ул. Йөргән машинасы да кеше кызыксынмаслык иске «Жигули» иде. Өстәвенә, кигән киемнәре дә игътибарны җәлеп итәрлек түгел. Шактый гына таушалган очучылар курткасы да, башында искереп барган эт бүреге, тән сакчылары да шул чама гына. Менә шуннан соң уйлап кара инде Казанның иң кырку егетләредер болар дип. Берәр җитәкче, ягъни кирәкле адәмнәр белән күрешергә кирәк булганда, Карель урманнары эчендә егетләрнең бик яхшы ял урыннары бар. Азәрбайҗан Алиев әзерләткән ризыклар телеңне йотарлык. Хашлама, пылау, бишбармак, шурпа, дисеңме, рәхим ит. Килгән-килгән, Артур егетләрен кунакка җыеп сөйләшеп алырга да җыенды. Беренче рангтагы капитан Азат Ибраев, генерал Илһам Сабиров, колбаса заводы директоры Камил Саттаров, тагын биш-алты иптәш чакырулы булды. Заманында Ленинградның Невский бандасы баскаклык ясый башлагач, казаннар килеп, тәртипкә салып киткәннәр иде. Хәзер, әнә, күпме кешегә терәк алар! Тире эшкәртү фабрикасының генераль директоры:

– Үзем килә алмыйм, хатынның әнисе каты авырып киткән, Туймазыга кайтып киләбез, Артур туган, гаеп итмә инде! – дип хәбәр салды. Аннан: – Сезгә бер утыз куртка тегәрлек яхшы күн җибәрәм, үзегезгә, хатыннарыгызга бүләк булыр! – дип тә өстәде.

– Анысы өчен рәхмәт, Фидаил Гарипович! Тик менә кемнән тектертербез икән аны? – дип сорады ул.

– Бар андый кеше – энекәш, Ленинградта яши. Бик яхшы оста, аэродром кепкаларын да тегә, күн курткаларны да төрекләр кызыгырлык итә, ялгышмассыз! Хезмәте өчен бераз түләсәгез, гаиләсен карарлык итсәгез, бик афәрин энекәш! – дип, сүзен бетерде.

– Аның хәтле кунакны сыйларга бер яхшы бозау кирәк! Безнең ял итәсе урыннан ерак түгел «Озёрный» совхозы урнашкан. Анда бер абзый бозау сатам дигән иде. Барып алсак, начар булмас! – дип тәкъдим ясады Алиев.

– Инде сатып җибәрмәгән булса? – диде Казан кунагы.

– Җибәрә алмагандыр? Акча юк бит хәзер халыкта. Совхозда эшләгән өчен дә йә чучка баласы, йә бозау ише нәрсә генә бирәләр хезмәт хакына. Барып килик, буш кайтмабыз! – диде Алиев.

* * *

...Әлеге сала, күлнең калку ярына урнашып, урман эченә сузылып кереп киткән иде. Сулык үзе көзгене хәтерләтеп, җәйрәп ята. Яр буенда «УАЗ» машинасы белән бишекле «Иж-Юпитер» мотоциклы туктап калган. Боз өстендә дүрт-биш адәм ятьмә сөйрәп кайнаша.

– Кайтышлый өлгерсәк, яңа тотылган балыкка да тукталып алырбыз, кабымлыкка балык шулпасы начар түгел бит, – дип куйды Алиев.

Совет заманында бик алдынгы хуҗалык иде әлеге совхоз. Меңнән артык мөгезле эре терлеге булган фермалары, балык тоту артеле, моннан дүрт чакрымдагы Андреевка авылында дуңгыз фермалары да бар. Алары үзәктән килгән түрәләргә, тикшерүчеләргә шашлык ясар өчен генә асрала. Совхоз-

колхозлар таралгач, терлек саны аз калган. Эшчеләр дә, акча түләмәгәч, качып беткәннәр. Калганнарына бәйрәм саен эчеп-тилереп алырлык кына сәмәннәр биреп алсалар, хезмәт хакының калган өлешен көз көне он-фураж, утын-печән, балык, тана-бозау белән каплыйлар.

Авыл хуҗалыгында намус белән хезмәт иткән Борисның – сала телендә әйткәндә, Борьканың – әлеге совхозда хезмәт иткәне өчен өч тана аласы калган иде. «Хезмәттәге уңышлары өчен» медален, Хезмәт даны орденын, өч «Социалистик ярышта җиңүче» билгесен тагып, «Балаларны укытырга кирәк бит!» – дип, Абрам Николаевич Песковка барган иде, ызгышып киттеләр. Теге живодёр аны мыскыл итеп: «Ычкын хәзер үк биредән, монгол калдыгы, югыйсә унынчыда укый торган кызыңны урман эчендә рәхәтләндерербез!» – дип, өнен алды. Борька хәзер бу игелексез совхоздан мал-туарын сатып, тизрәк качып китү ягын уйлап йөри иде. Балаларын күптән туган якларына озатты. Шуны белеп алган Песков үзенең иярченнәрен – Молдавиядә кеше үтереп, мал талап кайткан десантчы Иван Дубин белән заманында тирә-юньне көче белән куркытып торкан Игорь Звеняганы өстерде. Тегеләр мескен Борисны урманга утынга барган җирендә сагалап торып: «Бала-чагаларыңны кире кайтармасаң, бәреп үтерәбез!» – дип, нык кына дөмбәсләделәр. Сала мужигы шуннан соң атна буе урамга чыга алмыйча, җәрәхәтләнгән урыннарын өендә генә дәвалады. Дару алырга да тиеннәре калмаган мескен ир соңгы бозауларын сатарга ниятләп хәбәр салган иде. Менә бүген алырга да килделәр. Песков бәндәләре түгелме икән дип шикләнеп калган иде. Бәясен килешкәч, тән сакчысы Дамир тиешлесен бирде дә, Артурдан татарчалап:

– Биредә генә чалабызмы? – дип сорады.

Бу сүзләрне ишеткәч, хуҗа абзый уянып киткәндәй булды:

– Зинһар, кая булса да алып китеп суегыз, югыйсә Песковның бандасы ишетеп килеп җитәчәк! – дип, күз яшьләре белән ялварды.

– Нинди Песков ул тагын?

– Биредәге совхоз директоры, Абрам Николаевич, – дип, ачыклык кертте Алиев.

– Суегыз биредә генә, Дамир! – дип, каты гына әйтеп куйды Артур. Инде йорт хуҗасы Борис та кунакларның рус өммәтеннән түгеллеген аңлаган иде.

– Энекәш, зинһар, харап итмәгез, хәзер килеп җитәчәкләр бит, – дип, татарчалап үтенде. Гаҗәпләнеп калган Артур аңа:

– Нәрсә, сез дә татармы әллә? Нишләп чатанлыйсыз, ник битеңдә кыйналу эзләре? – дип төпченде.

– Балтачтан мин, энем, Балтачтан. Миңлевәли идем, Борькага әйләндем, – дип кычкырып елап җибәрде.

– Әйдә, сөйлә әле, абзый, ни булды? – дип, Артур явызлык корбаны булган хуҗага текәлеп карады.

– Энем, әйдә, түргә кереп сөйләшәбез! Апаң да өйдә ишегалдына да чыгарга куркып утыра. Әйдә, әйдә, өйгә кереп сөйләшик әле, кеше-мазар ишетә күрмәсен! – дип бимазаланды абзый.

Алгы якта егетне төсе киткән, вакытыннан алда чаларган, ләкин сылулыгын югалтмаган бер апай каршы алды.

– Исәннәрмесез, мин Артур булам! – дип, ике кулын сузды ул.

– Маша, – дип куйды хатын, калтыранып.

– Мөслимә ул, энекәш, Мөслимә! – диде йорт хуҗасы. Аннан хатынына: – Үзебезнекеләр бу, хатын, үзебезнең татарлар икән! – диде.

– Сөйлә әле барысын да, Миңлевәли абзый!

– Бирегә без, улым, 1980 елда, яхшы совхоз, хезмәт хакы да әйбәт, йорт та бирәләр дигәч килеп урнашкан идек. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, китте үзгәрешләр. Шуннан файдаланып, эт кавемнәре килде җитәкчелеккә, совхоз таланды, – дип сөйләде абзый. – Яшәрлегебезне калдырмадылар, энекәш. Сезгә дә вакытында бозауны алып таярга кирәк! Кайтып китәр идек, йортны саттырмыйлар, эшләгән өчен дүрт еллык хезмәт хакымны бозаулата бирәм дигән иде, дүрт бозау! Аларны да бирдертми; бусын ашатырга бернәрсә дә калмагач, сатарга булдым! – дип тезеп китте абзый кеше.

Ярты сәгатьләп сөйләшеп утырганнардырмы, ишегалдында ниндидер җанлану сизелде. Миңлевәли абзый өметен югалткан кешедәй:

– Килеп җиттеләр! – диде. – Иван Балда килгән. Китеп тә өлгерә алмадыгыз! Әй, энекәш, энекәш! – дип, караватат кырыена барып, балтасын алды.

– Кирәкми, Миңлевәли абзый, нишлисең?! – дип кисәтте Артур. – Үзем чыгам. Сез бирдә генә утырып торыгыз!

– Аллага шөкер, балаларымны Балтачка озатып куярга өлгердем. Аллага шөкер, хет алар исән-сау булсыннар!

– Абзый дим, тынычланыгыз! Комачауламагыз безгә! – дип, Казан егете тышка чыгып китте. Калганын Миңлевәли абзый тәрәзәдән генә карап торды. Банда башлыгы кыю Артурның борын төбендә зур йодрыкларын селеккәләде. «Исән чагында китегез моннан!» – дип янады. Ул да түгел, нык гәүдәле Дамир Балдага берне тамызган иде, бөтен саланың котын алып торган десантчы капкага килеп сыланды, авыз кырыйларыннан кан китте.

– Беттек, беттек без, Мөслимә, исән-сау качып китүләр насыйп түгел икән безгә! – дип ачыргаланып кычкырды Миңлевәли абзый. Үзе кабат тәрәзәгә капланды.

Дамир теге алпамшаның кесәләрен, түшен капшады, аннан Артурга:

– Үзе белән коралы юк! – диде.

– Киртә буендагы тиреслеккә кертеп бәрегез үзен!

* * *

...Песковның үзендә зур гына кунак бар иде бүген. Ул урман хуҗалыгы җитәкчесе Дмитрий Харитоновны чәйгә чакырган иде. Идарәнең ишегалдында яңа гына эшкәртелгән тана түшкәсе дә үз вакытын көтеп, асылынып тора. Хуҗа өстәлендәге өч литрлы ике банкада умарта балы, ысланган зур чучка боты Песковның муллыкта яшәгәнлеген күрсәтеп тора. Болар барысы да урман хуҗалыгы җитәкчесенә күчтәнәчкә хәстәрләнгән иде. Әлбәттә, бушка түгел! Абрам Николаевич Ленинградтагы әшнәсе – җитәкче бер түрәгә унга ун метрлы бура вәгъдә иткән иде. Ләкин ул гади генә түгел, ә сагызы алынмаган төз кедрлардан булырга тиеш. Әҗере дә кеше көнләшерлек. Ленинградлы аңа ике бүлмәле фатир вәгъдә итте. Менә шул сәбәпле, фин кавеменнән булган Хернестон, бүгенге көндәге Харитонов, чәйгә чакырулы иде.

– Әйе, әйе. Әлбәттә! Тикшерүчеләр тыгылып йөрмәсеннәр өчен урман

хуҗалыгы счётына символик сумманы гына кертербез, Дима туган, борчылмагыз! Үзегезне дә онытмабыз, ни дисәк тә, сезнең дә бит гаиләгез бар, аларның да тәмле итеп ашыйсылары килә, – дигәч, усал күзле Песков ямьсез итеп көлеп җибәрде. Херно бу адәмнән бик җирәнә иде, ләкин нишлисең, кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, диләрме әле? Карелиядә яшәүче кайбер милләттәшләренә ул: «Яшәргә кирәк бит, брат, яшәргә. Кайчан да булса безнең бу җирләр Финляндиягә кире әйләнеп кайтыр, шуңа күрә әлегә җайлашып яшәргә туры килә!» – дип аңлатты. Сүз дә юк, үз өммәтеннән булган ватандашларына ул гомер бакый ярдәм кулы сузып яшәде. Хәзер дә соңгы күлмәген салып бирергә дә риза ул үз халкына. Фамилиясен дә Херностоннан русныкына – Харитоновка алыштырды. Хәзер аны фин әнчеге дип мыскыл итүче юк. Ләкин ул үз милләтен җанытәне белән сөя иде, тик хисләрен беркайчан да тышка чыгарып салмады, беркемгә дә сиздермәде. Үз дәүләтеннән тартып алынган фин җирләре өчен җаны әрнеп яшәде. Аның күп сөйләнеп, шапырынып йөрмәве, бөтен эшләгән эшен законлаштыра белүе, килгән-киткән түрәләрнең җаена гына торуы абруен нык күтәрде. Карелиядә генә түгел, Ленинградның үзендә дә аны яхшы беләләр, хөрмәт итәләр иде. Җылы кәнәфидә арт санын туздырып утыручы түрә булсынмы, тирә-якны куркытып торучы төркем башлыгымы, бар да җанына җылылык эзләп, аңа килә, моң-зарын сөйли, хәтта катырак салып алсалар, эч серләренә хәтле рус булып йөрүче финга ачалар иде. Чөнки урман хуҗалыгы җитәкчесе сүз йөртми, күп сөйләнми торган тәрбияле зат иде. Ул үзенең мөнәсәбәтен сиздермәс өчен күзләрен яшереп, Песковка ияреп, хихылдаган булды. «Мин, Дмитрий брат, сезнең кебек адәмнәрнең күзенә туры карый алмыйм. Ләкин нишлисең, китереп терәделәр безне! Яшәр өчен этләнәбез, үзебез өчен дә түгел, тукта, балаларыбыз кеше булсын өчен, диюдән инде ул!» – дип акланды Песков.

Абрам үзен аклап сөйләде дә сөйләде. Херностон аны тыңлагандай, башын селеккәләде, елмайгандай итте, үзе эченнән: «Күпме хатын-кызны көчләдең, мохтаҗлыкларыннан файдаланып, яшь кызларның сафлыгын, тормышын боздың, хәшәрәт!» – дип әрнеде. Тагын самогон йотып куйдылар. Калын итеп туралган дуңгыз маен чәйнәделәр.

– Менә син мине каты бәгырьле дип уйлыйсыңдыр инде. Заманы шулай, туган, халык тәртәдән ычкынды. Хәзер эшләргә теләүче адәм калмады. Ә хуҗалыкта селкенеп йөрүчеләре хезмәт хакы сорап тинтерәтә. Монда безнең бер басурман бар, килә дә акча сорап бәйләнә, килә дә мозгаларны ышкый. Үзе тагын рус исемен алып, Борис булып йөри шунда, халыкны алдап. Ә мин аның татар икәнлеген вычислил, аңладыңмы? Бугазыннан: «Шакшы Монголияңә ычкын!» – дип буып алдым. Эшләгән хезмәте өчен бозаулата булса да бир, ди. Ул гына кеше, анда гына балалар бар, имеш. Ә бездә юкмы? Минем егетләр арт санын укыттылар тагын үзенең. Мәйтәм, өлкән кызың Зояны, үзләренчә Зөлфия икән, чибәр тагын зараза, сәркәтип булып, миңа килсен дип тәкъдим ясадым. «Син күпме мескен кызның башына җиттең!» – дип акыра, вәт шакшы татар! Хәзер өч баласын да каядыр озаткан, яшергән. Бәлкем Улан-Баторгадыр. Ну, мин ул татарвага күрсәтәм әле бөек Русиядә ничек яшәргә кирәклеген. Безнең белән бер дәүләттә тормыш итә башлагач кына юынырга өйрәнделәр бит алар.

– Алай ук түгел инде, Абрам Николаевич! Миңа татарлар белән аралашырга туры килде. Бик чиста-пөхтә, хезмәт сөючән халык. Күпчелеге намаз укыр алдыннан көнгә биш тапкыр юына.

– Чынлапмы?

– Чын! Дөресе шулай, Абрам Николаевич!

– Ә сез каян беләсез соң, Дмитрий Алексеевич? – дип, сынаулы караш ташлады.

Урман җитәкчесе нәфрәтен йөзенә чыгармас өчен ясалма елмаю ясап:

– Мин алар белән Чабаксар урман хуҗалыгы институтында укыдым. Авылларына кунакка да кайткаладым. Соклангыч халык! Горур халык! Ул өйләре искитмәле! Һәрберсендә чисталык, ул каралты-куралары, мин сиңа әйтим! – дигәч, кунак пауза ясап алды да рус дип әйтәсе урынга: – Финнар сокланырлык, – дип куйды.

– Ул Чабаксарда чувашлар яши түгелме соң?

– Татарлар да бик ишле анда, чувашларның үзләренә дә үрнәк булып яшиләр. Ә мунчалары безнең Карелиядә дә юк!

– Менә ничек! Теге басурман Борисканың да мунчасын чын хан сарае кебек, ди җирле халык, көнләшеп. Ләкин барыбер мин аның җанын алачакмын! Чиста булсалар да! Әйдә, братан, тотып куйыйк әле, чәнчелеп китсен монголоидлар, – дип, янә фужерын күтәрде.

...Дмитрий бит институтта укыганда, тулай торакта башта өч иптәше белән торган иде. Икесе чуваш, берсе рус милләтеннән булды. Бик тырышып, бүлмәне тәртипкә салырга маташса да, тора-бара пөхтәлекнең үзеннән гайре беркемгә дә кирәкмәгәнлеге ачыкланды. Эчү, өс киемнәре белән ятакта аунау чисталык яраткан фин кешесе өчен сәер тоела иде. Ярый әле, шәһәр мунчасына баргач, очраклы гына икенче курста укучы татар егете Кәрим белән танышып китте. Татар егете үзе җыеп бәйләгән себеркесе белән чабынырга рөхсәт итте. Шулай аралашып китеп, кая барсалар да, бергә йөри башладылар. Кәримнәр бүлмәсендәге чисталыкны, тәртипне күреп сокланды, шул сәбәпле татарларга тартылды. Өстәвенә, Кәримнең авылдашы Нияз яшертен генә намаз укый иде. Башта Дима аңа сәерсенеп, нишләп бик еш бәдрәфкә юынырга чаба икән, чирләмидер бит, дип аптыраган булса, һәр намаз алдыннан тән сафландырырга кирәклеген белгәч, соклануы артты гына! Эченнән генә «Их, шушы егетләр белән бер бүлмәдә торасы иде», дип хыялланды. Көзен икенче курска укырга килгәч, Кәрим деканаттан туган авылы Урмайга бәрәңге алырга кайтырга ике көн өстәмә ял сорап алганын әйтте. Татарлар белән кызыксынып киткән фин егете уңайсызланып кына:

– Булышырга кайтмыйммы соң? – диде. Кәрим шатланып:

– Әлбәттә! – диде. Аннан: – Хәзер деканга кереп, сине дә җибәрүләрен сорыйм, әйбәт кеше ул, үзебезнең чуваш! – диде.

Шулай итеп, беренче тапкыр татар дөньясы белән танышты, аралашты Дмитрий. Аларның чисталыгына, хезмәт сөючәнлегенә исе китеп йөрде. Анда тартма-тартма суган-сарымсак, кабак, помидор-кыяр базга урнаштырылуын көтеп ята. Каралты-кураларның төзеклеген-ныклыгын күреп тә шаккатты. Дусты Кәримнәр генә түгел, бөтен авыллары белән икешәр-өчәр катлы матур йортларда яшиләр. Ә мунчалары кечкенәрәк йорт хәтле. Менә нинди була икән татар мунчасы! Егет дүрт көн буена бөтен

дөньясын онытып, бәрәңге алышты, печән-саламын өеп, эштән ләззәт алып йөрде. Бар икән бит Россиянең ул белмәгән якты чырайлы урыннары да! Эшләгән кешенең кадерен беләләр икән биредә. Кәримнең әнисе Кадрия ханым алар эшләгәндә, ник чыгып, бер күз атсын! Төпле сәбәбе дә бар булып чыкты, көне буе, хәтта кичләрен дә аш бүлмәсендә кайнашты ул. Нинди генә ризык пешереп сыйламады студент егетләрне: ат итеннән шулпа, пылау, пәрәмәчләр! Кадрия ханым чәнечке белән алып, менә болар ак тамыр дип, авызларына нидер каптырды. Менә бавыр, каймакка манып ашагыз әле дип кыстый-кыстый сыйлады. Килешмәде фин корсагына туклыклы татар ашлары. Бертуктаусыз кыстап тормасалар, ул кадәр сыймас та иде. Ничек инде олы кешенең сүзен тыңламыйсың! Тыңлавын да тыңлады, ләкин эче йомшарып китеп, бәдрәфкә ешлады. Иптәшенең хәлен аңлап алган Кәрим: «Бәдрәфтән соң мунчага кереп тәхәрәтләнеп чык!» – дип өйрәтте. «Синең карын ияләшмәгән әле безнең туклыклы ризыкларга. Менә минем белән шулай кайта-китә йөрсәң, синең дә корсагың татарныкына әйләнәчәк!» – дип шаяртты. Аларны кире Чабаксарга Нурислам абый үзенең беренче маркалы «Жигули»е белән озата барды. Чөнки күчтәнәчкә бирелгән кишер, суган, бер капчык бәрәңге, бер тавыктан гайре, Кәримнең кыш чыгарга дигән үз күчтәнәчләре тагын да күбрәк иде. Тулай торакка кайткач, Дима:

– Кәрим туган, бу күчтәнәч азык-төлекне сездә генә урнаштырып булмас микән? – дип сорады. Дустының нинди шартларда яшәгәнен инде күптән белгән иптәше:

– Безнең Илшат апаларына торырга күчә, өч бүлмәле фатир алганнар иде, ятма тулай торакта таракан үрчетеп дип сүккәннәр. Күч әйдә аның урынына, йә безгә әллә кемне китереп тыгарлар, – диде. Бу хәбәрдән Диманың шатлыгы эченә сыймады.

«Ә монда руска күчеп, славян булып кыланучы мөртәт, фамилиясен Песковка үзгәрткән дә рус халкы исеменнән мөселманнарны мыскыл итеп ята. Русларны котырта, өстерә. Үзе җиң сызганып, совхозның малын талый, хатын-кызларын мыскыл итә. Ирләре, түземлекләре бетеп, бар кыюлыкларын җыеп, муенын борырлар дип тә уйламый микәнни? Әллә инде Балда белән Амбалның бандасына таяна микән? Иртәме-соңмы, таеп китүең бар!» – дип уйлады Харитонов Песков турында һәм:

– Әле Ленинградка барган идем. Теге завод директоры Гольфенгерны Талкочта бандасы бәреп үтергән дип ишеттем, – дип куйды.

– Кайсы Гольфенгерны? – дип сәерсенеп сорады Песков. – Теге, ЖБИның генераль директорынмы?

– Әйе! Ну, китте заманалар, мин сиңа әйтим, безнең якларга гына килеп җитмәсеннәр инде, диюем.

– Шулай, шулай, килеп җитә күрмәсеннәр! Теге яһүдине олактырганнар инде алайса. Күптән кирәк иде аңарга. Юкса бөтен ил байлыгын кесәләренә салдылар, без рус халкына йомычкалары гына калды. Израильгә куарга кирәк аларны, бөтен урлаганнарын тартып алып, – дип, шешәдәшенең фикерен ачыкламакчы булды хәйләкәр Песков.

«Ача алмассың минем телне, Штенгерд, мин сезнең кавемне яхшы беләм!» дип уйлады Харитонов һәм:

– Әйбәт кеше иде ул! Гольфенгерны әйтәм, яһүди булса да, – дип куйды.

– Шулай дисеңме?

Кинәт кабинет ишегеннән Артур, аннан Дамир белән Гена, тирескә баткан Балданы сөйрәп алып керделәр.

– Бу синең хайваныңмы, кеше өенә килеп баскынлык итеп йөри?! – дип кычкырды Артур. – Кем җибәрде сине, әйт әле?

– Менә бу, Абрам Николаевич кушты! – дип, башын түбән иде, әле күптән түгел генә авылның кендеге булып йөргән бәндә. Песковның акайган күзләре орбитасыннан тагын да ныграк тышка бүселеп чыкты.

– Сез кемнәр? Хәзер үк чыгып китегез!

– Әй, син, начальник, кемне куркытасың?! – диде Артур.

– Минме?! Минме?! Мин хәзер милиция, ОМОН чакыртам! Хана була сезгә! – дип калтырана-калтырана, телефонга үрелде.

Яшен тизлегендә бер сугып алуга, мөртәт идәнгә сузылып төште. Артур өстәлдәге коньяк шешәсен алып, эчендә калган сыекчаны совхоз директорының битенә агызды. Теге селкенеп куйды, өстәл кырыена тотына-тотына, көчкә урыныннан торды.

– Нәрсә өчен? Нәрсә өчен, егетләр?!

– Хатын-кызлар көчләгән, үзеңнең хезмәткәрләреңне талап, менә бу дебилларга кыйнатып ятканың өчен!

– Мин беркемне дә көчләмәдем, беркемне дә! Алар үзләре теләп...

– Алайса, зонада рецидивистларга үзең аңлатып карарсың! Ә сез кем буласыз? – дип, Артур шатланырга да, көенергә дә белмичәрәк басып торган Дмитрийга эндәште.

– Эш белән генә кергән идем, урман хуҗалыгы җитәкчесе мин, – диде ул, каушап калганлыгын сиздермәскә тырышып.

– Сез, зинһар, барыгыз да чыгып торыгыз! Дамир, хәзер үк Миңлевәли абзый керсен, – дип әмер бирде.

Бүлмәгә бу көтелмәгән хәлләрдән тетрәнеп калган татар абзые үзе керде. Аның кара тут чыраена куркып, югалып калу төсмерләре иңгән иде.

– Ничек әле исемегез?

– Абрам! Абрам Николевич, – диде теге, канлы иреннәрен селкетеп.

– Яһүдмени?

– Юк, юк, әнием, рус кызы минем!

– Менә нәрсә, чиста канлы рус абзыкае, хәзер үк Борис дәдәгә бирәсе бурычларыңны түлә. Күпме тиеш син аңа?

– Өч бозау кебек!

– Дүрт тана бир! Хәзер үк! Аннан, син аның кызын көчләү белән янагансың икән, үзеңнекеләр ничек соң, бозау ите ашап көрәйгәннәрдер. Әгәр дә тагын менә бу кешеләргә зыян саласың икән, ике кызыңны да Ленинградтан килеп, син кылган галәмәтләрне кылачаклар, үзеңне төрмәдә акылларын югалткан, ыжгырып торган җинаятьчеләр кулланачак. Аңладыңмы?

– Әйе. Барысын да аңладым. Син гафу ит инде мине, Борис. Шулай килеп чыкты инде, мин гаепле! – дип, совхоз җитәкчесе күзләрен челт-челт йомгалап, Миңлевәли абзый алдына тезләнде.

– Аннан, ул биредән күченеп китә, йортын өч миллионга сатып аласың, аңлашылдымы?! Хәзер үк акчасын бир! Йорт шуннан соң синеке!

– Андый акчаларны... – дип карыша башлаган иде, Артур аның сүзен бастырып:

– Хәзер үк! – дип җикерде.

Мескен бер шәүләгә әйләнгән бәндә, өстәл тартмасын ачып, калтыранган кулы белән бер төргәк чыгарды.

– Менә ике миллион ярым. Бүтән бер тиенем дә юк!

– Алайса тагын ике сыер да өстә!

– Яхшы, яхшы, егетләр, булыр! Әйдәгез, хәзер барысын да җайлыйм! Киттек терлек фермасына! Барысы да сез дигәнчә булыр! Тик, зинһар, балаларыма гына тимәгез, – дип, урыныннан торды.

Миңлевәли абзый һушына килә алмый аптырап торганнан соң, борын төбеннән:

– Дөрес буламы соң инде болай? Көчләп алабыз түгелме? Утыртмаслармы безне? – дип мыгырдады.

– Күптән утыртканнар бит инде сезне, Миңлевәли абый – дядя Борис! – дип әйтеп куйды Артур ачу белән.

Алыш-биреш хәлләре беткәч, казанлылар совхоз җитәкчесеннән, «Хуҗалыкка куйган өч еллык хезмәте өчен, шуның хакы буларак дүрт тана һәм ике сыер бирелә. Шулай ук аның йортын ике миллион ярымга совхоз сатып ала, шуны раслап кулымны куям!» дигән белешмә яздыртып алдылар. Аңа түп-түгәрәк хуҗалык мөһерен дә суктырдылар. Бик четерекле һәм куркыныч булып күренгән гамәл җиңел генә бетеп тә китте. Шул ыгы-зыгыдан файдаланып, урман хуҗалыгы җитәкчесе җай табып:

– Рәхмәт, сезгә, егетләр! – дип пышылдады. Артур аңа күтәрелеп, сынап карады.

– Сез бу җирләрнеке түгел бугай?

– Фин кешесе мин, татар туганым! Иблиснең сихерен юк иткәнегез өчен бик зур рәхмәт! Юлыгыз туры килсә Иске Финка саласына миңа кунакка рәхим итегез! Сезнең милләт кебек кунак итеп булмаса да, милли ризыкларыбыз өстәлебездә ташып торыр!

– Рәхмәт, фин туган! Ләкин мин...

– Аңлыйм, исән-сау йөрегез! – дигәч, Хернестон, борылып, кырыйда иләсләнеп торган Миңлевәли агайга:

– Борис, идарә ишегалдында бер тана түшкәсе эленеп тора, ул синеке, аны да ал әле, миннән әзме-күпме ярдәм булыр, – дигәч, бүгенге хәлләрдән иләсләнеп калган абзый:

– Зинһар, Мөслимә апагызга вакытыннан алда җиткерә күрмәгез, мин аны хәзер Татарстанга озатам, булганын сатып, аннан үзем дә юлга чыгачакмын! Әйтә күрмәгез, зинһар, йөрәге тузган! Күтәрә алмас бу кадәр шатлыкны!

– Алиев, син әлеге терлекләрне берәр җиргә урнаштыра аласыңмы?

– Кирәк икән, урнаштырам, ләкин үзем белән андый суммалар юк!

– Үзем биреп торам! – дип, Артур тән сакчысы Дамирга ымлады. Аркадашы аннан:

– Күпме? – дигәч, барысын да ишетеп торган Борис, мескенләнеп кенә:

– Юк, юк, җегетләр. Ярты гына бәясен бирсәгез дә җитә, – дип әйтеп куйды.

– Менә, Вәли абзый, бу сезнең акчалар, хәзер үк җыенығыз, юлга чыгыгыз! Казанда минем туганнан туган энекәшем яши. ЭПАХ дигән оешмада эшли, исеме – Ирек. Ул сезгә, теләсәгез, шәһәрдән – фатир, авылдан йорт алып бирергә булышыр! Очраклы кешеләргә, мошенникларга эләгеп, урамда кала күрмәгез, дим.

– Яхшы, энекәш! Яхшы! Алланың рәхмәте яусын үзегезгә! Йөргән юлларыгызда мәрхәмәтле адәмнәр генә очрап торсын! – дип, агай күз яшьләрен җиң очына сөртеп алды.

– Амин, шулай булсын! – дип, Артур битен сыпырып куйды.

***

Әти-әниләре, туганнары Әлмирәне дүрт күз белән көтеп торганнар. Очрашу шатлыгының иге-чиге булмады. Әле абыйсы килеп кочып ала, әле әнисе күз яшьләрен алъяпкычына сөрткәли. Көтә-көтә көтек булган дәү әнисе дә, кышкы юл дип тормаган, үзе килеп җиткән. Әлмирәнең тулып, алсуланып торган битләреннән чупылдатып үпте, тутырып-тутырып, балкып торган күзләренә бакты. Шомырт кара чәчләрен иснәде. Әйтерсең лә, үзенең Әлмирә нарасыемы, әллә түгелме, дип тикшерә иде. Башын әбисенең түшенә куйган кызның борынына кечкенәдән таныш булган тәмле исләр ярып керде. Ул шунда гына үзенең өендә, туганнары арасында икәнлегенә тулысынча төшенде. Казанына биш ай гына түгел, биш ел кайтмый torгандай тоелды аңа.

– Дәү әнием, – дип, үсмер кыз сабый баладай назланып, карчыкның кочагына сыенды. Әбисе озын җиңле, озын итәкле, якасы бөтен күкрәген каплаган, татарчалап тегелгән күлмәген кигән, азык-төлек пешергәндә, ризыкка чәч бөртекләре төшә күрмәсен дип, башына ак яулыгын бөркәнгән, оч-очларын артка тарттырып бәйләгән. Оныгы күрсен дип, ахры, Сабаның Юлбат авылындагы бабайдан татар орнаментлары белән бизәкләп ясаткан көмеш беләзеген элгән. Ярым айны хәтерләткән алтын алкалары да ут яктысында җем-җем килә. Әбисенең күлмәгенә сеңгән затлы ризык исләре, балачагын искә төшереп, борынын кытыклый. Авызда эри бит дәү әнисе пешергән пәрәмәчләр, гөбәдияләр.

Нәрсә генә юк иде бүгенге бәйрәм өстәлендә. Тутырылган каз, авыл тавыгы салып пешерелгән токмачлы шулпа, пәрәмәчләр, өчпочмаклар, кош телләре... Кытлык булуга карамастан, табынны телемләп киселгән лимон, алма белән груша бизи. Туганнарыңны сыйларсың дип, Лиза белән Валя җибәргән анарлар да өстәлдә урын алды. Көязләнергә яраткан абыйсы эшләпәсен киеп, көзге каршысында бөтерелде. Әнисенең: «Улым, соңыннан киеп караган булыр идең! Утыр инде, кеше белән беррәттән!» – диюенә: «Монысын кая барсаң да, кияргә була икән, рәхмәт, сеңлем!» – дип җавап бирде. Ничә касә чәй эчкәннәрдер, Әлмирә хәтерләми дә. «Уф, шартлыйм хәзер!» – дип, кыз фарфор касәсен әйләндереп тәлинкәсенә каплады.

...Туганнары белән аралашып, бәхет хисләре кичергән кызның көтеп алган ике атна ялы сизелмичә дә үтеп китте. Менә ул кабат тәгәрмәч тавышларын тыңлап, Ленинградка китеп бара. Күңелендә аерылу хисләре. Үзен нишләптер әбисе алдында да гаепле итеп тойды, әтисе каршында да уңайсыз булды аңа. Шулай хәл-әхвәлләр белешеп, янында иркәләнеп ятканда, дәү әнисе:

– Кызым, күрше Исрафил абыең белән хат алышасыңмы соң? – дип сорагач:

– Әйе, дәү әни, – дип, коры гына әйтеп куйды. Өлкән кеше аның тавыш төсмерен үзенчә аңлап: «Дөрес эшлисең, кызым, мәхәббәт серләрен кешегә бик ачарга ярамый аны!» – дип уйланып алды. Исрафилгә дигән галстукны бүләк итеп биргәндә, әтисе: «Бу яшьләрский түгелеме соң?» – дип, нидер сизенгән кебек сорап куйды. «Кичерегез, зинһар, кадерлеләрем, кичерегез! Серләремне ачып бетерә алмаганым өчен. Кыен миңа, дәү әнием, гафу ит, кичер, кадерле әтием! Нишләп, нишләп, шулай иттең, Исрафил абый?! Мин бит сине якын туганымдай күрә идем! – дип, пауза ясады да: – Сөя дә идем!» – дип пышылдады. Аның күңелен рәнҗеш катыш тирән сагыш биләп алды.

***

Уку елының икенче өлеше, вак-төяк борчуларны санамасаң, әллә ни үзгәрешләрсез дәвам итте. Укуында да алдынгылар рәтендә, дус-ишләре дә хөрмәт итәләр. Тик Лиза ахирәтенең генә чечен егетенә гыйшкы көчәйгәннән-көчәя бара. «Ике билет юнәткән идем, әйдә, иптәшкә бар әле», – дип, берәр кинофильмга, йә булмаса театрга үзе белән кавказлыны ияртеп китә. Соңгы айда гына да «Бриллиантовая рука», «Иван Васильевич меняет профессию» дигән фильмнарны карап, көлә-көлә эчләре катып, көлгәннәрен сөйли. Чыркылдый-чыркылдый көлә-шаярта да кинәт кенә моңсуланып кала. Соңыннан яшьле күзләре белән Әлмирәгә текәлеп: «Матурым, әйт әле, сез мөселманнарда ике-өч хатын алу каралган бит, дөресме ул?» – дип сорый. «Юк шул, Лиза, совет власте бетерде аны. Элек инкыйлабка хәтле дүрт хатынга хәтле рөхсәт ителгән, анда да беренче хатының бала табалмаса яисә чирләп китеп, ирен, сабыйларын тәрбияли алмаса гына. Дөрес, акчасын кая куярга белмәгән, симерүе җиткән бай бәндәләр өсте-өстенә дүрт хатынга хәтле өйләнгәннәр. Иң мөһиме, Лиза, балалар ятим ителмәгән, дәү әнием шулай дип аңлата», Лиза әрнеп: «Нишләп ул ислам кануннарын җимергәннәр, нишләп? Мин аңа икенче, өченче, унынчы хатыны булырга да риза!» – дип сыкрый. «Ни галәмәт инде бу, уйнаштан бала табарга ярый, законлы рәвештә чираттагы хәләл җефете булып дөнья куып булмый. Үләм мин, Әлмирә, түзә алмамын, ахры, мин!» – дип, ятагына сыгылып төшеп, күз яшьләрен түгә. Күпмедер вакыттан соң ачылып китеп, тагын нинди юллар бар икән дип, чечен егете белән очрашу мөмкинлекләрен эзли. «Тиздән Мәскәү циркы килә, Валядан ике билет табып бирүен сорыйм. Майда Зур театрда Чеховның «Өч сеңел» әсәренең премьерасы. Анда минем авылдашым баш администратор булып эшли», – дип, хыял дулкыннарына чума. Әлмирә бүлмәдәш кызының интегүләрен күреп кызгана да, үлеп-янып сөя белүенә соклана да. Валялары да бер көнне кайтып кереп, сюрприз ясап, күңелләрен төшерде. Ишектән керүгә: «Гафу итегез инде мине, кызлар, китәм тулай торактан!» – дип оран салды. Ике иптәше өне китеп: «Ничек инде? Шундый тату гына торганда?! Ни булган? Әгәр аның урынына күңелләренә ятмаган адәм баласын кертсәләр? Валя булганда, өстәл тулы ризык, әле кайтса да, ял итәргә берәр тәүлек урыныннан тормыйча йокларга гына кайта. Фигаро монда, Фигаро тегендә

дигәндәй, аннан да яхшырак бүлмәдәш, белмим инде, табылырмы? Лиза үпкәләп: «Кайсы бүлмәгә күчәсең инде?» – дип сорады.

– Шуның хәтле кайгыга батмагыз әле, килеп-китеп йөрермен!

– Кияүгә чыгасыңмы әллә? – дип сорады Лиза.

– Нинди кияү, кызлар! Юк, бернинди кияү дә булмастыр инде... Миңа әти бер бүлмәле фатир алып бирде. Шул гына!

– Ничек кызганыч!

– Ни сөйлисең син, Лиза дустым?! Җылы суы агып тора, рәхәтләнеп ванна кереп китәрсез, гөнаһлы тәннәрегезне сафландырып, балконына чыгып, чибәр-чибәр егетләрне күзләрсез! Икегез өчен дә минем ишек ачык, менә бер ачкычымны биреп, бүген үк калдырып китәм.

– Анысы өчен рәхмәт инде. Тик... – дип, Лиза кабат авызын бөрештерде.

– Нәрсә тик?

– Синең урынга берәр күсене, йә шайтанны кертсәләр, Дуня кебекне!

– Анысы бар шул, кызлар! Әйдәгез, болай итәбез. Җәйге каникулга хәтле койкамны тапшырмыйм. Соңыннан яңа уку елыннан күз күрер. Берәр спонсор табам да, рәхәтләнеп түләп торсын! Бер сум ярым айга күпмени инде ул? Ә сез Әлмирә белән иркенләп икәү генә яшәрсез! – дип елмайды моңсу гына.

– Сагыначакмын инде мин сине, дуамал баш, Валюша җанкисәгем!

– Мин бит килеп йөриячәкмен! Америкага китмим. Лиза, Альмира, сез бит миңа килеп йөриячәксез, шулай бит! Гел аралашып яшәрбез, борчылмагыз!

Валя күчеп киткәч, бүлмәгә чит кешене кертмәсәләр дә, күңелләре кителеп калгандай булды. Ярый әле бәхетләренә уку елы бетеп килә, тиздән имтиханнар, июль ахырларында туган ояларына таралачаклар. Дәү әнисе, әти-әнисе, абыйсы, гүзәл моңлы Казаны көтә Әлмирәне!

Исрафил абыйсыннан ай саен хатлар килеп торды. Укымады ул аларны, ертып кына ыргыта иде.

***

...Әлмирә алдагы ел ярымын тулай торакта бикләнеп диярлек укуына бирелде. Атнасына ике тапкыр бию түгәрәгенә баруларны, Динамо стадионында үткәрелгән физкультура дәресләрен санамасак, кирәк-кирәкмәгәнгә, бөтен Россия халкын ат урынына җигеп, эт тормышында яшәтеп төзелгән калага бик чыгып йөрмәде. Иптәш кызлары кафе-ресторан кебек җирләргә кыстап та, үгетләп тә карадылар, тик ул шундук башка сүз әйттермәслек итеп, кире какты. «Юк, юк, кызлар, андый заведениеләргә йөрү миңа, гомумән, килешми. Ыгы-зыгы, көчле музыка тавышы башыма каба, зинһар, сүз әрәм итеп, кыстап та маташмагыз», – дип, кире кага иде. Икенче курсны тәмамлаганда, бик җитдиләнеп, имтиханнарга әзерләнде. Үткән җәйне ясый башлаган эскизларны тапшырырга дип төннәр буе эшләп, буяуга батып бетте. Бер рәсеме аның Сөембикә манарасын үзәгенә алган булса, икенчесендә Бөек Болгар хәрабәләре сурәтләнгән иде. Язу-сызу, буяу эшләреннән бушадымы, ихтыяр көчен җигеп, китапларны кабат-кабат укып чыга. Бигрәк тә аңа иҗат әсәрләренә кагылган темалар хуш килә иде. Шулай, хәреф чүпли-чүпли, кайчагында башын китап өстенә куеп, йокыга да киткәли. Инде уянса, кабат Пушкин, Лермонтов, Гоголь,

Чехов китапларының эчтәлекләрен кабат барлап чыга. Нәтиҗәдә, барлык фәннәрдән дә «бишле» алды, дияр идең; татарларны сөймәүче тарих укытучысы гына аңа «дүртле» куйды. Бик исе китми хәзер Әлмирәнең. Күңел түрендә үпкә сакласа да, берәүгә дә сиздерми. Беренче курста чагында яшереп кенә күз яшьләрен түккән чаклары була иде. Борынгы әби-бабаларының вәхши, кыргый булганнары өчен ояла, татарларга шундый алдынгы тормыш төзеп биргән рус халкына ихтирамы арта. Тик шуны гына аңлап бетерә алмый: татарларның кигән киемнәре дә затлы, торган йортлары да төзек, бизәкле. Әллә русларның башкаларга яхшы тормыш төзибез дип йөреп, үзләре өчен вакытлары калмаганмы? Һич кенә дә төшенеп бетә алмый Әлмирә шуны! Сорашырга Әхмәт абыйсы да еракта, Казан каласында.

Икенче курсны тәмамлап, каникулга кайтса, сорашыр кешесе Әлмәт дәүләт театрына кием, декорация эскизлары ясарга дип китеп барган. Сеңлесен ялга кайткач кына күреп калды. Атна башында: «Ярый, сеңлем, без анда Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» мелодрамасын куеп ятабыз, эш тыгыз, баш режиссёр Гали Хөсәенов ашыктыра!» – дип, маңгаеннан бер үпте дә китеп барды. Абыйсы киткәч, кыз тагын да күңелсезләнеп калды. Ике көн шулай үзенә шөгыль табалмыйча тилмергәч, Таллы Күлгә кайтып килергә уйлады. «Бәлкем Исрафил абыйсы да шундадыр... Әлмирәнең күзләренә туры карый алыр микән ул?»

Кайтып төшкән көнне әбисе белән сөйләшеп туя алмады. Үзе ишегалдына чыккан саен күршеләргә күз аткалады. Тик күрергә теләгән кешесе генә пәйда булмады. Бөдрә чәчле егет салкын су белән мускулларын уйнатып юынмады, су чәчрәтеп, кызның киемнәрен чылатмады. «Әллә иманга килеп, марҗадан туган баласы янына китеп барганмы?» Әбисеннән төпченергә дә оялды, яхшысынмады. Ләкин гомер кичкән карчык сизми каламыни?!

– Ни бит әле, кызым, Кавказда чуалышлар башланган, ди. Исрафил абыеңны да комсомол буларак шунда чакырганнар икән. Әнисе бик борчылып ята инде, бичаракай! Исән-сау гына әйләнеп кайта күрсен яхшы күңелле бала! – дип борчылып пышылдады әби.

«Яхшы күңелле бала?! Хезмәт иткән җирендә бер балага гомер биреп, ташлап качкан кеше яхшы күңеллеме инде ул?! Шул бәләкәч хакына булса да, исән-сау әйләнеп кайтырга язсын инде аңа!» дип уйланды кыз. Шуннан артыгын әбисеннән сорарга йөрәге җитмәде.

***

Ленинград көзе быел Азия якларындагы кебек кояшлы, җылы килде. Яңгырлары да сибәләп кенә китә дә, Аллаһы Тәгаләнең түгәрәк лампасы тагын нурларын мулдан чәчә. Сентябрьнең өченче атнасының шимбә белән якшәмбесендә институт шәкертләре арасында көзге спартакиада башланды. Җиңүчеләр бөтен Ленинград өлкәсендәге вузлар арасында ярышачаклар икән. Катнашучылары да, тамашачылары да Динамо стадионына Нева суы кебек агылды. Шулар арасында хатын-кызлар да җитәрлек иде.

Өнә аерым төркем булып өч туташ килә. Икесенең чәчләре җылы җил исеп куйган саен дулкынланып, таралып тирбәләләр. Өченчесенең шомырт кара, куе чәчләре калын толымга үрелгән. Көн җылы булу сәбәпле,

алай-болай суытып җибәрә калса дип алган кофталарын беләкләренә салганнар. Яшьлекләре ташып торган чибәркәйләрнең кәефләре күтәренке, шаярышып-көлешеп атлауларын беләләр. Лиза дигәне:

– Альмира, а как переводится на татарский «люблю тебя?» – дип сорый.

Тегесе аңа:

– Яратам сине! – дип тәрҗемә ясый.

Иптәше чит-ят сүзләргәияләшеп җитмичә:

– Тагын бер кабатла әле! – дип үтенә.

– Мин сине яратам! Мин си-не я-ра-там!

Шуннан соң ахирәте дә үзенчә:

– Мин сине яратам! – дип кабатлый.

– Ну, как, Альмира, получается? – дип сорый.

– Почти!

– Ничек кызык икән татар теле!

Шуннан Әлмирә түзми:

– Мин сине яратам! Мин сине яратам! Мин сине барыбер үземә каратам! – дип җырлап җибәрә.

Валя белән Лиза:

– Браво, подруга! – дип кул чабалар. Валюша шунда:

– Ә безнеңчә ничегрәк була инде? – дип сорый. Әлмирә уйланып бара да:

– Юк, кызлар, русчага тәрҗемә иткәч, рифмасы килеп чыкмый! – ди.

– Соң якынча булса да әйт инде! – дип үтенә Лиза.

– «Я тебя люблю, я тебя люблю, рано или поздно все равно станешь моим!»

Лизага бу сүзләр бик ошады. Ул анда ниндидер зур мәгънә табып:

– Какие красивые слова, девчонки! – дип куйды.

Шулай шаярыша-көлешә, кызлар Динамо стадионының капкасыннан кереп, буш урын эзләп, тирә-яктагы утыргычларга күз салдылар. Каршыдагы секторда гына кеше сирәгрәк иде. Өченче рәттәге артсыз озын агач эскәмиягә утыргач, мәйданга күз салдылар. Анда вуз спортчылары разминка ясый. Кайберләре йөгерә, икенче берләре гимнастик күнегүләр ясап, мускулларын җылыта. Мәйдан эче кайнап тора. Лиза шулар арасыннан үзенең сөйгәне, яшьлек мәхәббәте, чечен егете Аслан Мөхәммәтовны эзли! Шунда ул аны күреп алды, шатлыгы эченә сыймыйча, йөрәге ярсып тибә башлады, хәленнән килсә, янына очып барып, баш очында кош булып сайрар иде. Аның сүзләре дә бая Әлмирә дусты җырлаганча, «Мин сине яратам, мин сине яратам, мин сине барыбер үземә каратам!» дип яңгырар иде.

– Ой, кызлар! Аслан да монда бит, мин аңа көч биреп торачакмын! Нинди чибәр ул! Бөдрә чәчләре кара миләш кебек, тәлгәш-тәлгәш! Гәүдәсе борынгы грек атлетларыныкы кебек! Әйдәгез, мин аның ничек ярышканын якыннан күрәсем килә, әйдәгез, кызлар, үтенеп сорыйм, якынрак барыйк?!

Кешеләр арасыннан этенә-төртенә түргә юл ярдылар. Ниһаять, судьялар тезелешеп утырган өстәлләр янына килеп җиттеләр. Валя шунда:

– Әнә бит, безнең Роман да биредә икән! – дип әйтеп куйды. Хисләрен җыйнап алмаган Лиза, төшенеп бетмичә:

– Нинди Роман? – дип сорады.

– Соң, ике ел элек ресторанда теге Захарчукны акылга утырткан Роман инде. Ул да судья, ахры. Альмира, таныйсыңмы?

– Ул чакта кемне дә булса хәтерләп калырлык хәлдә идеммени? Шуны гына беләм, нindидер пәһлеван гәүдәле ир заты мине кардан күтәреп алган иде.

– Әнә ул баһадир, шул бит инде. Хәзер мин аны үзебезнең янга чакырам!

– Юк, юк, кирәкми, оялам мин аннан. Ничектер уңайсыз! – дип межелдәде Әлмирә.

– Өченче курста укыйсың түгелме соң инде?! Һаман шул бер җебегән кыз үзең! Роман Мартыниянович, Роман! – дип кычкырды ул, кеше тавышларын басарга тырышып. Ишетте, ахры, егет тавыш кайдан килә икән дип, як-якка карана башлады.

– Роман Мартыниянович, без биредә, биредә, – дип, Валентина кул болгады. Әкияттәге рус баһадирлары кебек олпат гәүдәле ир урыннан торып, алар ягына атлады.

– О-о, Валентина Валерьевна, сезне күрүемә бик шат, бәйрәм белән барчагызны да, чибәркәйләр! – дип сәламләде. Әлмирә ялгышмаган икән, гәүдәгә пәһлевандай булса да, егетебезнең тавышы чыннан да ягымлы иде. – Кадерлеләрем, сезнең белән рәхәтләнеп бер кафега кереп гәпләшеп утырыр идем, бүген мин судья әле биредә. Сезне очратуыма бик шат, ләкин...

– Ә син тагын безнең арадан кемне булса да таныйсыңмы соң? – диде Валя.

Егет Лиза белән Әлмирәгә күз атты.

– Зинһар, гафу итегез, Валентина Валерьевна! Һич кенә дә танымыйм! Әллә безнең чынлап та элегрәк очрашканыбыз бар идеме? – дип гаҗәпләнде егет.

– Ике ел элек... «Балтика» рестораны... Бер кызга бер адәм заты бәйләнгән иде.

– Нәрсәдер булган иде шикелле...

– Безнең дустыбызга бәйләнгән Захарчукны якасыннан тотып, кар өеменә бәргән идең...

– Әйе, әйе! Нәрсәдер килеп чыккан иде шул. Ул кыз да биредәме әллә?

– Әйе! Тик менә үзең танырсың микән?

– Йәле, йәле, әйбәтләбрәк карыйм әле, – дип, кызларга күз салды. – Ни кызганыч, хәтерләмим, гафу итегез! Шул арада гына каян хәтерләп бетерәсең инде.

– Менә ул кыз, безнең Әлмирә! – дип төртеп күрсәтте Валя. Егет төбәлеп, аңа карады да әллә нишләп китте. Бәлкем, чибәр кызның шомырт кара күзләре гипнозлы тәэсир иткәндер... Ниндидер эчке тетрәнү кичерде ул. Кызның күзләреннән карашын ала алмыйча торды.

– Рома, Рома, дим, таныдыңмы инде? Рома!

– Нишләдеңме?

– Таныдыңмы, дим?

– Таныдым кебек! Ләкин шундый чибәр кыз дип, күз алдына да китерә алмас идем. Сез искитмәле чибәр икән! Гаҗәеп матурлык!

– Әле ул тәртипле, тәрбияле дә! – дип өстәп куйды үткен Валентина.

Әлмирә, уңайсызланып, Лизаның артына поса барды. Валя бу хәлне күреп:

– Нишләп котың очты, өркәк тавык, бу бит җен-пәри түгел, нибары Роман Мартыниянович кына! Исең китмәсен, Рома, татаркалар шундый тыйнак булалар икән! Коты очты рус баһадирын күреп.

Ул да түгел, тавыш көчәйткечтән:

– Балахолкин Роман Мартыниянович, сез судьялар өстәленә чакырыласыз! – дигән әмер яңгырады. Егет бернидән дә оялып тора белмәгән Валя белән сәерсенеп карап торган Лизага:

– Миңа китәргә вакыт, гафу итегез! – дип баш иде дә Әлмирәгә тутырып бакты. Хәзер инде ул баягы кыю гына кызлар янына чыккан тәвәккәл ир заты түгел иде. Ничектер уңайсызланып, хәтта күпмедер дәрәҗәдә каушап калган тәҗрибәсез егетне хәтерләтте. Менә ул күзләрен Әлмирәгә төбәгән килеш артка чигенде дә бөтен кыюлыгын җыеп: «Кызлар, әйдәгез, ярыштан соң берәр җиргә кереп сөйләшеп утырабыз!» – дип тәкъдим ясады.

– Яхшы, сөйләштек, – диде Валя, авызын ерып.

– Нәрсә булды соң аңа? – дип сораган булды Лиза.

– Нәрсә булсын, гыйшкы парализовать итте.

– Альмирагамы?

– Сиңа түгел инде, әлбәттә! – дип куйды Валя.

– Менә сиңа мә! Көйдердең бит егет кисәген! – дип, дусты Лиза Әлмирәне кочып алды. Тик чибәркәй генә оятыннан кып-кызыл булган иде.

***

Алевтина Ивановна Балахолкина улы Романны алты яшеннән берүзе генә карап үстерде. Ире Мартын бик тырыш, көчле кеше иде. Ләкин ул үзенең гайрәте белән беркайчан да масаеп, өстенлеген күрсәтеп йөрмәде. Әлбәттә инде, якыннарына, дус-ишләренә янасалар, шундук зимагур бәндәләрне урынына куя, сүз белән генә аңламасалар, корыч кебек куллары белән эләктереп алып, башларын чәкештерә торган булган. Шулай бервакыт кичкырын Алевтинасы белән су буйларында йөреп кайтырга дип чыксалар, боларга эчеп алган алты матрос килеп бәйләнә. «О, карагыз әле нинди ындыр табагы кебек арт сан, бөтен ротага җитәрлек»! – дип, берсе кабахәтләнә башлый. Башкалары хихылдап көлешәләр, икенче бер тинтәге яннан килеп, хатынның күпереп торган җиренә үрелә. «Нишлисез, оятсызлар, совет солдатлары түгелме соң сез?!» – дип кычкырып җибәрә Алевтина, рәнҗеп. Шунда Мартыниянның түземлеге бетә. Теге мөртәтне сугып аудара да, аякларыннан тотып, баш очында әйләндереп, мәнсез диңгезчеләрнең өстенә ыргыта. Тагын өчесе җиргә ава, берәм-берәм барысын да дөмбәсләп чыккач, канга баткан кулларын кулъяулыгына сөртеп: «Сез мөртәтләрдән беркайчан да совет солдаты чыкмаячак!» – дип, өсләренә төкереп кайтып китә. Халык әле дә сагынып сөйли аның турында. «Чын кеше иде ул, гадел, намуслы иде!» – дип искә алалар. Андый тәртипле, тәрбияле кеше Аллаһы Тәгаләгә дә кирәк, дигәндәй, бу дөньядан бик яшьли китеп бара ул. Метро төзүчеләр бригадиры буларак, шахта тишеп, алга барганда, өсләренә җир җимерелеп төшә. Иң алда баручы пәһлеван әнә шулай туфрак астында калып һәлак була. Аны озатырга ярты шәһәр чыккан иде, дип сөйлиләр.

Роман алты яшендә этисез кала. Иң кадерле кешесен югалткан Алевтина

бөтен мәхәббәтен улына багышлый. Ни сораса, шуны алып бирергә тырыша, эштән соң сабыен ияртеп бассейнга, икенче көнне шахматчылар түгәрәгенә, хәтта драмтүгәрәккә дә йөртә. Улы атасы кебек зур гәүдәле булып үсә. Тик андый килбәт бассейнда яхшы урыннар алырга гына комачаулады. Шахмат түгәрәгенә дә күпме генә йөрмәсен, беренче разрядтан ары күтәрелмәде. Драмтүгәрәктә дә аның янында иптәшләре лилипут булып күренә иде. Ләкин арада бик талантлылары да булып, осталык ягыннан пәһлеванны уздыралар иде; шуңа карамастан Роман беркемнән дә көнләшмәде, ничек бар шулай кабул итте. Бишенче класста укыганда, малай волейбол белән мавыгып китә. Унсигез яшендә, «Динамо» командасының капитанына әйләнә. Әнисе улының уңышларын күреп: «Нәкъ әтисе инде, балакаем, үзе гадел, үзе мәрхәмәтле, үзе көчле!» дип горурланып яши. Әлмирәне дә киң күңеллеге, игелеклелеге белән үзенә җәлеп иткәндер Роман.

***

Көзге спартакиада уеннарыннан соң Роман кызлар яшәгән тулай торакка еш килә башлады. Әйтерсең, ниндидер билгесез магнит тартып китерә торды аны бирегә. Әлмирәне күргән саен ул халәте көчәйгәннән-көчәя барды. Тора-бара кызны күрмичә бер генә көн дә яши алмый башлады. Кыз исә, егет дус итеп кенә киногa чакырса да, барды, театрга да каршы килмәде. Тулай торакка килгән саен пирожныен, тортын, конфетын күтәреп керә, гел-гел булмаса да, чәчәк букетларына да тиеннәрен кызганмый. Бер мәлне Әлмирә аңа: «Зинһар, шулкадәр расходланмагыз инде, миңа бик уңайсыз, Роман!» – дип әйтергә мәҗбүр булды. Егет: «Мин синең өчен гомеремне бирергә дә риза, Әлмирә! Чөнки мин сине яратам!» – димәсенме. Кыз бер мәлгә телсез калды. Үзен шулай өзелеп сөйгән егеткә: «Мин сезне яратмаячакмын, Роман!» – дип әйтергә көч таба алмады. Аның күңелендә барыбер Исрафил абыйсына булган хисләре сүнеп бетмәгән иде. Шулай да мәрхәмәтле дустын рәнҗетмәс өчен дөресен әйтеп, йөрәген яраламаска булды. Ә көннәрнең берендә теге билгесез адәмнән тагын хат килеп төшмәсенме. «Синең Исрафилең Кавказда, чеченнарга каршы сугышып йөргәндә, медсестрага өйләнгән. Сугыштан кайткач, хөкүмәт Мәскәүдән өч бүлмәле фатир бирәчәк икән», дип язылган иде хәтта.

Әлмирә шунда гына Исрафил абыйсын мәңгегә югалтканлыгын аңлап, һушыннан язар дәрәҗәгә җитте. Лиза бүлмәдәше аны күреп, уңлап-суллап, яңагына суккач кына, кычкырып елый башлады.

– Нишлисең, дустым, чиргә сабышасың киләме әллә? Беткән ди сиңа ир, шундый чибәрлегең белән! Әнә Роман үлеп ярата үзеңне! Менә дигән ир заты, тот та кияүгә чык, өч бүлмәле сталинкалары, шәһәр кырында бакчалары. Балалар тап та тик ят рәхәтләнеп, ул синең өчен барысын да эшләячәк! Их, Аслан да мине шулай яратсамы, нинди бәхетле булыр идем мин! Кайтып киткәненә өч ай инде, үзен бер күрергә тилмереп яшим. Тиздән Ходайның бер рәхмәте, юанычым булачак, аның төсе итеп үстерәчәкмен! – дип, кабарып торган корсагын сыйпаштырып куйды.

Әлмирә әллә ишетте, әллә ишетсә дә, үгет-нәсыйхәтләрен аңламады, тагын да үртәлебрәк елап җибәрде. Лиза караватыннан торып, иптәшенең янына килде, кырыена утырып, бөдрә чәчләреннән сыйпады.

– Булды, булды, матурым, тынычлан. Барысы да үтә дә китә! Бетермә үзеңне!

– Әгәр Роман килсә, зинһар чыгып әйт әле, беркая да бармый, башы авырта, дарулар эчеп йокларга ятты, диярсең.

– Аңладым, Әлмирә! Сиңа, чыннан да, үз-үзеңне кулга алырга, тынычланырга кирәк! Үтә ул, борчылма!

***

Өзгәләнде Роман, атна буе интекте. Ни булды икән Әлмирә белән? Әллә сөйгән егете бармы? Шулай булып чыкса, ничек яшәргә кирәк?Ниләр генә уйлап бетермәде гашыйк егет. Инде түземлеге беткәч, бердәнбер сердәше әнисенә ачылырга кирәк дип тапты.

– Әйтәм, улым, саргаеп киттең, чирләдеңме дип, котым очып йөргән иде. Ходайның биргәненә шөкер, яшьлек мавыгуы гына икән. Үтәр ул, кем башыннан үтмәгән андый хәл!

– Үтми, әнкәй, үтми, әгәр дә мин Әлмирәне югалтсам, яшәвемнең мәгънәсе калмый, аңла шуны!

– Ни сөйлисең, җүнсез, әтиең утыз яшендә безне ташлап китте, инде син дә кирәкмәгән гөнаһлы сүзләр сөйлисең. Минем бит яшәвемнең мәгънәсе син, анаң барлыгын да оныттың. Нинди җен кызы сихерләде соң үзеңне?

– Татар кызы ул!

– Татар кызы! Йа Аллам! Басурманкамы? Әллә тилердең инде, балам?

– Әгәр дә ул минеке булмаса, йә тилерәм, йә асылынып үләм! Юк миңа ансыз яшәү!

– Булды, булды, улым, тынычлан! Яхшы, син аны өйгә кунакка чакыр әле, күрәсем килә, шул хур кызыңны! – диде ана кеше, ә үзе эченнән генә: «Сихерләгәннәр моны, башына җитәчәкләр нindидер монголоидлар. Алар сихер-михергә, ырым-шырымга хирыс була, дип сөйлиләр. Ничек матур гына яшәп ятканда!», – дип уйлады.

– Яхшы, әнкәй, мин аны кунакка чакырып карармын. Тик ул инде ни сәбәпледер бер атна минем белән очрашырга теләми!

– Менә ничек? – дигәч, Алевтина Ивановна тагын үзенчә фикер йөртте. «Димәк, сихер көче ныграк тәэсир итсен өчен юри Романны янына якын җибәрми! Кыздыра!»

– Сез аның белән бергә булмагансыздыр бит?

– Нинди булу, әни? Аның кебек тәрбияле, акыллы кыз Ленинградында юк.

– Ә минем подругам Варвара Тимофеевнаның бердәнбер Татьянасы кемнән ким? Элек каршы түгел идең кебек. Кунакка да баргаладың, Таня да, миңа калса, сиңа битараф түгел?

– Сине үпкәләтмәс өчен генә йөрдем аларга! Безнең арада бернинди хисләр юк, әнкәй!

– Алай димә, улым! Мин тиз генә Татьяна белән сөйләшәм дә... Бергә кавышсагыз, Монголияң дә, татаркаң да онытылыр! Сиңа битараф кыз түгел ул!

– Әгәр дә тагын бер миңа шул Варвара түтәй кызын көчләп тагасың икән, бүген үк өйдән чыгып китәм!

– Яхшы, яхшы, улым! Таня читтә калсын. Ә теге әтиеңнең дусты Антон дәдәңнең Ульянасы ничек соң?

– Миңа Альмирадан гайре беркем дә кирәкми. Мөселман булса ни дә, католик булса ни? Мин комсомол секретаре, дин минем өчен бернәрсә түгел! Синең чиркәүгә йөрүең икебез өчен дә бик җиткән!

– Ярый, ярый, улым, тынычлан, мин каршы түгел. Башта үзен күреп сөйләшик әле, шулай бит!

– Дөрес, әнкәй! Дөрес! – дип, гашыйк егетнең чырае яктырып китте. – Син дә мине аңламасаң, кем генә хәлемә керер икән соң? – дип, фил хәтле ир әнисенең күкрәгенә сабый баладай барып сыенды. Ярата иде ул анасын, бар нәрсәдән дә күбрәк ярата кебек иде. Үзен якты дөньяга тудырган кешедән дә ныграк сөйгән кеше дә килеп чыгар дип, башына да китермәгән иде.

– Ярый, улым, кунакка чакыр, уйлашырбыз!

– Рәхмәт, әнкәй!

* * *

Каникулында да кайтмаган сеңлесе өчен борчылып, көннәрдән бер көнне Ленинградка, көтмәгәндә, Әхмәт абыйсы үзе килеп төште. Кызның агарып калган чыраен күреп: «Берәр хәл булмагандыр бит?» – дип борчылып сорады. «Исрафил абый медсестрага өйләнгән икән бит!» – дип чак кына ычкындырмады Әлмирә, шулай да телен тешләп калды.

– Юк, абый, барысы да элеккечә, эшкә кердем, ардыра! – дип акланды.

– Соң кем кушкан сиңа, сеңлем, ялында да Казанга кайтмыйча эшләп йөрергә?! Дәү әни сине бер күрергә тилмереп ята! Әти-әни саргая, ташла эшеңне, менә сиңа 100 сум акча, барыбыз бергә җыеп, ай саен тагын 50 сум җибәреп торырга сөйләштек. Ташла бүген үк! Аллага шөкер, мин эшләп торам, шабашкалары да була, карап торып, сине интектереп ятмабыз! Нинди эш соң ул синең?

– Туңдырма сатам!

– Кыш көнеме?

– Әйе!

– Әйдә, хәзер үк барабыз да эштән китәргә гариза язабыз. Каникулың бетәргә бер атна калды. Кайтып дәү әниеңне күреп кит, соңгы айларда нык биреште ул! Көн саен кайтмадымы дип, сине сораша! Һич булмаса, шалтыратып ал инде... Хәлен бел!

* * *

Роман гүзәл Әлмирәнең эшеннән китеп, абыйсы Әхмәт белән Татарстанга кайтып киткәнен Елизаветадан ишетеп белде. «Димәк, Казанда сөйгән яры бар, аның белән күрешергә дип ашкынган. Атна буена минем белән күрешүдән качып йөрде, ничек яшәргә соң хәзер миңа, ничек?

– Лиза, әйт әле дөресен, Әлмирәнең берәр кешесе бармы?

– Әйтә алмыйм. Белмим, – дип, кыз күзләрен читкә алды.

– Нишләп яшерәсең, әйт дөресен?! – дип төсе киткән пәһлеван рәнҗеп, аңа карады. Кайчандыр үзе дә чын ярату хисләре кичергән, шуның утларында янып-көеп яшәгән Елизаветага каршысында Роман кызганыч иде.

– Тик, зинһар, үзенә җиткерә күрмә! Ни бит... Аның яраткан кешесе икенче берәүгә өйләнгән, кәефе юк, нык борчылып, чирләп ятты, тулай тораксан да чыкмыйча!

– Чынлапмы, Елизавета матурым?

– Әйе! Фортуна үз кулыңда, ычкындырма, бүтән андый намуслы, тәртипле затны мәңге таба алмаячаксың, аяк асларында туфрак бул, әгәр чынлап торып яратасың икән, – дигәч, көмәнле кыз бүксәсен сыйпап куйды. Егетнең эченә җылы йөгереп, кәефе күтәрелеп китте.

– Лиза, матурым, сиңа берәр нәрсә кирәкмиме соң, күреп торам, йөкле икәнсең, – дип сорады ул, күзләреннән шатлык очкыннары чәчеп.

– Уңайсыз инде... Ни сәбәпледер, болгар борычы ашыйсым килә... Кызылын! Улым Аслан сорый...

– Ә кыз булса?

– Зөлфия дип кушачакмын.

– Яхшы, яхшы, матурым! Бөтен Ленинград каласын, таныш-белешләремне кубарам, сиңа болгар борычы табып бирмәсәмме? Тулай торагында гына бул! – диде дә, күңеле күтәренке Роман чыгып йөгерде.

Тагын өч сәгатьтән егет, тирләп-пешеп, азык-төлек сеткасына кызыл, сары, яшел төстәге нигъмәтләр тутырып кайтып керде.

– Булды, Лизочка, менә! Көчкә таптым! Иптәш малайның әтисе диңгез портында эшли, шуннан юнәттем.

– Тирләп-пешкәнсең бит инде, Ромочка, рәхмәт инде, үзеңә! Ой, әнә улым Аслан да рәхмәт Роман абыйга, дип тибенә.

– Ну, молодец! – дип, егет көлеп җибәрде.

– Син өстеңне сал, хәзер чәй куеп җибәрәм!

– Мин бит чәй янына бернәрсә дә алмаган идем, гафу ит!

– Борчылма, миндә чәй эчәрлек кенә кабымлыклар бар! Күренеп тора, чын кавказлы инде. Башта өрек-күрәгә, йөзем сорап йөдәтте. Аннан шурпа... Менә хәзер кызыл борыч… Тора-бара шашлык-машлык сораячагын, аннан лезгинка биегәнен көт тә тор! Бездәгеләре бит тозлы кыяр, тозлы кәбестәгә дә разый, ә моңа деликатес китер! Йа Ходам, әнә тагын тибенеп алды, чынлап малай була бу! Хәзер, улым, хәзер борычны юып керәм! Син, Рома, утырып тор, мин хәзер, – дип, әрсез кыз чәйнекне алып чыгып китте. Егет сөйгәне Әлмирә ята торган тимер карават янына килде. Ятакның баш ягындагы күтәртмәсендә кызның яшел төстәге яулыгы эленеп тора иде. Ул аны җайлап кына кулына алды, назлап сыйпады, шуннан битенә якын китереп иснәде. «Ты божественная, любимая!» – дигәч, күз яшьләре атылып чыгып, шәлгә сеңделәр. Исерде гашыйк егет кадерле кешесенең серле исеннән. Яулыктан ислемай исенә кушылып сеңгән,ул аңлап бетермәгән хуш исләр да килә иде.

– Ой, гафу итегез, борычымны алып чыгып юарга онытып калдырганмын! – дип, Лиза кире килеп керде. Егет уңайсызланып, үзе өчен бик кадерле булган яулыкны кире урынына куйды.

Тагын ярты сәгатьтән алар чәй өстәле янында ачыктан-ачык гәпләшеп утыралар иде инде.

– Бик тәртипле, бер гөнаһсыз чибәр кыз ул! Шау-шулы җирләргә йөрергә яратмый. Көне-төне укый, гел «бишле»ләр генә ала. Килеп, сүз катып караучыларны кире озатып кына тора. Теге юлы Захарчук та

иптәшенә: «Мин ул кызны ятагыма салмасам, кушаматым Хохол булмасын! – дип бәхәскә кергән булган, затлы костюмын бәхәскә куйган. Соңыннан Әлмирәне буйсындыра алмагач, көчләп, кунакханәгә алып китмәкче була, дуамал баш!

– Дөмектерәм мин аны, – диде, олпат гәүдәле ир урыныннан торып, көрәктәй кулын йодрыклады.

– Син утыр, кызма, ул инде институтны тәмамлап кайтып китте Харьковына!

– Шулай яшь-яшь кызга көч кулланып маташырга кемнең хакы бар, Лиза?

– Шулай, шулай, Рома, бик дөрес әйтәсең! Бөтен кеше дә синең кебек мәрхәмәтле түгел шул! Ә дустымның күңеле саф, ихлас. Чын күңелдән әйтәм, өченче ел инде бергә яшәмәсәк, татарларның кемлеген дә белмичә үлә идем.

– Искиткеч ул! Лиза, ә үзеңнең ирең кем соң? Урынсыз сорау биргән булсам, гафу ит!

– Әти дигән кешебезнең Кавказда ярәшкән кызы бар иде. Алар әйтмешли: «Вәгъдә – иман!» Ярамый вәгъдәнә хыянәт итәргә. Иттеңме, әлеге ыру белән кан дошманга әвереләсең, алар өчен зур хурлык, мәсхәрә санала. Ләкин мин барыбер яраткан кешемнеке булдым, улымны да аның төсе итеп үстерәчәкмен, – дигәч, рәнҗеп, күңеле тулган кыз куллары белән битен каплап, үксеп елап җибәрде.

– Тынычлан, тынычлан, матурым, барысы да уңайланыр әле!

– Әти белән әни, туганнар: «Беткән булгандыр инде сиңа рус өммәте, дип сүгәләр, абортка бармасаң, күзебезгә күренмә, антихристың белән чәнчелеп кит», – диләр, Рома! Ярый әле бәхетемә Валентина Валерьевна бар! «Үземә күч, мин барыбер өйдә сирәк булам, кирәк чакта балаңны да карашырмын!» – ди. Каян бала тәрбияли алсын инде ул, аның үзен карарга кеше кирәк! Ашарына да пешереп ашый белми бит, барган саен Әлмирә белән тау кадәр өелгән савыт-сабаларын юып, өен җыештырып кайтабыз! Ашамлыкларны да заказ биреп кенә китертә. Күпме акчасын әрәмгә түгә, тоже миңа аристократ, патша кызымыни, кыланмышларын карап торсаң! Ә үзе шуның кадәр юмарт, кешелекле, һәрчак икебезгә ярдәм итеп яши.

– Беләм, Валентина Валерьевна шулай ул! – дип, Роман кызның сүзен җөпләде. Аның кабат-кабат Әлмирә турында ишетәсе килә иде.

– Аннан тагын безнең Ленинград блокадасын кичергән Вера түтәй Андреевна бар! Минем хәлләрне ишетеп белгән дә, бездә вахтада утыра ул, Әлмирәгә әйткән:

– Ул баланы урамда калдырмыйм, укып кына бетерсен! Сабыен да, ул белем алганда, үзем карап торырмын, – дигән.

– Елизавета, матурым, без дә сезне ташламабыз, борчылма! Гафу ит! Әлмирә нәрсәләр ярата соң? Кино-театрларга мөнәсәбәте ничек?

– Шау-шулы җирләргә, гомумән, йөрергә теләми, кафе-рестораннарга аяк та атламый. Соңгы тапкыр Мөслим Магомаев концертына көчкә алып бардык. Билетларын Валя юнәткән иде. Ярты көн үгетләгәч кенә: «Мөслим абыйның әбисе татар, шуның хөрмәтенә булса да барыйк инде алайса!» – диде. Русча-азәрбайҗанча җырларын, бигрәк тә «Королева красоты» дигәнен исе китеп тыңлады. Тик шулай да тулай торакка

кайтканда: «Әбисе хөрмәтенә бер татарча җыр башкарса да буладыр иде бит!» – дип үпкәләде.

– Алайса мин «Королева красоты» җырын өйрәнеп, аңа башкарам. Тренер: «Тавышың матур, чиркәү хорына йөрсәң дә була!» – дип шаярта, – дигәч, кеткелдәшеп алдылар.

– Әле без үзебез дә Әлмирә белән бер татар җырын өйрәндек. Сүзләрен дөрес итеп әйтергә бик кыен. Алар алфавитында «у», «а» урынына йомшак итеп әйтелә торган «ә» белән «ү» дә бар, шуңа күрә сөйләмнәре назлы, үзе әйтмешли, моңлы яңгырый.

– Лиза, өйрәт әле миңа да шул җырны!

– Кая инде миңа өйрәтергә, үзеннән сорарсың! Бигрәк тә татар җырын!

– Үтенәм. Ялварам, ул кайтканчы бераз өйрәнеп куясы иде.

– Мин бит ике юлын гына беләм, Рома!

– Булсын! Әлегә шул ике юлы булса да ярап куяр!

– Ладно! Мәгънәсе болай: Я тебя люблю, я тебя люблю, я тебя все равно полюбить заставлю! Якынча шулайрак, Рома! Ә татарчасы болайрак: «Мин сине яратам, мин сине яратам, мин сине барыбер үземә каратам!»

– Нинди матур көй! Өйрәт әле, Лиза! Ә мин сиңа шуның өчен Аслан ни сораса, шуны табып китерәм!

– Кит инде, шуның өченме! Борычларың өчен дә бик зур рәхмәт! Башладык алайса! Мин сине яратам!

«Мин сине яратам, мин сине яратам, мин сине барыбер үземә каратам!» дигән сүзләр тулай торак бүлмәсендә шактый яңгырап торды.

***

Әлмирә кышкы каникуллардан соң Ленинградка кайтып төште. Борынгы фин-угыр җирләре төксе генә каршы алды дисәк тә, дөрес булыр. Кар өстендә аунап яткан чүп-чар, дөньяны соры төскә кертеп, каралтып тора. Кызның үзенең дә күңеле нурсыз. Туган шәһәренә кайтса, хәле начарланып китү сәбәпле, дәү әнисен кыш чыгарга шәһәргә алып килгәннәр. Элегрәк Әлмирәне генә юксынып яшәсә, хәзер Таллы Күлен дә нык сагына икән дәү әнисе! Көн саен диярлек авыл карчыклары, ахирәтләре Фатыйма, Гарифә, Гайнекамаллар белән чәйгә йөрешкәннәрен искә ала. Күрше-күләнгә таратып калдырган тавыкларының үлән арасыннан җим эзләп кеткелдәп җырлап йөрүләрен искә төшереп: «Кеше акыллары бар иде бит аларда. Ак тавыгым Энҗе, алдыма ук менеп утыра иде. Шуны күреп, әтәчем Чуаркай канәгатьсезләнеп кыткылдап ала, килеп, галош очларын чукый. «Кил, үзеңне дә икенче теземә утыртам!» – дигәч, нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, тагын бер кыткылдагач, тавыклары янына китеп бара.

«Шаккатмалы хәлләр инде!» – дип, авылын сагынып искә алып ятты дәү әнисе. Бирешкән иде кадерле кешесе, күзгә күренеп картайган иде. Бите суырылып калган, күз карашлары тоныкланган, хәлсезлек төсмерләре иңгән. Кайгы-хәсрәт күрмичә үскән кыз өчен зур тетрәнү булды бу хәл!

Менә шул борчылулары белән кайтып төште ул Ленинградка. Вагоннан чыкса, каршысында иптәш кызы Лиза басып тора.

– Син ничек биредә? – дип гаҗәпләнде Әлмирә.

– Сине каршы алырга килдек! – диде иптәш кызы, нидәндер

уңайсызланып. Күтәрелеп караса, Елизаветадан читтәрәк, елмаеп, Роман басып тора иде. Кыз аптырап куйды. Аннан: «Менә ни өчен Лиза кайчан кайтасың, нинди поезд, кайсы вагон, дип төпченгән икән!»

Шул арада Роман студент кызның чемоданын үзенә алды.

***

Соңгы айларда Роман көн аралаш диярлек Әлмирәләргә йә бер кап конфет, йә торт күтәреп килә, йә кинога, шимбә-якшәмбеләрдә яңа премьераларга чакыра, спектакльләргә алып китә башлады. Бүлмәдәше Лиза да: «Үлеп ярата ул сине! Егете дә шәп бит, эчми-тартмый, тәрбияле, тәртипле, өстәвенә, спортчы»! – дип мактап тора. Анысы дөрес инде. Роман беркайчан да бер кеше белән дә дорфа сөйләшми, кызга игътибарлы булып, бер алдына, бер артына төшеп торды. Өрмәгән җиргә дә утыртмады. «Алай бик зурламагыз инде, мин бит хан кызы түгел», – дип уңайсызланса: «Син – минем ханым да, солтаным да!» – дип шаяртты.

Май башында Әлмирә дәү әнисен җирләп килде. Роман күңел төшенкелегенә, депрессиягә бирелеп, авыр тойгылар кичергән сөйгәнен көн саен килеп юатты, кайгысын уртаклашты. Кызның да егеткә булган хөрмәте арткannан-арта барды. Шуның белән беррәттән элек кинофильмнардан гына карап белгән мафия, клан, җинаятьчел төркемнәр Россия халкының тормышына килеп керде. Әле анда, әле монда үтерешәләр, зәһәр егетләр көтүе мал бүлешә, андый бүлешләр урыны-урыны белән үтереш, канлы атышларга әверелә. Завод-фабрикалар ябылып, эшсез калган яшьләр төрле җинаятьчел төркемнәргә керергә мәҗбүр булды. Россиянең икенче башкаласы саналган Ленинград та әлеге болганышлардан читтә калмады. Хәзер төнлә шәһәр урамнарына чыгып йөрүләре тагын да куркыныч. Ярый әле, Әлмирәнең янында Илья Муромец кебек баһадир гәүдәле Роман бар, ул аның белән йөргәндә, беркемнән дә шүрләми. Чөнки бандитлар аннан курыкмасалар да, хөрмәт итәләр иде. Кыз үзенең тән сакчысына шулкадәр ияләшеп китте. Егет берәр җиргә ярышка китеп, юкка чыгып торса, юксына башлый, иптәш кызына сиздермәскә тырышып, бик еш кына тәрәзәгә күз салгалый. Спортчы егетнең туган шәһәренә кайтуы була, кулына букет тотып, килеп тә җитә. Шундый мизгелләрне сагынып көтеп йөргән кыз янына бермәлне озак кына югалып торган, исем-фамилиясен русныкына алыштырган Николай Нәсихович килеп чыкты. Гадәттәгечә, пөхтә киенгән, чалбарындагы сызыгы да ялгыш кагылсаң, бармагыңны кисеп алырдай тоела. Ялтырап торган лаклы кара ботинка, ак күлмәк кигән, якасына зәңгәрсу галстук таккан. Ләкин күпме генә тырышса да, сүзләре ябышып китмәде.

«Казанга кайтканың бармы?» «Имтиханнарга әзерләнәсеңме?» «Әйе», «Юк!» дигән кыска диалоглардан торды әңгәмәләре. Кыз аның белән татарча сөйләшергә тырышса, өркәк егет кисәгебез үзенең рус арасында яшәгәнлеген истә тотып, аларча гына гәпләште. Үзе тагын нәрсәдер әйтергә дә маташа, әллә берәр җиргә кино-фәләнгә алып барырга нияте бармы, тутырып кына әйтергә йөрәге җитми. Авызыннан берәр тәкъдим чыгар бәлки дип көткәндә, ишекне киң ачып, кулына чәчәк букеты тоткан Роман килеп керде. Кыз янында икенче берәүнең утырганын күреп, чыраендагы елмаю качты.

– Исәнмесез! – дип куйды ул дорфа гына, бу кем соң, дигәндәй.
– Якташым Николай Нәсихович, дүртенче курста укый.
– Бик әйбәт! – дип куйды спортчы егет, көнләшүен сиздермәскә тырышып.
– Мин икенче юлы яме, соңыннан сөйләшербез, – дип, Николай шундук бүлмәдән чыгып сызды.
– Вакыт-вакыт якташ буларак хәл белергә кергәли ул шулай! – дип акланды Әлмирә.

***

– Мин яратам аны, әнкәй, ансыз мәңге торалмыйм!
– Нигә алайса, өйгә алып килмәдең, таныштырмадың?!
– Башта проблемалары булды, әбисен җирләде, шул кайгысын авыр кичерде. Хәзер әниеңнең күзенә күренергә оялам, ни сәбәп табып, сезгә барыйм, ди. Киләчәк ул, әнкәй, менә күрерсең. Бераз иялəшә төшсен!
– Сине чыннан да яратса, күптән килгән булыр иде инде, – дип, ирония белән әйтеп куйды Алевтина Ивановна.
– Киләчәк ул, менә күрерсең! Сиңа да ошаячак ул, әнкәй, – дип, егет эшне җайларга тырышты.
– Улым, беткәнмени сиңа үзебезнең чын рус кызы. Әллә каян, даладан килгән кыргый, ат исе килеп торган нәрсәгә күзең төшмәсә?
– Нинди дала, нинди ат исе, Алевтина Ивановна?! Ул бит институтта да «бишле»гә генә укый.
– Теге бергә эшләгән подругам Варвараның бердәнбер кызы Танянын кай җире ким? Үзебезнең кавем, үзебезнең тел, гореф-гадәт, өч бүлмәле фатирлары, өч сутый бакчалары, әтисенең «Москвич» машинасы бар!
– Кирәкми миңа ул кыз! Өстәвенә, бик иркә, үзен әллә кемгә саный!
– Булсын-булсын, улым, зато үзебезнеке!
– Юк, әни, минем үлеп-бетеп яраткан кешем бар!
– Юк, юк минем ризалыгым! Төн йокыларымны калдырып, ике-өч эштә эшләп, шуның өчен үстердеммени мин сине?! Нindидер даладан, Монголиядән килгән нәмәстә бердәнбер улыңа хуҗа булсын әле!
– Әнкәй, юкны сөйлисең бит, ул әле сиңа үз кызың кебек якын булачак. Син бит, әни, белмисең генә...
– Беләсем дә, күрәсем дә килми. Әтиең исән булса, күрсәтер иде сиңа күрмәгәнеңне!
– Ул исән булса аңлар иде хәлемне!
– Йа Хода, нинди хәлләргә калдырдың син мине, олыгаймыш көнемдә?! – дип, Алевтина елап җибәрде. Үзе: «Мәңге хәер-фатихам юк сезгә!» – дип сөйләнде.

***

Сизми дә калды Әлмирә ничек итеп, Романга кияүгә чыкканын. Егетнең әнисе бу никахка аяк терәп каршы торганлыктан, кызныкылар да шатлык хисләре кичермәячәген аңлагач, кушылуның шаһитлары бары тик Валя белән Лиза, Романның тренеры Андриянов һәм тагын ике дусты Артём белән Алексей гына булдылар. Бәхетле парларга остазы спорт мәктәбенең

тулай торагыннан бүлмә алып бирде. Өйләнешүләренең өченче елында гына Казаннан Әхмәт абыйсы килеп, туганнары җибәргән күчтәнәчләрне тапшырды. Әллә ни сөенмәсә-көенмәсә дә: «Үзең тапкан карта, аша тарта-тарта!» – дип куйды. Эчендә нинди утлар янганын сиздермәде, Әхмәт белән Рома тиз арада уртак тел табып, аралашып, дуслашып киттеләр. Өстәвенә, өчәүләшеп, футбол карарга да, кино-театрларга да йөрделәр. Кичләрен абыйсы белән ире вакытларын коньяк эчеп, шахмат уйнап үткәрделәр. Киткәндә ул: «Ике якны да хөрмәт итегез, әйбәт яшәгез!» – дип саубуллашты. Кая бара алсын инде ул, риза булмыйча.

– Абый, зинһар, кайтып, әти-әнигә начар сүз әйтә күрмә. Барысы да әйбәт диген!

– Борчылма, сеңлем! Тик сез кайтып күренгәләп китегез үзегез дә. Роман болай начар кешегә охшамаган!

– Яхшы, абый. Бераз тормышлар җайлангач әйләнеп чыгарбыз! – дип, кадерле кунагын озатып калды Әлмирә. Ул күңеленнән: «Кичерерләрме, кабул итәрләр микән якыннары? Әхмәт абыйсы ризалашты кебек бит», – дип борчылды. Ул да түгел, карынындагы нарасые тибеп куйды. «Алла, улым!»

Әлмирә Валяның фатирында Асланны үстереп ятучы дусты Лизага шалтыратты. «Беләсеңме, дустым, ул беренче тапкыр китереп типте!» Иптәше шаккатып: «Ромамы?» – дип сорады.

– Юк инде, юк! Туачак улым, улым тибенә! Нәрсә кирәк икән аңа?

– Бәлкем берәр нәрсә ашыйсың киләдер?

– Тозлы помидор сорый күңел, бәлкем шулдыр, – дип киңәшләште Әлмирә.

– Шулдыр! Хәзер үк җыен да Валяларга кил! Әле яңа гына әтинең энесе килеп китте. Тозлы кыяр, помидор, сало кертте. Мине кичермәсәләр дә, әниләр, кереп хәлен белеп чык, дип җибәргәннәрдер, күрәсең. Баланың әтисе килеп күренәме соң, дип тә төпченде. Килә, минәйтәм, аралар ерак булу сәбәпле, айга бер-ике генә күренә, – дип ялганладым. – Әти-әниләр улым Асланны күрсәләр, үзләре үк яратып туя алмаслар әле. Аның матурлыклары, аның терелекләре. Күрсәң шаккатырсың! Кыен булса да, шуның белән юанып яшим. Ярый әле Валентина Валерьевна бар, балалар караватын да, креслосын да ул бүләк итте. Кием-салымын да гел күтәреп кайта, ярый әле ул бар, ярый әле хәлемне белеп торучы син татаркам бар, – дигәч, кыз әрнеп елап җибәрде.

– Тынычлан, тынычлан, бәгърем, мин хәзер килеп җитәм, Лизочка матурым!

Озак гәпләшеп утырды алар. Кавказда ятучы Асланны да тәнкыйтьләделәр. Соңыннан: «Бүгенге көндә анда нindiдер ыгы-зыгылар, сугыш хәрәкәтләре бара, шуңа күрә улын килеп күрергә вакыт таба алмыйдыр», – дип, үзен акладылар да. Әлмирә вакыт-вакыт йоклап ятучы нарсый янына килеп: «Күз тимәсен, нинди матур сабый! Тфү, тфү, – дип төкергәләде. Балачагын күреп белгән кеше кебек: – Асланның нәкъ кечкенә чагы инде!» – дип куйды.

– Нәкъ үзе инде! Күрсә шаккатыр иде. Койган да куйган. Үзең ничек соң, Алевтина Ивановнаның килеп, хәлегезне белеп киткәне юкмы?

– Юк!

– Булса да булыр икән шундый тәкәббер хатын! Берәү булса, бердәнбер улым өйләнде, тиздән оныкларым туачак, – дип шатланыр иде.

– Нишләтәсең инде. Романны дустының кызы Таняга өйләндермәкче булып йөргән. Ә ул азык-төлек базасының директоры Варвара дигән хатынның бердәнбере, ди.

– Менә нидә икән эш!

– Өч бүлмәле фатирлары, бакчалары, машиналары бар икән! Ә монда чүпрәк-чапрагыннан гайре бернәрсәсе булмаган, аныңча Монголия далаларыннан килгән кызый аның бердәнбер малаена кияүгә чыга. Әле аны үземә сихерләп каратканмын икән, дип тә сөйләп ята, ди. Хет Казанның Монголиядә түгеллеген картадан карап ачыкласын иде, Татарстанда монголларның эзе дә юк бит. Үзбәк, таҗиклар да өрек, йөзем, чикләвек сатарга гына килеп китәләр.

– Борчылма, Әлмирә! Балагыз туса, шайтаныма да бара алмас! Оныгын тулай торакта яткырмас бит инде, үзендә бит ваннасы, җылы суы дигәндәй, өч бүлмәле, кыр хәтле сталинка!

– Бәлкем килеп тә чыгар. Ләкин төрле сүз йөртеп, рәнҗетте ул мине. Имеш, улын сихерләгәнмен, чәенә нәрсәдер салып биргәнмен. Имеш, мин кияүгә чыкканчы ук азгын булганмын, Ленинград пропискасы кирәк булганга гына Романга чыкканмын, Казанда үземә ир таба алмаганга бирегә ауга килгәнмен. Сөйләсәң, сүз күп инде!

– Әллә тилергән инде ул, карт тинтәк! Рома нишләп аңлатмый соң аңа?

– Кая ул аңлатмаган, тырышмаган! Сине сихерләгәннәр татарлар, хәзер син шуның тәэсиреннән котыла алмыйсың, поп чакыртып укытырга кирәк дип, теңкәсенә тигән! Ул да өенә бармаска, аяк атламаска сүз бирде. Соңгы тапкыр әнисе каядыр салага киткәч кенә, калган кием-салымын, вак-төякләрен җыеп кайтты.

– Миңа калса, улын синнән көнли ул!

– Бәлки шулайдыр. Ярый, дустым, транспортта кеше күбәйгәнче кузгалыйм әле мин. Рома кайтканчы аш пешерәсем бар! Токмачлы татар шулпасын үз итте ул! Пәрәмәч пешерсәм, унарны бергә юк итә!

– Аның хәтле гәүдәгә егермене ашаса да, исең китмәс! Ул пәрәмәчләрең үземнең дә төшләремә кереп йөдәтә.

– Алайса иртәгә үк хәстәрлим, камырын бүген үк әчетергә куям. Көтәм! Асланны алып иртүк кил, сагындым үзегезне! – дип кочаклашып алдылар. Алар сөйләшкәннәнме, әллә астын юешләткәнме, кавказ егете тавыш салды.

– Әй, бытылдашып баланы да уяттык инде!

– Торсын әйдә, ашатыр вакытым да җитте. Тор, улым, тор! Кил әле җанашым, апаеңны озатыйк та, рәхәтләнеп имезермен!

***

Дүртенче курсны тәмамлап, җәйге каникулга чыгарга өлгермәде, Әлмирә үзе дә ир малай алып кайтты. Романның шатлыгы эченә сыймады. Акчасы бетсә дә, бурычка батып булса да, тиеннәр, сумнар юнәтеп, дус-ишләрен, күрше-күләнне сыйлады. Ул үзенең шатлыгын да, әнисенең тискәрелеген дә бергә кушып юа башлады. «Мин аның янына бер аягымны да атламаячакмын, – дип, эчеп алгач, рәнҗешен белгертә торган булды.

Күбрәк тутырса, елап та җибәргәли. Кәефе күтәренке чакта исә вакыт-вакыт, «Мин сине яратам, мин сине яратам, мин сине барыбер үземә каратам!» дип, Елизавета өйрәткән җырны мәтәштерә иде. Ире Роман Мартыниянович белән беренче сүзгә килүе балага исем сайлаганда чыкты. Бәйләнде генә бит Пётр исеме кушабыз, дип. Ләкин бу мәсьәләдә Әлмирәнең үзенең фикере бар иде. «Кайчан да булса Казанга, минекеләр янына кайтсак, ике якка да ярарлык исем кирәк, әйдә, яңадан уйлашыйк әле, тыңла инде, зинһар!» – дигәч, исем сайлау тагын бер атнага сузылды. Руслан, Искәндәр, Альберт, Артём, Муслим дигәннәргә Әлмирә басым ясаса, Андрей, Николай, Павел дигән патша династиясенең исемнәренә Роман басым ясады. Шулай да озак бәхәсләшә торгач, малайны Родион дип атарга килештеләр. «Родион Романович Балахолкин!» Яңгырый бит бу, Әлмирә! Булды, исеме Родион булачак!

Ниһаять, килде ана кеше. Оныгын күрер, килененең хәлен белер өчен түгел, улын сагынуга түзә алмыйча килде. Баланы, ягъни оныгын күрергә телим дигәне тәкәбберлеген аклар өчен сәбәп кенә иде. Аның ачуы соңгы ел ярымда кимисе урынга, көчәйде генә. Шулай да дорфалыгын, тәкәбберлеген тирәнгә яшереп килеп керде ул. Улын үлепләр сагынган иде ана кеше.

– Нихәл, әни! – дип, кичке ашны ашап утырган ир урыныннан торды. Әлмирә дә итагатьле генә итеп: «Исәнмесез, әни!» – дип куйды.

– Менә оныгым туганны белгәч, хәлегезне белергә килдем әле. Югыйсә кеше аша гына ишеттем, – диде дә сүзсез калды. Анасына рәнҗегән Роман да элеккечә: «Нихәл, кадерле әнием! Бердәнберем!» – дип кочаклап алмады, шулай да бераз уңайсызланып торгач:

– Әйдә, әни. Бергәләп чәй эчәбез! – дип кыстады. Әлмирә дә:

– Әйдәгез, әйдә, Алевтина Ивановна, түрдән узыгыз, – дип кыстады.

«Ничек кунакчыл булып кылана! Уҗым бозавына әйләнгән Роман түгел мин. Төчеләнеп маташма, алай гына үзеңә карата алмассың!» – дип, явызларча уйлап куйгач:

– Бераз гына утырып торырмын инде! – дип, буш урындыкка килеп утырды. Аннан: – Улым, сумкамда сезгә дигән күчтәнәчләрем бар, бушат әле шуны, – дип үтенде. Биштәрдән биш кап һинд чәе, өч йолдызлы бер коньяк, казылык, ярты кило чамасы сыр һәм өч йөз граммнан артык булыр, сало чыкты. Яңа туган сабыйга бернәрсә дә юк иде. Бүлмәдәгеләр бер мәлгә тынып калдылар. Явыз хатын эченнән ямьсез итеп: «Сезнең көчегегез миңа кирәкми, әнә татар әби-бабалары иркәләсен, назласыннар!» – дип уйлап куйды. Үзе улын тикшерде. Роман ябыгып, уйчанланып калган. Сары чәчләренең чалара башлануы күзгә ташлана. «Бетергән бәгырь кисәгемне! Бетергән!» – дип эченнән генә сыкрады.

– Әнкәй, әйдә, чәйдән авыз ит!

– Ярый, ярый, улым, хәзер! Ни теге кул сумкамны гына китереп бирә алмассың микән? Рәхмәт! Менә кечкенә улыма егерме биш сум акча, үзегезгә нәрсә кирәк, шуны алырсыз! Яле, бер күз салсам ярыймы соң? – дип сорады.

– Рәхмәт, әнкәй! Әлмирә, Родионны китер әле!

Хатын теләр-теләмәс кенә ятагында йоклап яткан баланы карават аркасы аша иелеп алды да китереп, Романга тоттырды. Әнисе иелеп, сабыйга күз салды.

– Яле, яле, кемгә охшаган икән? Бигрәк кара йөзле, үзбәкләр кебек! – дип чәпеп куймасынмы!

– Әнкәй, кара, колакларын, иреннәрен, нәкъ минекеләр! Каракучкыл төс әнисеннән! Әлмирәнең мин беренче ир кешесе!

– Һәм соңгысы! – дип әйтеп куйды яшь хатын, ачуы чыгып.

– Шулайдыр, шулайдыр, балам, – дип ышангандай итте ана. Белә иде ул хатын-кызларның нинди хәйлә-мәйләләргә барганнарын. Романның этисе Мартын өйләнәм дип артыннан йөри башлагач, тутасы Настенькага чишелде. «Апай! Әз генә гөнаһларым бар иде, беренче кичне нишләргә икән?» – дигән борчулы соравына: «Сыйла, бертуктаусыз эчерт син аны, караватта бернәрсә дә төшенә алмаслык хәлгә җиткер!» – диде.

– Ә кан? – дип аптырап сорады булачак килен.

– Мин бер кечкенә генә флаконга хайван каны әзерләп куярмын, урын-җиреңә шуны тамызырсың! – дип тынычландырды.

Шул сәбәпле белә ул хатын-кыз затын. Үземнекен эшлим дисәме, теләсә нинди этлеккә бара, җен-пәриләр белән әшнәләшә! Малаемны, беркатлы Романымны шудыргансың икән, мине шулай җиңел генә утырталмассың! Шулай да ул үз-үзен йөгәнләп:

– И балакаем, елмая да башлаган икән, шушы нарасыйны ничек яратмыйсың инде?! – дип төчеләнә башлады. Аннары: –Улым, күчегез өйгә, ваннасы, җылы суы, туалеты, бөтен уңайлыклары бар! Өч бүлмәнең берсендә сез торырсыз, икенчесендә – мин, кунаклар килсә, залга урын җәярбез! Менә Казаннан кодалар килеп чыкса, Ходайның биргәненә шөкер, урыныбыз җитәрлек. Ерак түгел Маяковский бакчасы, бала белән Әлмирәгә һава суларга да чыгарга уңай, – дип тезеп китте әби-бабушка.

***

Илдә ыгы-зыгы нык көчәйде, кибетләр бушап калды. Завод-фабрикалар ябылып таланды, миллионнар эшсез калды. Бигрәк тә бу аяусыз хәл яшьләргә нык китереп сукты. Бер яктан ил байлыгын түрәләр таласа, икенче яктан бәхетсез халыкны төрле зурлыктагы җинаятьчел төркемнәр чишендерә башлады. Шундый имансыз көннәрнең берсендә Родионга бер яшь тулды. Кич белән үзләренчә шуны билгеләп үтәргә җыендылар. Әлмирәнең ахирәте Лиза да кара-чутыр Асланны кунакка алып килергә тиеш иде. Ике көн элек, дус-ишләре, элеккеге спортчылар аша Роман өстәмә аракы алырга талоннар да юнәтте. Ләкин Әлмирәнең ни сәбәпледер күңеле тыныч түгел иде. Каенанасы Алевтина малаена хуҗа булып алган басурманканың һәрбер эшеннән пычрак эзләде. Яшь килен, күченеп килгәннән соң, өч көн фатирны кыра-кыра юды, хәтта каралып беткән тәрәзә пәрдәләренә хәтле алып, җебетеп, юып, киптереп, үтүкләп эләргә хәстәрләп куйды. Ахирәтләрендә өч көн кунакта булып кайткан түтәй чисталыкны күреп, башта аптырабрак калды. Аннан соң бәйләнергә сәбәп эзләп:

– Нишләп пәрдәләр эленмәгән, нишләп залдагы өстәлнең клеёнкасы юк, минем җылы башмакларым кайда? – дип, бер сәбәпсез бәйләнеп йөрде. Аныңча әллә каян килгән монголоидканың фатирына хуҗа булып йөрүе җен ачуын чыгарды. Шуннан соң бертуктаусыз улының колак итен ашый башлады. Имеш, басурманкага өйләнгәнче өйләрендә тынычлык булган,

хәзер татарка килен булып төшкәч, әле акчам, әле йөзегем югала дип, яла ягарга да тартынып тормады. Акчалары, бөтен әйберләре соңыннан табылса да, гафу сорарга көче җитмәде.

– Әни, җитте, бертуктаусыз нигә аңа бәйләнәсең, әгәр туктамасаң, кире тулай торакка китәбез, йә булмаса фатирны суд аша бүлеп алам, сиңа бер бүлмә, безгә икелесе була! – дигәч, әбиең эшнең ни белән янаганына төшенде, астыртынрак кылана башлады. Өйләрендә тынычлык булмавы, Родионга да начар тәэсир итеп, ул көйсезгә әйләнде. Әлмирә этләк бабушкалары өйдә чакта бүлмәсеннән чыгып йөрмәс булды, кухняга да баласын ашатыр өчен генә чыккалый башлады. Тик бабушка гына бу хәлләрне:

– Кара, ничек карак мәче кебек йөри, шакшы татар, гомерендә яхшы тәрбия күрмәгән нәрсә, бүлмәсендә генә бикләнеп тыгына башлады! – дип, улына җиткерде. Ике араны килештерә алмаган, әнисенең әшәке телен яхшылап тыялмаган аю хәтле ир заты хатыны Әлмирә каршысында кечерәйгәннән-кечерәя бара иде. Рәнҗеде килен каенанасына. «Биш тапкыр тәһарәт алып, биш тапкыр намаз укыган дәү әнисен, туганнарын искә төшереп, йөрәге әрнеде. Ничек итеп чиста-пөхтә татарлар турында бернәрсә дә белмәгән килеш шундый әшәке сүзләр сөйләргә була? Үзе бит ике атнага бер мунчага барса бара, бармаса бармый, ваннага да сирәк-мирәк кенә керә, керләрен чайкарга да бик омтылып тормый, шул сәбәпле, юыну бүлмәсеннән гел сасы ис килә.

Икенче зур тавыш Родионны чиркәүгә алып барып чукындырырга, чын «истинный христианин» ясарга кирәк, дигәч чыкты. «Истинный» христианнарның тормышын аңлый башлаган яшь хатын аяк терәп бу нияткә каршы чыкты.

– Чиркәүгә дә бармыйбыз, мәчеткә дә бармыйбыз! – дип, үз гомерендә беренче тапкыр иренә кычкырды. Бу ызгышлардан соң Романның өйгә салып кайтулары ешая башлады. Үзе тагын алпамша хәтле булса да, дуамал түгел, тавыш чыгарып, хатынына кул күтәрмәде. Кая эләксә, шунда: йә диванда, йә кәнәфидә, кайчагында хәтта идәнгә дә ятып йоклый. Гомердә аракы исе иснәп үсмәгән Әлмирәдә ире Романнан сәрхушлек исләре килүенә җирәнү хисләре көчәйгәннән-көчәйде.

– Роман, балабыз Родион хакына, үтенеп сорыйм. Зинһар, ташла эчеп кайтуыңны! – дип ялварды.

– Менә нинди хәлгә калдың шул нәрсәгә өйләнгәч, идәндә ауныйсыңмы хәзер?! – дип, әнисе улын бертуктаусыз котыртты.

...Менә бүген кадерле улы Родионга бер яшь. Шул сабыйны иркәләп, назлап яшисе әбекәй ник бер кулына алып сөйсен баланы! Кайчагында Роман янында гына яраткан булып кылана. Сизә нарасый әбисенең кем икәнлеген, ул кулына алдымы, шундук көйсезләнергә, еларга тотына. Карчык анда да:

– Менә шулай була ул, әбисенә күрсәтмичә баланы йокы бүлмәсендә генә бикләп тоткач, – дип, киленен гаепләп калдыра.

Туган көнгә башта үзенең бәләкәче Аслан белән ахирәте Лиза килеп керде. Бүләккә зур гына чүпрәк аю алып килгәннәр. Валя дусты да килергә тиеш иде дә, Грузия сәүдәгәрләре белән кичектерергә ярамаган эше килеп чыгып, очрашуны икенче вакытка калдырган. Ярый әле аңа рәхмәт, шундый

кытлык чагында ун кило сыер ите табып бирде, алма белән грушасы да – аның тырышлыгы. Кичке алтыда торт күтәреп, салмыш ире кайтып керде. Сизелә, тагын спортчы дуслары белән күрешкән, кайгысын уртаклашкан...

– Исәнмесез, кадерлеләрем! – дип, барысын да кочаклап чыкты.

– Улым, туган көнең белән! – дип, Родионны сөйде. Инде әллә ни мулдан булмаса да, кунак өстәле әзер, сабыйның әбисе генә кайдадыр тоткарланды. Күчтәнәчкә Лиза алып килгән коньякны күргән ир:

– Әллә башлыйбызмы? – дигәч:

– Көтик инде, яхшы түгел! – дип, кире какты Әлмирә. Элеккеге сабакташы биредәге хәлләрдән хәбәрдар иде. Ул түзеп-түзеп утырды да:

– Роман Мартыниянович, миңа калса, сезгә бу фатирны бүлеп, рәхәтләнеп аерым яшәргә кирәк!

– Нишләп алай дисең?!

– Хәзер бит инде бүтән замана, әби-чәбиләрнең дә, яшьләрнең дә аерым яшиселәре килә. Шулай аерым торганда, ул кадер-хөрмәтең дә арта, кунакка йөрешәсез, сагынышасың, – дигәч, шыпырт кына Әлмирәгә күз кысып куйды. Роман аңа карап уңайсызланып торды да:

– Алай әлбәттә яхшырак буладыр да... Әни ялгыз кала бит! Ни дисәң дә, ул мине берүзе карап үстерде! – дип, авыр сулап куйды. Ул бу фикернең каян килеп чыкканын аңлый иде.

– Әлмирә, матурым, бераз булса да компромисска барыйк әле әни белән. Син уйлаганча, явыз хатын түгел, шул теге ана эгоизмы гына анда! Бердәнбер улын һаман имчәк баласы дип белә. Миңа бит өчегез дә кадерле.

– Минем бит бер начарлыгым да тигәне юк аңа! Ничек аралашыйм, ничек мөнәсәбәтләрне яхшыртыйм, аңлат миңа шуны!

– Кайчагында дәшми кал, берәр нәрсә эшләргә тотынса, ярдәм итәргә тырыш!

– Дәшмим бит болай да, күзенә күренмәскә тырышам. Ярдәм итәргә алынсам, йөрмә әле комачаулап, дип куа. Ничек ярдәм итим, өйрәт мине! – дип, ачу белән әйтеп куйды Әлмирә, Родион елап җибәрде. Идәндә туп тәгәрәтеп уйнап йөргән Аслан да, эшләр хөрти, ахры, монда дигән кебек аңа кушылды...

Шулай балаларны юата, тынычландыра гына башлаганнар иде, Алевтина Ивановна үзе кайтып керде. Усал күз карашы белән залдагыларны өтеп алды. Салмыш Роман:

– О, көткән бабушкабыз да кайтты! – дип, өстәлдәге коньяк шешәсенә үрелде.

Алевтина Ивановна: «Сез монда типтереп ятасыз, безнең эштә кыскартулар башланды, яңа хуҗалар килде АТПга», – дип, усал итеп әйтте дә йокы бүлмәсенә кереп югалды. Әнисенең чыкмаячагын аңлаган Роман ишек төбенә барып:

– Әни, нишләп югалдың анда, сине генә көтеп утырабыз, калганын иртәгә сөйләшербез! – диде. Транспорт предприятиесендә хуҗалык мөдире булып эшләгән ана:

– Үзегез генә утырыгыз, кәефем юк! – дип, кире какты. Роман болай булыр дип көтмәгән иде.

– Үз оныгың бит, яратмасаң да яратмадың инде баланы! Ярый, алайса чәнчелеп кит, без ничек яшәргә икәнлеген белербез!

– Роман, алай тупасланма инде, әйдә, улыбызны котлыйк та ашап-эчик, югыйсә Лизадан да уңайсыз, зинһар, тавыш чыгара күрмә! – дип үтенде Әлмирә.

– Юк, мин монда яши алмыйм. Сезне дә яшәтмим, бүләбез фатирны! – дип дулады ире. – Вот так и живём, Лиза! Шулай яшәргә буламы инде? Гафу ит, зинһар, әйдә, улымны туган көне белән котлыйм әле! Бәхетле бул, Родион Романович!

***

Көннәрнең берендә Алевтина Ивановна дусты Варвара Тимофеевна белән очрашты.

– Нәрсә булды бу Роман белән? Теге татаркага өйләнгәч сихерләп куйган кебек, бөтенләй үзгәрде, – дип зарланды ул дустына.

– Бозым ясаганнар, күрәсең, багучыларга барырга кирәк! Минем бер танышым бар, Елга урамында тора, бик дөрес әйтеп бирә, диләр. Кирәк дисәң, бүген үк адресын табам! Аграфена Чудакова. Борчылма, Алевтина Ивановна, сине ялгыз калдырмабыз! Таняны синең яныңа җибәргәләрмен! – дип, күз кысты.

– Роман бит бөтенләй акылын югалтып бара, фатирны бүләбез, ди, гомерендә авызына капмаган кеше, көн саен диярлек эчеп, тыгынып кайта! Теге татарка фатирсыз калдырачак мине, – дип, Алевтина авызын сузып елап җибәрде. – Шул динсез, имансыз зат килеп кергәч, дөньябызның асты-өскә килде. Роман эчә башлады, мине эштә кыскарттылар, хәзер фатирсыз да калсам, асылынып үләргә генә инде. Варвара Тимофеевна, беттем мин. Ничек шулай гөрләп барган тормышыбыз җимерелде, – дип шыңшуын белде.

– Бирешмә, Алевтина Ивановна! Ярдәм итәрбез, нык бул!

***

...Аграфена Чудакова дистәләгән шәмнәрне зажигалка белән ашыкмый гына кабызды, шуннан соң авызындагы сигаретын көйрәтә-көйрәтә, карта салырга тотынды.

– Менә, пиковая дама, ниндидер кара чырайлы чибәр хатын-кыз улыгызга бозым ясаган. Менә червовый валет та биредә, күрәсеңме, артында, ул хатынның фикердәше тора.

– Сөяркәсеме? – дип, ачыклык кертергә тырышты Алевтина мескен чырай белән.

– Бик мөмкин! Өегездә ниндидер сихер кәгазе яшерелгән булырга тиеш! Кайткач яхшылап, караватасларын, матрас тирәләрен актарып эзләп карагыз, тапсагыз тагын миңа килеп, бозымын куарбыз, югыйсә соң булуы бар, – дип куйды багучы, авызыннан төтен алкалары чыгарып.

***

Икенче көнне иртән Әлмирә Родионны алып, үзе эшли торган мәктәпкә, балаларга рәсем ясарга өйрәтергә дип киткәч, Алевтина көтмәгәндә, берәрсе кайтып кермәсен дип, ишекнең эчке келәсен элде дә улы белән килене йоклаган бүлмәгә кереп китте. Биредә чисталык, пөхтәлек иде. Бөтен җир ялт итеп тора. Шкафтагы кием-салымнар юылып, үтүкләнеп,

таслап өеп куелган. Менә болары улы Романныкы, икенче бүлемтектә басурманканыкылар, өченчесендә оныгы Родионның чүпрәкләре. Тәрәзә төбендә гөлләр чәчәк атып утыра. Алевтина башта бала ятагында казынды, шуннан улы белән килене йоклый торган караватка ревизия ясады. Йөрәге жу итеп китте, багучы дөрес әйткән икән, матрас астыннан целлофан пакетка төрелгән адәм заты аңламаслык язулар килеп чыкты. Ул шикләнеп, бармак очлары белән генә алып, әлеге сихерле язмаларны кул сумкасына салды да шунда ук Аграфена Чудакова янына ашыкты.

...Багучы шәм яктысында ниндидер аңлашылмый торган догалар укыды, ниндидер билгесез көчләрне үз янына чакырды. Аннан бозымга эләккән хатынга күтәрелеп карап, үзгә тавыш белән:

– Килделәр, икесе минем янда, берсе синең артыңда! – дигәч, Алевтинаның коты ботына төште. Багучы тонык тавыш белән:

– Сизәсеңме, аркаңдагы салкынлыкны тоясыңмы, Алевтина? – дип сорады. Коты очкан хатын көчкә телен әйләндереп:

– Әйе! – дип куя алды.

– Сезнең улыгызга явыз рухлар аша бозым ясалган, менә алар шуны раслап, безнең янда басып торалар. Тиздән, диләр, менә бу хатынга да кабер туфрагы белән бозым ясалачак!

– Нишләргә соң безгә, Аграфена кадерлем, коткара күр, зинһар! Коткар!

– Без хәзер сихер кәгазьләрегезне шушы өстәлгә куеп яндырабыз һәм сихерне мин үземә алам. Соңыннан төнлә зиратка барып, куып чыгарам. Бик авыр эш, сәламәтлегемә шуннан соң зыян гына килеп тора, кайбер айларда берәр атна дәваханәләрдә ятып чыгам. Бозымны куу үтә дә четерекле авыр эш! Ләкин Хак Тәгалә безне кешеләргә ярдәм кулы сузып торырга җибәргән икән, беркая да барып булмый, – дип, тимер савытка кәгазьләрне салып яндырды. Бүлмәгә янган кәгазь исе таралды. «Киттеләр, киттеләр!» – дип улады багучы хатын.

– Блокировать итәр өчен тагын өч сеанс үтәрбез, әлеге явыз көчләр кабат сезгә зыян салмасыннар өчен өшкерербез, куарбыз! Иртәгә үк өегезгә килеп, бүлмәңдә догалар укып, сихерне эзләрбез! Хәзер кайтыгыз! – дип, урыныннан торды.

– Басурманнар бозымы ул! – дип куйды тетрәнеп калган Алевтина, бу мәсьәләдә мәгълүматлы кеше кебек.

– Дөрес әйтәсез. Нәкъ шулай! – дигәч, акча җыя торган тимер савытны Алевтинага шудырды. – Бөтен җыйган акчалар ятим балаларны тәрбияләргә, мохтаҗларга ярдәмгә китә! – дип, авыр сулады багучы.

Менә бүген дә биш йөз сум әлеге тартмага төшеп чумды.

Кич белән улын күтәреп кайткан Әлмирә бүлмәсендә кемнеңдер казынганлыгын сизеп алды. Әллә берәр нәрсә тыктылар инде дип шикләнеп эзләнде. Шулай актарына торгач, мәрхүм әбисенең «Җенпәриләргә каршы» дип язып биргән догаларының матрас астыннан юкка чыкканлыгын күрде.

Икенче көнне Аграфена Чудакова, сөйләшенгәнчә, төгәл көндезгә унда пәйда булды. Бүлмәләрне җентекләп карап чыкты да Алевтина Ивановнаныкында тукталды.

– Биредә инде булганнар!

– Боже мой, беркемне дә кызганмый икән бу мөртәт эт хатын, иблис токымы!

– Кем ул?

– Киленне әйтәм!

– Бик кызганыч, фактлар шуны дәлилли. Ярый, башлыйбыз. Хәзер миңа порталны ачар өчен бер стакан чиста су кирәк.

– Нинди портал соң ул?

– Үлеләр дөньясы белән элемтәгә чыгар өчен уртадагы ишек – портал дип атала.

– Йа Аллам!

– Борчылмагыз, соңыннан кире җибәреп порталымны ябып куям, бер генә рух та биредә калмаячак. Суны алып килегез!

– Хәзер, хәзер Аграфена Васильевна! – дип, иләсләнгән хуҗа хатын кухняга ашыкты. Кулына стакан тотып, кире кергәндә багучы хатын идәнгә тезләнеп, кечкенә генә җәймә өстенә әкәм-төкәм кабыклары, күсетычкан баш сөякләре, кара мәче тәпиләрен чәчеп куйган, үзе бер халык та аңламас телдә нидер укына иде. Шуннан бер мәлгә тынып калды. Күзләре алышынган, куркыныч булып яналар иде.

– Суны бирегез, суны, портал-ишекне ачам! Син утыр әнә теге урындыкка, бер сүз әйтмә! – дигәч, авызына су каба-каба, бүлмә чатларына бөркеп чыкты. Шуннан ухылдап, икенче урындыкка килеп чумды:

– Килделәр, килделәр! – дип сөйләнде багучы сәер тавыш белән. Алевтина сагаеп кына, тирә-ягына караштырды, тик беркемне дә күрмәде.

– Кемнәр килде соң? – дип сорады ул, куркып.

– Үлгән кешеләрнең рухлары, берсе синең артыңда тора, бик зур гәүдәле, җирән чәчле, нихәл, Алевтина кадерлем, бердәнберем! – ди.

Хәйран калган хуҗа хатын:

– Ирем Мартын инде ул, – дип кычкырып җибәрде...

– Әнә тагын икенчесе, зур сакаллысы, муенына көмеш тәре таккан бабай, башына кара яулык бәйләгән әби дә биредә.

– Иремнең әти-әнисе алар, йа Аллам! Ай Аллам! – дип чукынырга ук тотынды.

– Бабай әйтә, рәхмәт, килен, Роман оныгымны кеше итеп үстердең! – ди. – Йа Ходай, мәрхәмәтеңнән аерма килен белән оныгымны! – ди.

– Рәхмәт, рәхмәт, эткәй, рәхмәт! – дип дулкынланып, кабат чукынырга тотынды.

– Ирең Мартыниян әйтә: «Оныгым Родионны алып калып, теге антихристны куыгыз, изге йортыбызда эзе булмасын, адәм актыгының!» – ди.

– Аңладым, Мартыным, аңладым!

– Шыпырт, әнә күрсәтә, кием шкафы астына күрсәтә!

– Нәрсәне күрсәтә?

– Хәзер ачыкларбыз! – дип, багучы кулын аска тыгып, кечкенә генә кара янчык тартып чыгарды.

– Менә ул бозым билгесе! – дип, җебен сүтте дә кара балчыкны күрсәтте. – Кабер туфрагы, әгәр тагын бер атнага тапмыйча калдырган булсагыз, эшегез харап буласы икән!

– Йа Аллам!

– Мин бу туфракны бөтен шартын туры китереп, бозымны үзенә кайтарам. Бик көчле сихерчегә ясаткан, кире озатуы кыен булачак! Бөтенләй котылыр өчен тагын ике дә җитә, әлбәттә, ләкин төпле булсын өчен өч сеанс үткәрәбез, аннан мин туфракны Нева елгасына сибәчәкмен дә, кире кайтмаслык итеп, бер дуңгызны корбанга чалдырачакмын, тагын бер чучка кирәк булачак!

– Яхшы, яхшы, Аграфена Васильевна!

– Сез борчылмагыз, үз тормышымда моннан да көчлерәк бозымнарны кире кайтарганым бар. Мәрхүмнәрнең рухларын озак тотарга ярамый, хәзер кире озатырга кирәк! – дип, идәндәге җәймәсенә иелде.

– Сез китегез, кайтыгыз, тыныч кына ятыгыз. Сезнең хәер-фатихадан имин булыр йортыбыз! – дигәч, сөякләр өстенә башын иеп, кабат пышылдап кына, нидер укынып алды. Аннан: – Үлгән туганнарыгызның җаннары китте, хәзер бозымга каршы мөрәҗәгать итәбез! – диде. – Әй, җир-күктәге ияләр, безгә ишек ачыгыз, ярдәм кулы сузыгыз, бетмәсенгә башыбыз. Кара көчләр китсеннәр, тәмугны үз итсеннәр. Бозымнары таркалсын, бүлмәләр бушап калсын! – дип көйләде. Шуннан һушыннан язып, идәнгә ауды. Алевтина Ивановна коты очып, аңа иелде.

– Аграфена Васильевна, Аграфена Васильевна! Ни булды сезгә? Йөрәк даруы биримме? – дип, чыраена төбәлде. Багучының бөтен тәне калтырап, дулкынланып алды. Соңыннан кинәт күзләрен ачып, хуҗа хатынга бакты.

– Озаттым, озаттым, барысын да озаттым! – дип пышылдады, шуннан соң күзләреннән эре яшь бөртекләре бите буйлап тәгәрәп төште.

Чәйләр эчкәч, биш йөзлекне кесәсенә шудыргач, кайтыр юлга кузгалды кара көчләрне куучы. Ишек төбенә җиткәч, Алевтина Ивановна аннан:

– Чиркәүдән батюшка да чакыртып, өйне яктыртсам, әйбәт булыр иде бит, Аграфена Васильевна? – дип киңәш сорады.

– Әлегә кирәкми! Бозымны куарга барыбер көче җитми аларның! – дип, ишеккә борылды да киң итеп елмаеп алды. Әлбәттә, аның шулай авыз еруын хуҗа хатын күрмәде, күрсә дә, сихер-михерләрне, бозымнарны куып чыгара алуына шатлана гына дип уйлар иде.

Ни сәбәпледер, Роман бүген көндезге берләрдә үк кайтып керде, авызы салынган, күренеп тора, нидер булган.

– Нишләп иртәләдең әле, Роман? – дип төпченде ана кеше.

– Әй, әни, сорама әле, – дип кул гына селтәде улы.

– Бердәнбер анаңнан яшермә, улым, дөресен сөйлә!

– Эштән җибәрделәр, әни! Команда минем тренерлыкка каршы чыкты. Имеш, эчә, рәтле-башлы комплекслы шөгыльләнүләр дә юк, шул сәбәпле рәттән дүрт уенда җиңелдек дип, мәсьәләне күтәреп чыктылар. Төкерәм мин ул оешмаган командага, хезмәт хакы рәтле булса ярар иде, ашап-эчәргә дә җитми ул 130 сум.

– Әй, улым, улым, бөтен бәлаләребез син шуңа өйләнгәч башланды бит! Син һаман ышанмыйсың! Бозым ясаттырган безгә, синең сөекле хатының! Бозым!

– Әй инде, әни, әллә нинди әкиятләр сөйләмә әле, заманы ул түгел! Нинди бозым, Әлмирәгә нигә кирәк ул?

– Аграфена Васильевнага барган идем, теге карта салып багучыга. Өегездә бозым бар, кайсыдыр җирегездә сихерле кәгазьләр яшерелгән, кара

чырайлы, бик чибәр хатын улыгызга ясаган, хәзер сиңа да үлем бозымы кертәчәк, – дип кисәтте.

– Син шул мошенникларга ышанасыңмы?

– Син тыңлап бетер, бүлдермә! Шуннан өйгә кайтып, сезнең бүлмәне тикшергән идем, ятагыгыздан сихерле язулар табып алдым, аны багучыга алып барып, сихерен кире кайтарттык.

– Нинди язулар, нинди сихер, әни? Егерменче гасыр ахырында яшибез түгелме?!

– Ул гына да түгел, Роман, бүген Аграфена Васильевна минем шкафым астыннан сихерле янчык табып алды, эченә мәет яткан гүр туфрагы салынган, сине үтерергә җыеналар, ди. Мине юкка чыгарып, фатиргә хуҗа булырга йөри бит хатының!

– Юкны сөйләмә әле, әнкәй!

– Ышанмасаң, татаркаң кайткач, үзең сора, таләп ит, дөресен әйтсен сиңа, әгәр дә чынлап ярата икән... Родионны чиркәүгә алып барып чукындырырга да ирек бирмәде. Бетерәчәк ул безне! Йа Хода, нинди гөнаһларыбыз өчен шундый сынаулар җибәрдең икән безгә?! – дип шыңшый башлады анакай. Әлеге яңалыклардан аптырап калган Роман әнисен кочып алды.

– Борчылма инде, әни! Әлмирә эшеннән генә кайтсын, сорармын, нинди язмалар булды икән ул. Җитте, җитте, тынычлан! Әйдә, булмаса, элеккеге чаклардагы кебек икәү чөкердәшеп чәй эчик әле бер, әни! Әле синең, Алевтина Ивановна, катырак нәмәстәң дә бардыр? – дип елмайды.

– Булыр, булыр, улым, анысы да булыр, монысы да булыр, синең өчен җаным да жәл түгел! Тик... Ул эчеп йөрүләреңне туктатырга вакыт! Әнә бит эшеңнән дә сөргәннәр. Борчылма, улым, Варвара Тимофеевна белән сөйләшермен, товар базасына урнаштырыр, мине склад мөдире итеп алам, диде.

***

– Әлмирә, безнең урын-җир астыннан әни нindidер серле язмалы кәгазьләр табып алган, – дип, тонган күзләре белән карап каршы алды эштән кайткан хатынын ярым исерек ире.

Әлмирә матрасны күтәреп, кулы белән капшап, нидер эзләсә дә, бернәрсә дә тапмады.

– Нинди язулар иде алар? – дип, усал итеп карады ире, хатыныннан шикләнә башлап.

– Ни хакы бар аның безнең бүлмәгә кереп актарынырга?

– Димәк, ул кәгазьләр бар иде?

– Аларны бит җен-пәриләрдән, сихер-михердән төн йокыларыбызны саклар өчен мәрхүмә әбием язып биргән иде.

– Сихер-михердән, димәк, әни белеп сөйли. Өстәвенә, теге багучы да шунда, шунда нindidер бозым язмалары ята, дигән! Сәер! – диде Роман, гаҗәпләнеп. – Нишләп әнинең бүлмәсенә гүр туфрагы яшердең?

– Нинди гүр туфрагы? Роман, әллә чирлисеңме, әллә эчә-эчә бөтенләй ычкына башладыңмы? Әнә бала безне тыңлап, борчыла, туктат бу урынсыз бәйләнүләреңне! Ятыйк, әйдә, йоклыйк! Ичмасам, юк-барга башыңны

тинтерәткәнче Родионга садик сөйләшер идең! Көн дә Лизага кертеп калдырам бит улыңны! Ярый әле алар бар!

– Теге ниндидер кара халыктан уйнаштан бала тапкан дустыңны әйтәсеңме?

Әлмирәнең, әйтерсең, тәненә энә белән төрттеләр!

– Нинди уйнаш? Ни сөйлисең, үлеп-үлеп яратты бит ул Асланны! Искитмәле яхшы кыз ул Лиза! Балаңны карашканы җитмәгән, син аңа карата пычрак атасың!

– Сездә анда Казанда ничектер, бездә дөресен һәм турысын әйтәләр.

– Казанда да шулай! Ярый, җитте, улымны ашатып яткырасым бар, – дип, яшь хатын сабыйны иелеп, ятагыннан алды. Роман ямьсез итеп елмайды да кәнәфидә торган иске мендәрнең берсен алып, залга йокларга чыгып китте. Аның артыннан ишек ябылгач, Әлмирә улын кочаклаган килеш ятагына сыгылып төште. «Йа Хода, нишләп шушы хәлләргә калдырдың, нишләп? Исрафил абый, нигә, нигә мине шушы эт оясыннан тартып алмадың?! Миңа ничек яшәргә соң хәзер? Иртәгә үк чыгып качар идем, кая барыйм, ничек итеп, әти-әни, туганнарымның күзенә ничек күреним?» – дип, гөнаһсыз күз яшьләрен койды.

* * *

Әлеге котсыз мохиттә интегә-кайгыра, тагын ярты елы үтеп китте. Шундый газаплы көннәрнең берсендә фатирга кайтып керсә, аларның йокы бүлмәсендә анадан тума ялангач Роман белән Алевтина Ивановнаның иптәш хатынының кызы Таня тәгәрәп яталар иде.

Иренә нык рәнҗегән бәхетсез хатын икенче көнне үк аерылышырга дип, судка гариза биреп кайтты. Унбиш көн дә үтмәгәндер, аларның гаиләләре таркалды. Алевтина Ивановнаның шатлыгы эченә сыймады. Улын тизрәк Танюшага өйләндерергә иде дип тырышты. Тагын ике айдан бу хыялы да тормышка ашты. Шуннан бирле Әлмирә үз бүлмәсендә улы белән генә бикләнеп яшәде. Өйдәгеләр берәр җиргә китсәләр генә кухняга чыгып, чәен, ашын куйды. Улына кирәк булса дип, җылы суын термоста тотты. Суыткычы булмау сәбәпле, азык-төлекне бик азлап кына сатып ала иде.

Роман белән Таня бик еш кунакларга йөри башладылар. Салмыш кайтып, оятларын югалтып, залдагы диван өстендә әүмәкләштеләр. Аларның ахылдашып ятуларын ишетеп торган Әлмирә ниләр кичергәнен, йөрәге әрнүләрен, әллә үз-үземә кул салыйммы икән дип бимазалануларын үзе генә белде, бүтән беркемгә дә язмасын иде минем язмыш, дип теләде. Бу тәмугта озак яши алмаячагын аңлап, иптәш кызлары Лиза, Валя белән дә киңәште дә фатирдагы үз өлешен бүлеп алырга уйлады. Шул турыда Романга җиткерде.

***

Болганчык, дөньяның асты өскә килгән, адәм баласының гомере бер тиенгә тормаган куркыныч чорлар башланды! Әле анда үтерәләр, әле монда яндыралар, талыйлар-суялар, һәркемнең үз хәле хәл! Ул үзләренең аерылышуларын туганнарына җиткермәскә тырышты.

Менә бүген дә ул улын күтәреп, балалар бакчасына чапты, аннан мәктәпкә

эшенә. Ярый әле хезмәтендә тырышлыгын, пөхтәлеген күреп яраталар, үз итәләр. Ул анда баргач, үзен ял иткәндәй тоя. Ә кичен Родионны алгач, фатирга кайтырга күңеле тартмый, анда үзен зинданга эләккәндәй тоя. Тизрәк, тизрәк торакны бүләргә, әлеге адәмнәрне күрмәс өчен ераккарак качарга кирәк. Шулай борчулы уйларга батып, Маяковский бакчасы аша баралар иде. Агачлардан сары яфраклар коела, табигать күзгә кереп маташа торган чак. Көтмәгәндә, биш-алты күн курткалы адәм чыгып, аны уратып та алдылар. Арадан берсе тук чырайлы, явыз күзлесе:

– Әй, подруга, әгәр дә үзеңнең һәм менә бу кечкенәңнең исән калуын телисең икән, торган фатирыңнан пропискадан төш! Мин ике әйтергә яратмыйм, белеп тор! Лёха партизан ике сөйләшми! Ике атна вакыт сиңа, – диде дә, шундук китеп бардылар. Әлмирәнең аяк астыннан җире убылып киткәндәй булды, өстәвенә, куркып калган Родион үкси башлады.

– Тынычлан, тынычлан, улым! – дип юата-юата атлады ул. Караңгы уйларына чумып барды да барды. Бер заман күтәрелеп караса, Валентина яшәгән йорт янында басып тора икән, әнә тәрәзәсендә уты да бар!

– Валя җаным, үтерәләр безне, бүген Лёха партизан дигән бандит фатирдагы пропискаңнан төшмәсәң, көчегең белән икегезне дә юкка чыгарам! – дип янады.

– Елама, елап, бернәрсә дә майтарып булмый! Беләм мин ул хәшәрәтне! Мондагы Яр буеныкылар бандасының атаманы ул. Димәк, бабуляң аны өстергән! Сине урамда калдырмакчы булалар. Инде хатын-кызлар белән сабый балалар өлешенә кереп, бизнес ясарга тотынган икән, бәдбәхет! Минем бүген Россия ресторанында кайбер кунаклар белән очрашасым бар, син биредә генә утыр! Хәлне аларга аңлатырмын, кирәгең чыкса, өй телефонына хәбәр салырмын! Ярый, сәгать җиденче ярты, кузгалыйм, алар соңга калганны яратмыйлар, – дип, урыныннан торып басты. Иптәш кызы чыгып киткәч, үзен кулга алырга тырышып, башта улын ашатты, шунда бергә үзе дә капкалады. Мөмкинлектән файдаланып, Родионны юындырды, сабые изелеп, йокыга киткәч, үзе дә аруланып чыкты. Кәнәфигә утырган килеш оеп кына бара иде, телефон шалтыраудан сискәнеп куйды.

– Дустым, мине көтмәгез, соң кайтам, ятып йоклагыз! Иртәгә сәгать кичке биштән соң кереп алам, Родионны Лизага калдырып торырбыз! Синең проблеманы беләләр, ярый, тыныч йокы! – дип, сүзен тәмамлады.

– Йа Ходаем, ярдәмеңнән ташлый күрмә инде! – дип үтенде бәхетсез хатын.

Икенче көнне алар утырган «Волга» машинасы Ленинградның үзәген үтеп, хуҗалык объектлары урнашкан җирләр буйлап барды. ЖБИ, асфальт җитештерү заводы, СМУ, ПМК, «Зеленхоз» күзгә ташланып кала. «Кая алып баралар икән соң, Валя да рәтле-башлы аңлатмады?»

Ниһаять, машина ачык тимер капкадан АТП дип язылган биләмәгә килеп керде, аннан күпмедер баргач, ангар эченә юл алды. Бу бинаның эче мастерскойны хәтерләтә иде. Чөнки дивар кырыендагы зур тимер өстәлләрдә тимер-томыр, машина кирәк-яраклары, пластик май савытлары өеп куелган, резина шиннар күзгә ташланды. Валя белән Әлмирә үзләрен алып килгән кара курткалы егеткә ияделәр. Сул яктагы яшел төскә буялган ишектән эчкә үттеләр. «Йа Ходаем! Нәрсә бу?!» Нык бәдәнле өч адәм бөтен

чырае сыдырылып-күгәреп беткән бәндәне чорнап алганнар иде.

– Артур, менә мин әйткән Әлмирә шушы була инде! – Ир кеше аңа карап:

– Казаннан буласың инде алайса! – дип куйгач, бу тамашадан өне киткән Әлмирә «әйе» дигәндәй, башын гына селкеп куя алды.

– Таныйсызмы бу бәндәне? Сине һәм улыңны үтерү белән янаган! Лёха, син хатын-кызлар һәм балаларга үлем белән янап, акча эшли башладыңмы? Күпме түләделәр инде шуның өчен?

– За что? Артур братан, ну за что, мин бит аңа янадым гына, үтермәдем!

– Күпме түләделәр дип сорыйм?!

– Бер меңгә сөйләшкән идек.

– Син беләсеңме соң зонада синең кебекләрне нишләтәләр? Әле бит синең өстеңдә яшь кызларны көчләүләр дә бар! Акча түләп кенә котылдың!

– Артур, гафу ит инде, хата китте, белмәдем шул! Белмәдем! Гафу итегез, шулай килеп чыкты. Гафу ит, Әлмирә! Мин китергән борчуларым өчен түләрмен!

– Әлмирә ханым, сез аны кичерә аласызмы соң? Бәлкем аны, муенына берәр тимер кисәге асып, суга батырыргадыр?

– Юк, юк, кеше җанын кыя күрмәгез, үтенеп сорыйм! – дип ялварды куркып калган яшь хатын.

– Ярый, Әлмирә! Менә күрәсеңме, Лёха, син аны ике дә уйламый теге дөньяга олактырмакчы идең, ә ул сине кызгана!

– Кичерегез, зинһар, нык гаеплемен!

– Валентина Валерьевна, сез Әлмирә белән кайта торыгыз, элемтәгә керербез. Безнең әле кайбер сөйләшәсе сүзләр бар!

– Яхшы, Артур туган, сау булыгыз, – дип, Валя иптәш кызына башы белән ымлады. Бүлмәдән чыккач, Әлмирә бөтен кыюлыгын җыеп:

– Кем соң ул? – дип сорады.

– Якташың, Казан егете! Бик намуслы, ярдәмчел шәхес! Җинаятьчеләр арасында мондыйлары бармак белән санарлык!

Әлеге хәлләрне Алевтина Ивановнага да җиткергәннәр, ахры, ул каушап-куркып калды. Әлмирә белән кухняда очрашсалар да: «Родион улыма менә туңдырма алдым әле! Берәр җиргә барырга кирәк булса, калдырып кит, иркенләп йөрерсең!» – дигән булып ярарга тырышты. Яшь хатын туңдырманы да алмады, аның бу йортка, аның ияләренә күңеле тулысынча сүрелгән иде. «Ничек бу фатирдан чыгып качарга, котылырга икән?» – дип бимазаланды. Казанга шалтыратып, абый белән сөйләшсәм! Юк, ояты ни тора! Романны алиментка биреп, берәр торакка йортка керергә генә кала?

Шулай аптырап йөри торгач, җылы май айлары да килеп җитте. Ул арада нинди генә хәлләр булмады. Романның бичәсе бик әрсез булып чыкты. Кирәк икән, чыгып китте, кирәк икән, дус-ишләрен җыеп, залда гөр килде, ашарга пешерү, өй җыештыру, кер юу дигәнне белми дә, теләми дә иде. Алтмышны тутырган Алевтина Ивановна ничек түзә диген? Беркөнне яхшы гына салмыш кайткан Роман да: «Әнкәй, нәрсәгә син мине шул себеркегә өйләндердең? Бернәрсә дә эшләми, мине иргә дә санамый бит! Өстәвенә, яратмыйм мин аны!» – дип дулады. Әби карчык берни булмагандай: «Аның каравы ул чын христианка!» – дип, үзенекен тукыды.

Соңгы вакытларда Роман кеше өйдә булмаганда, еш кына Әлмирәнең ишегенә килеп:

– Гафу ит мин җүләрне, әйдә яңадан кушылыйк әле, яратам бит мин сине, бәгърем! – дип, ишеген шакый торган булды. Ләкин поезд киткән, Әлмирәнең күңелендә аңа карата бернинди җылы хисләр калмаган иде. Ул шунда гына Романны беркайчан да яратмаганлыгын аңлады. Хәзер аның җаны тыныч, явыз карчык та артык бәрелми, курка. Өй җыештыра, кер юа, яраткан улына ашарга пешерә! Килене башкарасы эшләрне ах та ух килеп, үзе эшли. Дөрес, улы Роман анасын кызганып, чүбен түгеп керә, келәм-паласларны кага, кайчагында хәтта ашарга да пешерә. Ә яшь килен кайтса, залдагы диванга сузылып ята да телевизор кабыза.

Родионга дүрт яшь тулган көннәр иде. Әлмирә Ворошилов урамыннан барганда, Галимнәр йорты янындагы афишага күз салды. «Иртәгә, 24 көнне кичке сәгать алтыда Лев Николаевич Гумилёв белән очрашу була. Тарих сәхифәләрен ишетергә теләгәннәр рәхим итегез!» диелгән иде анда. Бу бит Әхмәт абыйсы: «Гумилёв укуларына йөрергә тырыш, гаҗәеп шәхес, татарларны яклаган, дөрес тарихны барлаган өчен төрмәләрдә утырып чыккан!» – дип әйткән иде. Ул чакта бу сүзләр Әлмирәнең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

«Икенче гасырда тугыз татарның бишесе, шулар арасында болгар, башкорт кавемнәре дә бар, һуннарга ияреп, Кара диңгез буйларына китәләр. Соңыннан татарларның бабалары Кубрат хан, аның бер улы Аспарух Болгариягә нигез салса, Кодрак хан Идел, Чулман буйларына менеп, Болгар дәүләтен төзи. Димәк, алтынчы-җиденче гасырларда аерым бер дәүләт булып оешып җитәләр. Иң башта әлеге җирләргә явызлык белән килгән Чыңгыз хан яуларына каршы торалар. Шуңа күрә Идел буе татарларының рус кенәзлекләрен тезләндерүдә, гомумән, катнашы юк, ә бөтен бәлаләрне аларга сылтыйлар. Шулай яла ягылу сәбәпле, күпме җәбер, җәфа күрә ул тырыш, хезмәт сөючән, данлыклы халык. Ә күпме шәһәрләр төзегән алар. Казан, Биләр, Тәтеш, Төмән, Тобол, Хаҗитархан, Ялта, Сембер, Самара, Сарытау, шулай ук башкалабыз Мәскәүгә дә алар нигез салган. Ә күпме шәхесләр биргән татар халкы, санап бетергесез! Рахманинов, Татищев, Шереметьев, Суворов, Кутузов, адмирал Нахимов, Куприн, Бунин, Карамзин һәм тагын меңләгән элита татар өммәтеннән!»

Бу лекциядән соң ул коточкыч тетрәнү кичерде, шаккатты. Димәк, аларны махсус түбәнсетер өчен яла якканнар. Гумилёв әйтеп киткәнчә, «Ислам динендәге татарларга, башка мөселман халыкларына каршы Ватикан, католик динендәге Европа тәре походлары оештырган!» Әлмирәнең күңеленә тагын шул кереп калды: «Безнең Россиядә иң зур мирас – татарларның бабасы булган Кубрат ханныкы. Кайбер экспонатлар белән Эрмитажга барып таныша аласыз! Ә калган әсәрләр музейның подвалында! Аларны бер ай йөрсәң дә, карап бетерерлек түгел!»

...Улымны алып барырга, йөрергә кирәк, күрсен, белсен үзенең Кубрат хан оныгы, мәгърур татар халкының бер вәкиле икәнлеген. Әлмирәнең үз халкының тарихы белән кызыксынуы көннән-көн көчәя генә барды. Милли хәтере ачыла, ныгыганнан-ныгый иде. Аның Казанга тартылуы тагын да көчәйде.

***

Соңгы вакытларда Казан чибәре күңел күтәренкелеге кичерде. Эшенә дә очып кына барды, баласын балалар бакчасыннан алып, Лиза дустының хәлен белергә дә вакыт тапты. Гумилёв дәресләренең берсен дә калдырмаска тырышты. «Татар халкы бөек халык, дистәләгән дәүләтләр төзегән халык! Җимерүче халык түгел, киресенчә, төзүче, алар булган җирдә сәүдә эшләре яхшырган, алыш-биреш үскән, төрле илләрдән товар агылган, яшәү шартлары да уңайланган! Без яшәгән Петербургны төзегәндә, Идел, Урал буе татарларының оста, тәртипле булуларын истә тотып, бирегә дистә меңләп татарны алып килгәннәр. Иң мөһиме, иң четерекле төзелеш эшләрен алар алып барган. Башка халыклар күпчелек очракта ярдәмче ролен генә үтәгән. Шунысын да искәртеп китәргә кирәк, Ленинград татар кешеләренең сөякләре өстендә утыра! Без Россия тарихын татарныкыннан башка аерып яза алмыйбыз. Чөнки рус язмышы татарныкы белән нык бәйләнеп барган. Йә бүлешкәннәр алар, йә берләшеп, дошманны җиңгәннәр!»

Шундый лекцияләрнең берсендә Әлмирә өч кешегә игътибар итте. Ничектер йөзләре дә таныш кебек! Кайда күргәне бар соң аның аларны, кайда? Исенә төшерә алмыйча, баш мие чыгымлады. Әлмирәнең игътибар белән күзәтүен сизеп алып, ир заты аңа башын селкеп, сәлам бирде. «Артур бит бу, аны күп бәлаләрдән коткарган абруйлы Казан егете! Минем бит аңа рәхмәт тә җиткерә алганым юк! Лёха партизанның явызлыгыннан соң, күңел газаплары кичергән өчен дә аңа биш мең доллар түләделәр, Валя алып кайтып, «мә» дип сузгач та, кире какты ул. Ничек алыйм бу акчаларны? Безне коткарганнары өчен дә мәңге бурычлы мин аларга! Югыйсә нәрсә булып бетәр иде бу хәлләр! Валя гына: «Биргәндә ал, кыйнаганда кач! – диләр бездә. Родионны үстерергә кирәк бит сиңа!» – дия торгач, улын исенә төшереп алды. Рәхмәт инде дусларына, нинди бәлаләрдән коткардылар. Алла бирсә, малаемны спорт түгәрәгенә бирәм, акчаны кирәкле инвентарь, кием-салым алырга тотармын алайса, – дип, план корып куйган иде. Аңа иң кирәкле чакта ярдәм кулы сузган татар Робин Гуды янәшәдә генә утыра. Лев Николаевичның лекциясен аның кебек бирелеп тыңлый!

...Лекция беткәч, тизрәк урамга чыгып, ишек төбендә, рәхмәт әйтергә дип көтеп тора башлады. Ниһаять, егетләр күренде. «Артур, бәгърем, бик зур рәхмәт!» – дип әйтергә генә җыенган иде, абруйлы егет иреннәренә бармагын куеп, дәшмәвен үтенде. Үзенең тән сакчылары белән китә башлагач, шулай да борылып, Әлмирәгә баш бармагын калкытты. Бу аның, «Барысы да тәртиптә, тик кеше күзенә артык чалынмас өчен аралаша гына алмыйбыз!» дигән сүзе иде. Матур итеп елмаеп алды да, урам чатына борылып, юкка да чыктылар. Нинди курку белмәс шәхес, ә күзләре зәп-зәңгәр, янып торалар. «Исән-сау йөр, батыр арыслан йөрәкле ир, мин сине яратам, якын туганым итеп яратам!» – дип кычкырасы килде аның.

Якшәмбе көн иде. Ишек кыңгыравы сәлам бирсә дә, улы белән шашка уйнап утырган Әлмирә кузгалмады. Чөнки белә: аның янына килүчеләр сирәк була. Килсәләр дә, әбиләре бакчага киткән чакта гына. Шунысы

яхшы: Таня килен, җомга көнне үк сәбәп табып, каядыр тая. Роман исә улы Родионны ияртеп, йә стадионга, йә ял паркына чыгып китә. Аек булганда гына бирә баланы Әлмирә, салмыш булса якын да китерми. Роман һаман яратам дип тора үзе, әйдә яңадан бергә кушылыйк дип ялына, эчеп алса, елап та җибәрә. Тик элеккеге хатынының гына күңеле күптән суынган. Кызганса да, хөрмәт итми ул аны! Аю кадәр гәүдәсе белән төрле ялалардан, явызлыклардан саклап калмады, ужым бозавы...

Кыңгырау тавышына, гадәттәгечә, Алевтина Ивановна чыга, бу юлы да ишекне ачканы, кем беләндер исәнләшкәне ишетелде. «Әлмирә, сиңа килгәннәр!» – дип кычкырды карчык. Родион сикереп торып: «Аслан белән Лиза апа килде, ахры!» – диде. Йомшак кына итеп кемдер ишекләрен шакыды.

– Рәхим итегез, керегез! – диде Әлмирә, сагаеп.

Бүлмәгә олыгаеп беткән Вера Андреевна килеп керде.

– Исәнме, кызым! – дип, Әлмирәне кочаклап алды.

– Вера апа! – дип, хатын шатлыгыннан бәреп чыккан күз яшьләрен сөрткәләде.

– Нихәл, Родион улым? Менә дөнья, нинди зур булып үсеп беткәнсең икән, матурым!

– Икенче елга укырга керәм, әни белән баскетбол секциясенә дә язылдык! – дип, балаларча мактанып та алды улы.

– Ой, молодец, улым. Кил әле, бер кочаклыйм үзеңне! Малай өлкән яшьтәге апага килеп сыенды.

– Әни миңа мәктәп сумкасы, дәфтәр-китаплар, ручкалар алып куйды инде! Форма да сатып алмакчы иде: «Тукта, бик тиз үсәсең, икенче елга мәктәпкә барыр алдыннан гына алырбыз, югыйсә, кечерәер», – диде. Мин бит бик тиз үсәм, Вера апа, бакчада иң озыны мин! Әни әйтә, Родион, син әтиеңә охшагансың, ди. Үскәч, мин аннан да зуррак булам.

– Булырсың, улым, булырсың! Әниең синең искитмәле тәртипле хатын бит, ул сине чын кеше итеп үстерәчәк!

– Ә мин үскәч, татар булам! Әни әйтә, татарлар бик тырыш, эшчән, матур халык, ди. Петербург каласын да безнең бабайлар төзегән, алар алынмаса, шулкадәр матур булмас иде, ди. Аннан минем Казандагы әби-бабаемны бик күрәсем килә. Әнием әйтә, улым, алар сине яраталар, сагыналар, ди. Үземнең дә бик күрәсем килә, алар белән танышасым килә. Чөнки мин аларны нык сагындым!

– Молодец, улым! Мин әле сиңа күчтәнәч тә алып килдем, – дип, Вера Андреевна үзе бәйләгән матур бияләйләр чыгарды. – Родион улым, кыш көне чана шуарга чыкканда киярсең, балам! Ә менә монысы оекбашлар, сиңа Әлмирә кызым! Рәхәтләнеп ки! Болары тузса, яңаларын бәйләп кидертермен! Нишләп килеп чыкмыйсың, кызым? Соңгы тапкыр ике ел элек күренгән идең!

– Шулай туры килде инде! – дип, авыр сулап куйды яшь хатын.

– Беләм, Әлмирә, беләм! Бер көнне гастрономда Лиза очрады, барысын да сөйләде.

– Без Родион белән Казанга кайтып китәргә җыенабыз. Моңа кадәр әти-әни күзенә күренергә оялу гына тоткарлады. Нык сагындым үзләрен,

рәнҗеп яталар инде миңа, телефоннан сөйләшкәндә дә, нык елый әнкәй! Әлегә Романнан аерылганымны, бик начар торганыбызны әйткәнем юк!

– Белдерергә кирәк, балам! Үзеңнекеләр бит! Лизаныкылар әнә кавказлыдан бала таптың дип үпкәләп йөргәннәр дә хәзер Асланны сөеп туя алмыйлар икән! Үз каннары, үз җаннары бит!

– Ә Аслан белән без дуслар! Ул миңа, мин аңа уенчыкларымны биреп торам. Менә аның «КамАЗ» машинасы! – дип, Родион әби янына күтәреп килде.

– Ой, улым, нинди зур машина!

– Көчле дә әле ул! Егерме тоннага хәтле груз тарта!

Шулчак ишек шакыдылар, «гафу итегез» дип, Родионның әтисе күренде.

– Исәнмесез, Вера Андреевна, әңгәмәгезне бүлдергәнгә ачуланмагыз!

– Юк, юк, Роман улым!

– Әлмирә, мин Родион белән стадионга барып, туп типкәләп кайтмакчы идем.

– Ур-ра, футбол уйныйбыз! – дип, малай шатланып кычкырып җибәрде.

– Ярый алайса! Тик кичке алтыдан да соңга калмагыз, юындырасым бар баланы!

– Сөйләштек! Сау булып торыгыз, Вера Андреевна!

– Сау бул, улым! Исәнлектә күрешергә язсын! – диде кунак әби. Родион белән Роман чыгып киткәч:

– Кызым, бирелгәге хәлләрне яхшы беләм, күч миңа, Казанга кайтып киткәнче рәхәтләнеп торыгыз! Ятма монда нервыларыңны бетереп!

– Чынлап әйтәсезме, Вера Андреевна?

– Әлбәттә, кызым! Кирәк чакта Родионны да карармын! Күчегез! Әле сиңа сәламәтлек бик кирәк булачак!

– Әнием кебек, дәү әнием кебек бит син миңа, Вера апа, – дип кочып алды Әлмирә өлкән яшьтәге хатынны.

– Безгә күчкәч, үзең беләсең, телефон бар, әти-әниеңә хәл белешеп, атна саен шалтыратып торырсың! Синең өчен кайгырып, борчылып яталар бит алар. Соңгы тапкыр Родион туганчы гына кайтып килгәнсең.

– Шулай шул, Вера Андреевна! Нәкъ шулай! Роман белән тора башлаганның беренче елларында гел җыендык! Тукта иртәгә, тукта берсекөнгә дия-дия суза торгач, еллар үтеп китте. Безнең тормышны әнисе боза, шул кайгыдан Роман да эчә башлагач, ничек кайтып күреним, ничек әти-әниемә аңлатыйм бәхетсез тормышымны дип, туктала килдек.

– Юкка, кызым, әниең барысын да кичерер, аңлар иде. Әйдә, җыена башла, иртәгә улым машинасы белән килеп алыр! Безгә күченүгә туганнарыңа хәл белеп шалтыратырсың!

***

– Нихәл, әнкәй?! Әти сау-сәламәтме? Бернәрсә дә яшермим, әнкәй! Барысы да тәртиптә! – дип, көчкә әйтә алды Әлмирә.

– Кызым, Әхмәт абыең түзеп йөрде-йөрде дә дөресен сөйләп бирде. Аерылышкансыз икән бит сез! Ятма анда үзеңне интектереп, кайтыгыз. Абыең белән җиңгәңә ике бүлмәле фатир бирделәр, килеп-китеп кенә йөриләр хәзер, кайтыгыз. Югыйсә кыр хәтле фатирда икәү генә калдык, көтмә без үлгәнне, исән чагыбызда яныбызда булыгыз!

Тетрәндерде бу сөйләшү Әлмирәне! Әнисен кызганып, йөрәге әрнеде. Икенче көнне үк ул пропискадан төшеп, мәңгелек Казан шәһәренә җыена башлады. Китәселәренә ике көн калгач, дусты Лиза белән, Валяларга барып аерылу сагышыннан кочаклашып елаштылар.

– Мин икегезне дә Казанда кунакка көтәм, зинһар, кайтып йөрегез. Сез минем өчен Ленинградта иң кадерле кешеләр! Вера Андреевна исә анам кебек!

Кайчандыр ятсына-читенсенә генә ияләшкән шәһәре белән аерылышу да җиңелләрдән түгел икән! Белем биргән институтын, укытучыларын ничек онытсын инде ул! Менә хәзер үзе өчен бала чагыннан ук кадерле булган туган шәһәре ничек каршы алыр аларны?

***

– Әни, әни, минем бер дә рус буласым килми, миңа татарлар күбрәк ошый!

– Синең бит әле татарларны күргәнең дә юк миннән башка!

– Әхмәт абый, ул чын татар бит!

– Син дә, улым, чын татар, чөнки синең дәү әтиең, дәү әниең, якыннарың барысы да – саф татарлар!

– Әни, ярыймы, мин исememне Ринатка алыштырам! Безнең балалар бакчасында шундый исемле малай бар, хәтерлисеңме?

– Әйе, улым! Исемеңне генә түгел, фамилияңне дә минем кыз чагындагысына күчерәбез! Ринат Закиров! Ничек матур яңгырый, хәтта күңелгә рәхәт! Ярый, улым, син ят инде, соң инде, әле поездда бик озак кайтасыбыз бар!

– Әни, тик Казанга җиткәч, мине уятырга онытма, яме!

– Яхшы, улым, тыныч йокы, – дип, улын үбеп, одеялын аның өстенә япты.

Малай күзләрен йоммыйча, дәү әнисе, дәү әтисе, Әхмәт абыйсы белән күрешәчәкләрен күз алдына китереп ятты да йокыга китте.

***

Шимбә көнне улы белән Әлмирәсен сагынып өлгергән Роман әнисенә:

– Тренировкага киттем әле! – дип ялганлап чыгып китте. Танясы җомга көнне үк, гадәттәгечә, мамуляларга барам әле дип чыгып тайган иде. Ир заты бу галәмәтләргә ияләшкән, хәтта битараф иде. Өстәвенә, ир белән хатынны бәйләп тотучы балалары да юк. «Башта айны, аннан күз күрер», – дип җавап бирде Таня, сүз шуңа терәлгәч. Менә Алевтина анасы да: «Кайчан миңа бер онык алып кайтасыз инде?» – дип, исләренә төшереп тора. Әлмирәләрдән бушаган йокы бүлмәсенә күчкәч, бөтен мөмкинлекләр дә бар югыйсә. Ике кодагый татар духын куабыз дип, бүлмәне хлорлы сулар белән юып, чүпрәк-чапракларын, хәтта элеккеге киленнән калган гөлләргә хәтле чүплеккә чыгарып бәрделәр. Чиркәүдән поп чакыртып, өшкерттеләр. Элек чисталык бөркеп, балкып торган бүлмә бер атнадан бардакка әйләнде. Анда күкрәк капчыгы, монда трусик-майка, диванда сорочка-халат, идәндә юылмаган киемнәр чәчелеп ята. Таня тәртипкә китерергә уйламый да.

***

Ишекне Вера Андреевна үзе ачты.

– Ә-ә, Роман улым икән! Тик соңга калдың! Әлмирәләр Казанга кайтып киттеләр шул! – диде күңелсез генә.

– Кайчан киләләр?

– Беркайчан да! Тиз генә пропискадан төште дә...

– Пропискадан да төште? – дип тетрәнеп куйды Роман. Аның өчен ярты дөньясы беткән, кителгән иде. «Ул сиңа Ленинград пропискасы кирәк булганга гына кияүгә чыккан, тиздән ярты фатирны бүлеп ала!» – дигән әнисенең явызлыклары исенә төште. Миңгерәп калган Роман саубуллашырга да онытып, баскыч буйлап түбән тәгәрәде. Вера түтәенең ишеге ябылганын гына чамалады ул. Ишек түгел, бәхете ябылгандай тоелды аңа.

– Син мине Родионсыз, яраткан кешемсез калдырдың! Әлмирә пропискадан төшеп, улымны алып, Казанга кайтып киткән, – дип акырды ул үз гомерендә беренче тапкыр. – Син мине, явыз карчык, бәхетсез иттең! Тизрәк дөмексәң иде, кабахәт җан! – дип анасына ташланды. Алевтина түтәйнең борынына затсыз аракы исе килеп бәрелде, ул, куркып, артка чигенде.

– Син нишлисең, улым? Нишлисең, газиз анаңа әллә кул күтәрергә җыенасыңмы? – дип, йөзен каплады.

– Бар, өнеңә кереп кит, карт ерткыч! – дигәч, Роман залга үтеп, идәнгә ауды да үксеп елап җибәрде.

Бу хәлләрдән соң тагын бер ай вакыт үтте. Салмыш Роман өметсез күзләре белән телевизорга төбәлеп утыра иде, кычкырып җибәрде.

– Әнә кара, Алевтина Ивановна, синең аферисткаңны күрсәтәләр, кара әнә, кара, – дип чакырды.

– Кичә Ленинградта, аның тирә-ягында эш итеп ятучы мошенница Аграфена Чудакова кулга алынды. Ул беркатлы ышанучан бәндәләрне «Сезгә бозым ясалган» дип, акча савып яткан. Фатирында яшерелгән алты миллион акчасын конфисковать иткәннәр.

– Булмас ла! – дип ышанырга теләмәде ахмак хатын. Әлмирәнең ятагында әллә нинди язулар бар иде бит, үзем таптым.

– Вера Андреевна әйтә, алар Коръән догалары булган. Мамуля, син бит шул мошенницага гомерең буе җыйган суммаларыңны чыгарып салдың! Бер машина сатып алырлык тәңкәләреңне...

– Алайса минем бүлмәдәге төенчектәге гүр туфраклары каян килде?

– Гүр туфрагымы, мүр туфрагымы, шайтан белгән! Аның өендә андый янчыклар дистәләп табылган. Хуҗалар күрмәгәндә үзе ыргытып чыга торган булган! Син бит намуслы, саф Әлмирәмне бозым салган дип, нахакка рәнҗеттең. Гөнаһысын ничек күтәрерсең, чын христианка!

– Булмас ла, булмас ла, булмас! – дип, исәрләнеп калган хатын бүлмәсенә кереп китте.

***

Кече кызлары белән оныклары кайту хөрмәтенә барысы да төп йортка җыелды. Родион алар арасыннан Әхмәт абыйсын гына таный, күреп белә иде, алдыннан төшмәде. Чәй өстәле янында утырганда гаҗәпләнеп,

барысын да гөнаһсыз күзләре белән тикшереп чыкты, «Нәрсә карыйсың, улым, шулай?» – дип сораган әнкәсенә:

– Үзебезнең чын татарларны күзәтәм, – дигән иде, Әхмәт абыйсы шаркылдап көлеп җибәрде. Аңа башкалар да кушылды. Дәү әниләре Галиянең дә шатлыгы эченә сыймады. Яраткан төпчек кызы белән оныгы кайтсын әле!

– Әй, Родион, җимешем минем! – дип аркасыннан сөйде.

– Мин, дәү әни, әле Родион гына, Ринат булгач, мин дә татарга әйләнәм! – дип, барысын да шаккатырды.

– Абый, Родион үзе шулай тели, исемен алыштырасы иде, фамилиясе дә Закиров булачак!

– Афәрин, энекәш! Безнең кан күбрәк, ахры, синдә, – дип куанды Әхмәт абыйсы. Аннан: – Иртәгә белешермен, сеңлем! – диде.

– Алия апа, син бит мәктәптә эшлисең, Родион кайбер сүзләрне белә, ләкин аны яхшылап татарчага өйрәтәсе иде.

– Без проблем! Чишмәледә төрек-татар лицее ачылды, бик талантлы балаларны гына җыялар, күреп торам, Родион фикер йөртә белә!

– Мин әле меңгә хәтле саный да беләм. Футбол да уйныйм. Дәү әти, ә син минем белән гол кертерсеңме?

– Әлбәттә, балам! Көн саен уйнарбыз!

– Аннары мин гармунда уйнарга өйрәнергә телим. Мин уйныйм, әни җырлый, шулай бит, әни? «Мин сине яратам, мин сине яратам, мин сине барыбер үземә каратам»! – дип, малай кечкендән өйрәнгән җырын җырлап күрсәтте. Бар да аңа сокланып, кул чаптылар.

– Афәрин, улым, болай булгач, гармун алып бирмичә ярамас! – диде Әхмәт абыйсы шунда: – Кайтасы да ерак! – дип, урыныннан кузгалды. Барысы белән дә кочаклашып саубуллашты: – Сеңлем, сиңа гына әйтәсе сүзем бар иде, – дип, читкәрәк алып китте. – Әлмирә, Таллы Күлгә кайтып кил әле син бер!

– Нишләп, абый? – диде Әлмирә, нидер сизенеп.

– Исрафил абыең ике ай госпитальдә яткач, авылга кайтты! Кавказда иде ул, каты яраланган, көчкә исән калган! Хәле начар!

– Ә гаиләсе?

– Юк аның гаиләсе, өйләнмәгән әле дә! Кайтып кил әле син, шулай ук дәү әнинең ихатасын да күреп килерсең, – диде.

***

– Улым Исрафил, тор әйдә, районга хәрби комиссариатка барам, дигән идең түгелме соң, тор, юын, чәйләр эчеп ал! – дип, әнисе Хәсимә апа улын йокысыннан уятты. Егет торып утырды, тәнен язар өчен гәүдәсен уңга-сулга, өскә-аска боргалады, операция урыннары әрнеп китеп, ыңгырашып куйды. Караватбашына ябышты, аякларына басты, урындыкка сөяп куелган таягын иелеп алды да сул аягына аксый-аксый килеп, ишек төбендәге элгечтән чалбарын үрелеп алды. Кире килеп, урындыкка утырды да кия башлады, таягы этелеп китеп, идәнгә төшеп шалтырады. Тавышка әнисе йөгереп керде.

– Әй, улым, әйтмисең дә, үзем булышкан булыр идем...

– Юк, юк, әнкәй! Ашыкмыйча гына мин, борчылма! Врач: «Тагын берәр айдан йөгереп йөри башлаячаксың! Иң куркыныч чорын үттең инде, әкренләп, аякка басачаксың», – диде.

Ул арада Хәсимә таягын китереп тоттырды. Исрафил, аксый-чатанлый, ишегалдына чыгып, су краны ягына атлады. Яшьтән өйрәнгән гадәте буенча рәхәтләнеп юынды. Сөлге белән ышкынып, тәнен генә корыта башлаган иде, колагына: «Исрафил абый!» – дигән назлы тавыш килде. Ахры, контузиядән соң калган галлюцинация саташуы гынадыр!

– Исрафил абый! – дигән тавыш тагын кабатлангач, эндәшүнең чынбарлыкта икәнлеген сизенеп турайды да катып калды. Борылып карарга да куркып: «Әлмирә бит бу! Үзе генәме, әллә гаиләсе, ире белән кайтканмы?» – дип уйлады. Салмак кына борылды. Күрше йортның ихатасында кунак кызы басып тора иде.

– Әлмирә! – дип кенә әйтә алды ул, сулышы кысылып, сүзсез калды. Зур шомырт кара күзләреннән эре яшь бөртекләре коелды, сөлгесен битенә каплап, ут-суларны кичеп кайткан солдат, дерелди-дерелди, үксеп елый иде. Казан кызы күрше егетенең тән яраларын күреп, өне китте, аркасында өч җирдә операцияләрдән соң барлыкка килгән җөйләре бүселеп тора. Ләкин әле ул аның нинди авыр йөрәк яралары йөрткәнен белми иде. Хатын атылып кереп, яшьлек мәхәббәтен кочып алды.

– Менә кайткан идем әле, Исрафил абый, әбием нигезен сагынып... – диде, сине дә дип әйтергә теле әйләнмәде, кодрәте җитмәде.

– Нишләп син минем хатларыма җавап бирмәдең, Әлмирә? – дип әрнеп сорады яралы егет.

– Сезнең өйләнгәнне, кайдадыр балагыз да калганны ишеттерделәр дә...

– Безнең авылның Сәвия ул. Мин госпитальдә ятканда үлә дип белеп, килде дә: «Кичер мине, Исрафил абый, үлеп яраттым сине, минем кебек беркем дә сөймәячәк сине! Әлмирәгә аның солдатта хезмәт иткәндә баласы калган, аннан Кавказда медсестрага өйләнгән, дигән хатларны җибәргән идем, зинһар, рәнҗеп китмә, Исрафил абый, кичер», – дип тезләнеп елады. Шуннан гына мин синнән хатлар килмәүнең сәбәбен аңладым.

– Димәк, сезнең хатыныгыз да, балагыз да юк.

– Утызга җиттем, әлегә юк! – дигән иде, авыр күңел өзгәләнүләре кичергән хатын һушыннан язып, ишегалдындагы бәбкә үләнгә ауды. Сәламәтлеге рәткә килеп бетмәгән Исрафил аны тотып кала алмады. «Әни, тиз бул, чык әле, Әлмирә!» – дип кычкырды.

***

Романның бүген дә хәленә кереп, спорт комитетыннан 500 сум акча бирделәр. Күп түгел, тик шулай да рәхмәт инде, элеккеге тренеры Андрияновка да. Әллә кызганып, әллә бераз гына булса да ярдәмем тисен дип булышкалый. «Эчүеңне ташла, яшүсмерләргә тренер итеп куярмын!» – ди. Ир үзе дә каршы түгел белгән-яраткан эше белән шөгыльләнергә. Әлмирә белән газиз улы ташлап кайтып киткәч, кайгыдан тагын да ныграк бетереште. Өенә кайтса да, базага барса да, бушлык иде аның күңелендә. Шул бушлыкны аракы белән тагын да ешрак тутыра башлады. Яшәргә бернинди максаты калмаган адәм теге биш йөз сумны ваклап, рюмочныйга

кереп чыкты, йөз илле граммны тончыктыргач, арлы-бирле йөрде дә кабат кереп өстәде. Кесәсендә тиеннәр генә калгач, өенә юл алды. Паркны кистереп чыкканда, кемдер аңа: «Сәлам, Рома!»– дип кычкырды. Борылып караса, җирле бандит Лёха партизан басып тора иде.

– Сәлам, Лёха! – дип теләр-теләмәс кенә, күңелсез генә әйтеп куйды. Ләкин теге Романның иренеп кенә сөйләшүен үзенчә аңлап:

– Ну, шулай килеп чыкты инде, братан, барып чыкмады! – диде гафу үтенгәндәй.

– Була торган хәл, – дип кенә куйды пәһлеван егет иренеп кенә, сүзнең ни турында барганлыгын аңламаса да.

– О-о-о, синең хатының артында нинди кешеләр тора! Валентина, беләсеңме, нинди абруйлы! Казанның иң зәһәр егетләре белән әшнәлектә!

– Валентина Валерьевнамы?

– Әйе, ул үзе! Әгәр дә шул себерке булмаса, сөйләшкәнчә, синең уйнаштан туган малаең белән себерке Әлмирәңне манчый идек, ну гафу ит, братан, барып чыкмады.

– Нинди уйнаштан туган малай, нинди себерке Әлмирә?! – дип, күзләре калайланып килде Романның. Ул хәзер өстеңә ташланырга торган, котырган үгезне хәтерләтә иде.

– Ну, син усалланма, сез биргән аванс акчаларыгыз чүп кенә ул, «за моральный ущерб» миңа биш мең доллар түләргә туры килде. Сумнарда гына түгел, баксларда! – дип, бармакларын ышкып күрсәтте җирле авторитет.

– Биш мең доллар?!

– Әйе, биш мең! Зинһар, Алевтина Ивановнага әйтегез, кире кайтара алмыйм әлегә аның миңа заказ биргән акчаларын! Менә күп итеп, ишелеп төшсә, бәлкем өлешләп түләрмен!

– Син нәрсә, хәсис! Минем улым Родион белән яраткан хатынымны үтерергә җыендыгызмы? – дип, мондый яңалыктан шашып калган ир көчле куллары белән мафиоз егетне тотып алып буа башлады.

– Син нәрсә, хайван, син нәрсә?! – дип чәбәләнде Лёха партизан. Шул чак Романның башына артыннан күсәк белән китереп тондырдылар.

Аңына килгәндә, кемдер милиция белән ашыгыч ярдәм күрсәтү машинасын чакырткан, күрәсең, формалылар белән ак халатлылар янында кайнаша иде. Кемдер: «Исән!» – дип әйтеп куйды. Иминлекне саклау вәкиле: «Кемнәр иде алар, таныдыгызмы?!» – дип төпчende. Рома:

– Арттан бәрделәр, күрми калдым! – дип ялганлады. Бер өлкән яшьтәге түтәй дә:

– Да, да, артыннан суктылар аңа! – дип дәлилләде. Нәрсәдер язган-сызган булдылар да Роман аягына баскач, китеп югалдылар.

***

– Валя, нәрсә булды анда, нигә мин белми калдым. Лёха партизан нишләп минем улым белән Әлмирәмне үтермәкче булган?

– Роман, синең оешмаганлыгың, акылсызлыгың аркасында да бик әздән генә улың белән Әлмирәңнең башына җитмәделәр.

– Кем, кем эше ул?

– Сөйлисем дә килми, тик шулай да әйтим инде, улың белән хатыныңны әниең заказать иткән! Башта пропискадан төшсен, дип куркытып карагыз, тыңламаса...

– Лёха партизан шундый җинаятькә барган булыр идеме?

– Алевтина Ивановна денсез Лёхага Әлмирәне бөтен тулай торак белән йоклаган фахишә иде, улыма кияүгә чыкканчы ук балага узган булган, хәзер соңгы фатирыбызны бүлеп алмакчы, Казаннан унар туганы килеп, ашап-эчеп яталар, бүлмәмнән дә чыгарга куркып ятам, дигән.

– Чыннан дамы??

– Син, Роман, саф күңелле, намуслы кешене югалттың! Калган гомереңдә шундыйны таба алырсың микән?!

– Әлмирә, бәгърем, улым Родионым, кичерегез мине, – дип акырды ир кеше. Аның йөрәк яргыч тавышыннан тәрәзә пыялалары чыңлап, шкафларга хәтле селкенеп куйды.

***

Август аеның соңгы көннәре. Быел көз бик тиз килер кебек тоела. Агач яфраклары төрле төсләргә керә башлады. Бигрәк тә каеннарда сары төсләр күренгәли. Иртәрәк түгелме?! Шулай да бүген көн искитмәле: аяз һава, зәңгәр күктә кояш мул итеп нурларын сибә, җиле дә тынып калган. Әлмирәләрнең күңелле үтте бүгенге көннәре. Улы Ринат беренче тапкыр зур оркестрда баянда уйнады. Уналты яшьлек яшүсмернең шул югарылыктагы сәнгатькә кереп китүенә ничек куанмыйсың, ди. Алар уйнаган музыкага бит республиканың иң-иңнәре, иң талантлылары җырлады. Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхәбиев, Зөһрә Шәрифуллиналар яңгыратты бүген татар моңнарын, бәйрәм концерты өч сәгатькә сузылды.

– Рәхмәт, улым, куандырдың, – дип мактап куйды әнисе аны, кара бөдрә чәчле башыннан сыйпап.

– Бабама рәхмәт, бала чагымда миңа баян алып бирмәгән булса, бүген андый йолдызлар белән концертта катнаша алмас идем. Әни, анда беләсеңме, бәйрәмгә Әлфия апа, Илһам абыйлар да килгән иде. Оркестрның арткы ягында Шамил Зиннурович белән сөйләшеп тордылар.

– Шулаймыни?

– Әйе! Мин каерылып-каерылып карагач, Әлфия апа күз кысты!

– Чынлапмы, улым!

– Әйе! Әни, әйдә кайтыйк инде, иртә таңнан баян күтәреп йөреп, ардырды, дәү әни яраткан өчпочмакларыңны, пәрәмәчләреңне пешереп куям дигән иде. Бу Татар ашларына кереп тормасак та була иде.

Галия ханым балаларын ишегалларында ук көтеп тора иде.

– Әни, нәрсә булды, кибет-мазарга чыкмагансыңдыр бит? – дип сорады Әлмирә.

– Кызым, сиңа гына әйтәсе сүзем бар! – дип, әнисе Әлмирәсен читкә алып китте.

– Анда бик озын гәүдәле ир кеше килде. Сине күрәсем бар иде, ди. Әллә мәйтәм, теге... – дигәч, әби кеше сораулы карашын ташлап, туктап калды.

Хатынның йөрәге «жу» итеп китте. «Роман бу!»

– Өйдә юклар, кайчан кайтасыларын да белмим дигәч, мин Ленинградтан,

әй, хәзергечә Петербургтан, ди. Басып тормасын дип, подъездга урындык чыгарып бирдем.

– Ярый, әни, дөрес эшләгәнсең, бар керә тор, без хәзер! – дигәч, Галия ханым ире янына ашыкты.

– Исрафил, нинди җилләр ташлагандыр, бәлкем ун елдан соң улын күрәсе килеп киткәндер, Роман эзләп тапкан. Зинһар, үпкәләмә инде.

– Син нәрсә, матурым, улын күрәсе килгәч, начар түгел инде, шулай бит, улым?!

– Минем бер генә этием бар, ул да булса син! – дип, Ринат Исрафилны кочып алды.

– Рәхмәт, улым!

– Кызым Сөембикә, ә син хәзер кергәч, дәү әниеңә булышырсың, без теге абыең белән сөйләшеп алабыз яме, балам!

– Яхшы, әнкәй!

Подъездда чәчләренә чал төшкән, ябык, күз төпләре пилмән сыман бүлтәеп чыккан, чыраенда яшәү дәрте качкан Роман Мартыниянович басып тора иде. «Йа Ходаем, шәүләсе генә калган!» дип, Әлмирә аны кызганып куйды.

– Зинһар, гафу итегез, менә улым Родионны соңгы тапкыр булса да күрергә дип килдем. Нихәл, улым?

– Яхшы, Роман Мартыниянович! – дип, Ринат төбәлеп, бу мескен кыяфәтле кешегә җентекләп карап тора башлады.

– Кичерегез безне, зинһар, һәм мин ахмакны, сезне яклап та, саклап та калалмаганым өчен!

– Үткән эшкә салават, диләр бездә. Улым, чакыр Романны өйгә, чәй эчеп китәр, күршедән генә кермәгән бит, – диде Исрафил аптырап торган улына. Үзе ачык ишеккә юнәлде. Аның артыннан Әлмирә дә кереп китте.

– Ничек яшәдегез соң, улым?

– Аллага шөкер, Роман Мартыниянович!

– Чын ир кеше булгансың, Родион улым!

– Ринат мин, Ринат Исрафилович Закиров!

– Үзгәрткәнсең икән.

– Башка халыкларны сөймәс милләт вәкиле булып яшисем килмәде минем. Аллага шөкер минем әнием генә түгел, үзем дә йөз процентлы татар! Бәлкем әле ике йөз процентлыдыр. Синнән миңа мирас булып спортка тартылу гына күчкән. Мин хәзер УНИКСның үсмерләр командасында уйныйм.

– Молодец, улым! Татарлыкка күчеп, дөрес эшләгәнсең! Поезд тәрәзәсеннән авыл-шәһәрләрегезнең матурлыгын, кырларда барган эшләрне күреп сокландым. Безне бит гомер буе алдадылар, хәзер дә ялганлыйлар. Соң аңладым, – дип, көтелмәгән кунак тынып калды. Ишектә Исрафил күренде.

– Улым, әйдәгез, чакыр кунакны, чәебез суына, – диде.

Өстәл артында утырганда, Әлмирә түзмәде:

– Алевтина Ивановна, Танялар ни хәлдә соң? – дип сорады. Роман авыр сулап куйды.

– Әнкәйгә өч ел элек инсульт булган иде, Татьяна: «Әйдә, инвалидлар

йортына озатабыз!» – дигәч, мин каршы килдем. «Алайса астын да үзең чистарт, үзең юындыр да, киендер дә!» – дип чыгып китте. Әнкәйне өч ел буе үзем тәрбияләдем, бер ай элек китеп барды.

– Авыр туфрагы җиңел булсын! – дип куйды Әлмирә.

– Үләренә бер өч ай кала, сизенгәндер инде китәсен, чакырып алды. «Улым, соңгы әманәтем, фатирны үзеңнән соң үтенеп сорыйм, сатып эчеп бетерә күрмә, Родионга яздыр, мин бит аңа, җан кисәгемә, бер генә дә яхшылык эшләмәдем. Мине анда да тәмуг утлары көтә, бусында да соңгы өч елымны шунда яшәдем, – диде. – Әлмирәдән мине бәхилләвен тезләнеп сора, үтенәм синнән, Казанга кайтып кил», – диде.


Кунак кеше искереп барган кәчтүменең эчке кесәсеннән кәгазьләр чыгарды да Ринатка сузды.

– Бу – фатирның сиңа дип яздырткан документлары. Ринат Закиров исеме белән йөргәнеңне Валентина Валерьевна әйтте. Бәхетле бул, Ринат! Рәхмәт сезгә, миңа поездга соңга калырга ярамый, зинһар, гаеп итмәгез! – дип, Роман китәргә ашыкты.

Китте Роман Мартыниянович. Авыр тойгылар калдырып кайтып китте. Гомер ничек тиз үтә, ничек аяусыз икән ул! Шуңа күрә кадерен белеп, мәгънәсен табып, әйләнә-тирәңне хөрмәт итеп яшәргә кирәк! Тик соң аңлыйбыз икән шул! Кеше бәхетен җимереп, үзеңнекен бәрәкәтле итеп төзеп булмый! Моңа Исрафил белән Әлмирә күптән төшенделәр. Кызлары белән улларын татар иманында тәрбияләргә тырышалар. Яшәвебезнең кадерен белегез дип, бик еш төшендереп торалар.

Роман Балахолкин кайтып китүгә бер атна да үтмәде, Валентина Валерьевна элемтәгә чыкты. «Әлмирә, кадерлем, Ринат белән Исрафилны алып, Петербургка килеп китегез әле! Кичә Роман Мартыниcivaновичны җирләдек. Лиза да килгән иде улы Аслан белән. Барыгызны да нык сагындым, бик күрәсем килә, зинһар, Исрафилны алып кил, үзе бит ул, мине кайткач, өрмәгән җиргә дә утыртмый. Сузмагыз, тагын бер айдан мине чит илгә эшкә җибәрәләр. Фатир документларын онытмагыз, тиз генә рәсмиләштерергә булышырмын. Галия апага да, чибәркәй Сөембикәгә дә зур сәлам! Барыгызны да кочаклыйм, пока-пока-пока!»

Нишләп адәм балалары Лиза, Валя, Вера Петровналар кебек кешелекле түгел икән?! Югыйсә алар да бит рус өммәтеннән. Бәлкем алай да түгелдер?.. Петербургны төзегәндә, татарларның бер өлеше шунда төпләнеп калган, ди бит! Гумилёв бабай шулай, ди.



Идият
Аширов

# БЕЗ БУ ҖИРНЕҢ БАРЫ КУНАКЛАРЫ

## Гомерләрнең кышкы балкышы

Декабрьнең соңгы минутлары...
Яңа елны көтә кешелек.
Аяк басу белән яңа таңга
Килер төсле бәхет ишелеп.

Һәр ел саен шулай хыялланып,
Өметләнеп яшидер кеше.
Үтеләсе еллар-чакрымнарның
Яхшырагы алдадыр төсле.

Онытыла тормыш ваклыклары,
Матур уйлар тула күңелгә.
Һәм телибез: Ил-көн имин булсын,
Саулык, муллык иңсен һәр өйгә.

Кабатлана ел да шушы халәт –
Гомерләрнең кышкы балкышы.
Кешелекнең зур ышаныч белән
Яңа елга кереп барышы.

## Карлар ява

Карлар ява. Кышның да бит
Үз бизәге, үз ямьнәре.
Сүтелгәндер кебек күктә
Әниемнең каз мендәре.

Карлар ява. Күчә җиргә
Аклыклары, сафлыклары.
Күмелеп кала кар астында
Тормышның бар ваклыклары.

---

Идият АШИРОВ (1947) – *шагыйрь, «Гомер юллары», «Урал аһәңнәре», «Әманәт», «Күзләр балкышы» һ.б китаплар авторы. Пермь краеның Барда район үзәгендә яши.*

Ак төсләрдән, пакь хисләрдән
Җылынып китә дөньям тагын.
Карлар ява, сагындырып
Ерак калган малай чагым.

## Авылым таулары

Таулы якта туып үскәнгәме,
Кечкенәдән тауга гашыйк мин.
Кайткан саен илһам, көч алырга
Иң беренче шунда ашыктым.

Малай чакның рәхәт минутларын
Таулар белән ешрак бәйләдем.
Кышларында чаңгы, чана шудым,
Җиләкләрен җыйдым җәйләрен.

Хәтеремдә тауга менгән чаклар,
Шау-гөр килеп, кичке уенга.
Әти сөйли: «Элек бу тауларда
Бәйрәм иттек Сабан туенда».

Үткәннәрнең телсез шаһитләре –
Табыла монда окоп эзләре.
Күргән төсле булам шул чагында
Бабамнарның кырыс йөзләрен.

Монда алар гомер кичергәннәр,
Тормышлары булган кыеннан.
Бәхет эзләп читтә йөргәне дә
Ахыр монда кайтып сыенган.

Менгән саен һаман биеккәрәк,
Сафлана җан, арта хозурлык.
Тауга карап, таулар булмасак та,
Без шулардан алдык горурлык.

Кечкенәдән канга сеңеп калган
Авылым тауларына тугрылык.
Шушы хисләр бүген чишмә төсле
Йөрәгемнән чыга ургылып.

## Нәселебез – игенчеләр нәселе

Нәселебез – игенчеләр нәселе,
Без – бу җирнең эшче куллары.
Күзләр кергән чакта,
Сөйләр безнең хакта
Тук башаклы иген кырлары.

Бетховенның симфониясенә
Алыштырмыйм тургай җырларын.
Белмидәдер әле шәһәр кешеләре
Авылларда мондый моң барын.

Килмәгәнбез юкка без бу җиргә,
Без – игенче халык уллары.
Шуңа җанга якын
Гүзәл туган якның
Арыш кыры, басу юллары.

## Хуҗасыз йорт

Утлар сүнгән. Хуҗасыз йорт
Кемне каргап ятадыр?
Шушындый йортларга карап,
Җанда сагыш артадыр.

Ишегалдын җәен чирәм,
Кышын карлар басадыр.
Ябылып бетмәгән капка –
Каерып җилләр ачадыр.

Әле кайчан сау хуҗалар,
Инде гүрдә ятадыр.
Балаларның үз кайгысы,
Монда сирәк кайтадыр.

Хуҗасыз йорт. Шомлы тынлык.
Күңелне моң басадыр.
Үги калган бу нигездән
Фәрештәләр качадыр.

Хуҗасыз йорт. Бер уйласаң,
Гаепләү дә хатадыр.
Бәлки «өстәгеләр» безне
Бетерәбез, дип, ятадыр.

## Без бу җирнең бары кунаклары

*Сәүбән Чуганаев көе.*

Керде алтын көзләр,
Шиңде яфрак-гөлләр,
Үтеп үзәкләргә җил исә.
Әллә инде без дә
Гомер көзебезгә

Кереп барабызмы югыйсә?

К у ш ы м т а:
Килү, яшәү, китү,
Кабыну, яну, сүнү –
Әйтерсең лә, утлы күмерләр.
Без – бу җирнең бары,
Бары кунаклары.
Һай кыска шул, кыска гомерләр.

Бушап калды кырлар,
Тиздән төшәр карлар.
Җанга сагыш өргән көз үтәр.
Абынмый ялгыштан,
Зарланмый язмыштан,
Гомер итүләргә ни җитәр?!

К у ш ы м т а.

Кыш артыннан язлар,
Аннан җәйге назлар
Бер-бер артлы тезелеп үтәләр.
Кешеләр дә шулай,
Аккан дәрья судай,
Киләләр дә җиргә... китәләр.

## Яшәешнең ике чиге

Елап туа кеше. Сөенәбез,
Елаганын күреп.
«Бәхетең белән кил әйдә», – дип,
Мактауларга күмеп.

Еламыйча китә кеше,
Озатабыз елап.

Искә алып гомер юлын,
Яхшылыгын уйлап.

Туу, үлү – яшәешнең
Бары ике чиге.
Килә, китә, онытыла,
Яши игелеге.

## Күңелем язларны сагына

Тагын килде язлар,
Кайтты киек казлар.
Кояштан җылы нур коела.
Язгы матур көндә,
Кошлар кебек син дә
Кайтып килерсең күк тоела.

К у ш ы м т а:
Саф сөю – мәңгелек,
Сулмый ул гөл кебек,
Йөрәктә ут булып кабына.
Яшьлек тиз узганга,
Ахрысы, шуңа да
Күңел гел язларны сагына.

Су буе, болыннар,
Без йөргән урыннар
Чәчәккә күмелде быел да.
Тәүге саф сөюне,
Януны, көюне
Санап йөрегәнбез уенга.

К у ш ы м т а.

Һаман истә әле
Яшьлекнең шул мәле,
Күңелгә моң булып уела.
Күп еллар узса да,
Хыялда булса да,
Кайтырсың шикелле тоела.

## Моңсу халәт

Моңсу калган кырлар, урман тып-тын,
Ишетелми кошлар тавышы.
Кыштыр-кыштыр яфрак төшә җиргә,
Көрәне бар, кызыл, сарысы...

Куе томан сарган су буйларын,
Баш өстендә болыт агышы.
Сибәләп кенә яуган яңгырларның
Күңелләргә күчә сагышы.

Кабатлана ел да шушы халәт –
Табигатьнең күзгә балкышы.
Гомеремнең бүген шундый чагы –
Алтын көзгә кереп барышы.

## Кереп барабыз кышка

Үтте-китте җылы көннәр,
Керәбез инде кышка.
Әле кайчан алтын көзгә
Сокланган идек, юкса.

Еласаң да, җырласаң да,
Туктамый, гомер кыска.
Шунысына күңел тыныч,
Үтелмәгән ул бушка.

Соңгы көннәре көзләрнең –
Төне озын, көн кыска.
Сау гомер сорап Ходайдан,
Кереп барабыз кышка.

## Рәхмәтлемен язмышыма

Кемдер килә, кемдер китә,
Карамый бернигә.
Нишлисең, Җир-Ананың без
Бер бөҗәге генә.

Табигать кануны шундый:
Килү, яшәү, китү.
Кирәк аз гына булса да
Эз калдырып үтү.

Башкармасам да зур эшләр –
Азрак яздым-сыздым.
Ничә пар итек туздырдым,
Күпме юллар уздым.

Атлап керелсә дә бүген
Инде җитмеш бишкә,
Зарланырга, «Уф», – дияргә
Исәбем юк һич тә.

Ник уфтаныйм, берәүне дә
Рәнҗетмәдем кебек
Кеше малына кызыгып,
Өлешенә кереп.

Яхшылык җиңәргә тиеш,
Дип ышанып йөрдем.
Куенында таш йөрткәнгә:
– Кеше булыйк, – дидем.

Тормышта төрле чак булды,
Үкенмим үткәнгә.
Рәхмәтлемен язмышыма –
Бәхетле иткәнгә.

**Редакциядән:**
*Бу айда каләмдәшебез үзенең олуг юбилеен – 75 яшьлеген билгеләп үтә. Без аңа бәрәкәтле озын гомер, алга таба да шулай милләттәшләрен шатландырып иҗат итүен телибез.*

Марат
Кәбиров

# ТИК СИН ГЕНӘ

ПОВЕСТЬ

**14**

«Каршылыклар кыры»н узгач, Илнур берничә адым читкәрәк атлады да чирәмгә ауды. Чалкан төшеп, кулларын як-якка сузып тынып калды. Һавада зәңгәрсу болытлар йөзә. Нindидер саф, үзенчәлекле төс бу, җирдә очрамый торган... Болытларның чите кояш нурларында эреп, үзенчә бер төскә кергән. Ул төсләрнең нинди икәнен дә төгәл генә әйтеп булырлык түгел, кайберләре зәңгәрсу, кайберләре саргылт. Кояш нурларының тәэсире нәтиҗәсендәдер инде һәркайсы үзенчә балкый...

Остаз иртән нәрсә дигән иде әле? Кояш нурлары... Кояш бер булса да, аның нурлары бихисап һәм төрлечә. Сез дә шул кояш нурлары кебек барыгыз да бертуган. Барыгыз да уртак максат өчен яшисез, хезмәт итәсез. Сез – бертуганнар!

Бертуган булгач, бер максат өчен хезмәт иткәч, бу егетләрнең берәрсе аз гына булса да, юл куярга тиештер бит инде. Илнурның ничек интеккәнен күреп торалар югыйсә. Юк, алар бу хакта уйлап та карамады, бөтен көчләренә каршы тордылар. Хәер, шулай тиеш булгандыр. Һәртөрле юл куюлар, бирешкән булып кыланулар үз-үзеңне алдау гына бит ул, чын ярдәм түгел. Ә болар Илнурга чын ярдәм күрсәтте, алымны тиешенчә үзләштерергә булышты. Болар – туганнар. Шуңа да бит аларны алдатып, теге алымны куллану өчен Илнур әллә нинди хәйләләр уйлап табарга тырышты.

Бу – көч, җитезлек, физик әзерлек кебек сыйфатларга корылган гадәти көрәш кенә түгел, ә шахмат уены шикелле, бертуктаусыз уйланырга, эзләнергә мәҗбүр итә торган үзенчәлекле алыш иде. Илнур, әлбәттә, нәрсәдер уйлап тапты. Тик көндәшләренең берсе дә аяктан егылмады, бөгелеп төшмәде... Димәк, кичә өйрәнгән алымны ул яхшы дәрәҗәдә куллана алмаган булып чыга.

– Торып бас! – дигән катгый боерык яңгырады.

Илнур мизгел эчендә аягына күтәрелде. Теге өчәү инде юкка чыккан, аның янында Өрәк-егет кенә иде. Ул Илнурга бер тын сынап карап торды:

– Бу өч егет синең иртәнге, төшке һәм кичке ашың иде, – диде ул, мәйданчык читендәге грушалар ягына атлап. – Син ике алышта теге алымны дөрес куллана алмадың, димәк, иртәнге һәм кичке аштан колак кактың.

---

*Ахыры. Башы узган санда*

Илнур иңнәрен генә сикертеп куйды. Иртәнге якта ул шәһәрдә дә бик ашап тормый иде, берәр стакан чәй яки су да җитә. Кичке аш та ул кадәр үк зур югалту түгел, су эчәсең дә ятып йоклыйсың. Хәлләр әлегә аны канәгатьләндерерлек иде.

– Хәзер син теге алымны грушада кабатлыйсың, – диде Өрәк-егет. – Аннан соң миңа каршы кулланып карыйсың. Һәм яңа алым өйрәнәбез. Аңлашыламы?

Илнур баш чайкады:

– Юынырга кирәк иде...

Өрәк-егет катыргы тартмаларның берсеннән литр ярымлы минераль су алып, Илнурга ыргытты. Егет рәхмәт белдереп, баш иде дә баллонга капланды, юынудан бигрәк, эчәргә кирәк иде. Су инде җылынып өлгергән, тик ул барыбер су иде. Сусаган кеше өчен аннан да татлырак нәрсәнең булуы мөмкин түгел. Эчеп туйгач, Илнур Өрәк-егет ягына борылды:

– Зур рәхмәт сиңа! Үлемнән коткардың...

Тик егет инде каядыр киткән иде. Илнур суны учына алып, битләрен чайкатып алды да баллонны агач төбендәге күләгәрәк җиргә ташлады. Кире тартмага куйса, кабат бирмәсләр шикелле тоелды. Һәм шундук уйга калды. Кем бирмәс? Әлегә монда берәү дә юк. Кеше күрмәгәндә, тартмаларга күз салып чыкканда, бик яхшы булачак икән. Бәлки, кирәге чыгардай берәр нәрсә бардыр. Стакан, кофе, чәйкайнаткыч, чәй... Беткәнмени шунда... Илнур агач төбеннән суны кабат барып алды да тартмалар янына килде. Аларны бер-бер артлы тикшереп чыкты. Су, ярмалар, тоз, шикәр... Аларның берсендә яссы калай савыттагы балык консервалары иде. Егет берсен кесәсенә яшерде дә тирә-ягына каранып алгач, башкаларын да актарырга тотынды. Берсеннән чәй килеп чыкты. Пакетлы! Егет пакетны ачты да чәй капчыкларын алып, бөртеп тормаслык итеп, кесәләренә тутырды, ә буш пакетны аскарак яшерде. Кеше кулы тигәнне сизәрлек түгел иде. Беркадәр уйланып торгач, кечкенә шикәр кабын алып, каеш астына тыгып куйды. Булды. Җитте. Артык мавыгырга ярамый. Кешене мохтаҗлык түгел, нәфес харап итә.

Бишмәтен салып, җиргә ташлады да грушада шөгыльләнергә тотынды. Кояш инде ярыйсы күтәрелгән Беркадәр шөгыльләнүгә маңгаена тир бәреп чыкты. Каеш астындагы шикәр дә җеби башлаган кебек тоелды. Аптырагач, Илнур аны бишмәт кесәсенә салып куйды. Һәм күнегүләрен дәвам итте.

Якындагы агач башына эленгән тавыш көчәйткечтән музыка ишетелде. Илнур танылган рэпперларны чамалый иде, әмма монысын ишеткәне булмады. Шулай да башкаручы бик оста иде. Нинди телдә башкарганы аңлашылмый, Илнур белми торган нindидер тел инде, ләкин шуның арасында торым-торымга таныш авазлар да ишетелеп куя:

Кешелекне коткару! Җәмгыятьне уяту!
Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү!
Кешелекне коткару! Җәмгыятьне уяту!
Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү!

Таныш түгел авазлар арасында бу сүзләр шулкадәр күңелгә якын булып ишетелә һәм үзең дә сизмәстән кабатлый башлыйсың. Илнур да ирексездән кабатлады, грушага һәр бәрүе шушы сүзләрнең берсе белән озатылды.

Хәтта җырчы башка телгә күчкәч тә, Илнур ритмга ияреп, үзе белгәнне кабатлады: «Кискен каршылык күрсәтү!», «Күңелләрне тетрәтү!» Боларны әле тагын үз сүзләрең белән дәвам итү теләге дә бар иде, тик әлегә егетнең шигъри сәләте генә җитеп бетмәде.

Бераздан Өрәк-егет килеп җитте дә спарринг кебек нәрсә ясап алдылар: Илнур һөҗүм итте – кичәге алымын кулланырга тырышып, һәртөрле комбинацияләр уйлап чыгарды, тик көндәше аннан күпкә тәҗрибәлерәк тә, көчлерәк тә, җитезрәк тә иде, ул ирек бирмәде. Сәгать чамасы шулай маташкач кына, Илнур аның каршылыгын ерып, бер тапкыр суга алды. Ярыйсы гына килеп чыкты.

– Маладис! – дип мактап алды Өрәк-егет. – Хәзер менә мондый алым өйрәнәбез...

Өрәк-егет башта үзе сугып күрсәтте. Аннан соң акрын гына хәрәкәт ясап, Илнурга кабатларга кушты. Нәкъ менә кичә Джон өйрәткәнчә булды. Илнур хәрәкәтләрне әйбәт кенә үзләштергәч, кул сугышы буенча күнекмәләрне туктатып тордылар.

– Бүлмәңдә үзең кабатларсың, – диде Өрәк-егет. – Һәрбер хәрәкәтең автоматизм дәрәҗәсенә җитәрлек, уйлап тормый куллanырлык булсын. Кичке якта, ату дәресләреннән соң, бәлки, икәүләп шөгыльләнербез.

Бүлмәсенә кайткач, Илнур ишекле-түрле йөренеп, табышын яшерерлек урын эзләде. Консерва банкасын унитаз бачогына тыгып куйды. Һәрвакыт су эчендә, таза урында, өсте каплаулы, кеше күзенә чалынырлык түгел. Шикәрне шкаф түбәсенә ыргытты, аңа ихтыяҗ артык зур түгел, монда аны болай да күп бирәләр, алуы да бушка китмәсен дигәннән генә иде. Менә чәйне кайда яшерергә? Монысы кирәк нәрсә инде. Хәтта салкын суда җебетеп эчсәң дә, чәй тормышны бизәп җибәрә. Тик бүлмәдә аны яшерерлек урын юк иде. Шуңа Илнур чәй капчыкларын бишмәт һәм чалбар кесәләренә таратып кына чыкты. Шулай яхшырактыр да әле: бүртеп тормыйлар, пычранмыйлар һәм һәрвакыт үз янында.

Аннан соң кран борыныннан су эчеп алды да груша янына килде. Үзаллы рәвештә беркадәр кабатлады. Сугу техникасы камилләшә барган саен, бәрү көче арта төште, аның саен Илнурның күңеле күтәрелде. Һәм бераздан теге музыка үзеннән-үзе калкып чыкты. Ул инде хәзер агач башындагы тавыш көчәйткечтән түгел, ә Илнурның үз күңеленнән ишетелә иде:

Җәмгыятьне ояту!

Кискен каршылык күрсәтү!

Күңелләрне тетрәтү!

Күпмедер шулай шөгыльләнгәч, ишек ачылып китте һәм анда бая гына «Каршылыклар кыры»нда катнашкан өч егет пәйда булды. Болар юньле эш белән йөрмиләрдер инде, шундук өсләренә ташланып, кирәкләрен бирергә кирәк. Тик Илнур өлгерә алмый калды, калкурак буйлысы:

– Төшке ашка, – дип сөрәнләде. Илнурның карыны ача башлаган иде, «төшке аш» сүзен ишетүгә, йөзе яктырып китте.

– О, рәхмәт! – дип елмайды ул.

Тик егетләрнең йөзендә бер җепсел дә селкенмәде. Калкурак буйлы егет телгә килде:

– Тик аның шартлары бар, – диде ул һәм сүземне аңладымы бу дигәндәй,

бераз текәлеп торды. – Хәзер коридорга чыгабыз һәм без сине үткәрмәскә тырышабыз. «Каршылыклар кыры»ндагы кебек, әмма монда вакыт чиге юк. Сугышу да ирекле – нинди алым кулланырга телисең – бар да үз ихтыярыңда. Без аерым-аерым да, өчебез бергә дә һөҗүм итәргә мөмкинбез. Син җиңеп чыгасың икән, мул табын көтә, җиңеләсең икән – ач каласың. Аңлашыламы?

Аңлашылуын, әлбәттә, аңлашыла иде.

– Алайса, башлыйбыз.

Егетләр коридорга чыкты. Илнур да иярде. Боларны ничектер алдатырга, кара-каршы сугышмаска кирәк иде. Тик Илнур берни дә уйлап таба алмады. Ә болай итеп карасаң... Ишектән чыгу белән Илнур егетләрне аралап, алга чыкты да кинәт йөгерергә кереште. Моны көтмәгән егетләр бер мәлгә аптырап калды. Калкурак буйлысы алдарак һушына килде бугай, Илнурны куарга тотынды. Иптәшләре дә бераз гына калышып, аңа иярде.

Әле генә күнекмәләр үткәргәч, Илнурның тәне кызган һәм авырлыкларга әзер иде. Шуңа ул бөтен көченә коридорның теге башына омтылды. Мизгелдән мизгелгә тизлеген арттыра барды. Тик артыннан куучы да төшеп калган егет түгел иде. Ул менә-менә куып җитәрдәй булып, аның артыннан ташланды. Ләкин соңлабрак кузгалу сәбәпле, араны якынайта алмады. Илнур коридорның каршыдагы ишегенә барып җитәргә ике-өч метр чамасы калгач, кинәт чүгәләде – артыннан куып килүче моны сизми калды һәм аңа абынып, мәтәллеп барып төште дә ишеккә бәрелеп туктап калды. Икенче егет тә нәрсә булганын аңлап җиткерә алмады бугай. Һәрхәлдә, ул тизлеген киметергә өлгермәде һәм Илнурга абынып, иптәшенең өстенә очып барып төште. Өченче егет тизлеген киметте, әмма Илнур аны көтә иде – чүгәләгән җиреннән торган уңайга ян яктан аның касыгына типте. Теге бөгелеп төште.

Бераздан ишек ачылды. Аларны Өрәк-егет каршылады, барсы да һуш җыеп, җир өстенә чыктылар. Калкурак буйлы егет баягы битарафлыгын бераз җуйган иде:

– Болай дөрес түгел, син сугышырга тиеш идең, – дип шелтәләде ул Илнурны. – Ә син качтың.

Илнур елмайды. Ул үзеннән канәгать иде.

– Син теләсә нинди алым кулланырга була дип әйттеңме?

– Әйттем.

– Шулай булгач? – Илнур Өрәк-егеткә карап, күз кысты: – Мин йөгерү дигән алым кулландым.

Илнурның күңеле көр, күз алдында – мул сыйлы табын, ә иреннәрендә сизелер-сизелмәс елмаю иде. Ләкин Өрәк-егетнең сүзләре аны тетрәнергә мәҗбүр итте:

– Уен тәртибен бозган өчен син төшке аштан мәхрүм ителәсең, – дип кистерде ул.

– Бу – бозу түгел, – дип, каршы төште Илнур. – Бу – авыр хәлдән чыгуның көтелмәгән әмәлен табу.

Тик аның сүзләре игътибарсыз калды. Алдан ук оештырылган нәрсә инде бу, димәк. Аны хәзер ачлык белән сынарга телиләр... Джон да әйткән иде бугай бу турыда... Әмма уйга бирелеп торырга чара куймадылар.

– Ә хәзер – спарринг! – дигән боерык ишетелде. Өрәк-егет Илнурга

карады: – Син һөҗүм итмисең, бары тик сакланасың гына. Йөгерергә, качарга ярамый. Блоклар, читкә тайпылулар, иелеп калулар һәм башкалар. Ә сез һөҗүм итәсез. Әзерме?

Подвал янындагы ачыклыкка чыгып бастылар. Һәм әмер ишетелде:

– Башладык!

Бернинди каршылык күрсәтмичә саклану җиңел түгел иде. Читкә тайпылып калдың, ди, инде... Тик бу көндәшләреңә әллә ни зур зыян сала алмый. Егет акрын гына мондый сугышның да җаен тапты – башыңа төшсә, башмакчы буласың икән. Илнур аларның һөҗүмен блок белән каршыларга, шул вакытта аяк-кулларының иң авырта торган ноктасына тондырырга тырышты. Моның бераз файдасы тиде – егетләрнең берсе аксаклый башлады, икенчесенең уң кулы сафтан чыкты. Бераздан ул айкидо алымнары турында хәтеренә төшерде. Көрәшнең бу төрен ул бик белми иде, шулай да көндәшенең сугуыннан янтаеп калган очракта, аны сугу уңаена этеп җибәрде, кайчагында аяк чалып та ярдәм итте.

Сугышу ярыйсы гына сузылды. Бу Илнурның күңелен күтәрде. Үзең сугу хокукына ия булмаган килеш, шулкадәр озак вакыт буена аягыңда килеш кала алу – начар түгел бит! Моның өчен гәүдәңне, кул-аякларыңны гына түгел, башыңны да эшләтергә кирәк.

Тик барыбер ул җиңелүгә хөкем ителгән иде. Туктаусыз рәвештә өч әзерлекле кешенең һөҗүменнән котылырга тырышу хәлне ала, аңны томалый, хәрәкәтләрне сүлпәнләндерә. Кинәт Өрәк-егетнең:

– Җитте! – дигән тавышы ишетелде.

Илнур җиңел сулап куйды һәм шул ук мизгелдә җилкә тамырына кемнеңдер йодрыгы килеп төште. Илнур упкынга очты...

## 15

Илнур унитаз бачогыннан консерва банкасын тартып чыгарды да озак кына карап торды. Кул астында пычак-фәлән булмаса да, ул аны ачу ысулын уйлап тапкан иде инде. Тирдан алып кайткан буш гильзаның башын гантель белән яньчеп тә куйган иде. Хәзер шуны капкач өстенә куярга да гантель белән сугып барырга гына кирәк. Җайлы түгел, әмма нәтиҗәле. Тик ул балык консервасын бүген дә ачмаска булды, аны кабат урынына куйды да караватына барып ятты. Көчне бер дә юкка әрәм итәргә ярамый.

Кул сугышы дәресләреннән соң, төшке аш ашамагач, ату күнекмәләренә кадәр әле аның хәтсез генә вакыты бар иде. Тик уйлары һаман консерва банкасына тартылды. Ул телевизорны кабызды да бөтен уен шуңа юнәлтергә тырышты.

Экранда полиция хезмәткәрләре ниндидер митингны тарата иде. Җыелышып, нәрсәгәдер каршылык күрсәтергә җыенган кешеләрне эт өстереп куркыталар да, тегеләр чигенә башлагач, арткарак калучы кешегә җилем таяклар белән өелешеп ташланалар. Аны сугып егып, бераз типкәләгәч, якында гына торган машиналарына сөйрәп алып китәләр... Этләрнең авызыннан селәгәйләре агып тора, аларны да берничә көн ач тотканнар бугай...

Ризык турында уйларга ярамый иде. Бу телевизор ярдәм итәчәк, чөнки

анда гел файдалы һәм эчтәлекле тапшырулар гына күрсәтелә. Бу шәһәр телевизоры түгел. Шәһәрнекендә генә ул гел ашау: нинди генә фильмны, яки тапшыруны алсаң да, йә ашап, йә чәй эчеп утыралар, йә булмаса, минут саен нindидер ризыкны рекламалыйлар, кешенең бөтен игътибарын ашау-эчүгә юнәлтергә тырышалар.

– Сугыша беләинде безнең хәрбиләр коралсыз халык белән, – дигән тавыш ишетелә кадрлар артыннан. – Тик әлегә сүз ул хакта түгел. Менә сез игътибар итегез! Ниндидер бөек идеяләрне яклап, митингка чыккан халык нишли соң?

Илнур бернинди дә гайре табигый хәл күрми, ә кадрлар артындагы тавыш дәвам итә:

– Митингка болай гына чыкмыйлар, нәрсәнедер яки кемнедер яклау өчен чыгалар. Гадәттә, бөек үк булмаган хәлдә дә зур идеяләрне, олы максатларны яклау өчен. Болар да шуңа дип чыккан. Сүзләребезне җитәкчеләр ишетсен дип. Полициянең тукмаклы төркемен чакырырлык булгач, идеяләре зур, максатлары нык, сүзләре кискен булгандыр.

Кинокамера кадр артындагы тавышның сүзләренә җавап эзләгәндәй, плакатлар, транспарантлар өстеннән уза. Тик аларның барысы да диярлек түбән төшкән, кайсылары җирдә аунап ята, нәрсәләр язылганлыгын аңларлык түгел.

– Тәртип сакчылары кыйный башлагач, алар үзләренең фикердәшләрен якларга тиеш, – дип дәвам итә тавыш. – Сугышырга котыртмыйм, һич югында сүз белән каршылык белдерергә тиеш. Ә болар нишли?

Илнур аларның нишләгәнен чамаларга тырыша. Тик ул нидер күреп өлгергәнче, кадр арты тавышы җавап бирә:

– Фотога һәм видеога төшерә!

Чынлап та шулай бит! Әлеге күренешне түгәрәк эченә алганнар да бер-берсен этешә-төртешә, телефонга төшерәләр. Кадр артындагы тавышта киная яңгырап китә:

– Берни дә эшләп булмый инде монда. «Безнең өчен сәнгать төрләренең иң мөһиме – кино һәм цирк!» Ленин бабай әйткән, диләр моны. Менә ул революция ясаганда, матрослар телефоннарын чыгарып, фотога яки кинога төшерә башласа, ничек булыр иде икән? Яки Гитлер һөҗүм иткәндә?

Камера берничә секундка фотога һәм видеога төшерүче кешеләрне күрсәтә. Аннан дикторның тавышы ишетелә:

– Милициягә каршы барырга ярамаганын аңлыйм инде мин. Ләкин гадәти хулиганнар кемнедер кыйнаганда да, шундый ук күренеш икән. Мондый видеоларның чиге-чамасы юк.

Чираттагы кадрлар: урам уртасында, көпә-көндез берничә егет өлкән генә яшьтәге бер абзыйны кыйный. Аяктан екканнар инде үзен, йөзен-башын канга батырып ташлаганнар. Типкәлиләр.

– Ә узгынчылар... – дип аптырый кадр артындагы тавыш. – Юк, алар ярдәм итәргә уйлап та карамый. Алар тәртип сакчыларын да, «ашыгыч ярдәм» дә чакырмыйлар. Мөмкинлекләре юк. Телефоннары – «занято». Алар видео төшерәләр. Видео төшерә алмаганы фотога төшерә.

Кадрлар алышынып тора. Диктор тавышы аларга аңлатма бирә:

– Бозлавык юлдан барганда, бер әби таеп егыла икән – һоп, Алла бирде!

– Аны видеога төшерергә кирәк. Ничек ята, торырга маташа, дүрт аягына баса, тагын таеп китә... Әзер сюжет бит инде. Ярдәм итәргә ярамый! Бу кешелекнең максатына каршы килә. Ярдәм итеп, аны аягына бастырасың икән, син әллә ничә кешене яхшы видеодан мәхрүм итәсең. Берсенеке төшмәсә, берсенең каргышы төшәргә мөмкин.

Дикторның шул рәвешле ирония беләнрәк сөйләве Илнурга ошый төшә. Иреннәре хәрәкәтсез калса да, күңелендә елмаюга тартым бер хис пәйда була. Рәхәт кебек тоела. Ә тавыш дәвам итә:

– Хәтта юл буенда аварияләр булып, кешеләр канга батып ятканда да, безнең халык хәзер иң беренче телефонга үрелә. Юк, ярдәм чакырыр өчен түгел. Фотога һәм видеога төшерер өчен. Сәнгать корбан таләп итә дип, юкка гына әйтмәгәннәр икән. Бүгенге сәнгать өчен корбан кирәк. Һәртөрле фаҗигаләр, аварияләр, урам сугышлары, кан коелу, үтереш... Менә нәрсәләр бүген сәнгатьне алга этәрүчеләр. Бөтен кеше сәнгать белән шөгыльләнә. Ул башта киного төшерә, аннан ярдәм чакыра... Яки чакырмыйча китеп бара... Чакырмаса да, берни әйтеп булмый. Кызыгы бетте бит инде теге бәндәнең.

Яшәү шартлары үзгәреп, тормыш камилләшкән саен кешенең кешегә кирәге кими бара. Элек адәми зат бер-берсенә терәк-таяныч булып яшәгән. Ә хәзер...

Әйе, алар бертуган булып яшәгән, бергәләшеп, ауга йөргәннәр, бергә ашаганнар... Илнурның күз алдына борынгы кешеләрнең мамонт аулавы, учак янында ит кыздырып утыруы килде. Хәтта татлы төтен һәм учакта пешкән итнең тәмле исе бөтен бүлмәгә таралгандай булды. Бу халәттән котылырга теләп, телевизорны сүндерде дә бүлмә буйлап йөренергә тотынды. Тик аяклары тагын унитаз бачогы янына алып килде... Һәм ул груша янына килеп, аны төйгечләргә тотынды.

Җәмгыятьне уяту!

Кискен каршылык күрсәтү!

Күңелләрне тетрәтү!

Ач торуына ничә көн булгандыр инде, Илнур хәтерләми, бик күп кебек тоела. Баштарак бу аның үзенә дә кызык иде. «Ничә көн түзә алырмын икән?» дигән кызыксыну үз хәлең белән килешергә ярдәм итте, көч өстәде. Әмма тиздән бу тойгы да юкка чыкты. Нindidер сүлпәнлек, битарафлык, аңгыраю тойгысы өстенлек алды. Бары тик таң белән Остаз үткәргән рухны ныгыту дәресләре генә күңелгә рәхәтлек бирә, үзеңне кешеләргә кирәкле һәм файдалы шәхес итеп тоярга мөмкинлек тудыра иде. Ул рух ныгыту дәресләрендә дә, бүлмәдәге кечкенә колонка аша да, караватө өстендәге экраннан да төрле темаларга вәгазьләр сөйли, гыйбрәтле мисаллар китерә һәм һәр сүзе Илнурның күңелендә теләктәшлек таба яки сорауларына җавап булып ишетелә, тормышка яңача карарга мәҗбүр итә иде.

Шуңа күрә ач торуы да вакытлыча сынау, үз мөмкинлекләреңнең чиген билгеләү чарасы гына булып тоелды. Туалет бачогында балык консервасы, шкаф түбәсендә шикәр, бишмәт кесәсендә чәй барлыгын белсә дә, ул берсенә дә кагылмады. Бу сынауны гадел узарга кирәк иде. Остазның, Джонның һәм башка хуҗаларның сүзен тыңларга, әйткәннәрен үтәргә тиеш иде ул. Чөнки бу сынаулар көрәшнең үзе түгел, ә җитди адымга әзерлек баскычы гына. Алда, бәлки, тагы да зуррак авырлыклар көтәр,

аларын да җиңеп чыгарга кирәк. Чөнки Илнурның тормышта үз вазифасы, үз максаты бар: ул җәмгыятьне уятырга, кешеләрне үз язмышлары турында уйландырырга тиеш. Моның өчен барлык кешеләр сискәнерлек, тетрәнерлек, төн йокыларын онытырлык хәтәр гамәл кылырга кирәк. Остазлар шулай өйрәтә. Әлегә Илнур үзенең нәрсә эшләргә тиешлеген тәгаен генә белми, әмма аның бик тә җаваплы, куркыныч икәнен чамалый.

Ачлык сынавын уза дип кенә күнекмәләр тукталмады. Һәр иртәдә Остазның рух ныгыту дәресләре, аннан соң кул сугышын өйрәнү, төз ату буенча күнекмәләр, каршылыклар-киртәләр аша йөгерү, чыдамлык тәрбияләү алымнары... Ял иткәндә, төрле кинофильмнар карау, аудиокитаплар тыңлау... Боларның барысы да файдалы, барысы да шәхесне үстерүгә булышлык итә иде. Кайсыларыдыр физик мөмкинлекләреңне ача, чын ир-егет итеп тәрбияли. Кайсылары белемеңне арттыра, аңыңны үстерә, тормышны аңларга, өзек-ертык сурәтләрдән тулы канлы картина төзергә булыша. Күнегүләрнең берсе дә зыянга түгел иде.

Көтмәгәндә, ишек шалтыраган тавыш ишетелде һәм Джон килеп керде.

– Хәлләр ничек? – диде ул, баштанаяк күз йөгертеп. – Сынауларга түзеп буламы?

Илнур сер бирмәскә тырышты:

– Була. – Әмма тавышы үзе теләгәнчә үк көр чыкмады, ул хәлсез һәм беркадәр битараф иде. – Була!

– Маладис! – дип мактады Джон. – Бүген сиңа кичке аш китерәчәкләр. Ачлык газабы шуның белән тәмам.

Илнур үз колакларына үзе ышанмады. Ул инде тәмам өметен өзгән, башкача бөтенләй ашатмасалар да, гаҗәпләнмәс кебек иде. Ул түзәчәк. Ләкин Джонның сүзе күңелен күтәреп җибәрде, димәк, бу сынауны да уңышлы узды. Димәк, ул – җиңүче. Ачлыкны гына түгел, ә үз нәфесен дә җиңә алды – консерва банкасына да, шикәргә дә кагылмады. Бу чынлап та зур куаныч иде. Әмма Илнурның бер хәрәкәтендә дә бернинди хис сизелмәде. Хәтта йөзенең бер җепселе дә селкенмәде.

– Ә хәзер ату буенча күнекмәләр, – диде Джон. – Бүген иң катлаулысы булачак.

Беренче көнне «снайпер» дип мактасалар да, күнекмәләр катлаулана барды. Башта бер юнәлештә генә хәрәкәт итә торган мишеньнәргә аттылар, аннан соң – әле уңга, әле сулга төрле тизлек белән хәрәкәтләнә торганнарга. Тора-бара мишеньнәрне манекеннар алыштырды, адәм кыяфәтендәге ул манекеннарның йә кулына, йә аягына, йә маңгаена тидерергә кирәк иде. Манекен килеп чыга, һәм Джон әмер бирә:

– Уң кулына ат!

Кыска вакыт эчендә уң кулына тидерергә тиеш буласың. Ә икенче манекен килеп чыгуга башкачарак әмер ишетелә:

– Сул күзенә!

Бүген күнегүләр үзенчәлекле иде. Башта манекеннар әле бер, әле икенче почмактан килеп чыкты. Кинәт. Алар авырлы хатын, кайберләре карт-коры, кайберләре сабый кыяфәтендә иде. Илнур барысын да кыйратты. Соңгы вакытта гел шундый күнегүләр булгач, ул моңа күнеккән иде.

Аннан соң Джон аны уртага чыгарып бастырды. Манекеннар төрле

яклап, аның өстенә килә, ә Илнур аларның барысын да атып егарга тиеш. Башта алар акрынрак хәрәкәт иттеләр. Әле алдан, әле арттан, әле ян яктан тавыш-тынсыз пәйда булсалар да, игътибарыңны бер ноктага туплагач, аларны атып егу бик авыр түгел иде. Әмма тора-бара тизлекләре арта барды. Аларның барысына да өлгерү кыенлашты. Монда син башка бер нәрсә турында да уйлый алмыйсың, бер секунд та вакытың юк: күзеңә чалындымы – атып ек, шунсыз мөмкин түгел.

Озак кына шулай дәвам итте. Бу мәхшәрдән беркайчан да котылып булмас кебек иде. Ләкин Илнур бирешергә теләмәде. Фәкать шушы шөгыль өчен ясалган махсус машина шикелле ул һәрберсен атып екты. Хәтта манекеннарның тизлеге тагын бераз арта төшкәч тә югалып калмады, адәм ышанмаслык төгәл хәрәкәтләр белән ата торды. Иң соңыннан пәйда булган манекеннар ничектер сәер тоелды, тик бу хакта уйлап торырга вакыт юк иде. Бәлки, моңа кисәк кабынган музыка сәбәпче булгандыр.

Кинәт утны сүндерделәр. Ә музыка әкренәя төште.

– Җитте! – дигән боерыгы ишетелде Джонның. – Мылтыгыңны читкә ыргыт!

Илнур, җиңел сулап, мылтыгын ераккарак атып бәрде. Ату авыр булса да, күңелле иде. Ул бер дә ялгышмады, манекеннарның барысын да егып салды. Кинәт утны яндырдылар. Илнур тирә-ягына күз салды. Һәм күңелен әйтеп-аңлатып булмаслык газап томалады. Идәндә аунап яткан манекеннар астыннан куе кызыл күлләвек булып кан агып чыккан иде. Ул кан акрынлап кына, төрле тарафтан Илнур ягына шуышты, монысыннан инде мылтыктан атып кына да котылып булмый иде.

Музыка тынып калды. Тирә-якта ыңгырашу тавышлары ишетелде. Илнур курку, гаҗәпләнү, сорау һәм тагын әллә нинди хис-тойгылар тулы карашын Джонга төбәде. Тик Джонның бөтен кыяфәте – гәүдәсе, басып торышы, йөзе, күзләре – таш стена сыман иде. Бу Илнурны тагы да йомшартыбрак җибәрде. Әмма көтмәгәндә кире каккысыз катгый боерык ишетелде:

– Эшләрен бетер, интегеп ятмасыннар.

Һәм кулына штыклы мылтык китереп тоттырдылар. Илнур бер мәлгә аңгыраеп торды. Тирә-якка карау да куркыныч булып тоелды. Аннан соң колагына ыңгырашу авазлары килеп бәрелде. Бу авазлар үзен уратып алган этләр өередәй бөтен булмышын талады.

– Әйдә!

Джон кинәт аның яңагына чабып җибәрде һәм Илнур бераз һушына килгәндәй булгач, җитәкләп диярлек идәндә чәбәләнеп яткан карт янына алып килде.

– Менә шулай эшләргә кирәк, – диде ул балаларга дәрес бирүче укытучы тавышы белән һәм яралының йөрәгенә чәнечте. – Хәзер син дәвам ит.

Идәндәге карт беркадәр тартышты да күзләрен акайтып тынып калды. «Котылды», дип уйлады Илнур. Уйларын пышылдап та кабатлады бугай, Джон аңа:

– Башкаларын да коткар, – дип, ары атлады.

Илнур беркадәр басып торды да эшкә кереште, аның карышырлык чарасы юк иде. Бераз вакыттан соң тир эчендә тынлык урнашты. Колакны

ярырдай, җанның астын-өскә китерердәй тынлык. Илнурның уйлары инде йөгереклеген югалткан, хис-тойгылары да элеккечә үткен түгел иде. Әмма бер нәрсә ачык: ул ниндидер күзгә күренми торган чикне атлап чыкты, ә бу чикне бер бозгач, аны беркайчан да, берничек тә төзәтеп булмый, нинди генә игелекләр кылып, ничек кенә акланырга тырышсаң да, кирегә юл юк иде.

Көтмәгәндә, тир эчендә таныш тавыш ишетелде:

– Рәхмәт, улым! Син бик зур игелек эшләдең... – диде стенадагы тавыш көчәйткеч Остаз тавышы белән. – Бу кешеләрнең үткәне дә, бүгенгесе дә, киләчәге дә юк, алар үз-үзләренә кул салырга омтылып та исән калган бәндәләр, чарасыздан яшәргә хөкем ителгән мескен затлар иде. Син аларны газаптан да, гөнаһтан да коткардың... Син – коткаручы...

Остазның сүзләрен тыңлау һәрвакыттагыча рәхәт иде. Аның тавышы гына да күңелгә май булып ягыла, ә фикерләре... Һәр мәсьәләгә бөтенләй башка яктан карый һәм карашын кире каккысыз дәлилләр белән ныгытып, үзенең хаклылыгына ышандыра ала. Бу юлы да шулайрак килеп чыкты. Остазның тавышы тынып калганда, Илнурның күңелендәге үкенү ачылары, газаплы тойгылар юкка чыккан иде инде. Ул үзен коткаручы, кешеләр язмышын хәл итәргә сәләтле, алай гына да түгел, нәкъ менә кешеләр язмышын хәл итү өчен яратылган илаһи зат итеп тойды. Болары бары тик күнекмәләр генә, хәлиткеч гамәлләре алда иде әле.

Ишек янында аны Джон каршылады. Кулында Илнурның рюкзагы иде.

– Хәзер юынып чык, киемнәреңне алыштыр. – Ул рюкзакны Илнурның иңенә элде. – Шуннан соң шәһәргә чыгып кайтырбыз. Син кешеләрнең нинди икәнен үз күзләрең белән күрерсең.

## 16

Юыну бүлмәсенә керүгә аны таныш түгел егет каршы алды. Көзге алдындагы өстәлгә тезеп куелган җайланмаларга күз салгач, Илнур аның парикмахер икәнен чамалады.

– Утыр, әйдә, – диде Парикмахер, өстәл артындагы урындыкка ымлап. – Хәзер сине матур егеткә әйләндерәбез.

Илнур утырды һәм көзгегә күзе төште. Йа Хода! Чәчләре керләнеп, тузып беткән, йөзен сакал-мыек баскан. Бу кыяфәттә күрсә, үз әнисе дә танымыйча узып китәр иде.

Парикмахер уйларга чумып торырга юл куймады. Аның башын нык итеп чылатты да хуш ис аңкытып торган шампунь белән ышкырга тотынды. Аннан сөлге белән корытты, бераздан идәнгә киселгән чәчләр төшә башлады. Сәер иде: менә шушылай утыру рәхәт тә, күңел төбендә ниндидер бик авыр тойгы да бар, шул ук вакытта үзеңнең өстенлегеңне тою да каядыр ашкындыра. Тик бу тойгыларның берсе дә өскә калкып чыкмый, бер-берсе белән көрәшәләр дә хәлсезләнеп тынып калалар.

Җылымса су шундый назлы иде. Ачы тир, кан, тузан катнашкан келәй сыман нәрсә белән капланган тәненә кагылуга, Илнурның күңелен рәхәтлек биләде. Ниндидер күзгә күренмәс кул аның бөтен тәнен назлыйдыр, рухын чистартадыр кебек тоелды. Талгын музыка астында бөтен булмышын назлаган судан да татлырак нәрсә дөньяда юктыр шикелле иде.

Ул ашыкмыйча гына бөтен тәнен сабынлап чыкты, стенада эленеп торган

өр-яңа мунчаланы алып яхшылап юынды, коенды... Бөтен күзәнәкләре чистарынып, җиңеләеп калгач та, мондый рәхәтлектән аерылырга теләмичә су астында озак басып торды.

Юынып, киемнәрен алыштыргач, көзгегә карады. Анда инде бөтенләй бүтән егет иде. Яшь. Чибәр. Хәер, элекке кыяфәте белән чагыштырып карасаң, бөтен кеше дә чибәр булып тоеладыр инде. Ул елмайды. Тик ни өчендер елмаю килеп чыкмады, аруы, ачлыгы үзенекен итәдер, тик ул барыбер канәгать иде.

Джонның машинасына утыргач, башына кара бөркәнчекне кабат кидерделәр.

– Тәртипне үзең беләсең, – дип акланды Джон. – Барысын да аңларга тырыш.

Илнур аңлый иде. Ул нәрсәдер мыгырдады да башын утыргычка терәде. Бераздан йоклап та китте. Юынып чыкканнан соң тәне үзеннән-үзе йомшарып, изрәп калды. Бөтен гәүдәсе таралып төште, күзләре йомылды. Бернинди төш тә күрмәде, хәтта үзенең оеп китүен дә аңлый алмады. Аз гына йокымсыраган кебек иде, менә инде шәһәргә килеп тә җиткәннәр. Ул бары тик Джон аның башындагы япманы салдырганда гына уянды.

Машинаны калдырып, бер парк эченә уздылар. Джон монда килүләренең сәбәбен аңлатты:

– Бу да безнең бер дәрес шикелле нәрсә, – диде ул, җитди итеп. – Игътибарлы бул, һәр нәрсәне күрергә тырыш.

Илнур баш какты. Тирә-ягына каранып алды. Һуш китәрлек әллә нәрсә юк иде. Сукмак буйлап бер исерек китеп бара. Ару гына җиппәргән, бер яктан икенче якка кыйшаеп атлый. Һә!.. Арырак ике полиция хезмәткәре бара. Күрәчәк инде алар бу абзыйны, бәйләнәчәкләр инде. Хәер... Бәйләнмәячәкләр. Чөнки аларның каршысына калашник автоматы күтәргән бер ир килә.

Джон да шуны ук күзәтә иде бугай.

– Полиция хәзер кемгә бәйләнәчәк? – дип куйды.

– Автомат тоткан кешегә, әлбәттә.

– Бәхәсме?

– Бәхәс!

– Нәрсәдән?

– Кафе. Кичке аш.

Юк!.. Зинһар өчен!... Юк, шайтан алгыры... Иңенә автомат салган ир тәртип сакчылары яныннан бер каршылыксыз узып китте. Тегеләр аның ягына борылып та карамадылар... Алар исерекне күреп, адымнарын тизләттеләр. Ничек шулай булырга мөмкин?! Хәер, шулай дөрестер дә. Уенчык автомат икәнен сизеп калганнардыр. Зыян салырга җыенган нинди кеше шулай итеп корал болгап йөрсен инде...

– Автомат күтәреп килүче – безнең егет, ә полицейскийлар – чын, барып тикшереп карый аласың, – дип аңлатты Джон. – Син күрсен өчен бу күренешләрне без махсус оештырдык.

– Ник алар бәйләнмәде соң?

– Исерек – алар өчен гарантияле акча чыганагы. Алар өчен урамда берничә төрле генә җинаять бар, алар шуны гына күрә. Шуңа көйләнгәннәр.

– Ә кафе кызганыч, – дип, авыр сулады Илнур.

– Хәзер арырак китәбез.

Алар якындагы җир асты чыгышы алдына барып бастылар. Кеше күп иде. Кинәт бер егет чалыш-чолыш атлап килде дә егыла башлады. Кемнәрдер аны этеп җибәрде, кемдер читкә тайпылып, ары атлады.

– Зинһар, ярдәм итегез, – дигәне ишетелде егетнең. – Ярдәм...

Тик аңа берәү дә игътибар итмәде. Әле берсенә, әле икенчесенә эләгеп барды да төркем атлаган юл читенә чыгып егылды. Ниһаять, әнисе белән җитәкләшеп килүче бер кыз аны күреп алды һәм әнисен шуның янына сөйри башлады:

– Әни, ул ялдәм солый бит...

Анасы аны тупас кына итеп, үзенә тартты да адымын тизләтте. Ярдәм сорап кычкырып ятучыга беркем дә якын килеп карамады. Шактый вакыт узгач кына, ниндидер бер хатын килеп, хәлен белеште дә телефонын алды. Ашыгыч ярдәм чакыра иде бугай.

– Монысы да безнең егет, – диде Джон. – Аның җирдә аунап ятуына сәгатьтән артык вакыт узды. Чынлап та йөрәк чирле кеше булса, берсүзсез үләчәк иде.

– Ә мин боларны нигә күрергә тиеш?

– Синең алдыңда – зур максатлар, җитди эшләр. – Джон аңа беркадәр текәлеп торды. – Күңелеңдә беркайчан да шик, икеләнү булмасын өчен син бүгенге җәмгыятьнең, кешеләрнең асылын үз күзләрең белән күрергә тиеш.

– Мондый күренешләрне минем болай да күзәткәнем бар, – диде Илнур гамьсез генә. – Үземнең дә теге егет урынында калганым бар. Шундый чакларның берсендә синең белән танышкан идек.

Джон баш кагып куйды да дәвам итте:

– Ләкин менә бу очракта син бер нәрсәгә игътибар бирергә тиеш. Күзәт син, әнә, кешеләрне. Алар бер-берсен күрми. Барысы бер җирдән атлый һәм һәрберсе үз дөньясында яши. Алар ниндидер гипноз астында. Алар йокыда, үз иллюзияләре эчендә яшиләр.

Илнур моны бераз чамалый иде. Бер мәлне институт алдында икеләнеп басып калды. Нәрсәдер уйланып, нидер хәл итәргә теләп, берничә минут басып торды. Шул арада аңа әллә ничә кеше килеп бәрелде. Кешеләр аны күрми иде: йә үз уйларына бирелеп, йә телефоннарына капланып атлыйлар. Бик гаҗәпләнгән иде ул чакта егет. Соңыннан да моны берничә тапкыр төрле урыннарда кабатлап карады әле – үзгәреш юк, кешеләр аңа бәреләләр иде.

– Барысы да үзен уникаль кеше, кабатланмас шәхес дип уйлый, – дип дәвам итте Джон. – Ә барысы да – джинсыдан, өстендә футболка. Барысының да тормыш максаты: мөлкәт туплау – затлы фатир, затлы машина һәм балаларын яшәү урыны белән тәэмин итү. Әгәр араларында башкача фикер йөртүче, башкача яшәүче кеше бар икән, алар аны сытып, изеп юл читенә чыгарып ташлыйлар. Болардан соң бернинди матурлык та, яктылык та калмый. Болардан мөлкәткә табына торган буш күңелле һәм таш бәгырьле балалар кала. Алар туганлыкның да, дуслыкның да, рухи кыйммәтләрнең дә кадерен белмәячәк. Чөнки болар – зомбилар.

Джон хаклы иде. Чынлап та кешеләрнең киенү рәвешләре дә, атлап йөрешләре дә охшаш иде. Барысы да каядыр ашыга... Бер-берсен күрмиләр дә, күрергә дә теләмиләр...

– Менә шушы кешеләрне без чынбарлыкка кайтарырга тиешбез, – дип нәтиҗә ясады Джон. – Алар тирән тетрәнү кичермичә айнымаячаклар. Алар уяныргa һәм үз дөньяңда гына яшәп булмаганын, иңгә-иң терәшеп, бер-береңә ярдәмләшеп тормыш итәргә кирәклеген аңларга тиешләр. Син шуны тоясыңмы?

Шәһәрдә эшләрен бетергәч, Джон бер кафе янына килеп туктады.

– Хәзер кереп, бераз капкалап чыксак та, ярый, – дип елмайды.

Илнур ихлас баш какты. Ул шат, ул моны тели иде. Шатлыгыннан хәтта сүз дә әйтә алмады, баш кагып кына торды. Ә кафедан таралган тәмле аш-су исе буыннарын йомшартып җибәрде.

**17**

Икенче көнне кул сугышы буенча күнекмәләр булмады. Көн саен кем беләндер сугышып өйрәнгән Илнурга бу хәтта бераз сәер дә тоелды. Һәр мизгелдә куркыныч көтү, һәр урында сак кылану, уяулыкны югалтмау аның гадәтенә сеңә башлаган иде бугай. Ә кул сугышыннан ял итү әйбәт. Болай да бөтен тәне, мускуллары авыртып тора, ә хисләре ул авыртуларны тоймаслык дәрәҗәдә тупасланган. Сугышудан, ә бәлки кыйналудандыр, беркадәр ял итеп алу файдага гына булачак.

– Син үзеңне күрсәттең инде, – диде Джон, аның уйларын куәтләгәндәй. – Хәзер кул сугышы күнекмәләренә артык мохтаҗлык юк. Ял ит, кинолар кара.

Һәм ул кул сумкасыннан алып, бер флешка калдырды.

– Менә монда яхшы язмалар бар.

Язмалар чынлап та яхшы булып чыкты. Флешкадагы ике видеоның берсе җәнлекләр турында тапшыру, икенчесе нәфис фильм иде.

Талгын гына музыка астында барган тапшыру хайваннар тормышын сурәтли. Башта филләр турында сөйли. Аларның үз балаларын ничек тәрбияләүләре, хоботларын кулланырга өйрәтүләре, кояш көйдермәсен өчен гәүдәләрен лай белән каплаулары... Ниндидер куркыныч хәл килеп чыкса, филләр төркеме бөтен балаларны уртага ала икән – саклау өчен шулай кирәк. Әгәр балалары арыса, аларны күтәреп йөртәләр.

Һиндстанда шундый бер вакыйга була. Якындагы авылларның берсендә яшәүче браконьерлар филнең баласын дару биреп йоклаталар да, үзләре белән алып китәләр. Һәм шул ук төнне бер көтү фил авылга һөҗүм итә. Бары тик әлегә зоопарка озатылмаган фил баласын тапкач кына тынычланып, аны үзләре белән алып китәләр. Бу хакта сөйләгәндә, дикторның соклануы тавышына чыккан иде. Ул Илнурга да күчте.

Әлеге язма Илнур белән булган бер вакыйганы калкытып чыгарды. Ул чакта кечкенә иде әле, ничәнче сыйныфта укыгандыр, төгәл хәтерләми. Иптәш малайлары белән уйнап йөргәндә, бер тупыл башындагы оядан мәтәлеп төшкән карга баласын күреп калдылар. Әле кечкенә генә, шулай да усал – янына килә башлауга ук ямьсез тавыш белән кычкырырга тотына. Авызын зур ачып кычкыра, томшыгының эче карбыз төсендә икән. Бу аны

отыры куркынычрак итә, янына якын барырга берәү дә тәвәккәлләми. Илнур барды, карга баласын күтәреп алды да томшыгын икенче кулы белән каплап агач башына карады. Оялары бик биектә иде, менгереп куя алырлык түгел. «Әйдә, ачыклыкка чыгарабыз, бәлки анасы килеп алыр», – диде кемдер.

Аланлыкка чыгуга, чынлап та анасы очып килде. Тик ул рәхмәт әйтергә дип килмәгән иде, ямьсез тавышлар белән каркылдый-каркылдый, малайлар өстендә әйләнә башлады. Кинәт кенә җиргә ташлана да, инде чукып алдым гына дигәндә, тагын күтәрелеп китә. Моннан шүрләгән малайлар төрлесе төрле якка сибелеп, хәвефсез урыннан күзәтергә тотындылар. Ә карга, баласы янына төште дә, аны күтәреп, үз оясына очып китте. Ләкин эш моның белән генә бетмәде. Илнур кая барса да, баш очында теге карга пәйда булды. Кайчагында ул бик якыннан, кул сузымы арадан очып узды, кайвакыт ерактанрак озатып барды. Бары тик бер-ике атнадан соң гына күзгә күренми башлады. Аңламассың инде, рәхмәт әйтергә теләгәндерме, әллә үч алыргамы?

Клинт Иствуд төшергән «Алыштыру» дигән триллер да бала, дөресрәге, улын югалткан ана турында булып чыкты. Бу режиссёрның һәр әсәре кызык, үзенчәлекле һәм Илнур аларны бик ярата иде. Ләкин бу фильмны караганы булмаган икән. Баласын югалткан ананың бу хәл белән килешергә теләмәве турында инде бу әсәр. Ана үз баласының исән икәненә ышана, өметен өзәргә теләми һәм аны табу өчен адәм акылы җитмәслек адымнарга бара, үзеннән мең тапкыр көчлерәк затлар белән көрәшкә чыга. Һәм үз өстенлеген исбат итә – улын табуга ирешә.

Иствудның бу фильмы да тетрәндергеч иде. Үз баласы өчен ата-ана нинди генә михнәтләргә бармый да, нинди генә хәтәр адымнар ясамый икән. Илнурның эти-әнисе дә әллә күпме хәтәр гамәлләр кылды инде аның өчен. Кылдылар. Егет моны әйбәт белә. Әмма нинди гамәлләр икәнен генә төгәл хәтерли алмый. Күңелендә бикле бүлмәләр шикеллерәк ниндидер урыннар да бар бугай аның. Берничек тә кереп булмый торган...

Уйларга бирелеп торырга мөмкинлек булмады. Ишек тавышы ишетелде. Илнур гаҗәпләнебрәк, шул якка төбәлде. Төшке ашка да, ату дәресләренә дә иртә иде әле. Джон килеп керде:

– Хәзер юынасың, киемнәреңне алыштырасың һәм киңәшмәгә барабыз, – диде ул керә-керүгә үк. – Остаз чакыра. Киттек.

Остаз янәшәдәге калкулык-подвалларның берсендә яши икән. Монысы яктырак та, уңайлырак та – әйбәт кенә оешманың офисы шикеллерәк, тәрәзәләре генә юк. Остазның бүлмәсе дә офис директорыныкы кебегрәк. Якты матур бүлмә, ян-яктагы стеналардагы алтынсу тоткычларда шәмнәр янып тора, алардан борынны иркәли торган хуш ис сибелә. Каршы як стенада – шкафлар, түрдә Т хәрефе рәвешендәрәк эшләнгән киң өстәл, өстәл янындагы тәхеткә тартым кәнәфидә Остаз утыра. Керүчеләрне күрүгә, ул урыныннан торып, каршы алды да, ике куллап күрешкәч, кәнәфиләргә ымлады:

– Утырышыгыз, туганнар, сүзем бар.

Үз урынына барып утыргач, бер тын Илнурга карап торды. Карашлары көчле иде аның, бөтен булмышыңны, һәр күзәнәгеңнең нинди хәрәкәт ясаганын күреп торадыр шикелле иде.

– Әзерлек ничек бара соң?

Илнур нидер әйтеп өлгергәнче, Джон телгә килде:

– Ул инде әзер.

– Бик яхшы, бик яхшы... – Остаз тагын Илнурга текәлде. – Син мине... Мине генә түгел, ә бөтенебезне дә сокландырган искиткеч шәкерт булдың...

Остаз тикле Остазның авызыннан мондый сүзләрне ишетү зур бәхет иде Илнурга. Димәк, ул барысын да дөрес эшләгән, димәк, ул сынауларны уңышлы уза.

Остаз өстәл читендә торган ком сәгатен бармаклары арасында әйләндерде дә үзенең алдына куйды.

– Син барлык сабакларны да тиз үзләштерәсең, аң-гыйлемгә, яңа эшчәнлеккә синең күңелең һәрвакыт ачык, чөнки әйткәнне тыңлыйсың, һәр сүзне үзеңә сеңдерәсең, гамәлдә кулланасың. Бу – синең өстенлегең.

Ягымлы матур тавыш белән талгын гына әйтелгән мондый сүзләрне ишетү дә, үзеңә сеңдерү дә, гамәлгә ашыру да рәхәт иде.

– Ничә көннәр буе ач торып та, син бүлмәңдә яшереп куйган ризыкларга тотынмадың. Түздең. Бу – соклангыч. Чөнки адәм балаларының күбесе ачлыкта гына түгел, ә иркенлектә дә үз нәфсесен тыя белми. Ә син үз-үзеңне тота алдың. Бу үзе үк синең гади кеше түгел, ә илаһи зат икәнеңне күрсәтеп тора.

Илаһи зат... Илаһи зат ул Аллалар затыннан дигән сүз. Син гади генә кеше түгел, син урамдагы төркемнең бер өлеше түгел, син – илаһи зат. Һәм моны Остаз үзе әйтә.

– Гади адәм баласы булса, югалып калыр иде, ә син авырлыклардан, котылгысыз хәлләрдән чыгуның һич көтелмәгән юлларын эзләп таба белдең. Аллалар затыннан син.

Остаз алдында торган ком сәгатен кирегә әйләндереп куйды да дәвам итте:

– Шуңа күрә бик мөһим бер мәсьәләдә синең белән киңәшләшергә булдым.

Ул Илнурга төбәлде. Ялкынлы карашлар үзенә тарта, алардан берничек тә аерылып булмый иде. Егет шушы карашларга бәйләп куелган кешедәй бер хәрәкәтсез калды, ул хәтта сулыш та алмый иде бугай, һәрхәлдә моны үзе тоймады. Ул тулысынча Остаз иркендә, аның карашлары ихтыярында иде.

– Без җәмгыятьне уятырга, зомбига әверелгән кешеләрне кичекмәстән дәваларга, азат итәргә, тулы канлы тормыш белән яшәтергә бурычлыбыз. Ә моның өчен җәмгыятьнең бер тетрәнеп алуы таләп ителә. Нык тетрәнеп, сискәнеп уянуы кирәк. Мондый хәл, әлбәттә, корбаннар сорый. Һәм без кешеләрнең иң йомшак урынын табарга тиешбез. Һәркемгә кагыла, беркемне дә битараф калдыра алмый торган әрнү ноктасын табарга кирәк.

Илнур бар булмышы белән ләззәтле дулкында тибрәнеп утырса да, Остазның сүзләрен аермачык ишетә иде. Әле ул үз бүлмәсендә караган фильмнарны исенә төшерде. Кешеләрнең, гомумән, барлык җан ияләренең дә иң йомшак урынын ул белә иде.

– Бала, – дип пышылдады Илнур. – Балаларны кулланырга кирәк...

– Балаларны? – диде Остаз, бу сүзнең мәгънәсен үлчәп карагандай. – Яхшы. Бик яхшы. Ә син үзең моны ничек күз алдына китерәсең?

Илнур уйга калды һәм барысын да күз алдына бастырырга тырышты. Аның җаны гәүдәсеннән аерылып, югары күтәрелгәндәй булды. Югарыга менде дә балалар бакчалары, парклар, спорт мәйданчыклары, хастаханәләр аша очып узды. Һәм бер мәктәп өстенә килеп туктады. Бу аның үзе укып чыккан мәктәп иде. Иң уңышлы урын. Илнур аның төзелешен дә яхшы белә, укучы балалар да бик күп.

– Бу вазифа сиңа йөкләтелә, – дигән тавышы ишетелде Остазның. – Чөнки син – бердәнбер. Алла. Алла гел мәрхәмәтле генә була алмый. Кешеләр азынып, бозылып киткән чакларда ул җәза коралына әверелә һәм адәм балаларын һәртөрле вулканнар, җир тетрәүләр, су басулар аша җәзалый. Меңнәрчә корбаннар барлыкка китерә. Син дә – җәзалау алласы. Син кешеләрне утлы корал аша җәзалаячаксың. Дөньядагы бар тереклек өчен иң кадерле нәрсә – бала. Син аларның балаларын алып, барлык кешеләрне, хәтта үз балалары булмаганнарны да тетрәнергә мәҗбүр итәчәксең. Син берүзең... бөтен җәмгыятьнең астын-өскә китереп, кешелекне уятырга сәләтле зат. Син – алла! Дөньядагы бөтен җан иясе сиңа буйсына.

– Мин – алла, – дип кабатлады Илнур. – Мин алла һәм үз вазифамны үтәргә тиеш.

– Хыялдан чынбарлыкка тик бер адым. Үз гамәлләреңне күз алдына бастыр. – Остаз бер мизгелгә тынып торды да әмер бирде: – Вакыт!

– Вакыт... Вакыт... Вакыт... – дигән кайтаваз кабатланды Илнурның аңында. – Вакыт...

## 18

Ул талгын гына музыка астында ләззәт диңгезендә йөзде. Урамнар буйлап атлады, кибетләргә керде, парклар аша үтте, өендә әти-әнисе янында булды, тагын әллә күпме гади һәм гадәти гамәлләр белән мәш килде.

Кинәт галәмнәр күкрәгеннән дәһшәтле тавыш ишетелде:

– Вакыт!

«Вакыт!» – бу гади әмер генә түгел, ә аның бөтен язмышын билгели торган сүз иде. Хәзер аның бу тормыштагы иң мөһим мизгеле, яшәвенең мәгънәсе хәл ителә. Моңа кадәрге бөтен гомере – шушы мизгелгә әзерләнү иде. Ә хәзер – Вакыт!

Күңелендә тәвәккәллектән башка бернинди хис юк иде. Аның максаты изге, юлы дөрес, күңеле чиста. Кешелекне гафләт йокысыннан уяту өчен ул аларны тетрәнергә, сискәнергә мәҗбүр итәргә тиеш. Моның иң тәэсирле бердәнбер ысулы – аларны газиз балаларыннан мәхрүм итү.

Илнур автоматын болгый-болгый... Юк, автоматын иңенә асып, парк буйлап атлады. Каршысына ике полиция хезмәткәре килә иде... Юк, автоматын түгел... Теге вакытта коплар исереккә алданып калды калуын, әмма бу юлы башкача булуы да мөмкин иде. Шуңа саграк кыланырга, алдыңны-артыңны уйлап эшләргә кирәк.

Коба төстәге гитара чехолы аскан Илнур парк буйлап килә. Чехол эчендә – ул яраткан төрек винтовкасы. Паркны чыгып, беркадәр атлагач, мәктәп ихатасына керде. Ихатада кеше күп түгел, аның белән бер үк вакытта мәктәпкә кереп баручы кыз. Ашыга-ашыга атлый. Атарга! Юк, аны атарга ярамый иде... Бөтен эшне мәктәпкә үтеп кергәч башларга кирәк. Юк, атарга...

Илнурның иңендә гитара чехолы юк, ә мылтык аның кулында иде. Монда нәрсәдер дөрес түгел бугай. Күңеленеңме, баш миенеңме кайбер урыннарында ул үтеп керә алмый торган бүлмәләр бар бугай. Һәм ул нинди генә алла булмасын, кайбер нәрсәләр аның ихтыярына буйсынмый бугай. Әллә алай түгелме... Аң төпкеле дип сөйлиләр бит әле, монда да шул хәрәкәт итә һәм үзе дөрес дип тапкан нәрсәләргә өстенлек бирә, күрәсең.

Ләкин ул хаклы түгел, эшне мәктәп ихатасыннан ук башлау – акылсызлык. Башта эчкә узарга һәм кешеләр һушына килеп өлгергәнче мөмкин кадәр күбрәк кешене атарга кирәк. Мантыйк буенча шулай. Ләкин ниндидер көч аның болай эшләвен теләми, ахмакларча кылануын көтә иде. Болай итү өчен психик авыру булырга кирәк. Псих.

Яхшы...

Ул мәктәп ихатасына керә һәм андагы кызга ут ача. Бер, ике, өч... Өч тапкыр атып та тидерә алмый. Кыз качып өлгерә, мәктәп почмагына йөгерә дә күздән югала. Илнур үртәлүдән ыңгырашып куя. Болай булырга тиеш түгел, ул яхшы ата, үз ихтыярында булса, бу кызга ул йомык күз белән дә тидерә алачак иде. Тагын бер егет пәйда була... Анысын да чүкергә... Кыскасы, мәктәп ихатасында кемдер очрый икән, барысын да атарга. Берәү дә очрамаса, шым гына узарга...

Тик егет уйларга бирелеп тора алмый, кайдандыр килеп чыккан ягымлы җил сыман талгын музыка аны үзе белән ияртеп алып китә. Ә икенче мизгелгә аның аңындагы мантыйк буенча эшли ала торган бүлмәнең дә ишеге ябыла.

Ул мәктәпкә уза. Монда кораллы сакчылар юк. Вахтада утырган карт аның юлына аркылы төшә:

– Кемгә киләсез? Документларыгыз?

Бу бабайны Илнур хәтерли әле. Элек ул ниндидер фәннән укыткан, хәзер пенсиягә чыккач, вахтёр булган. Кырыс карт, кирәген дә кирәкмәгәнен дә тикшерергә ярата.

– Нинди документ, – ди егет. – Мин бит бу, Илнур. Менә, мылтыкны китерәм, военруктан алып торган идем.

Вахтёр аңа текәлеп карап тора да танымый:

– Илнурлар бетмәс монда, – ди ул кипкән сөяк шикелле коры тавыш белән. – Документларыңны күрсәт, юкса, полиция чакырам.

«Зомби, – дип уйлый Илнур. – Юк итәргә кирәк!» Һәм атып җибәрә. Коридордан узып баручы ниндидер ир ишеккә килеп каплана, аны ябып куя да ачтырмаска итә. Илнур аңа бер тын аптырап карап тора. Олы гына яшьтәге кеше югыйсә, ә башы эшләми. Башы эшләсә, ул качар, яки телефоннан ярдәм чакырыр иде. Ә бу пыяла ишекне ачтырмаска итә... Әгәр алдыңда корал тоткан кеше тора икән, сине пыяла ишек саклый алмый. Ә бу ахмак шуны да аңламый. «Зомби», – дип уйлый Илнур һәм атып җибәрә. Һәм артык ашыкмый гына баскыч буйлап күтәрелә...

Өченче катка җитүгә класс бүлмәсеннән чыгып баручы укытучы пәйда була. Илнур аны атып ега һәм бүлмәгә кереп, ут ача... Бу тирда ату гына түгел икән... Класста мәхшәр куба, чыр-чу килгән коточкыч тавышлар яңгырый. Ул мылтыгын яңадан корган арада кемнәрдер парта астына яшеренә, кемнәрдер тәрәзәдән сикерә. Егет яңадан ут сиптерергә тотына...

Коридорга чыгып күршедәге сыйныф бүлмәсенә җитүгә, галәмнәр

төпкеленнән таныш тавыш ишетелә. Илнур бер мәлгә берни аңламыйча аптырап кала, аннан сүзләрнең мәгънәсе аңына барып ирешә:

– Яхшы! Син үз вазифаңны үтәдең, – ди Остаз тавышы. – Хәзер китү юлларын хәстәрләргә вакыт.

Илнурның колагына сирена тавышлары ишетелеп кала, тик аны ниндидер ягымлы музыка өзә. Ягымлы гына булып, талгын гына агылса да, бу көй бөтен җаныңны, тәнеңнең бөтен күзәнәкләрен айкап чыгара, ул сине сүтеп җыядыр кебек тоела.

Бераздан Остаз үзе дә пәйда була. Ул һаман үз бүлмәсендә, түрдә тәхет сыман кәнәфиендә утыра икән. Джон күренми, кай арададыр ул чыгып киткән. Остазның йөзендә канәгать елмаю балкый.

– Син барысын да җиренә җиткереп башкардың, – ди ул, баласын мактаган эти ягымлылыгы белән. – Кайбер урыннарын төзәтербез.

Илнур аны үзенчә аңлый.

– Әйе, – ди ул, бераз кәефе кырылып. – Мин әйбәт ата алмадым. Аннан соң... башта мәктәпкә үтеп керергә, аннан соң гына эшне башларга кирәк иде...

Остаз серле елмаеп куя:

– Юк, син сайлаган юл бик дөрес.

– Тик бу бит ахмакларча...

– Әйе, синең һәрбер хәрәкәтең мантыйкка сыймаслык, адәм балалары аңлый алмаслык булырга тиеш.

– Ник?

– Чөнки син – алла.

Илнур нидер әйтеп өлгергәнче теге ләззәтле музыка яңгырый. Егет бөтен уй-фикерләрен, хис-тойгыларын оныта да моңда тибрәнүче кечкенә күзәнәкләргә әверелә. Беркадәр шул халәт сихерендә ләззәт чиккәч, сизелер-сизелмәс аваз ишетелә:

– Вакыт!

Илнур мылтыгын болгый-болгый, парк буйлап килә, каршысына очраучыларга сәлам бирә. Парк аша узуга, мәктәп ихатасына керә, ишеккә атлый...

Бу юлы ул бернәрсәгә дә карышып тормады. Нәрсәләр билгеләнгән – барысын да төгәл үтәде. Берни турында да уйламады. Уйланырга кирәкми дә иде. Алар кешене икеләнергә, үз-үзе белән көрәшергә мәҗбүр итә. Монда алай ярамый, үзең – икенче яссылыкта, иң мөһиме – вазифаңны үтәү иде.

Шул рәвешле берничә тапкыр кабатлап, һәр хәрәкәтне истә калдыргач, Илнур кабат чынбарлыкка кайтты. Бу юлы да Остаз аны мактап алды.

– Бик яхшы! Син, чынлап та, илаһи зат! – Һәм кабат Илнурга текәлде. – Хәзер син барысын да онытып торырга тиешсең. Вакыт җиткәч, сиңа хәбәр килер һәм нәрсә эшләргә тиешлегеңне исеңә төшерерсең. Хәзер син элекке Илнур түгел, син бүтән зат. Аллалар затыннан. Элекке тормышыңа күнегү авыррак булыр, тик син бирешмәскә тиеш. Бүтәннәрдән артык аерылырга тырышма. Озакламый синең дә вакыт килер. Син шуны сизәсеңме?

Илнур баш какты. Остаздан соң авыз ачып, сүз әйтү затлы картинага тимер буявы сибү кебек иде.

– Син монда әзерлек үтүеңне дә, вазифаңның нинди булуын да онытырга тиеш. Хәтереңнең тиешле өлешләрен мин хәзер бикләп куярмын. Син бер ай буена эштә, төзелештә булдың, йөк ташыдың, цемент болгаттың...

Остаз шул рәвешле сөйли башлады. Талгын музыка астында изрәгән Илнур аның һәр сүзе саен үзенең кайда, нинди һөнәр буенча эшләвен, ничә сум хезмәт хакы алуын, кайда яшәвен күз алдына китерә барды.

– Син әлегә йокла, ял ит, – диде Остаз тавышы бераздан. – Будильник тавышына уянырсың.

**19**

– О, безнең эшче улыбыз кайтты, – дип килеп кочаклады әнисе ишектән керүгә үк. – Бигрәк тартылып киткәнсең әле, ашатмадылармы әллә? Әйдә, уз, чит кеше кебек басып торма.

Илнур рюкзагын бүлмәсенә кертеп куйды да әнисе янына кухняга чыкты. Әнисе бер дә үзгәрмәгән кебек иде. Гадәттәгечә, юка яулыгын чәчләрен җыярлык итеп чөеп бәйләгән, искереп, сурәтләре таркала башлаган зәңгәрсу халаттан, табын әзерләп йөри. Тиздән әтисе дә кайтачак. Улы кайткач, ул тагы да дәртләнебрәк китте, озак күрешмәделәр, сагынгандыр.

– Исән-сау гына тордыгызмы, әни?

– Бер көйгә генә, улым. – Ул өстәлгә тәлинкәләр тезде. – Бар, син кулыңны ю башта, аннан табынга утырырсың. Бар, ишек яңагына сөялеп торма.

Илнур кулын чайкап чыкты. Ул арада әтисе дә кайтып җитте. Ишектән кергәндә йончурак булып күренгән йөзе шунда ук яктырып китте.

– Һо, улым! Исән-сау кайттыңмы? Эшләрең уңдымы? – дип кочаклап алды ул. – Бераз ябыккансың, ә болай ничава гына күренәсең.

– Әйбәт, әти. Үзең ничек соң? Барамы эшләр?

– Ипләп кенә инде, балам, – дип, моңсу гына түргә узды әтисе. – Хәзерге заманда әллә ни мантып булмый бит инде. Тырышкан булабыз шунда кулдан килгәнчә. Үзең ничек соң?

Әнисе табынга чакырды. Утырдылар.

– Төзелештә, әти, – дип, әнисе пешергән бәрәңгегә үрелде Илнур. – Бу өлкәдә белем булмагач, кара эштә әлегә. Соңрак үрләү мөмкинлеге дә юк түгел.

Әтисе көлемсерәп куйды:

– Шулай алдап йөрттеләр инде мине дә гомер буена. Акчасы ничек соң?

Илнур чәй уртлап, авызындагы ризыгын чәйнәп бетерде дә җавап көтеп текәлгән әтисенең күзләренә бераз карап торды.

– Әйбәт, әти, – дип елмайды. – Эше бик авыр, тик акчасы әйбәт.

Ул арада әнисе дә эшен бетереп, табынга утырды:

– Әйбәт дигән сүз ничә сум була ул?

– Әйе, – дип чынаягын куйды әтисе дә. – Аена күпме чыга?

– Йөз мең.

Чәй уртлап куйган әнисе кинәт тончыкты да ютәлли башлады, әтисе аның аркасына суккалады. Бераздан әтисе сорап куйды:

– Йөз мең сум дисеңме син?

Әнисе кулъяулык кебек чүпрәк кисәге алып, авыз-борынын сөртте дә улына төбәлде:

– Инде төзелешләрдә йөреп, ирләр эше эшләп кайтканнан соң, алдашуыңнан туктарсың дигән идем. Күрәсе көнем юк икән.

Башка вакытлар булса, Илнур ярсып китәр иде. Әле елмаеп кына куйды.

– Алдашмыйм мин, әни, – дип аркасыннан сөйде дә ишеккә атлады. – Хәзер...

Бераздан меңлекләрдән торган ике пачка акчаны өстәлгә китереп салды.

Әтисе белән әнисе бер мәлгә тынсыз калдылар, карашларын берчә акчага, берчә малайларына төбәп, әйтер сүз табалмыйча тордылар.

Шуннан әтисе әйтеп куйды:

– Анаңны сатыйм!.. Мондый акчаны без бит ел әйләнәсенә дә җыя алмыйбыз.

Әнисе кулын акчага сузды да кинәт улына борылды:

– Берәр мафия-фәләнгә эләкмәдеңме син? Эше авыр булса да, мондый акчаны бирергә бер җирдә дә атлыгып тормыйлар бит. Менә әтиеңнең дә эше җиңел түгел...

Аңа әтисе дә кушылды:

– Әйе, миңа менә бер дә түләмиләр. Ә синеке нинди эш соң ул?

– Төзелеш, – дип елмайды Илнур. – Хәрби төзелеш.

– Ә-ә-ә!.. – дип эләктереп алды әтисе. – Хәрби булса булыр. Сугыш өчен бернәрсә дә кызганмыйлар бездә. Менә белем, тәрбия, сәламәтлек өлкәсендә генә тиененә кадәр кысып тоталар. Ә сугыш өчен...

Әнисенең йөзе кабат яктырып китте:

– Ярый инде алай булгач, хәрби булса да, – дип елмайды ул. – Әле мин ялгыш юлга кереп китмәдеңме дип курыккан идем. Нигә бер дә шалтыратмадың соң?

Илнур елмаеп куйды:

– Хәрби объект булгач, телефоннар рөхсәт ителми.

– Ә без борчылдык.

– Борчылмагыз. Беләсезме, анда безне ничә кеше саклап тора! Берәр җиреңне канатсаң да, шундук медикларга илтәләр. Ул яктан барысы да әйбәт.

Әтисе тамак кырып куйды:

– Ә безнең белән берәр хәл булса?

Илнур уйга калды.

– Менә анысы авыррак инде. Монысы – эшнең тискәре ягы.

– Ярый, – дип елмайды әтисе. – Һәрбер эшнең бер ошамаган ягы була инде. Барыбызга да исән-сау булырга язсын.

Сөйләшүдән туктап, капкалап алдылар. Әнисенең пешергән ризыклары сагындырган, алар һәрвакыт тәмле була. Илнур тимер юл вокзалында кафега кереп чыккан булса да, ару гына состырды. Чәйне дә кабат-кабат ясатып эчте.

– Акчаларыңны алып куй инде, улым, – диде әнисе, ирләр табыннан кузгалганда. – Монда тормасыннар.

Илнур исем өчен генә биш-алты меңлекне санап алды да калганын әнисе ягына этәрде:

– Болары – гаилә чыгымнарына булыр, әни.

Әнисе акчаны кабат улына этәрде:

– Юк, улым, беренче хезмәт хакыңны үзең тот.

Илнур елмайды:

– Әни! Минем аны сезгә бирәсем килә. Интекмәгез бүтән, бераз ял итегез, дарулар алыгыз. Ә мин үземне үзем хәстәрләрмен.

Әнисе бер акчага, бер улына карап торды да күз читләрен сөртеп куйды:

– И, аларны уйлый белгәч, бик рәхмәт инде, балакаем. – Аның тавышы бераз калтыранып чыкты. – Куанычкайларын күрергә язсын инде. Ә син акча кирәк булса, сорап алырсың. Туктале, монда бит ике йөз мең?..

Илнур аның аркасыннан сөйде:

– Әйе, әни. Мин бер ай эшлим, бер ай ял итәм. Ике ай да хезмәт көненә исәпләнә, шул рәвешле, аена бер йөз чыга.

– Хәрбилә-әр... – дип көрсенде әтисе.

– И балакаем, рәхмәтләр генә яусын сиңа! – дип кочаклап алды әнисе һәм сулкылдап елый башлады. – Үз игелекләрең үзеңә әйләнеп кайтсын! Бәхет-шатлык эчендә йөзеп яшәргә язсын.

Әти-әнисе янында күңеле күтәренке булса да, үз бүлмәсенә кергәч, Илнур изрәп киткәндәй булды. Хәрби төзелештә эш чынлап та авыр булды шул, йончыткандыр да инде. Көнне төнгә ялгап, тир түгүләрен исәпкә алсаң, арытырга тиеш тә шул. Бөтен буыннар хәлсезлектән интегә, бөтен тән авырта, хәтта баш та оеган кебек. Нindидер уй уйлыйм дисәң, ул ярты юлда өзелеп кала... Илнур үзенең цемент болгатканын, кирпеч ташыганын, авыр йөкләр белән әллә ничәнче катка кадәр менгәнен хәтерли, ә бергә яшәгән, бергә эшләгән кешеләрне исенә төшерә алмый. Кемнәр иде алар? Нәрсә турында сөйләштеләр? Бер сүз әйтешмичә генә эшләмәгәннәрдер бит инде... Ә берсе дә хәтерендә түгел. Ярый, өенә кайтты инде. Беркадәр ял иткәч, барысы да урынына утырыр әле.

Ул рюкзагыннан иске эш киемнәрен алып, ваннага кертеп куйды. Чисталыкка чиста инде алар, тик барыбер юып куйсаң, яхшырак булыр. Аннан соң телефонын алып, зарядкага тоташтырды. Монысын да ай буена ачып караганы булмады. Иптәш егетләре аны югалткандыр инде. Иптәш егетләре... Кемнәр иде соң әле алар? Илнур аларның кем булуын тонык кына хәтерләгәндәй итә, тик төгәл генә күз алдына китерәлми. Шайтан алгыры! Адәм баласы шул кадәр үк арыса да арыр икән. Ә бәлки... Ул башын тоткалап карады – берәр җирдән егылып, йә бәрелеп зәгыйфьлек килмәгәнме, янәсе. Башында авырткан, күпкән урыннар бар иде. Тик болар гына әллә ни зыян китерә алмый бит инде. Ярый, ял итәргә кирәк. Соңгарак барысы да хәтеренә төшәр әле.

Ә әлегә... Коенып чыгарга да йокларга. Хәзергә аның йокысы килә иде.

**20**

Икенче көнне Илнур сәгать ун тулып киткәч кенә уянды. Әтисе дә, әнисе дә эшкә киткәннәр иде инде. Алар турында уйлауга, күңелен нindидер җылы җил иркәләп узгандай булды. Элек гел битәрләп торалар иде бит, менә хәзер тормышы көйләнеп киткәч, уллары өчен сөенәләр. Авыр вакытта төрткәләп алулары ничек кенә кыен булмасын, зыянга түгел инде, әзрәк уйлансын, шушы авырлыктан чыгу юлларын эзләсен, диләрдер. Балаларының тормышы җайланып китсә, аларның да җаны тынычлана

бит инде. Әнә бит ничек өзгәләнеп торалар! И, эти-әниләр беркайчан да начарлык теләми инде үз балаларына. Хәтта кайвакыт катырак кагылсалар да, яман ният белән кагылмыйлар. Йомшак җәеп, катыга утыртучылары да бик күп бу дөньяның. Ә эти-әниләр бүтән. Аларның кырыслыгы да фәкать балаларына яхшылык теләүдән.

Юынып, кофе кайнатып эчү белән Джонга шалтыратты. Тегесе хәзер үк килеп җитәргә вәгъдә бирде дә ярты сәгать дигәндә, әллә нинди озын чехол, кәгазь коробкалар күтәреп килеп тә керде. Әйберләрен почмакка куйгач, Илнурны кочаклап алды:

– Исән-сау кайттыңмы, хезмәт батыры! – дип, куенына кысты ул Илнурны. – Ябыгып киткәнсең әле, ашатмадылармы әллә?

– Ябыкмадым ич, шул килеш, – диде Илнур сүзсез калмас өчен генә. Ә Джон үзенекен итте:

– Мин перронда озатып калганда тазарак идең.

Илнур бер мәлгә аптырап торды һәм гаҗәпләнүле карашын аңа төбәде:

– Перронда? Озатып калганда?

Хәзер инде гаҗәпләнү Джонга күчте:

– Нәрсә? Хәтерләмисеңме әллә?

Илнур дәшмәде. Тимер юл вокзалын, перронны исенә төшерергә тырышты. Гомумән, ничек эшкә урнашуын...

– Юк, – диде ул, кинәт күңеле сүрелеп. – Мин бернәрсә дә хәтерләмим. Беләм, синең коллекторлардан коткарып калгач, эшкә чакыруыңны. Соңыннан очрашуны да хәтерлим. Син анда ниндидер әзерлек үтү турында сөйләдең бугай... Авыр булачак, дидең...

Джон аның аркасыннан какты:

– Әйе, әлегә авыр эштә йөрергә туры киләчәк дип кисәттем. Әзерлек ул нәкъ шушы инде. Авыр эшләр, йокысыз төннәр, ачлы-туклы чаклар... Син барысын да кичергәнсеңдер бит инде?

– Әйе...

Илнур боларны кичерүен белә иде, тик бер күренешне дә төгәл генә хәтерли алмый. Җирнең түгәрәк икәнен бөтен кеше дә белә. Аның глобус яки туп шикелле түгел, ә ничектер бозык түгәрәк икәнен дә беләләр. Тик беркем дә диярлек аның рәсемен ничек бар шулай итеп ясый алмый. Һәрхәлдә, эше шуның белән бәйле булмаган кешеләр. Илнурның да хәле шул чама иде.

– Менә шул инде әзерлек, – дип елмайды Джон. – Тора-бара син югарырак баскычка күтәреләчәксең һәм эшең дә җиңелрәк булачак.

Ләкин Илнур иптәшенең шатлыгын уртаклаша алмады:

– Джон... – диде ул, бик төшенке тавыш белән. – Мин чынлап та хәтерләмим. Күп нәрсәләрне...

Джон беркадәр уйланып торды:

– Бу, бәлки, синең ай буена авыр эштә эшләп, йончуыңнан киләдер, – диде ул хәстәрлекле тавыш белән. – Ни генә әйтсәң дә, физик талчыгу аңны да томалый бит ул. Борчылырга ашыкма син. Бер-ике атна ял иткәч барысы да җайланыр.

– Ә җайланмаса?

– Вакытыннан алда куркуга бирелмә инде, – дип шелтәләде Джон. – Әле

бит кайтканыңа бер көн дә юк. Ә син барысын да тиз генә үзгәртмәкче буласың, ашыктырасың... Алай ярамый инде... Болай паникага бирелсәң, ялың да ял булмас.

Джон дөрес әйтә иде. Илнур үзен кулга алырга тырышты.

– Әйдә, кофе эчеп алабыз.

– Рәхмәт, Илнур, башка вакытта, – дип, Джон күтәреп килгән әйберләрен бүлмәгә алып керде. – Менә мин нәрсәләр китердем!

– Нәрсәләр?

Джон чехолны ачты да өр-яңа Hatsan Escort PS винтовкасын тартып чыгарды. Илнурга бу мылтык таныш иде, авылдагы аучы туганының да нәкъ шундый коралы бар. Илнур аннан әйбәт кенә ата белә, гомумән, ул әйбәт ата иде. Ләкин Джон каян белгән? Ник алып килгән ул моны? Хәер... Менә бит исенә төшә башлады. Коллекторлар белән интеккән вакытта пистолетмы, автоматмы сораган иде егет.

– Нәрсә, аптырап калдың, әллә монысын да хәтерләмисеңме?

– Хәтерлим... – Илнур мылтыкны кулына алды. – Монысын хәтерлим.

Джон катыргы тартмаларны тумбочкага куйды:

– Болары патроннары.

Илнур мылтыкны уйнатып, аткан хәрәкәтләр ясады да тумбочкадан биш патрон алып, бер-бер артлы мылтык эченә озатты.

– Корылган килеш торсын, – дип елмайды ул, предохранитель төймәсенә басып. – Дөнья хәлен белеп булмый. Һәм мылтыкны да, патроннарны да шкаф эчендәге сейфка урнаштырып бикләп куйды.

– Рәхмәт сиңа, Джон! Күпме тиеш булам?

Джон көлеп җибәрде:

– Моның бәясе – әйтеп бетергесез. Чөнки әле аның менә бу нәрсәсе дә бар.

– Нәрсәсе?

Джон аңа кәгазьләр сузды:

– Документлары, – диде ул корал сыман салкын тавыш белән. – Лицензия, паспорт, һәм башкалар. Кыскасы, бу документларың янында булса, син урам буйлап мылтык болгап йөри аласың.

Документларны караган саен Илнурның йөзендәге елмаю яктырак балкыды. Монда барысы да әзер, хәтта аның корал тотарга өйрәнү буенча курсларда укуы турында да таныклык бар иде. Шайтан алгыры! Бу Джонның кулыннан килмәгән берәр эш бар микән? Менә бит... Бөтенесен җиренә җиткереп куйган.

– Рәхмәт, Джон! – дип кочаклап алды аны егет. – Мең рәхмәт!

– Әйбәт кешеләр бер-берсенә ярдәм итәргә тиеш, – дип елмайды Джон. – Без бит туганнар!

– Әйе, туганнар, – дип җөпләде Илнур һәм күңеленең кайсыдыр почмагында бу сүзнең яшерен сыман мәгънәсе дә ишетелеп киткәндәй булды. Бер генә мизгелгә. Илнур аны тотып өлгерәлмәде, әмма күңелендә ниндидер эзе калды.

Джон ишеккә атлады:

– Ярый, күрешербез әле, – диде ул, саубуллашырга кулын сузып, – әлегә эшләрем күп, озаклый алмыйм. Ә син ял ит.

Джонны озаткач, Илнур мылтыкны сейфтан алып, әйләндерептулгандырып торды. Яхшы нәрсә инде бу! Бәлки, авылга кайтып, ауга чыгып караргадыр? Җәнлек-җанвар атмыйча, калай тәлинкәләрне, су балоннарын гына кыйратып кайтсаң да, ярар иде, урман буенда йөрүнең, яшеллек арасында булуның үзгә бер шифасы бар аның. Җәяүли-җәяүли, аякларың мамыкка әйләнеп бетсә дә, күңелең ял итә. Болай дип уйлауга аяк буыннары үпкәләгәндәй тартышып куйды, тәнендәге авыртулар үзен сиздерде. Ярый, әлегә физик көчәнүләрдән тыелып торырга туры килер.

Мылтыкны урынына куйгач, Илнур кофе кайнатып эчте дә, нәрсәгә тотынырга белмичә аптырабрак торганнан соң, телефонын актарырга кереште. Шалтыратучылар, хәбәр җибәрүчеләр хәтсез генә иде. Аларны бер арада иркенләп карап чыгарга кирәк булыр. Ул үзе дә сизмәстән фотоларны актара башлады һәм Ләйлә белән икесе йөргән мизгелләргә тукталып калды. Күңелендә якты хисләр кабынды. Хәтта кочаклашмыйча-нитмичә, янәшә генә басып төшкән сурәтләрендә дә алардан сафлык, яктылык, мәхәббәт бөркелеп тора. Икесе дә ихлас, карашлары бер ноктага төбәлгән. Беркадәр вакыт узуга бер-берсен ташлап китәчәкләр, дип, беркем дә уйларлык түгел. Гомерләренең азагына тиклем шулай матур пар булып калырлар, мәхәббәттә, татулыкта яшәп, бәхетле балалар үстерерләр, хәтта әҗәлләре дә бер көнне, бер сәгатьтә килер шикелле.

Көрәшергә кирәк. Аңлашырга. Хәтта Денис куенында булуы да артык әһәмиятле түгел бугай. Ярату бар икән, барысы да җайланыр. Ә Илнур аны һаман ярата. Кешеләр хәтта ирдән аерылган, бүтәннән бала тапкан хатынга да өйләнәләр. Һәм бер дигән итеп яшиләр. Әгәр кеше бер тапкыр хаталанган икән, бу мәңге кичермәслек хәл түгел. Илнурның тормышы җайланды хәзер, ул бүгеннән өйләнергә әзер. Ләйлә каршы килмәсә, әлбәттә. Ә каршы килсә? Монда инде берни дә эшләп булмый. Аның фикерен хөрмәт итәргә һәм үз язмышың белән килешергә генә кала. Яраткан кешеңнең тормышын боза алмыйсың бит инде.

Көрәшергә кирәк.

**21**

– Син мине аңларга тырыш, – диде Ләйлә хис-тойгылар турында сүз чыгуга ук һәм Илнурның күзләренә текәлде. – Аңлый аласың икән – рәхмәтле булырмын, юк икән – үзең кара...

Илнурның йөрәге жу итеп куйды. Ул инде сөйләшүнең ничек тәмамланачагын чамалый иде. Хет хәзер үк борылып кит, әмма соңыннан күңелеңне үкенечләр тырнамасын, ялган өметләр белән кабынырга, азактан үкенергә туры килмәсен өчен барысын да ачыкларга кирәк.

– Минә минем әти белән әни, – дип дәвам итте Ләйлә, – бер-берсен яратып өйләнешкән. Яратышып яшәделәр дә бугай. Әмма алар арасында да еш кына тавыш чыга һәм моның сәбәбе акча җиткерә алмау иде. Көнетөне эшлиләр, казганалар, ә акча җитми, аңлыйсыңмы?

– Һе, – дип куйды Илнур, аның елмаясы килгән иде, тик елмаю килеп чыкмады. – Аңлыйм, әлбәттә. Безнең үзебездә дә шундый ук хәл.

Алар үзләренең йорты белән мәктәп арасындагы парк эскәмиясендә утыралар иде. Бу элек аларның яраткан урыны иде, якында гына

атынгычлар, таганнар, арырак китсәң – карусель. Элек алар эңгер төшкәч, шунда атыналар, әйләнәләр, көлешә-көлешә мәш киләләр иде. Ул чакларда әти-әниләренең ярлылыгы да, үзләренең кесәсе буш булу да борчымый, алар болай да бәхетле иде. Хәзер менә...

– Ә хәзер менә күз алдыңа китереп кара, – Ләйлә бераз тынып торды да дәвам итте, – әгәр әни берәр баерак егетне сайлаган булса, һич югында икесенең берсе бәхетле булыр иде. Бу тиклем үк интекмәсләр иде.

Илнур көлеп җибәрде:

– Ул чагында бу дөньяга син түгел, ә бүтән кеше туган булыр иде.

– Кем белә? – дип, иңнәрен сикертте Ләйлә. – Тик бу бүтән мәсьәлә... Синең белән тормыш корсак, без дә шулай булачакбыз. Ә ярлылык, җитмәүчәнлек мәхәббәтне сүрелдерә ул. Без икебез ике якта акча дип чабачакбыз, ә аралар суыначак.

– Шул гынамы?

– Гына түгел. – Ләйлә җитдилеген җуймады. – Менә син икебез йөргән вакытларны күз алдыңа китер. Инстаграмга гына күз сал... Минем яшьтәге кызларның барысы да диярлек матур күлмәкләрен киеп төшкән фотоларын куя. Көн саен яңа кием. Йә диңгез буенда ял итә, йә чит илләрдә, һич югында үзебезнең берәр ял йортында. Затлы рестораннарда кәеф-сафа корып утыралар. Егетләре белән!

Шайтан алгыры! Нәрсәгә алданып йөрде икән Илнур, ник аз гына игътибарлырак булмады икән? Югыйсә берәр ресторанга кереп утырырга да, ял итеп кайтырга да җай таба алыр иде бит инде. Юк! Сөйгәне аны-моны сиздермәгәч, ул аны болай да бәхетле дип уйлады.

– Мин әйбәт урынга эшкә кердем, – дип акланды ул. – Хәрби төзелешкә. Акчаны анда әйбәт түлиләр, без интекмәячәкбез.

Ләйлә аңа сынаулы караш ташлады.

– Хәрби төзелешкә? – Ул елмайгандай итте, тик бу елмаюда астан кисә торган ниндидер үткенлек бар иде. – Әйбәт түлиләр! Котлыйм, димәк өстеңдәге затлы костюмыңны прокатка алмагансың. Ә машинаң... Ә фатирың кайда? Ник без затлы ресторанда түгел, ә паркта сөйләшеп утырабыз? Ярый инде, паркта очрашабыз дип үзем әйттем, үзебезнең мәктәптә практика узам бит, әмма син ресторанга алып китәргә дә мөмкин идең...

Бу сүзләр, шаян чаялык белән әйтелмәсә, Илнурның йөрәген теләргә дә мөмкин иде. Тик егет тыныч калды. Бәлки, моңа матди хәленең чынлап та яхшыруы да сәбәпчедер инде.

– Киттек ресторанга, – дип елмайды ул. – Кая барырга телисең?

Ләйлә чәчен төзәтеп куйды:

– Рәхмәт. Андый мохтаҗлык юк. Денис та тиздән киләчәк.

– Яратасыңмы соң?

Ләйлә дертләп китте:

– Синеме? – Күзләрендә очкын кабынды. Тик ул үзен тиз кулга алды. – Илнур, син һаман аңламыйсың... Хәзер хис-тойгыларга бирелә торган заман түгел. Без кечкенәдән дуслар булып, бергә үстек, үсмер чакны, яшьлек иртәсен бергә каршыладык. Без бәхетле булдык. Ләкин... Без хәзер олы тормышка аяк басабыз. Ә анда хисләргә урын юк. Тормышыңны яхшы

итеп көйлим дисәң, хис түгел, ә аек акыл, исәп-хисап алдан йөрергә тиеш. Заманы шундый.

Илнур аның сүзләрен нәрсә дип тә кире кага алмады. Кире каккан очракта да Ләйләне үзгәртү мөмкин түгел иде инде, ул үз карарында нык тора һәм аны ачыктан-ачык белдерә. Шулай да егет:

– Заманны без ясыйбыз, – дигән булды.

– Бу заманны акча ясый, – дип төзәтте Ләйлә. – Ул идарә итә.

Бер мәлгә тынлык урнашты. Илнур үзен матур гына атлап барган җирдән таш стенага килеп бәрелгән кеше кебек тойды. Бөтен ягында да таш стена иде, бер яктан да бәреп чыгарлык түгел. Шулай да ул сүз әйтерлек көч тапты.

– Димәк, синең күңелдә миңа карата бернинди дә хис юк?

Ләйлә бер мәлгә тынып торды да бөтен гәүдәсе белән егет ягына борылды. Аның куенына ташланырдай булып укталып куйды, әмма тыелып калды, бары тик күзләрендәге татлы газап белән үрелгән нур гына озак сүрелде. Бугазындагы төерне йотып куйды да:

– Бар, Илнур, – диде һәм хәлиткеч алышка әзерләнгәндәй тынып торды. – Дуслык та, туганлык та... Мәхәббәт тә... Мәхәббәтен күңелнең иң төбенә яшердем инде. Син аны казып чыгартырга тырышма, яме. Югыйсә миңа бик кыен булачак. Ә дуслык һәм туганлык... Алар һәрвакыт әзер. Нинди генә авырлыкка төшсәң дә, хәбәр ит – мин иң беренче килеп җитәчәкмен.

Беренче мизгелдә үзен мәхәббәт давылына уралгандай тойса да, Ләйләне кинәт кочаклап алырга, иреннәрен эзләп табарга, иркәләргә-назларга теләсә дә, Илнур тыелып кала алды. Яраткан кешеңнең йомшаклыгыннан файдаланырга ярамый иде. Ул сабырлыгын җуймаска тырышты. Аңлашырга дип килде, аңлаштылар. Ләйләнең үз язмышын сайлау хокукы бар һәм аны хөрмәт итәргә кирәк. Кыз да боргаланып-сыргаланып тормады бит, ачыктан-ачык, ихлас күңеленнән әйтеп бирде. Аның бу сыйфаты үзе генә дә ихтирамга лаек иде.

– Яхшы, – диде ул, тавышы моңсурак чыкты һәм тирән көрсенеп куйды да ныклырак булырга тырышып дәвам итте. – Яхшы. Туганнар булып калыйк.

Туганнар сүзен әйткәндә, тагын күңелендә нидер кыбырдап алды, тик әле аның кайгысы түгел иде. Һәм Илнур дәвам итте:

– Нинди генә авырлыкка төшсәң дә, син дә хәбәр бир. Мин синең иң беренче туганың.

Тын калдылар.

– Ә мин сине башкача борчымам. Үзең сайлаган юлда бәхетле бул.

– Сиңа да бәхет телим, – дип, урыныннан кузгалды Ләйлә. – Бу безнең соңгы очрашу булсын...

Илнур да кузгалды.

– Соңгы тапкыр бер кочаклашыйк инде... – дип, колачын җәйде ул. – Туганнарча гына булса да.

– Туганнарча... – диде Ләйлә һәм Илнурга сыенды. – Юк, сөйгән ярларча. Әмма соңгы тапкыр.

Сөйгән ярыңны кабат куеныңда тою шулкадәр ләззәт иде. Илнурның бөтен күзәнәкләре сөю дулкынына, мәхәббәт назына күмелде, бу халәтнең

соңгы тапкыр икәнен белгәнгә күрә аерыласы килмәде. Ләйлә читкәрәк тайпылса да, Илнур аны ычкындырырга теләмәде...

– Әй, сез!.. – дигән тавыш ишетелде. – Ләйлә!

Ләйлә коты алынып, Илнурның куеныннан арынды һәм гаепле кыяфәттә басып калды. Эскәмия янында Денис басып тора иде. Илнур аңа каршы атлады:

– Денис, син онытмаган булсаң, Ләйлә минем яратканым иде, – диде ул тыныч кына. – Без теге вакытта кинәт аерылыштык, аңлашалмый калдык. Ул сиңа мөкиббән китте.

– Әлбәттә, шулай булырга тиеш иде, – дип батырланды Денис. – Тик әле нигә кочаклашып торасыз?

Илнур елмайгандай итте:

– Без аңлаштык. – Ул бер мәлгә тынып калды, Денисның йөзеннән кара шәүлә үтте, тик егет аңа борчылырга ирек бирмәде. – Без аңлаштык. Ул сине сайлады.

Денис бераз тынып торды да тавышын күтәрә биреп:

– Син болай кыланырга тиеш түгел идең, – дип, телефонына үрелде һәм нәрсәдер баскалаганнан соң дәвам итте: – Бу сөйләшүдә мин дә катнашырга тиеш идем. Ә хәзер... Син мине рәнҗеттең. Абруемны төшерергә тырыштың. Җавап бирергә туры киләчәк.

Илнур аңа кулын бирде:

– Бу безнең соңгы очрашу иде, – диде ул, ягымлырак булырга тырышып. – Син мине башкача беркайчан да күрмәячәксең. Мин сезне бүтән борчымаячакмын.

Денис аның килешергә сузылган кулын игътибарсыз калдырды:

– Әлбәттә, борчымаячаксың, – дип ыржайды ул. – Ә монысы өчен җавап бирергә туры килер. Хөрмәтле кешенең абруен төшерү – яхшы түгел.

Илнур сабыр булырга тырышты, әмма җавапсыз кала алмады:

– Минем алда синең абруең юк, – диде ул. – Ә булмаган нәрсәне күтәреп тә, төшереп тә булмый.

Һәм борылып китеп барды:

– Хуш, Ләйлә!

– Хуш!

– Кунакларны каршыларга җыен, – дип калды Денис аның артыннан һәм Ләйләгә боерды: – Ә син... Марш, машинага!

Бик теләсә дә, каршы торалмаслык әллә нинди көчләр мәҗбүр итәргә тырышса да, Илнур артына борылып карамады. Хәзер аңа артка борылырга түгел, алга барырга һәм үз өлеше белән килешеп яшәргә кирәк иде.

Агачлык куерганрак урынга җитүгә кемнеңдер тавышы ишетелде:

– Әй!

Илнур тавыш ягына күз салды. Озын таза гәүдәле егет тора иде. Ул арада моның иптәшләре дә чыкты һәм уратып алдылар. Егетләрнең басып торуына карап та аларның спорт, аның да сугышчан төре белән шөгыльләнүләре сизелә иде.

– Ә ихтирамлы кешеләрнең хатыны белән очрашырга ярамый, – диде беренче булып Илнурны сәламләгәне. – Моның өчен җәза каралган.

Денис бая телефон төймәсенә баскалый иде. Тиз, шайтан алгыры.

Өстәвенә, элекке шикелле җебек нәрсәләр түгел, берсеннән-берсе таза, чын сугышчылар. Бишәү. Болардан котылам дисәң, йөгереп кенә качып буладыр. Тик ни өчендер ул йөгерергә ашыкмады. Алда торган егет ашыкмыйча гына якынайды да аягын күтәрде... Илнур аның аягы җирдән аерылу белән сул аягының кыры белән туктатты да ниндидер гади дә, көчле дә алым кулланды. Һәм икенче мизгелдә артында торган егеткә сикерде... Шул рәвешле, берничә секунд арасында биш әзмәвернең бишесен дә җиргә сылап, һуштан яздырды. Бер мәл аптырап карап торды. Аннан соң иелеп, һәркайсын тикшереп чыкты, сулышлары бар, йөрәкләре тибә иде. Һәм тиз-тиз атлап, ары китте.

Үзенең уңышына ул үзе дә аптырый иде.

**22**

Ләйләне гаепләп тә булмый инде, бер карасаң. Чынлап та, акча кытлыгы кичерми яшәү бик рәхәт: ул тамак туклыгы, өс бөтенлеге генә түгел, ә күңел хөрлеге дә икән. Кесәңдә җил уйнаганда, син үзеңне мескен итеп тоясың, офыкларың тарайганнан-тарая барып, газап зинданына әверелә, тормышыңның нурын томалый. Ә акчаң барда син хаким – ни теләсәң шуны уйлый, әйтә, эшли аласың. Ни генә дисәң дә, акчалы кеше иреклерәк була.

Илнур да шушы җитеш тормышының бөтен уңайлыгын файдаланырга тырышты. Монда чарасызлыкның да өлеше бар иде бугай. Кечкенәдән килгән мәхәббәт ул тиз генә күңелеңнән йолкып ата торган нәрсә түгел бит инде. Паркта очрашып сөйләштең, барысын да ачыкладың һәм онытып, җиңеләеп калдың, дигән сүз түгел. Күпме генә җиңәргә, аек акыллы булырга тырышсаң да, әрнүләре барыбер тынгы бирми, бергә үткәргән мизгелләр, парлашып корган хыяллар кабат-кабат искә төшә, уйланырга, сызланырга мәҗбүр итә.

Илнур башта кәгазьгә төшерелгән фотоларны бер папкага җыеп, балкондагы шкаф почмагына яшереп куйды. Тиз генә ачылмасын өчен ул аны скотч белән чорнап бетерде. Ташларга иде дә боларны, тик нигәдер көче җитмәде. Аннан соң телефонында, компьютерында булган фотоларны җуйдырды. Берсен дә калдырмаска тырышты. Онытырга кирәк. Онытырга.

Әмма Ләйләнең йөзе, сыны күз алдыннан китмәде. Ул аны бернинди фотосурәтсез дә күрә, юксына иде. Тора-бара онытылыр әле. Әлегә ул бергә үткәргән мизгелләренең һәммәсен хәтерли, онытырга теләсә дә, оныта алмый иде. Шулай җәфалана торгач, ул үзенә шөгыльләр эзләргә тотынды. Бу халәттән ничек тә котылырга, игътибарны читкә юнәлтергә кирәк иде.

Иң беренче эш итеп, ул деканга шалтыратты. «Мин сиңа иң мөһим темаларның исемлеген табып бирермен. Кыскача язылган конспектлар рәвешендә...» – дигән иде ул теге вакытта. Әле шул хакта исенә төшерү белән:

– Хәзер үк килсәң дә ярый, биреп җибәрермен, – диде.

Илнур аны барып алды. Декан үзе юк иде, кинәт кенә каядыр чакырып алганнар. Кәгазьләрне сәркатип кызга калдырган. Өенә кайткач, Илнур аларга күз йөгертеп чыкты. Чынлап та яхшы нәрсә иде бу. Лекцияләрнең кыскача конспектлары, укырга тиешле китапларның кыскартылган вариантларын кайдан табарга икәне. Болары интернетта бар икән. Тагын

әллә нәрсәләр... Вакыт табып өйрәнергә генә кирәк. Ә өйрәнергә кирәк иде. Вакыт ул болай да, тегеләй дә үтә. Файдалырак үткәрсәң, күпкә әйбәтрәк.

Илнур театрларга йөрде. Элек бик кызыкса да, акчасын жәлли торган иде. Әйтик, дәресләрдә Кәрим Тинчуринны үтәләр икән, театрга барып, аның әсәрен карап кайту үзе бер өстенлек. Ләкин кесәңдә җил уйнаганда, алай итеп булмый иде. Ә хәзер – хөррият. Татар спектакльләренең барысы да диярлек мәхәббәт турында икән. Аларны караганда, күзгә яшьләр килә, үз хәлләреңне искә төшереп, күңелең айкала да, чистарынып каласың.

Концертларга йөрде. Монда да кызык иде. Тере җырчыны сәхнәдән күрү әллә нинди тылсымлы күренеш икән. Аның халыкка мөнәсәбәте бөтен залга тарала да тамашачыларны урап ала. Дөнья мәшәкатьләрен, күңел яраларын оныттырып тора. Концерт тәмамланып, урамга чыккач, үзеңне бөтенләй башка тормышка аяк баскандай тоясың. Әмма концертларның тәэсир көче Илнурга җитеп бетми иде. Илнурга ниндидер көй, ниндидер моң җитми иде.

Һәртөрле паркларда, аттракционнарда йөрде. Һич югында кибетләргә кереп, үзенә бер кирәге булмаган нәрсәләрне карап, гомер уздырды. Монысы да кызык иде. Соңгы елларда әллә күпме яңа төр товарлар сатуга чыккан икән. Моңа кадәр бер дә игътибар иткәне юк иде. Кайберләренең хәтта нәрсә икәнен дә белерлек түгел.

Бер азык кибетенә кергәч, килька балыгы консервасы янында тукталып калды. Элекке танышын очраткандай, бер тын карап торды. Бу балык консервасы аңа чынлап та таныш, якын, кадерле сыман тоелды. Тик Илнур ник шулай икәнен генә аңлый алмады. Һәм консерваны кәрзиненә салды. Касса янына җиткәч тә, аны кулына тотып әйләндерә-әйләндерә карап торды.

– Нәрсә шулкадәр әйләндерәсең, – дип көлде кассир хатын. – Кием-салым түгел бит инде ул, җебе чыкмый, җөе күренми.

Илнур дәшмәде. Подъезд алдына кайткач та, эскәмиягә утырып, килька балыгын өйрәнде. Бу гади консерва түгел, ә ниндидер тылсымлы әйбердер, ул үзе аңлап җиткермәгән нәрсәләрнең ачкычы нәкъ шушында ятадыр шикелле иде. Озак утырды. Тик балык консервасы да, дөнья да үзгәрешсез калды.

Өйгә кергәч, ваннага кереп, кулларын юды. Аннан туалетка кереп, унитаз бачогына балык консервасын яшерде. Ул үзенең ник болай эшләве турында уйлап та карамады. Тагын ваннага кереп, баштанаяк коенып чыкты да кофе кайнатып эчте. Өйдә кеше юк иде. Фикерен читкә тарткалаучы булмагач, уйлары тагын Ләйләгә әйләнеп кайтты. Ул бергә чакларының һәр мизгелен хәтерли иде. Истәлекләргә бирелеп... Дөресрәге, ул истәлекләрне хәтереннән җуярга тырышып, диванда беркадәр аунагач, көтелмәгән уйдан дертләп китте.

Моңа охшаш уй элек тә вакыт-вакыт калкып ала торган иде. Тик ул чакларда кыска вакытка гына ялтырап китә дә шундук юкка чыга. Эзе дә калмый. Ә бу юлы Илнур ул уйны җилкәсеннән песине эләктергәндәй тотып алды һәм гаҗәпкә калды.

Ул бу уйны кем белән уртаклашырга да белмәде. Элекке дуслары белән күптән инде аралашканы юк, аның тормышы белән хәбәрдар булмагач, бу халәтне аларга аңлатып та булмыйдыр. Ләйлә белән аралары өзелде.

Карале, Илнурның эч серләрен уртага салып сөйләшер кешесе дә юк икән ләбаса. Элегрәк, мәктәптә укыганда да, институтка кергәч тә, ул йомык кеше кебек түгел иде, иркен аралаша, дуслары да күп кебек тоела. Эч серләрен бүлешәм, дисә... Күңеленең иң төпкелендә яткан серләрне дә ул Ләйлә белән уртаклаша ала, шуңа күрә җан дусларына кытлыгы юк шикелле иде. Әле менә барысы да бүтән төсмер алды. Аның бер чын дусты да булмаган икән. Хәзер дә юк. Джоннан башка, әлбәттә.

Илнур тагын шуңа шалтыратты:

– Джон... – дулкынлануы аның тавышына ук чыккан иде: – Мин... Мин бөтен нәрсәне дә хәтерлим.

– Нәрсә? Бөтен нәрсәне дә? – Джонның тавышында да дулкынлану, хәтта бераз курку ишетелгәндәй тоелды. – Төгәлрәк әйт әле. Син нәрсәләрне хәтерлисең?

– Бөтен нәрсәне дә!

– Моның булуы мөмкин түгел... – диде Джон һәм кинәт тукталып калды. Бераз тын торды, аннан дулкынлануы бетмәгән тавыш белән дәвам итте: – Аңлатып сөйлә әле.

Илнур сулышын тәртипкә китерде, уйларын бер җепкә тезәргә тырышты, шуннан соң гына сүз башлады:

– Мин бөтен нәрсәне дә хәтерлим, – диде ул һәм үзенең һаман шул бер сүзне кабатлавын сизеп, тезеп китте: – Ләйлә белән йөргән вакытларның һәр мизгелен, бөтен нечкәлекләре белән. Мәктәптә укыган чакларны, институтта үткәргән мизгелләрне... Паркта кыйналып аунап ятканда, синең ничек килеп җитүеңне, коллекторлардан коткарган вакытыңны... Барысын хәтерлим.

– Шуннан? – дип түземсезләнде Джон. – Кыскарак сөйлә инде.

– Мин төзелештә эшләгән вакытымны гына төгәл хәтерли алмыйм. Нәрсә төзедек, кемнәр белән эшләдек, нинди киемдә идек, кайларда нәрсә ашадык... Кыскасы, мин боларның берсен дә искә төшерә алмыйм.

Джон ничектер җиңеләеп калды бугай, кычкырып көлеп җибәрде. Тавышы да күтәренке иде:

– Һәй, сантый... Һаман шуның белән баш катырасыңмыни әле... Үтәчәк бөтенесе дә.

Тик Илнурның тавышы шомлы иде:

– Син аңламадың, Джон, – диде ул, авыр сулап. – Әгәр барысына да талчыгу сәбәпче булса, мин бернәрсәне дә төгәл хәтерләмәскә тиеш булыр идем. Мәктәп елларын да, сине дә... Ә монда алай түгел. Теге кинодагы шикелле... Хәтерлисеңме? «Тут помню, а тут не помню».

– Шулай шул... Анысы бик дөрес... – Джонның тирән уйда икәне тавышыннан ук сизелә иде, ул озак кына дәшми торды да кинәт нәрсәнедер исенә төшерде. – Карале, безнең бер егет белән дә шундый хәл булган иде бит... Нык яшерен объектта эшләгәнлектән, нindидер чаралар белән аның хәтерен вакытлыча томалап торган булганнар. Бер айдан узды.

– Бер айдан?

– Әйе. Син борчылма, үтә торган нәрсә бу. – Джонның көлгәне ишетелде. – Яшәргә бик комачауламый торгандыр бит?

Илнур да елмайды:

– Юк, анысы... Тик кайвакыт гаҗәпкә генә калдыра... – Илнур бер мәлгә

икеләнеп торды да әйтергә булды: – Без Ләйлә белән очраштык...

– Шуннан?

– Денис моны сизеп калды да мине кыйнау өчен биш егетне җибәрде. Әзмәверләр. Һәм мин аларның барысын да мизгел эчендә җиргә сыладым.

Джонның көлгәне ишетелде:

– Маладис!

– Шулай анысы... Тик мин бу дәрәҗәдә сугыша белми идем... Әллә нинди үзем белмәгән алымнар кулландым...

– Нәрсә? – Джонның тавышы бераз сәеррәк ишетелде, ул бер мәлгә тынып торды. – Үзең белмәгән алымнар? Бала-чага булма инде, Илнур. Бу «үз-үзеңне саклау инстинкты» дип атала. Йөзә белмәгән кешене суга ыргытсаң, ул чәбәләнә-чәбәләнә дә иң кирәкле хәрәкәтләрне үзе уйлап таба һәм йөзеп китә. Монда да шул ук хәл бит инде. Әзмәвердәй биш егеттән кыйналасың килмәгәч, син дә нәрсәдер маташтыргансың.

Илнур үзен бер дә юкка чәбәләнүче бала сыманрак тоеп, гарьләнеп куйды. Башыңда ниндидер таракан уянган саен болай кылана башласаң, акылдан язуың да бар.

– Борчылма, бар да яхшы булачак!

– Рәхмәт, Джон, тынычландырдың, – дип елмайды Илнур. – Кайчагында мин сабый бала кебек инде... Гафу ит...

– Ярый. – Джон да елмайды бугай. – Син дә тынычландырдың. Әле мин җитди проблема бармы әллә дип борчылган идем. Ярый... Ә-ә-ә... Бүген өеңдә кун әле син. Иртән бәлки күрешербез.

**23**

Джон белән сөйләшкәч, тынычлангандай булса да, бу халәте озакка җитмәде. Паркка барып, тирга керү белән күңелен тагын шик биләп алды. Илнур мылтык күргән кеше иде, әлбәттә, яхшы гына ата иде. Ләкин бу дәрәҗәдә үк түгел.

Башта күнегелгән җиңеллек белән бер-бер артлы хәрәкәтсез торган мишеньнәрне кыйратып чыкты. Аннан соң каядыр йөгерә торган кечкенә калай җәнлекләрне пыр туздырды. Моңа хәтта тирда эшләүче абзый да гаҗәпләнде:

– Ай-һай, егет... – дип, тел шартлатты ул. – Син хәтта төзәп тә тормыйсың бугай. Кайда остардың шул хәтле?

Илнур иңнәрен генә җыерып куйды. Үзенең мәргәнлеге, тир хуҗасының сүзләре аңа горурлык өстәде. Тагын бераз атты да кочак тулы бүләк күтәреп, ары китте. Парк буйлап болай бару уңайсыз, ә бу уенчыкларның берсе дә аңа кирәк түгел иде. Карусель янына җыелган бала-чага янына җиткәч, ул аларны өләшеп чыкты. Мондый көтелмәгән бүләктән сабыйларның түбәсе күккә тиде:

– Зур рәхмәт сезгә, абый!

– Рәхмәт!

Сүзләрдән бигрәк, аларның самими, саф тавышлары, күзләрендә балкыган ихлас шатлык нурлары җанга ләззәт булып ягылды. Сабыйларны сөендерә алуына үзе дә шатланып, озак кына атлады Илнур. Кешеләрне шатландыра алу зур бәхет инде, бер карасаң. Әнә бит, Ходай күпме куаныч бирә адәм

баласына... Кешеләр шатланган саен ул да сөенәдер, аңа да рәхәт буладыр, шуңа күрә ул мәңге яшидер дә.

Парк капкасын узып, тукталышка атлаганда гына күңелендә нәрсәдер «кылт» итеп куйды. Илнур хәтта тукталып калды. Аптыраулы карашларын тирә-якка йөгертте. Өнме соң бу? Төш кенә түгелме?

Өн иде. Тротуар буйлап кешеләр каядыр ашыга, кемнәрдер үз уйларына чумган, кемнәрдер телефонга төбәлгән, берсенең дә тирә-якта гаме юк – күзеңә карый-карый килсәләр дә, күрмичә узып китәләр. Моннан да чынрак өннең булуы мөмкин түгел иде.

Ләкин Илнурны сискәндергән нәрсә бүтән иде. Тир! Тирда ул берни уйламыйча, ничектер автоматик рәвештә бөтен мишеньнәрне кыйратып чыкты. Ул әйбәт ата иде. Әмма башта төзәп тора, сулышын тәртипкә китерә... Ә бу юлы ул ату өчен махсус эшләнгән робот шикелле кыланды. Ату аның канына сеңгән, ана сөте белән дә, тана сөте белән дә кергән шөгыль кебек иде.

Һәм шундук Ләйлә белән көрешкәннәреннән соң, акылга утыртырга килгән егетләрне мизгел эчендә сузып салганын искә төшерде. Бу ике күренешне янәшә куйгач, хәтта куркыныч булып китте. Мактану теләге ничек кенә борын чөяргә тырышмасын, бу бик сәер күренеш – Илнур бу дәрәҗәдә сугыша да, ата да белгән кеше түгел иде. Шундый җиңел генә эшләнә торган сугыш алымнарын аның үзләштергәне юк, хәтта барлыгын да белми иде. Мылтыктан ату серләренә дә бу тиклем тирән керә алганы юк.

Төзелештән кайткач, ул беркадәр үзгәрүен үзе дә сизә иде. Сабыррак булып калдымы соң шунда, уй-фикерләре талгынракка әйләндеме... Тормышка карашы да бераз аруланды бугай. Моны ул ярлылыктан котылу белән бәйли иде. Акчаң җитәрлек булып, теләгәнеңне эшли алгач, бик зарланып йөрмисең бит инде. Иркенлектә яшәгәч, үзең дә киң күңеллерәк буласың.

Тик хикмәт анда гына түгел бугай. Сугышканда һәм атканда, ул бөтенләй башка кешегә әверелә, аның һәр хәрәкәте җиренә җиткерелгән була. Тагын нәрсәләр белә икән ул? Нинди өлкәләрдә югары дәрәҗәдәге осталык күрсәтә ала икән? Боларны тик торганнан гына тикшереп карау мөмкинлеге юк, һәркайсы үз вакыты белән ачылачак иде. Вакыт... «Вакыт» дигәндә, күңеленең бер почмагында нәрсәдер ачылып-ябылгандай булды. Тик бу төнге яшен яктысында күренеп калган кара шәүләләр сыман гына иде. Берни аңларлык түгел.

Хәтерләргә кирәк иде.

Төзелеш... Джон аны перронда озатып калдым, ди. Нинди поезд иде ул? Кайсы якка бара? Нинди купега утырды? Анда кемнәр бар иде? Кайсы станциядә төштеләр? Кемнәр каршы алды? Эшкә урнашу барышы ничек булды? Кайда яшәде? Шайтан алгыры! Сораулар шул тиклем күп, ә берсенә бер төгәл җавап юк.

Хәтер ишекләре бикле иде. Илнур үзен чынлап та бер бүлмәдән икенчесенә ишек шакып йөргән кеше кебек тойды. Тик ишекләр хәрәкәтсез калды, эчке яктан да җавап бирүче булмады. Аптырагач, ул тибәргә, бөтен авырлыгын салып этәргә тырышты. Файда юк. Бу ишекләрне нәрсә

беләндер ватарга, яки нindидер хәйлә уйлап табарга кирәк иде. Тик ул бер чара да таба алмады.

Джонга кабат шалтыратырга кыенсынды. Бәлки, ул берәр чара таба алыр иде, чөнки аның башы да йомры, тәҗрибәсе дә зур. Һәрбер катлаулы хәлдән чыга белә. Тик адым саен аны борчып, эшеннән бүлү дөрес тоелмады. Әйтте бит инде, сабыр ит, борчылма, беркадәр вакыттан соң бар да узачак дип. Шулай булгач, аңа шалтыратудан да файда булмаячактыр. Тагын шул ук сүзләрен кабатлар да тынычландырырга тырышыр.

Бәлки, чынлап та тынычланырга кирәктер? Әгәр Илнур белән үзгәреш булган икән, начар якка үзгәрмәгән бит. Ир-егет өчен иң кирәкле һөнәрләрне үзләштергән. Шулай булгач, әлләниләр уйламыйча гына үз тормышың белән яшәргә кирәк. Тыныч кына. Ә бераздан барысы да хәл ителер.

Ул урам буйлап озак кына йөрде дә күз бәйләнә башлагач кына кайтып керде. Әтисе гәзит укып утыра. Әнисе өй җыештырып йөри, уены-чыны белән кемнедер тирги.

– Нәрсә булды? – дип сорады Илнур. – Тавышың әллә каян ишетелеп тора.

Әнисе алъяпкычына кулын сөртеп алды да бәдрәфкә ымлады:

– Бар әле, бачогын ачып кара... – диде ул, шелтәле елмаеп. – Әтиең консерва банкасы яшереп куйган. Аракысы да булгандыр инде аның, анысын алып эчкән дә монысын оныткан.

Әтисе гәзитен ташламыйча гына әйтеп куйды:

– Мин куймадым аны. Үзең беләсең, эчмәгәнгә дә хәтсез була.

Илнур туалетка кереп, унитаз бачогын ачып карады. Аның төбендә яткан килька консервасын күреп катып калды. Күзләрен алалмыйча озак торды. Әнисе өчен аның бу кыяфәте сәер булып тоелды бугай, ул тавыш-тынсыз гына улын күзәтте.

– Әллә синең эшеңме бу, Илнур? – дип куйды соңыннан.

Илнур баш какты. Әнисе башын чайкап куйды:

– Ник алай иттең соң, улым?

Илнур иңнәрен генә сикертте дә тавышланмаска кушып, учын югары күтәрде. Һәм бачок төбендәге консерва банкасына текәлеп торуында булды. Бераздан бачок бөтенләй икенче төрлегә әйләнде. Аның чит-читләре бераз тутыккан, төбенә юшкын утырган, ә шул юшкын өстендә торган консерва банкасы нәкъ шул килеш иде. Илнур аны күтәреп алды. Ашыйсы килә иде. Моны ачарлык мөмкинлеге дә бар аның, буш гильза башын яньчеп, үзенчә җайланма ясаган иде. Тик моны ашарга кирәкми инде, түзәргә кирәк...

– Нишләп торасың инде һаман, – дип җилтерәтте аны әнисе. – Килька күргәнең юкмы әллә? Бар, юын, тамагыңны туйдыр. Монда миңа җыештырырга кирәк.

Илнур дәшми генә үз бүлмәсенә узды. Әле генә күз алдына килгән күренешне дәвам итәргә тырышты, тик бернәрсә дә кабатланмады. Ул караватка утырды да бар гәүдәсен йомшартып тынып калды, күзләрен йомды, сулышын иркенгә җибәрде. Су өстендә йөзгән мамык хәлендә шулай беркадәр утыргач, нәрсәдер исенә төшкәндәй сикереп торды да шкаф өстен сыпырып карады, анда бернәрсә дә тапмагач, элгечтә асылынып торган киемнәренең кесәләрен актарырга кереште, тик анда да ул эзләгән нәрсә юк иде. Һәм иң кызыгы: ул үзенең нәрсә эзләгәнен белми иде.

## 24

Урынга яткач та, Илнур йокыга китәлмәде. Көне буе урамда йөрү арыткан булса да, тәннең һәрбер күзәнәге ял таләп итсә дә, уйлары котылгысыз бер дәрья булып ургылды да ургылды. Аның тормышында нәрсәдер дөрес түгел, җанында тигезлек югалган, ә баш мие шул тигезсезлекнең сәбәбен табарга тырышып эшли, аны тыеп торырлык кодрәт юк иде.

Уйлары аны әллә кайларга алып китә. Кай тарафка гына юллансалар да, тупыйкка килеп төртеләләр, йә упкынга очып югалалар һәм, яралы ерткычтай ярсып яңадан калкып чыгалар. Илнур аларны тыя да алмый, җыеп, бер тарафка юнәлтерлек көче дә юк, уйлар аны санламыйлар, үз дигәннәренә ирешергә тырышалар...

Кайчагында шул уйлар дулкыны өстендә ниндидер таныш чалымнар, таныш сурәтләр калкып чыга да, аның ни икәнен аңлап өлгергәнче күздән югала. Карашында чагылып өлгергән шул кисәкчәләрне бергә җыярга теләсәң дә, бу килеп чыкмый, алар таныш түгел алфавит шикелле аңлаешсыз булып кала.

Йокыга китәлмичә әле бер, әле икенче якка боргаланып ята торгач, Илнур торып утырды, утны яндырмыйча гына бүлмәдәге әйберләрне күз алдына китерергә тырышты. Түрдә – кечкенә өстәл, уң якта – карават, карават өстендә телевизор, каршы як – сугыш алымнарын өйрәнү өчен эшләнгән җайланмалар, идәнендә – 3-5 килолы гантельләр, ишек төбендәрәк – тактадан ясап, лак белән эшкәртелгән кием шкафы. Сул як ишек төбендә – кечкенә раковина, аның өстендә – стенага эленгән тартма, раковина янында – кечкенә тумбочка...

– Ниһаять!

Илнур торып, утны яндырды. Ниһаять, аның күз алдында ниндидер төгәл күренеш хасил булды. Хәтерендә калды. Бу бүлмә аларның тулай торагында идеме? Ә ник анда бер генә карават? Спорт кирәк-яраклары... Груша, макивара, кечкенә гантельләр... Болар нәрсә өчен? Димәк, Илнур нәкъ шушы эш урынында, хәрби төзелештә сугышырга өйрәнгән. Спорт секцияләре, ярышлар күз алдына килми. Шушы бүлмәдә шөгыльләнгән ул, ниндидер бик маһир остазы да булган. Күнекмәләр эштән соң идеме? Илнур күзләрен йомып, теге грушаларны, гантельләрне яңадан күзалларга тырышып карады – килеп чыкмады. Ә шулай да бүлмә күренеше хәтерендә калды. Ул чоңгыл өстендә бөтерелгән икмәк кисәге сыман Илнурның уйларында әйләнде дә әйләнде.

Бераздан ул бәдрәфкә кереп, унитаз бачогын тагын ачып карады. Килька консервасы һаман шунда тора иде. Илнур аңа бик озак итеп карап торды. Бернинди хис, бернинди тойгы кисәге яралмады. Аптырагач, ул күңелендәге сурәтләрне бәйләргә тырышты. Бүлмә, бүлмә почмагында бәдрәф, унитаз бачогы эчендә килька консервасы.

Моннан да мәгънәсезрәк нәрсәнең булуы мөмкин түгел иде. Ләкин шундук икенче нәрсә игътибарын биләде. Үзе соң... Ни өчен консерва сатып алды ул? Ни өчен аны үз фатирындагы бачокка яшерде. Ул бит ач та түгел иде. Килька яратучы да түгел. Ник? Килька балыгын соңгы тапкыр кайчан ашады икән? Бик күптән. Әллә түгелме? Ул күзләрен йомып, аның

тәмен хәтерләргә тырышты. Менә ул балык ашап утыра... Урманда... Юк... Өйдә... Юк... Теге бүлмәдә... Юк... Анда да түгел...

Монда торуның файдасы тимәде. Ул үз бүлмәсенә узды. Ишек төбенә басып, хыялындагы теге бүлмәне күз алдына китерергә тырышты. Ул уйлаганча килеп чыкмады, ниндидер куе томанга күмелгән картина кебек нәрсә генә чалымланды. Әмма бу тырышлык юкка гына булмады, тагын нәрсәнедер уятты... Сугышу! Грушалар, макиваралар һәм тагын әллә нинди җайланмалар булгач, Илнур шушы бүлмәдә дә шөгыльләнгән бит инде. Теге алымнарны кабатлаган. Һәм егет бүлмә уртасына басып, паркта кулланган алымнарының берсен кабатларга тотынды. Кабатлый алмас кебек иде. Тик тән хәтере көчлерәк булып чыкты, ул аны үзлегеннән берниндиди көчәнүсез, зур төгәллек белән эшләде. Тиз, кискен. Һәм тән хәтере аша нәрсәгәдер ирешергә теләп, бер-бер артлы алымнарны кабатлады. Аркасына тир бәреп чыга башлагач, иреннәрендә ниндидер сүз пәйда булды. Пышылдап кына әйтелгән бу сүзләргә ул башта игътибар итмәде, тик алар бераздан гына колагына барып иреште һәм кайтаваз булып аңында яңгырады:

Кискен каршылык күрсәтү!

Күңелләрне тетрәтү!

Илнур туктап калды. Монысы да бер табыш иде. Тик нинди табыш? Нәрсә белән бәйле? Ул аңлый алмады. Үз тормышы авыр чакларда ул илдәге вазгыять белән канәгать түгел һәм моны беркайчан да яшерми иде. Ләкин каршылык күрсәтү турында... Әйе, Джон белән танышкач, ул каршылык күрсәтүнең иң әһәмиятле алым икәненә ышанды. Монысы аңлашыла. Ә күңелләрне нигә тетрәтергә? Җавап юк иде.

Егет ваннага кереп чайканып чыгарга булды. Җылымса су да нәрсәнедер исенә төшергән кебек иде. Җайлы гына кебек барысы да, ниндидер пәрдә артында гына торадыр, кул сузымы арасында гынадыр кебек. Тик бернәрсә дә кылып булмый.

Юынып чыккач, тагы йокларга ятты. Ләкин уйлар өермәсе тукталмады. Хәзер инде ул үзенең нәрсә уйлаганын да аңларлык хәлдә түгел иде. Баш мие бер киреләнсә, киреләнеп тә карый икән! Берничек тә тотып тыярлык түгел. Ул бик озак боргаланып ятканнан соң, хәлсезләнеп йокыга китте. Монысын да йокы дип булмыйдыр әле аның. Бәлки аны һуштан язу дияргә кирәктер. Керфеген кыймылдатырлык хәле калмаса да, ул баш миенең хәрәкәтен тоеп яткан шикелле иде. Йокы белән уяулык арасында шулай кысылып ята торгач, үзе дә сизмәстән йокы куенына шуып төште. Монда рәхәт иде.

Йоклаучылар бер Илнур гына түгел икән, рәт-рәт булып унлаган егет тезелеп яткан. Бераздан алар шәүләләр җиңеллеге белән торып бастылар да тын калдылар. Бераздан сакал-мыегын пөхтә итеп кистергән кеше пәйда булды. Аның башында патшалар таҗына охшаган нәрсә, өстендә ерактан бик затлы булып күренгән җилән иде.

– Остаз! – дип пышылдады кемдер. – Ул безнең рухи терәгебез.

Чынлап та аны күрүгә бөтен кеше дә тураеп басып тынып калды.

– Хәерле яңа төн белән, туганнар! – дип сәламләде Остаз. – Яңа төннең якты йолызлары белән! Күк йөзе бер булса да, аның йолдызлары бихисап. Сез дә шул, йолдызлар кебек, барыгыз да – бертуган. Барыгыз да уртак максат өчен яшисез, хезмәт итәсез. Сез – бертуганнар!

– Бертуганнар! Туганнар! – дип, йокы аралаш сөрән салды Илнур һәм борылып ятты. Ә төшендәге күренеш өзелмәде. Остаз әле һаман аларның алдында тора иде.

– Йоклаган җәмгыятьне уяту өчен аны дер селкетеп алырга кирәк, – дип дәвам итте Остаз. – Бөтен кешеләрнең дә күңеле тетрәнерлек булсын. Бары тик шунда гына җәмгыять уяначак һәм үзен изүчеләргә каршы тору юлын караячак. Аларга кискен каршылык күрсәтергә кирәк.

– Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү! – дип кабатлады төркем. – Кискен каршылык күрсәтү! Күңелләрне тетрәтү!

Төркемдәгеләрнең сөрәненә йокысы ачылып, Илнур торып утырды. Тагын нәрсәдер хәтерләргә тырышып, озак кына маташса да, берни килеп чыкмады. Ул юынып килде. Йокысы ачылса, фикерләре дә үткенләнеп китәр сыман иде. Өлкәннәрне уятмаска тырышып, кофе кайнатып куйды. Бераз йоклап алгач, хәле яхшырыбрак киткәндәй булды. Кофе чүмерә-чүмерә, хәтерендә калкып чыккан кыйпылчыкларны бер рәвешкә китерергә маташты. Төгәл, анык сурәт килеп чыкмаса да, нәтиҗә чыгарырлык җирлек бар иде.

Димәк, болай килеп чыга... Аны бернинди төзелешкә дә алып китмәгәннәр, ә хәрби әзерлек үтә торган урынга... әлегә ачык кына әйтеп булмый инде... Кыскасы, аны... аларны ниндидер көчләргә каршылык күрсәтү өчен әзерлиләр. Ниндидер махсус отряд инде бу. Спецназ... Яки диверсион төркем... Алары әлегә караңгы.

Хәзер инде ул үзенең бик кодрәтле хәрби көчләр вәкиле икәнен аңлый иде. Хәтерен томалап торулары да аңлашыла. Мондый урыннарда иң затлы белгечләр хезмәт итә, диләр бит. Хәрби элита. Димәк, ул да шушы элитаның бер өлеше.

Шулай да күңеленең бер почмагында кыюсыз гына баш калкытып алучы бер көч бар иде. Илнур моңа игътибар итеп тормады. Кабат йокларга ятты. Тик бу юлы да йокысы бик тыныч булмады, өнендә кыюсыз гына баш калкытып маташкан көч, төшендә кешегә әверелеп, бүлмәнең бер диварын кирка белән тишәргә тотынды. Артык зыяны тимәде, шулай да стенага бәргән тавыш әледән-әле йокыдан арындырырга тырышып комачаулап торды.

– Тук! Тук! Тук!

Тик Илнур аңа бернинди каршылык та күрсәтә алмады. Хәтта сүз дә әйтмәде. Бар булмышы хәлсезлектә изрәгән иде.

**25**

Бераздан ул киркасын куйды да Илнурга борылды, сүз әйтмәде, кул изәп кенә чакырды. Аның бөтен кыяфәте серле иде, Илнур бер теләге булмаса да, кызыксынуын җиңә алмады, күзләрен уа-уа аның янына килде. Ап-актан киенгән карт иде бу. Башына да ак япма бөркәнгәнлектән аның кыяфәтен чамаларлык түгел. Карт әле генә үзе кирка белән ясаган тишеккә ымлады. Һәм күздән югалды. Илнур чиксез гаҗәпләнүле карашларын тирә-якка йөгертте, әмма картны таба алмады һәм беркадәр аптырап торганнан соң, теге тишеккә күз салды. Карт кирка белән тук та тук килсә дә, тишек тигез иде. Илнур күземне төртеп тишмәсеннәр тагы дигәндәй шикләнеп кенә стенаның теге ягына карады һәм сискәнеп китте.

Күрше бүлмәнең каршы диварында матур савытларга утыртылган шәмнәр янып тора, ә Т хәрефе рәвешендәге өстәлнең каршы ягындагы кәнәфидә күзләрен йомган килеш бер яктан икенче якка җиңелчә генә чайкалып, Илнур утыра иде. Ә өстәлнең түрендә – өстенә затлы җилән, башына таҗ кигән ак сакаллы изге зат.

– Остаз! – дип пышылдады Илнур. Һәм үзенең бу бүлмәдә утырган чагы хәтеренә төште. Монысын төгәл генә әйтерлек тә түгел иде әле. Аның җаны теге тишек аша узып, күрше бүлмәгә кердеме, дивар үзе юкка чыктымы – нәрсәдер булды, нидер үзгәрде инде. Әллә ул Остаз алдында утырган Илнур белән бергә кушылдымы… Нindидер зур үзгәреш булды, хәтта тирә-як яктырып китте. Бүлмәдәге исләр дә борынына килеп бәрелде, сизелер-сизелмәс агылган музыка да, хәтта остазның сүзләре дә ишетелә башлады.

– Без җәмгыятьне уятырга, зомбига әверелгән кешеләрне кичекмәстән дәваларга, азат итәргә, тулы канлы тормыш белән яшәтергә бурычлыбыз. Ә моның өчен җәмгыятьнең бер тетрәнеп алуы таләп ителә. Нык тетрәнеп, сискәнеп уянуы кирәк. Мондый хәл, әлбәттә, корбаннар сорый. Һәм без кешеләрнең иң йомшак урынын табарга тиешбез. Һәркемгә кагыла, беркемне дә битараф калдыра алмый торган әрнү ноктасын табарга кирәк.

Илнур бар булмышы белән ләззәтле дулкында тибрәнеп утырса да, Остазның сүзләрен аермачык ишетә.

– Бала, – дип пышылдый Остаз янында утырган Илнур. – Балаларны кулланырга кирәк…

Йокыдагы Илнурның җен ачуы чыга. Аның авызын томаларга, урыныннан сөйрәп торгызып, бүлмәдән чыгарып ыргытырга, кыйный-кыйный һушына китерергә тели. Тик шундук Остазның: «Нык тетрәнеп, сискәнеп уянуы кирәк», – дигән сүзләрен исенә төшерә дә тынып кала… Аның: «Бу вазифа сиңа йөкләтелә, – дигән тавышы ишетелә. – Чөнки син – бердәнбер. Алла. Алла гел мәрхәмәтле генә булмый. Кешеләр азынып, бозылып киткән чакларда ул җәза коралына әверелә һәм адәм балаларын һәртөрле вулканнар, җир тетрәүләр, су басулар аша җәзалый. Меңнәрчә корбаннар барлыкка китерә. Син дә – җәзалау алласы. Син кешеләрне утлы корал аша җәзалаячаксың. Дөньядагы бар тереклек өчен иң кадерле нәрсә – бала. Син аларның балаларын алып, барлык кешеләрне, хәтта үз балалары булмаганнарны да тетрәнергә мәҗбүр итәчәксең. Син берүзең бөтен җәмгыятьнең астын-өскә китереп, кешелекне уятырга сәләтле зат. Син – Алла! Дөньядагы бөтен җан иясе сиңа буйсына.

– Мин – Алла, – дип кабатлый Илнур. – Мин Алла һәм үз вазифамны үтәргә тиеш.

Чарасызлыктан йокыдагы Илнурның күңеле актарыла:

– Юк! – дип кычкыра ул, бөтен дөньяны уятырдай тавыш белән. – Юк!.. Болай эшләргә ярамый!

Тик аны беркем дә ишетми.

– Юк! Юк!..

Кинәт Остазның карашы аңа төшә һәм алдында дивар пәйда була. Анда инде ак япма бөркәнгән карт та, ул ясаган тишек тә юк. Әмма әле генә күргәннәре аның күз алдыннан китми. Һәм ул йодрыклары белән стенаны дөмбәсләргә тотына…

– Юк!

Илнур үз тавышына сискәнеп уянып китте. Сикереп торды да, әле генә күргән төшеннән айный алмыйча, дивар янына килеп басты. Тукталып калды. Тирә-ягына каранып алды. Саташу гына булды бугай… Тукта, башта юынырга, йокыдан айнырга кирәк…

Көннәр буена уйланып йөргәч, төшендә аның аңы күңеленең бикле ишекләрен кирка белән ватып керде. Ә Остаз – чынбарлык. Үзенең Остаз янында утыруы да – хәтердән җуелган вакыйгаларның бер өлеше. Ул үзен хәрбиләрнең элита төркеменә карый дип уйламакчы иде. Алай түгел. Аны балаларны үтерү өчен әзерләгәннәр. Террорчы ул. Зомби.

Кофе канны йөгертеп җибәргән кебек булды. Аның аңы да саф һәм йөгерек хәлгә килде. Тагын нәрсәләрнедер исенә төшерергә мөмкинлек булыр сыман иде. Тик кофе артыннан кофе чүмереп, уйлау сәләтен бар көченә кулланырга тырышса да, берни килеп чыкмады. Уйлары бөтенләй башка юнәлешкә йөгерде.

Үзеңнең зомби икәнеңне тану авыр иде…

Бушка вакыт әрәм итү… Монысына әле түзәргә дә буладыр… Ә бит ул моңа кадәрле вакытын гына түгел, ә тормышка карашын, димәк, гомеренең эчтәлеген дә бушка әрәм иткән. Җәмгыятьне, кешеләрне, үзен уратып алган кешеләрне дөрес күрмәгән. Бу дөньяда бар нәрсә дә бар икән бит, бары тик аны дөрес күрергә генә кирәк.

Ә бу җиңел түгел… Чөнки ул һәрвакыт синең күңел халәтеңә бәйле. Күңелең көр чакта син яхшылык, матурлыкларны күрәсең. Үзең дә шул матурлыкның бер бизәгенә әвереләсең, аны үзең бизисең. Күңелең кителеп, җаныңа урын тапмаган вакытларда тормышның авыр якларын, гаделсезлеген, пычраклыгын күрәсең. Һәм үзең дә пычраклыкның бер төренә әверелеп, тормышны тагы да ныграк гарипли башлыйсың…

Ә без бу тормышны бизибез дә, пычратабыз да… Чөнки без аның чикләрен белмибез… Аның чикләре юк та бугай… Кемгәдер кылган игелегем, кемгәдер явызлык булып кайта… Кемгәдер кылган явызлыгым игелеккә әверелә.

Барысы да гади кебек кенә күренсә дә, Илнурның күңелен авыр тойгы кисеп үтте. Аның дөрес кебек тоелган уйлары да дөрес түгел иде. Балаларга каршы кылынган явызлык беркайчан да, беркем өчен дә игелеккә әверелми. Чөнки алар безнең киләчәк. Үткәннәрне үзгәртеп корырга да мөмкин әле, тарихның теге яки бу күренешләрен бозып та күрсәтергә мөмкин. Ә киләчәкне бозу бүгенгене дә, иртәгәне дә һәлакәткә китерә.

Бүгенге көннең бер кабахәте дә кешелекнең киләчәгенә кизәнергә тиеш түгел.

Тормыш беркайчан да бер кимчелексез генә бармаган, һәр чорның, һәр дәвернең үз авырлыклары бар. Һәм алар һәрвакыт булачак. Чөнки яшәү – әнә шул авырлыкларны җиңүдән тора. Җәмгыять дәрәҗәсендә алсаң да, аерым кеше мисалында карасаң да.

Кемнәр ни генә дип әйтмәсен, бүгенге дәвер – кешелекнең иң рәхәт яшәгән вакыты. Адәм баласы бүген бик күп авырлыклардан азат һәм бар игътибарын үз шәхесенә юнәлтә ала.

Аны уятырга да, айнытырга да кирәкми.

Ә кешене бәхетле итү, аны яхшырту теләге белән башланган гамәлләрнең барысы да канкоешка килеп төртелә. Октябрь революциясен аласыңмы, һәртөрле сугышларнымы – барысы да бер. Канкоешлар беркемгә дә бәхет китерми. Кеше бары тик тынычлыкта гына бәхетле була ала. Әгәр ул бүген шушы халәтендә үзен яхшы хис итә икән, аны борчырга кирәкми дә, ярамый да.

Аны зомбига әйләндерүчеләр дә «кешелекне бәхетле итү» дигән шигарьгә капланып, үз мәнфәгатьләре өчен көрәш алып баручылар. Алар күзгә бәрелеп торган кимчелекләрне күпертеп, тормышны тоташ карадан тора дип күрсәтергә тырыша. Һәм күп очракта бу уңышлы килеп чыга. Кеше психикасын яхшы өйрәнгән кара күңелле белгечләр һәр күренешне, һәр җитешсезлекне үз файдаларына борып җибәрә ала һәм бу чынбарлык кебек тоела. Иң куркынычы – менә шул. Чөнки ул белемле һәм акыллы кешеләрне дә үз кармагына эләктерә ала.

Югыйсә Илнур да надан, акылсыз, ихтыярсыз кеше түгел иде. Ә менә ничек килеп чыкты. Аны авыр физик нагрузкаларга, ачлыкка, ялгызлыкка дучар итүләре бары тик егетнең аңын томалау, аңгырайту һәм шул халәтендә аңына үтеп керү, шәхесен алыштыру өчен генә булган.

***

Ә аның хәле аяныч иде. Котылгысыз. Ул үзенең тирда атып алган бүләкләрне балаларга өләшкән чагын хәтерләде, сабыйларның самими тавышын, күзләрендәге ихласлыкны кабат тойгандай булды. Җәмгыятьне уяту, кешеләрне бәхетле тормышка чыгару кирәк булган хәлдә дә бер гөнаһсыз сабыйлар гомеренә кул сузу олы җинаять, зур гөнаһ иде. Ләкин башыңа шундый коточкыч нәрсә салынган икән, аңа карышу мөмкин түгелдер… Ул иртәме-соңмы хәрәкәткә киләчәк һәм сине дөньяның иң кабахәт бәндәсенә әйләндерәчәк. Моны аңлаудан аның бөтен җанын-тәнен курку алды, газап телгәләде. Коточкыч гамәл кылып, үз-үзен, әти-әнисен кара кайгыга, мәңге җуелмас хәсрәткә батырып, кимсенү-мыскыллауларга калдырып киткәнче үз-үзенә кул салуы мең кабат артыграк иде.

Анысы да мактаулы гамәл түгел, дәү әниләренең авылында, әнә, үз-үзенә кул салучыларны хәтта зиратка җирләргә дә рөхсәт итмиләр. Ләкин алда торган коточкыч әшәкелек янында бу гөнаһ гафу ителмәслек түгелдер.

Әлбәттә, үзеңне шушы хәлгә төшерүчеләрне эзләп табып, юкка чыгарганда, бик яхшы булачак иде. Бик теләгәндә, бу адәм кулыннан килми торган гамәл түгелдер. Ләкин Илнурның вакыты юк иде. Теләсә кайсы мизгелдә аңа сигнал килергә мөмкин. Һәм шәхесен алыштырырга. Ул чакта Илнур шундый әйбәт егеттән зомбига, махсус әзерлек үткән әҗәл коралына әйләнәчәк. Һәм моңа беркем дә, хәтта Илнур үзе дә, каршылык күрсәтә алмаячак.

Фаҗигане булдырмый калу өчен бердәнбер юл – үз-үзеңә кул салу иде. Тормышың башланып кына килгәндә, күңелеңдә ал хыяллар балкып торганда, бу адымга бару җиңел түгел. Ләкин бер гаепсез сабыйларның гомерен саклау өчен бүтән чара юк. Мондый үлем, бәлки, гөнаһ та түгелдер әле ул. Бәлки, бу яу кырында шәһит китүгә тиңдер. Кемнәрдер иптәшләрен саклап калу өчен дошман амбразурасын үз күкрәкләре белән каплаган. Ә Илнур балалар гомерен саклап калу өчен…

Озакка сузарга ярамый иде. Кайсы вакытта нинди хәбәр киләсе билгеле түгел, ул чакта өлгерәлми калуың да бар.

Илнур тагын бер кат юынып чыкты да кара төстәге киемнәрен алып киде. Бу фатирда ярамый, әти-әниләренә мәңге онытылмаслык яра булып калыр. Өйгә кайткан саен искә алып газапланырлар, тормышлары тормыш булмас. Үкенеч зур иде. Югыйсә ул әле унтугыз гына яшьтә бит. Барысы да башлана гына. Тик Илнур бөтен ихтыяр көчен туплап, үзен кулга алырга тырышты. Эченнән генә дәртле көй көйләде… Бер карасаң, әллә ни куркыныч та түгел. Монысы аның нибары үлем генә. Ә балаларны һәлак итү… Менә анысы инде – фаҗига. Фаҗигане булдырмаска кирәк. Кара джинсы чалбар, кара футболка өстеннән шундый ук төстәге ветровка киде. Мылтыгы әзер, рюкзагында берничә кап патрон бар. Барысы да алдан әзерләп куелган шикелле иде.

Ишек төбенә җиткәч тукталып, бүлмәгә күз йөгертеп чыкты. Тамагына төер утыра башлавын тоеп, урамга ташланды. Урамда көн матур иде, кояш балкый, назлы җил исә. Агач башларында кошлар сайрый. Берничә кеше елмаеп, сәлам биреп узды. Бу тормышны хурлап булмый инде, бер карасаң. Тик ул хисләргә бирелмәскә тырышты. Паркка кереп, аулаграк урындагы эскәмияләрнең берсенә барып утырды. Алар монда Ләйлә белән еш булалар иде. Соңгы тапкыр шунда аз гына утырып торасы килде. Аз гына. Соңгы тапкыр…

Ул мылтыгын чехолдан алды, предохранителен ычкындырды һәм ашыкмыйча гына көпшәсен авызына якынайтты. Мондый чакта ниндидер дога укырга кирәк бугай. Тик Илнур берни дә белми иде.

Көтмәгәндә, телефонының будильнигы шалтырады. Илнур мылтыгын читкә алып, телефонга үрелде. Аны сүндерүгә, ватсаптан ниндидер хәбәр килде. Тавышлы хәбәр. Бик кыска гына язма булгач, Илнур аны тыңларга булды. Анда Остазның:

– Вазифаңны үтәргә вакыт җитте, – дигән сүзе ишетелде һәм катгый боерык яңгырады: – Вакыт!

Илнур бер мизгелгә упкынга очты, һушын җуйды. Бөтен җаны-тәне-аңы таркалып китте дә буш савыт булып кабат җыелды. Ул хәлсезләнеп, эскәмиягә сузылып төште, ә бераздан үзенең җыела, тула баруын, тормышка кабат кайтуын тойды… Тик ул инде бүтән шәхес булып кайтачак һәм ул шәхескә ирек куймаска кирәк иде. Моны хәзердән үк башларга теләсә дә, Илнур үзендә каршы килерлек көч таба алмады.

Соңлады ул… Соңлады, шайтан алгыры!

Тик бераздан бу үкенечләрен бөтенләй башка нәрсәләр алыштырды һәм ул, мылтыгын кулында уйната-уйната, тәвәккәл адымнар белән мәктәп ягына атлады…

## 26

«Вакыт!» – Бу гади әмер генә түгел, ә аның бөтен язмышын билгели торган сүз иде. Хәзер аның бу тормыштагы иң мөһим мизгеле, яшәвенең мәгънәсе хәл ителә. Моңа кадәрге бөтен гомере шушы мизгелгә әзерләнү иде. Ә хәзер – Вакыт!

Күңелендә тәвәккәллектән башка бернинди хис юк иде. Аның максаты изге, юлы дөрес, күңеле чиста. Кешелекне гафләт йокысыннан уяту өчен ул аларны тетрәнергә, сискәнергә мәҗбүр итәргә тиеш. Моның иң тәэсирле бердәнбер ысулы – аларны газиз балаларыннан мәхрүм итү.

Мәктәп ихатасында бер кыз бала китеп бара иде. Илнур мылтыгын аңа юнәлтте.

– Атма! – дигән тавыш ишетелде. Тавыш түгел, боерык. Әмма бу Остаз да, Джон да түгел иде. Илнурның үз тавышы. Егет бер мәлгә аптырабрак торды да ары атлады. Кем әйтсә дә, дөрес әйтә – атарга кирәкми, эшне мәктәпнең эченнән башлау әйбәт.

Ул мәктәпкә узды, монда хәрби сакчылар юк. Ишек төбендәге кечкенә будка сыман нәрсәдә вахтёр карчык утыра. Вероника Ивановна. Элек ул рус теле һәм әдәбиятыннан укыта иде, яхшы укытучы булды, Илнур аны яратты. Мәктәптән соң филология факультетын сайлавында аның да өлеше бардыр әле. Вероника Ивановна коры гына итеп:

– Кемгә киләсез? Документларыгыз? – дип кистерсә дә, елмаеп, аңа каршы килде. – Илнур түгелме соң?

Илнур ни әйтергә дә белмичә тынып калды. Аңа салынган программада мондый нәрсәләр юк, тик ул карчыкны атарга кирәген белә иде. Ә күңеленең кайсыдыр бүлмәсендәге билгесез көч ашыкмаска куша. Илнур мылтыгын төзәргә өлгергәнче, Вероника Ивановна аны кочаклап алды:

– Әйдә, үт, улым, – ди ул әниләрчә ягымлылык белән. – Урамда бик эссе, чәй эчеп кит.

– Юк... Рәхмәт... – Монысын Илнур үзе әйтми, аң астыннан килгән тавыш әйттерә. – Военрук монда микән, минә мылтыкны төзәтәсе иде.

Карчык Илнурның терсәгеннән алып, будкага алып тарткалады:

– Әйдә әле, улым, утыр әле. – Һәм үз итеп, күз кысып куйды. – Иң затлы үләннәр кушып ясадым. Синең мондый чәйне эчкәнең юк.

Илнур бутала, ишектән читкә тартыла. Чәе чынлап та тәмле була иде аның. Элек, югары сыйныфларда укыганда да, ул Ләйлә белән икесен чәйгә чакыргалый иде. Язучылар тормышының мәктәптә өйрәнелми торган мизгелләрен, әдәби әсәрләрнең язылу тарихын һәм башка шуның ише кызыклы вакыйгаларны сөйли. Хәзерге тормышка кагылышлы нәрсәләрне дә кузгатып ала. Аннан соң, шундый игътибары да күңелгә ятып кала. Ә чәе һәрчак тәмле иде.

– Филология факультетында укыйсыз икән дип ишеттем, – дип елмайды Вероника Ивановна.

– Әйе, – Илнурның тавышы корырак чыкты. – Шунда.

Илнур мылтыкны Вероника Ивановнаның эченә төбәде. Карчык моңа игътибар итмәде, Илнурны күрүгә ул чынлап та шат һәм аннан бернинди начарлык көтми иде.

– И, сөендем инде... – Вероника Ивановна аның аркасыннан кагып куйды. – Сез һәрвакыт өметле булдыгыз.

Илнур кинәт урыныннан кузгалды:

– Гафу итегез, мин ашыгам...

– Яхшы, яхшы, балам, чәйне төшкәндә эчәрсең...

Илнур ашыкмыйча гына өченче катка күтәрелде дә баскыч янындагы

класс бүлмәсе алдында туктап калды. Менә хәзер инде бөтен кешелекне тетрәндерерлек итеп кыйратырга була иде.

Ул – Алла. Алла гел мәрхәмәтле генә булып тора алмый. Кешеләр азынып, бозылып киткән чакларда ул җәза коралына әверелә һәм адәм балаларын һәртөрле вулканнар, җир тетрәүләр, су басулар аша җәзалый. Меңнәрчә корбаннар барлыкка китерә. Ул да – җәзалау алласы. Ул кешеләрне утлы корал аша җәзалаячак. Дөньядагы бар тереклек өчен иң кадерле нәрсә – бала. Алла аларның балаларын атып, барлык кешеләрне, хәтта үз сабыйлары булмаганнарны да тетрәнергә мәҗбүр итәчәк. Ул берүзе... берүзе бөтен җәмгыятьнең астын-өскә китереп, кешелекне уятырга сәләтле зат. Ул – Алла! Дөньядагы бөтен җан иясе аңа буйсына.

– Мин – Алла, – дип кабатлады Илнур. – Мин Алла һәм үз вазифамны үтәргә тиеш. Һәм класс бүлмәсенә атлады.

Кинәт бүлмә ишеге ачылып китте дә аннан китап-дәфтәрләр күтәреп чыккан яшь укытучы кыз күренде. Илнур шуны гына көтеп торгандай, атып җибәрде. Кыз стенага барып бәрелде дә шуып төшә башлады. Күкрәгеннән кан саркылып чыкты, йөзен гаҗәпләнү һәм сызлану пәрдәсе каплады, күзләре зур ачылып, түшәмгә төбәлде. Илнур катып калды. Мизгел эчендә күз алдыннан бөтен гомере узгандай тоелды. Комлыкта уйнап йөргән вакытлары, җитәкләшеп парк эскәмиясендә утырулары, таганда атынулары, беренче үбешүләре... Һәм бөтен булмышын газап көйдерде.

– Ләйлә, – дип пышылдады ул җан ачысы белән. – Ләйлә...

Ләкин шундук аңына икенче шәхес хуҗа булды:

– Син – Алла! Дөньядагы бөтен җан иясе сиңа буйсына, – дип кабатлады ул. – Син Алла һәм үз вазифаңны үтәргә тиеш.

Тавышка тирә-яктагы бүлмәләрдән кешеләр атылып чыкты. Шау-шу купты. Боларның барысын да кыйратырга мөмкин иде. Тик Илнурның чиксез тетрәнүләре аны бер мизгелгә үз акылына кайтарды һәм ул сөйгәненә карады. Соңгы тапкыр. Ләйлә стена буйлап шуып төште дә идәнгә егылып тынып калды. Илнурның аң төпкелендә:

– Син – Алла! – дигән тавыш яңгырады.

Ашыгырга кирәк. Соңларга ярамый. Ләкин басым чыдап булмаслык иде.

– Балаларны кыйрат! Вазифаңны үтә! – Тавыш көчәйгәннән-көчәя барды, ул читтән дә түгел, ә галәм киңлегеннән ишетелә иде. Күкләр җиргә төште, Илнурның бар булмышын кара болытлар чорнады, болытлар арасыннан дәһшәтле тавыш яңгырады, бу тавыштан егетнең башы чатнады. – Ат! Тәтегә бас!

Илнур бар көченә каршы торырга тырышты. Тик ниндидер кодрәт аны класс бүлмәсенә әйди, мылтыгын балаларга төбәргә мәҗбүр итә. Кулыннан кемдер тотып, юнәлтеп торган шикелле иде. Ул карышты. Һуштан язар чиккә җитсә дә, бирешмәскә омтылды. Тик мондый басымга түзәр чарасы юклыгын ул инде аңлый иде. Мылтык инде балалар ягына караган, аны бераз күтәреп тәтегә генә басасы бар...

Ашыгырга кирәк!

Тик ашыгып та булмый иде. Хәтта кулларны йомшартып та, мылтыкны ташлап та булмый. Берничә секунд – һәм бер гаепсез сабыйларның гомере

өзеләчәк. Ул җиңелә. Хәзер инде явызлык аның күңеленә үк үтеп керде. Карышу мөмкинлеге дә калмаячак...

Бөтен булмышы явызлык дулкыны белән тула баруын тоеп, ул кинәт мылтыгын күтәрә төште һәм көпшәсен үзенең ияк астына терәп тәтегә басты. Шартлау яңгырады. Бөтен дөнья ялкынга уралган вак кисәкчәләргә әверелеп тирә-якка чәчрәде.

– Өлгердем, – дигән шатлыклы уй һавада асылынып калды. – Балалар исән!..

* * *

Үзләренең нинди һәлакәттән котылып калуларын аңлап җитмәгән кешеләр телефонга үрелделәр. Тиздән «ашыгыч ярдәм» машинасының үзәк өзгеч тавышы ишетелде. Аның артыннан ук полиция хезмәткәрләре килеп җитте. Ә берничә минуттан әлеге хәл турындагы хәбәрләр, видеоязмалар, фоторәсемнәр белән бөтен интернет тулды...

Газета-журналларда шундый хәбәрләр пәйда булды:

«Ул үзен ташлап киткән кызны үтерә. Мәктәп коридорында!»

«Сөйгән кызы ташлап китү сәбәпле депрессия кичергән егет мәктәп балалары арасында үзенең яраткан кызын атып үтерә һәм үзенә кул сала...»

«Үтереш! Сөйгән кызы башканы сайлый, ә егет аның белән килешергә теләми!»

Бераздан интернетта ниндидер ханымның язмасы пәйда булды:

«Бу хәбәрләрне укыгач, үз улым турында уйландым. Ул да һич көтмәгәндә үзенә кул салды...»

Дөнья ул кояш кебек һәм аның нурлары да бихисап. Ул һәрбер нурын кешеләргә тигез өләшә. Нурлары күп. Кайберләренең кайда, кайчан, ничек сынып, юкка чыкканын да без тоймый калабыз. Кичә генә яныбызда булып, бөтен мизгелебезне балкыткан нурларның югалып калуын җиңел кичерәбез...

Күп вакытта үзебез дә нәрсә кылганыбызны, аның нинди нәтиҗәләргә китерәсен аңлап җитмибез. Безнең куллар, уйлар һәм язмышлар белән нәрсәдер идарә итәдер кебек тоела.

Тик бу без үзебез... Без кайвакыт бөтен нәрсәләр белән дә идарә итә алабыз. Ятлар кирәкми...

Бу ирекле дөньяда син ни теләсәң, шуны эшли аласың. Барысын да. Һәм син кылган гамәлләрең өчен үзең генә җавап бирәчәксең. Барысы өчен дә. Бары тик үзең генә... Кайвакыт синең бөеклегеңне күрми калулары да бар. Рәнҗемә. Күзгә күренгән кабахәтлеккә караганда, күренми калган бөеклек яхшырак. Ә бөеклек – ул үзеңчә яшәү. Үзенчә яшәүчеләр кешечә үлә алмый.

Һәм бу дөньяны да, үз язмышыңны да үзгәртә алырлык бер генә көч бар. Ул – син генә.

Тик син генә...



Фәтхулла Абдуллин

# СӘЕТ БАТЫР ТОКЫМНАРЫ

ПОВЕСТЬ

*Без – көрәшче халык затыннан.*
Зөлфәт.

Ике урман арасындагы мәйданда көрәшнең иң кызган чагы! Арыслан йөрәкле Габидулла белән Зиннур көрәшә. Бу инде сиңа малай-шалай көрәше генә түгел. Болар – күптәнге көндәшләр. Бу – соңгы алыш!

Зөлфәт белән Булат, мәйданны түгәрәкләп алган төркем алдына кереп, чирәмгә утырганнар да көрәшне күзәтәләр. Өлкәне Зөлфәт, этисе омтылыш ясаганда ярдәм итәргә теләгәндәй, урыныннан кузгалып-кузгалып куя, яисә йолкып алырдай булып, үләннәргә ябыша. Бәләкәй Булат та көрәшне күзәтә: авызын йомарга да оныткан!

Әйе, бу – соңгы алыш! Монда кемнең кем икәне күренәчәк. Кемгә – тәкә, кемгә... Ай-яй! Малайларның этисе сизми калдымы, аздан гына сыртына төшмәде! Аның өчен җан атучылар гөр килде.

– Юк! Булмады! Булмады!

– Яңадан!

Яңадан тотыналар. Сөлгеләр янәдән билләргә ята. Шулчак Зиннур гайрәт белән көндәшен күтәреп ала!.. Инде китереп сала дигәндә генә алыптай гәүдәле Габидулла (каян килгән аңа шундый елгырлык?) елан тизлегендә шуып, Зиннурның кочагыннан ычкына... һәм көндәшен аркасына сала!

Бу минутларда малайларга аяз күк йөзен болыт каплагандай тоелды. Малайлар уенча, һич кенә дә болай булырга тиеш түгел. Алар бит этиләренең батыр калуын, иңбашына тәкә салып, мәйдан әйләнүен көткәннәр иде. Шулай булырына өметләнгәннәр иде. Их эти, эти! Мәктәптә физкультура укыта бит әле. Укучыларын спорт серләренә өйрәтә. Күнегүләрне дә оста итеп күрсәтә.

Этиләре акланып тормады, тирләрен сөртә-сөртә:

– Үзем гаепле, сизгерлекне югалттым. Тизлек, җитезлек барысын да хәл итте. Габидулла аяк чалмады, хәрәмләшмәде. Мин аңа үпкәләмим, – дип кенә куйды.

* * *

Зөлфәт әтисенә ияреп, спортзалга йөри. Көрәшкәндә дә, башка малайлардан остарак көрәшә, ди әтисе. Шуңа күрә өлкәнрәк малайлар да аңа якын килмиләр. Үртәмиләр дә. Су коенганда, «каз боты» да кимертмиләр. Булат та быел беренче сыйныфка укырга керә. Сентябрь генә җитсен. Ул да абыйсыннан калмаячак. Үскәч, әтисенең җиңелү үчен алачак!

Җиде яшьлек малай, күңеленә килгән бу кыю фикернең коры үҗәтлек кенә түгеллеген, көрәшче бабалары каныннан килгән гаярьлек оеткысы икәнен каян белсен?!

Әтиләре мактанып йөрмәгәч тә, бабалары Фәтхелгыйлем дә көрәшче булган. Ә Мөхәммәтсалих... Сәет батырларның даны легендага тиң! Мөхәммәтсалих мәдрәсәдә укыган чагында ук мәйдан тоткан. Хәзрәт булгач кына туктаган.

(Традицияләребездән ничек тә биздерергә, халык хәтереннән җуярга тырышкан хакимияткә сатылган шәех һәм ахуннарның, хәтта кайбер мөфтиләрнең дә Сабан туен – «шайтан туе» дип, ә җыеннарны «шайтан бала тапкан көн» дип тыярга өндәгән фәтвалар чыгару йогынтысы?!) .

Ә шулай да аңа якташларының үтенечен үтәп, тагын мәйданга чыгарга туры килгән...

* * *

...Берзаман Ык буе авылларындагы Сабан туйларында Минзәлә урысы батыр кала башлагач, Мөслим аксакаллары урман эчендә утырган Сәет авылына, Мөхәммәтсалих хәзрәт хозурына килгәннәр. Сәлам биргәннәр. Хәл-әхвәл сорашканнар. Шуннан соң ил-көн яңалыкларына күчкәннәр.

– Карале, хәзрәт, ишеткәнсездер инде, Минзәлә ягыннан килгән бер урыс кешесе Иске авылда да, Вәрәшбашта да батыр калган бит әле.

– Мәлләтамакның атаклы көрәшчесен дә баш аркан чөйгән, ди.

– Чакмак Сабан туена да...

– Мөслим Сабан туена да килмәкче икән...

– Ык буеннан бер көтү тәкә җыймыйча китмим дип әйтә, ди, мәлгунь!

– Без йоклап торсак, булыр да. Улгин марҗасының утарына бер дистә тәкәне алып кайтып япкан, ди инде.

– Бүре бер ияләшсә, көтүне бугазлап бетермичә туктамый инде ул.

– Әйе! Бу кара йөрәкнең азынуына чик куярга кирәк, – дип, хәзрәт кызып китеп, хәтта йодрыгын селкеп алды. – И-их! Яшь чагым булса, үзем чыгар идем, ике дә уйламас идем!

– Син, кордаш, кызма инде! Синең белән миңа хәзер киңәш-табыш итәргә генә калган.

– Менә, хәзрәт, синең янга гозер белән килүебезнең сәбәбе шул: син – шәкерт чагыңда ук мәйдан тоткан егет. Мөселман өммәтен адәм мәсхәрәсенә калдырмыйк инде, хәзрәт. Әллә тәвәккәлләп карыйсыңмы?

Аксакаллар салмак, сабыр гына, сүзләрен дәлилле-дәлилле сөйләделәр дә туктадылар. Хәзрәтнең җавабын көтеп, өмет белән аның күзләренә төбәлделәр.

Хәзрәт тә аксакалларның сүзләрен сабыр гына тыңлап утырды. Бу – гайре җитди мәсьәлә, тота-каба гына хәл итә торган түгел. Яктылык дип,

утка очкан күбәләктәй ялкынга төшеп януың да бар. Ул җиңелчә генә тамак кырып алды:

– Хөрмәтле аксакаллар, ерак җирдән килеп сусагансыздыр. Әйдәгез, чәйгә рәхим итегез! Шунда әңгәмәне дәвам итәрбез.

Әңгәмә чәй табынында гына бетмәде. Аксакаллар хәзрәт хозурында кунып калдылар. Ястү намазыннан соң да озак кына киңәшләшеп утырдылар. Ахыр чиктә, Мөслим Сабан туена килергә хәзрәтне күндерделәр. Тик ул яшь-җилкенчәк кебек каударланып, ашыгып, Минзәлә батырына каршы чыкмаска булды.

– Сез, хөрмәтле аксакаллар, Мөслим Сабан туена Тамьян көрәшчеләрен дә чакырыгыз әле. Заманында чукындырырга килгән залимнәргә каршы да, Пётр патшаның чамасыз күп салымнарына халыкның түзәр хәле калмагач та, беренче алар күтәрелгән, алар башлап йөргән бит.

– И-и хәзрәт, фетнә бастырылгач, җәзалаудан качып, аларның күбесе Ык буйлап югарыга – Ырынбур якларына, башкорт далаларына күчеп киткән шул.

Аксакаллар белеп сөйлиләр иде. Салих хәзрәтнең Урал якларында хәлфәлек иткәндә башкорт чәчәннәреннән баш күтәрүчеләрнең җитәкчеләре Теләкәй, Күчем, Акай һәм Салават батырлар турындагы кобаирларны[1] ишеткәне булды. Гәрчә аларның гомере күптән инде фаҗигале төстә өзелгән булса да, чәчәннәр әйткән кобаирлар, һәрчак, ул батырлар әлегә далада качып кына йөриләр, бер көн килеп, гаярь егетләре белән таланган җирләребезне кире үзебезгә кайтарыр дигән өмет белән тәгәлләнәләр иде. Әйе, адәм баласын һәрчак өмет йөртә, өмет яшәтә. Менә бу чапан чабуларына төренеп утырган аксакаллар да аның ярдәменә, һич югы, киңәшенә өметләнеп килгәннәр.

Кызып китеп, йодрыкларын һавада селкеп алган аксакал, киңәшләшкән төсле бердәрләренә күз йөртеп алганнан соң, өстәде:

– Ул чорда сезнең авылның Сәет батыры да бит үзенә этрәт туплап, кыерсытучылардан үч алып йөргән.

Күр инде син боларны! Күптән булган хәлләрне онытмаганнар. Күрәсең, аларга өлкәннәр сөйләп калдыргандыр. Хәзрәт күңеленнән генә аларга рәхмәтләр укыды. Аның йөрәгендә, ихтыярсыз, үзеннән-үзе горурлык хисләре кабынды. Әйе, алар мәйданга бергә-бер чыккан көрәшчеләр генә түгел, алай[2] туплап изүче хакимияткә каршы чыккан куш йөрәкле батырлар! Аларның даны халык күңеленнән җуелырга тиеш түгел! Ул дәвам итәргә тиеш!

Хәзрәт уртаклашкан уйларын үзенчә йомгаклады:

– Ирек сөйгән кавемнең монда калганнарында да гаярьлек хисе сүнмәгәндер, шәт. Минзәлә егетенә каршы башта Тамьян көрәшчеләре чыксын. Бердән, аның җегәре кимер. Икенчедән, мин аның ничегрәк көрәшкәнен чамалармын.

* * *

Ул көнне Ык буендагы каенлык гөр килде. Мөслим Сабан туена җыенга җыелган кебек якын-тирәдәге авыллардан, хәтта Сарман, Азнакай, Бакалы якларыннан да килгәннәр иде. Каенлык, тора-бара, Ык буйлары да халык

[1] Кобаир – көйләп укыла торган шигъри әсәр.
[2] Алай – гаскәр.

диңгезенә күмелде. Ул көнне кояш та җиһанга елмаеп чыккандай булды. Шифалы нурларын мулдан сипте.

Тормыш никадәр генә авыр булмасын, бәйрәм бәйрәм инде. Бар халык сәйранга чыккан. Бер якта өздереп, курай уйныйлар, кубыз чиртәләр. Кызларның әдәп саклап, тыенкы гына көлгәннәре ишетелә.

Сабан туена сәүдәгәрләр дә килгән. Алар, елгыр халык, үзенә аерым бер дәүләт кебегрәк. Һәркайсы үзенә ошаган каен күләгәсен сайлап алган да товарларын мактый-мактый сәүдә итә. Әйтерсең, Минзәлә ярминкәсе!

Малайлар – йөгерешкә, кыюраклары көрәшкә чыгарга әзерләнә. Кызларның да яулыкка йөгерергә ниятләре бар-барын. Кыюлыклары гына җитми тора. Кемнедер багана башындагы әтәч ымсындыра. Кәүсәсен бигрәк нык шомартканнар шул! Ботак эзләрен шырпысын да калдырмыйча ышкылаганнар. Өске өлешенә сабын да сылап куйган булсалар, бетте баш! Әтәчкә үрелергә бер саплам ара калганда шуып төшкәнеңне сизми дә калырсың!

Катыклы табак төбеннән тәңкә эзләгән бабайдан егыла-егыла көләләр. Сакалыннан тамган катыгы күлмәге буйлап ага. Ул аны сизми дә бугай, тешенә кыстырган тәңкәне кулына алып, җиңүче кыяфәтендә югары күтәрә. «Менә күрегез!» дигән шикелле әйләндереп-әйләндереп ала. Ак яулык япкан әбиләр яратып кына шелтәләп алалар.

– Сакаллы сабый!

– И-и, карт тиле! Алай акча яраткач, абзар тутырып, мал асра!

– Каян беләсең? Мужыт хәләле «бүләксез кайтма!» дигәндер!

Монда елына бер килә торган хөрлек! Хөррият! Уенга катнашасыңмы? Көчеңне сынап карыйсың киләме? Рәхим ит!

Ир-атларның үз кайгылары. Аларның бар игътибары – көрәш мәйданында. Борчулары йөзләренә чыккан. Кем батыр калыр да, кем иңбашына тәкә салып, мәйдан әйләнер? Һаман шул килмешәк Минзәлә урысымы? Әллә инде берәр тәвәккәл егет табылырмы?

Минзәлә егете әлегә мәйдан тирәсендә күренми. Ул квас сатучы Улгин марҗалары тирәсендә кайнаша. Аларга өзек-төтек кенә нәрсәдер әйтеп ала да, тыңлаган атлы булып, тынып кала. Кызыксынып, тирәсендә бөтерелгән малайлардан берсенең борынын кысып алырга да өлгерә. Шаярта да белә икән, каһәр! Ул мәйданга, үз бәясен белеп, «иң-иңнәр» калгач кына чыгачак инде.

Малайлардан башланган көрәш әкренләп – үсмерләргә, аннан соң өлкәннәргә күчте. Көрәшчеләр бер-бер артлы чыга тордылар. Осталар, гайрәтлеләр ега тордылар. Ахыр чиктә, мәйдан уртасында иң-иңнәр генә торып калды. Баһадир гәүдәле Минзәлә егете, чыннан да, гайрәтле иде. Көндәшләрен бер-бер артлы чөйде дә мәйдан уртасында ялгызы басып калды. Тәкәббер генә бөеренә таянып тора бирде.

Өметләре сүнә башлаган аксакалларның йөзе кара коелды. Алар ни әйтергә, ни кылырга белми сүзсез-өнсез тордылар. Өммәттәшләребезнең буыннары шулай сыекланды микәнни?! Йа Раббым! Гөнаһларыбызны кичер! Ярдәмеңнән ташлама!

Минзәлә батырына каршы чыгарга беркем дә җөрьәт итмәсенә тәмам инанган хөкемдар, як-ягына каранып, сыек тавыш белән генә:

– Батырга каршы чыгучы юктыр инде, – дип куйды.

Шулчак халык төркеменнән Салих хәзрәт:

– Рөхсәт булса, Аллаһыга тапшырып, тәвәккәлләп карыйк әле, – дип аваз салды.

Җыйнак кына сакал-мыек җибәргән, кырык яшьләр тирәсендәге хәзрәт, салмак адымнар белән мәйдан уртасына чыкты. Иелеп, җирдә яткан яшел сөлгене кулына алды.

Мәйдан тирәли баскан халык төркеме берара умарта күче кебек гөжләп куйды.

– Каян килгән?

– Кайсы авыл батыры?

– Каян килсә дә, йөрәге җитеп, көрәшкә чыккан бит әле!

– Ай-яй, малай, бу әзмәвергә каршы тора алыр микән?

– Куш йөрәкле булса гына инде.

Кырыс тавыш сабырсызларның бәхәсенә чик куйды:

– Тавышланмагыз! Көрәшнең кызыгын югалтасыз!

Минзәлә егете, чыннан да, үгез кебек таза, гәүдәсе хәзрәттән бер башка калкып тора иде. Ул үзенә каршы чыккан хәзрәтне күргәч, чираттагы корбаны дип кабул итте. Чыраена мыскыллы кыяфәт чыгарып, ирен чите белән генә елмаеп куйды. Синең кебекләрне күргән бар, янәсе! Бу аның үз-үзен тотышында ук сизелеп тора иде.

Хәзрәт үзенең ихласлыгын күрсәтеп, егеткә саф русча:

– Здравствуй, знаком! – дип күрешергә ике кулын да сузды.

Егет:

– Какой я тебе знаком! Мы с тобой…– дип мыгырдап алса да, теләмичәрәк кенә сыңар кулын сузарга мәҗбүр булды.

Хәзрәт гәүдәгә егеттән кайтышрак булса да, төптән юан чыккан инсан иде. Егетнең кул чугы хәзрәтнең кушучына кереп югалды…

Сөлгеләр билгә яту белән Минзәлә урысы шундук хәзрәтнең касыгына ике яклап, баш бармакларын батырды. Салихның бөерен нидер чәнчеп алгандай булды. Кайсы җирең авырта, кул шуннан китми дигәндәй, андый чакта, ихтыярсыз, кешенең бар кайгысы авырткан җирне саклау була. Башка әгъзаларның сизгерлеге кими яисә бөтенләй югала. Беләк сеңерләре дә йомшап китә. Ә көндәшеңә шул гына кирәк тә инде. Сизгерлегеңне югалтсаң, мизгел эчендә дөпелдәп, сыртыңа төшкәнеңне сизми дә калырсың. Гадел көрәшчеләр алай эшләми. Бу – язылмаган закон.

Димәк, бу егет аларның барысына да төкергән. Хәрәмләшү аның өчен гадәти хәл.

Бу хәйләсе барып чыкмагач, ул хәзрәткә аяк чалмакчы булды. Хәзрәт бу юлы да вакытында саклану чарасын күреп өлгерде. Байтак тартыштылар. Икесе дә кара тиргә батты. Сөлгеләр сыгып алырлык булды. Берсенең дә бил бирәсе килмәде.

Бәйрәмгә җыелган халык бар кайгысын онытып, көрәш мәйданына өерелде. Сулышын кысып, көрәшне күзәтте. Кем батыр калыр?! Һаман шул килмешәкме? Әллә инде…

Түгәрәк мәйдан кысылганнан-кысыла барды. Күпләр күңеленнән генә хәзрәт өчен җан атып, сыкрап утырса, тора-бара эчтә кайнаган кайнар хисләр тыелгысыз көч белән тышка бәреп чыкты.

– Билеңне бирмә! Хәзрәт! Билеңне бирмә!

– Уяу бул!

– Билеңне!.. – дип, хәзрәтне дәртләндереп кычкырган авазлар ешайды.

Хәзрәт җиңүнең җиңел булмаячагын чамаласа да, көндәше булган егет аны әллә ни каршылык күрсәтә алмас дип ышанган иде. Әмма ул уйлаганча килеп чыкмады. Хәзрәт егетнең һәр адымына уяулык күрсәтте. Ул корган тозактан ычкына торды. Егетнең эче тулы мәкер икән. Берара ул бирешкән атлы кыланып, хәзрәтнең күкрәгенә төшмәкче булды. Үгез гәүдә мамык мендәр түгел. Аның бу хәйләсе барып чыкса… Алла сакласын! Кабыргалары исән калыр микән? Ярый әле, хәзрәт көндәшен читкә тайпылдырып өлгерде!

Егетнең адым саен хәрәмләшүенә хәзрәтнең ачуы кабара башлады. Ә ачу – аю! Кешенең ачуы килгәндә, куәте икеләтә-өчләтә арта, диләр. Хәзрәтнең күңеленнән «тәвәккәлләргә кирәк» дигән уй сызылып узды. Һәм ул, мәче тизлегендә, кискен генә егетне биленнән күтәреп алды, көндәше нинди дә булса саклану чарасы күргәнче, гайрәт белән иңбашы аша селтәп, аркасына салды! Егетнең килбәтсез озын аяклары һавада кабаланып атлаган сыман хәрәкәтләр ясый-ясый, дуга ясап ауды! Тизлек, җитезлек барысын да хәл итте дә куйды!

Халык «аһ» итте! Ниһаять! Шатлыклы авазлар Ык аръягындагы Метрәй тауларына орынып, кайтаваз булып яңгырады…

Хәзрәт иңбашына тәкә салып, мәйданны әйләнде дә, аксакаллар янына җиткәч туктап, тәкәне җиргә төшерде. Бу минутларда ил агаларының да хисләре ташып чыккан иде. Кемдер аның кулын кысты, кемдер аркасыннан какты…

– Афәрин! Егет икәнсең! Сиңа Аллаһның рәхмәте яусын!

– Сөбханаллаһ машаллаһ! Җилле егет икәнсең! Билеңне бирмәдең!

– Маладис! Тәки бил бирмәдең! – кебек сүзләр, мөгаен, соклану катыш иң күп әйтелгәннәре булгандыр.

Хәзрәт күкрәк сугып шапырынмады, тыйнак кына:

– Кардәшләрем! Минем өчен, бил бирү ил бирүгә тиң. Сезнең күзегезгә күренергә оят булыр иде, – дип кенә куйды. «Сәет батырның рухын рәнҗетү булыр иде» дип тә өстәмәкче иде, тыелып калды. Мактана дип уйлаулары бар. Югыйсә әйтергә хакы бар иде. Сәет батыр аларның җиденче буын бабалары иде…

Хәзрәт маңгаеннан аккан тирләрен сөлгесе белән сөртеп алды да, тезелешеп утырган аксакалларга дәште:

– Хөрмәтле аксакаллар! Менә сезгә миннән бүләк!

Һәм ул тәкә мөгезенә бәйләгән бауны аларга сузды.

– «Бисмиллаһ» әйтеп чалырсыз да, ятим-җилпене җыеп, Коръән укытырсыз! Ил-көннең иминлеген теләп дога кылырсыз!..

Ул көнне бәйрәмгә җыелган халык шатлыклы хисләрдән айный алмыйча, теләр-теләмәс кенә таралды. Әйтерсең, кабаланып, мәйданны ташлап китсә, күңел түренә тулган хисләр чайпалып түгелер сыман тоелды.

Фәкать кичке эңгердә генә Сабан туе мәйданында җылы җәйнең җиләс җилләре уйный иде…

Шушы вакыйгадан соң, Ык буенда Минзәлә урысының эзе суынды.

* * *

Вакыт агымсу кебек берөзлексез ага да ага. Җиләкле җәйләрне августның тынга каба торган эссе көннәре алыштырды. Сентябрьгә дә санаулы гына көннәр калды. Ел фасыллары үзгәрәчәген сиздереп, кайчагында күк йөзен куе болытлар каплап алды. Әмма кодрәтле җилләр, «кая ашыгасыз, күрмисезмени, игеннәр урылып бетмәгән» дигәндәй, болытларны офыкның аръягына, әллә кайларга куды.

Ниһаять, авыл уртасында урнашкан мәктәптә укулар башланды. Тирә-як бала-чага чыр-чуына күмелде.

Дәресләр классларда да, спорт залында да берьюлы башланды.

– Әти, мине дә алып бар әле, – дип әйтергә кыймый йөргән Булатны әтисе үзе спорт залына алып китте. Алар барып кергәндә, малайлар пыр тузып «шайтан чабалар» иде.

Кемдер җәтмәгә туп ыргыта, кемдер биеккә сикерергә талпына. Малайларның күбесе көрәшмәкче булып әүмәкләшәләр.

Булатның әтисе, кулындагы сәгатенә карый-карый, һәр төркемгә аерым-аерым күрсәтмәләр бирде. Булатка да өлеш чыгарды.

– Бүген малайларның көрәшкәнен генә карап утыр, – дип, стена тирәли тезелгән такта эскәмияләрнең берсенә утыртты да чыгып китте. Аның өлкән сыйныф укучыларына волейбол буенча дәресләр бирәсе бар иде.

Көтмәгәндә, Булатның каршына җиткән чәче колагын каплаган чандыр гына бер малай килеп басты. Кискен генә аның борынына чиртеп алды. Булатның күзеннән, ихтыярсыз, яшьләр атылып чыкты.

– Нәрсә, маңка малай, көрәшергә килдеңме? Әйдә, чык!

– Юк, чыкмыйм! – диде Булат, башын чайкап. – Миңа әтием карап кына утырырга кушты.

Җиткән чәч ис китмәгән кыяфәттә сызгырып алды да:

– Утыр инде алайса артың кабарганчы, – дип китеп барды.

Күпмедер вакыттан залга Булатның әтисе килеп керде. Аның янына килеп утырды. Яратып кына улының чәчләрен тузгытып алды. Елмаюын сиздермәскә тырышып, әкрен генә сорап куйды:

– Ничек, көрәшкә чыктыңмы соң, улым?

– Ю-ук! Үзең утырып торырга гына куштың бит.

– Утырып кына түгел, малайларның көрәшкәннәрен дә күзәтергә кирәк иде.

Булат борынына чиртеп киткән озын буйлы малайга төртеп күрсәтте:

– Әнә теге малай иптәшләрен төртеп ега да: «Җиңелдең! Җиңелдең!», – дип кычкыра.

– Улым, татар көрәшендә көндәшеңнең биленнән күтәреп алырга кирәк, белдеңме? Төртеп егу – хулиганлык кына ул.

Һәм ул урыныннан кузгалып, бил алышкан малайларга, көрәшкәндә, сөлгеләрне кулга ничегрәк урарга, аякларны, гәүдәләрне ничегрәк тотарга кирәклеген күрсәтте. Тагын нindидер күрсәтмәләр бирде дә кабат Булат янына килде:

– Бүгенгә дәрес тәмам. Әниең безне көтәдер. Коймак пешерәм дигән иде. Әйдә, коймак суынганчы тизрәк кайтыйк, – диде.

Әтисе Булатны җитәкләп алды, ишеккә җитәрәк борылып озын буйлы малайга дәште:

– Самат! Күнегүләр беткәч, залның ачкычын вахтёр Сәкинә апагызга биререгә онытмагыз, яме!

Алар кайтып кергәндә, коймак исе ишегалдына ук чыккан иде. Ул арада букчасын күтәреп, Булатның абыйсы да кайтып керде. Зөлфәт инде өченче сыйныфта укый. Мәктәп юлы аның өчен такыр. Озатып, каршы алып йөрергә кеше кирәк түгел.

Өстәл тирәли утырышкач, әниләре сөлге каплаган савытны ачып җибәрде. Кайнар коймак исе борынны кытыклады, авыздан сулар китерде.

Зиннурның кәефе күтәренке иде. Шөкер, уллары үсеп килә. Төпчекләре дә быел укырга керде. Үзенең яраткан эше бар. Көрәш белән мавыга. Уйласаң, спорт – ул сәламәт яшәү рәвеше. Балаларга да шуны сеңдерәсе иде. Симәк мәктәбендә физкультура укыткан чорда да аның Рамил Шәйхуллин кебек яшүсмерләр арасында Татарстан чемпионы дәрәҗәсенә ирешкән шәкертләре булды. Насыйп булса, улларын да...

Ул мыек астыннан гына елмаеп:

– Әнисе, беләсеңме, бүген безнең улыбыз малайлар арасында батыр калды бит, – диде ул, Булатка ымлап.

Булат әтисенең шаяртканын чамаласа да:

– Үзең утырып кына торырга куштың бит, – диде, авызын турсайтып.

– Улым, беләсеңме, карап кына утырып, бүген син укытучы кушканны үтәдең. Тәртипле малайлар шулай эшли. Димәк, синең тәртибеңә бүген «бишле» куярга була.

«Бишле» сүзе әниләренең күңеленә сары май булып ятса да, ул балаларын кызганып:

– Кавырсыннары катмаган балаларны ни дип интектерәсеңдер! Зөлфәте генә җитмәгән, Булатны да котыртмакчы икән инде. Үсеннәр әле! Өлгерерләр! Ул спорт залын күтәреп китүче юктыр! – диде, ярыйсы гына үтемле итеп.

– Энҗе, җанкисәгем, беләсеңме Тукай ни дигән?

– Ни дигән?

– «Картаеп буыннар каткач, эш белү уңайсыз ул», – дигән. Балаларны яшьтән үк, сөякләре камыр кебек чагында күнектерергә кирәк.

* * *

Зөлфәт көн саен дәртләнеп, көрәшкә йөри. Ярышларда катнаша. Район командасына кушылып, призлы урыннар яулый башлады. Зиннурның куанычы куенына сыймады.

Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, терекөмеш кебек тиктормас Булат та абыйсына иярде. Аңа да көрәш «җене» кагылды. Спорт залына барырга атлыгып кына тора. Уку елы төгәлләнгәндә, ул инде борынына чиртеп киткән Саматка каршы keләмгә чыкты. Көндәшен күтәрмәкче дә бит, аякларын (тамыр җибәргән диярсең) җирдән аерып булмый. Самат аны күтәрә дә ыргыта. Аркасына төшермәсә дә, очко ала.

Тренер әтисе:

– Улым, сөлгеңне көндәшеңнең калак сөягенә шудырма. Билен кысып ал! – ди.

Саматның да җиңел генә бил бирәсе килми шул. Яше дә Булаттан

өлкәнрәк. Нишләтәсең, җиңү тәмен тояр өчен җиңелү ачысын да татырга кирәк. Көрәшче булырга хыялланган кеше, «җиңелдем» дип, борын салындырып, келәмне ташлап китәргә тиеш түгел. Үҗәтләнеп, тагын да ныграк шөгыльләнергә тиеш. «Иренмәсәң, ялкауланмасаң гына максатыңа ирешәсең», – ди аңа әтисе.

Зиннур белгән догаларын укыды:

– Йа Раббым!.. Улларымда бабаларыбызның көрәш рухы сүнмәсен иде! Гаярьлек хисе каннарында дәвам итсен иде! Йа Раббым!.. Без бит Сәет батыр токымнары!

Ә Сәет батыр...

* * *

...Моннан нәкъ өч йөз ел элек, Пётр патша хакимлек иткән чорда чамасыз күп салымнарга түзәр хәле калмаган халык баш күтәрә. Сәет батыр Ык буенда купкан восстание җитәкчеләренең берсе булган. Ярсу атларга атланган җайдаклары белән көтмәгәндә һөҗүм итеп, баш күтәрүчеләрне бастырырга җибәрелгән карательләрнең үзләрен кыйратып, тәре күтәреп чукындырырга килүчеләрнең үзләрен «чукындырып» йөргән. Пётр патша:

– Поймайте мне эту Саитку вора! – дип, аяк тибә-тибә күпме генә нәгъррә орса да, унбиш ел буе тоттырмаган. «Тоттырмас үч алучы» исеме белән тарихка кереп калган.

Ахыр чиктә, ышанычлы яраннары белән куе урман уртасында йорт җиткергән, агач төпләп, иген иккән, мал-туар асраган. Ыкның уң ягын тоташ каплап алган урманда, руслар әйтмешли, «закон – тайга, медведь – хозяин». Карурманга кереп, аларны эзләп йөрергә беркемнең дә башы ике түгел! Агач башындагы сакчы куышыннан очкан сәрпи ук карчыгага түгел, аждаһа сурәте төшкән башлык кисәң дә, «ә» дигәнче тишеп керәчәк. Алар шулай беркемнән дә курыкмыйча, беркемгә дә буйсынмыйча, урман бүреләре булып гомер иткәннәр. Тора-бара авыл барлыкка килгән. Тирә-як халкы аны Сәет авылы дип йөри башлаган.

Өлкәннәрнең сөйләве буенча, егерменче гасыр башында батырлар яшәгән йортларның берничәсе исән булган әле. Колхозлашу чорында гына ул тузган йортларны сүткәннәр. Шул чорның шаһиты булып Иске йорт урманы, Иске йорт чишмәсе, Иске йорт басуы, Кызыл саз басуы дигән атамалар халык хәтерендә сакланып калган. Ул урман уртасындагы басуда авылдашлары әле дә иген игә.

* * *

Улларының уңышына сөенеп, «шушы ике улымны көрәшче итә алсам», дип хыялланып йөри әтиләре...

...Көзге пыскак, яңгырлы көннәрнең берсендә Зиннур мәктәпкә җитәрәк сәерсенеп калды. Балалар чыр-чуына куангандай, һәрчак «гөлт» итеп яктылык чәчеп торган мәктәптә ут сүнгән иде.

– Бу ни хикмәт? Энергетиклар забастовка ясаганмы әллә, – диде ул, ишек сагында кизү торган апага елмаеп.

Кизү торучы да елмаеп куйды:

– Төнлә давыл булды бит. Коеп, яңгыр яуды. Берәр җирдә кыска ялганыш булгандыр, йә чыбыклар өзелгәндер. Нишләптер, бүген электрик Рәкыйп озаклады. Өендә телефоны да юк ичмаса.

Зиннур сәгатенә карап алды. Дәрес башланырга вакыт бар иде әле.

– Кая, электр щитогын карыйк әле. Бәлки автомат рәвештә үзеннән-үзе генә сүнгәндер.

Кизү торучы хатын: «Барма! Электрик үзе карар», – дип әйтергә уңайсызланды. Акыл өйрәтә дип уйлавы бар. Мәктәптә Зиннурны хөрмәт итәләр. Тренер буларак, байтак үсмерләрне зур спортка чыгарды. Шул исәптән, кизү хатынның тайгак юлга баса язган улын да.

– Апаем, берүк саграк кылан инде, – дип әйтү белән генә чикләнде.

Зиннур электрикларның ток үткәрми торган резина перчаткаларын эзләп тормады, саклану чарасы итеп, кулына кулъяулыгын урады да тәвәккәлләп, щитокның капкачын ачты. Күз йөртеп чыкканнан соң, бер клемманың урыныннан купканын күрде. Зиннур монда әллә ни катлаулы әйбер юк икән, шул клемманы чистартып, оясына урнаштырсаң, мәктәптә ут кабынып китәргә тиеш дип уйлаган иде. Аянычка дияргәме, күрәчәге булгандыр дияргәме, ул уйлаганча килеп чыкмады... Зур көчәнешле ток мизгел эчендә аның гомерен өзде дә куйды...

* * *

Башлангыч сыйныфларда гына укучы ике улы белән тол калган Энҗегә ул көнне кояш тотылгандай булды. Көтмәгәндә башына төшкән бу кайгыдан чәүчәләк хатыннар кебек чәчләрен йолкый-йолкый илереп еларга тотынмады, алъяпкыч итәген йөзенә каплап, тын гына үкседе. Үзәк өзгеч сулкылдауга буйсынып, хатынның иңбашлары җиңелчә генә калтырап ала иде. Йа Раббым! Ялгызым балаларымны ничек аякка бастырырмын да, ничекләр кеше итәрмен?!

Иренең җидесен үткәргәннән соң ул, таянычы бар чагында ризалашмаган эшкә – дуңгыз фермасына китте. Хәзер аның ялгызына хуҗалык эшләре дә өелде. Сыгылсаң да, сынмаска кирәк! Ялгыз калганда, аның алъяпкыч итәген күз яшьләренә чылаткан чаклары да булгандыр. Ни хәл итәсең, беркемнең дә йөрәге таш түгел. Кайгы килгәндә, син хисләргә баш түгел... Ярый әле уллары ялкау булмады. Хуҗалыкта ни кушса, шуны җиренә җиткереп эшләделәр.

Ул аларның көрәш белән мавыгуларына да сүз әйтмәде. Уку калдырып, эштән качып йөрмиләр. Тәмәке тартып, тәртип бозып кына йөрмәсеннәр.

Ялгыз башына тормыш никадәр генә авыр булмасын, үз җае белән барганда, дөньяның асты өскә килде. Колхозлар таралды. Таркаттылар дисәң, дөресрәк тә булыр әле. Колхозлар белән бергә терлек абзарлары да туздырылды. Малларны каядыр алып киттеләр. Күп кеше, шул исәптән, Энҗе дә эшсез калды. Хәзер нишләргә? Кая барырга? Кемнән дә булса ярдәм көтәрлек түгел. Һәркемнең үз хәле хәл. Үз кайгысы баштан ашкан. Кайгы агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри шул. Ничек очын очка ялгарга белми, ары барып, бире сугылып йөргән Энҗене, Зиннурның хөрмәтле укытучы булганын истә тотыпмы, ятим калган балаларын жәлләпме, мәктәп ашханәсенә эшкә алдылар. Ул карулашып тормады – кая кушсалар, шунда эшләде. Повар да булды, кирәк икән каравылда да торды. Балаларын ач-ялангач итмәде, тәрбияләде, үстерде...

Өлкәне Зөлфәт аттестат алу белән, әнисенең: «Улым, гомер буе көрәшеп

йөри алмассың, бер төпле һөнәр алырга кирәк», – дигән киңәшен тотып, Әлмәттәге муниципаль институтның икътисад факультетына укырга керде.

Әнисе улын укырга озатканда, тагын бер мәртәбә:

– Улым, ишетсен колагың, хәзер сиңа уку турында гына уйларга кирәк. Көрәш белән мавыгуларыңны ташларга вакыт, – дисә дә, көрәш «җене» кагылган егетнең йөрәге бер атна түзде микән?! Лекцияләрдән соң ул спорт сараен эзләп китте.

Һо-о! Әлмәтнең спорт сарае! Үзе биек, үзе киң! Көрәш залы да авыл мәктәбендәге шикелле генә түгел! Ул залга кергәндә, трикодан гына калган егетләр берьюлы берничә келәмдә пыр тузып бил алышалар иде. Берничә егет, келәм бушаганын көтеп булса кирәк, стена буендагы эскәмиядә утыра. Бәләкәй буйлы, какча гәүдәле Зөлфәтне күргәч, аның авыл малае икәнен чамалап, көлемсерәп куйдылар. Харап көрәшче, янәсе! Ни гәүдәсе, ни кыяфәте, имеш!

– Әй, малай, җиңел атлетика белән күрше залда шөгыльләнәләр. Шунда бар! – дип тә куйды берсе, астыртын гына елмаеп.

– Юк, мин көрәш секциясенә язылырга килдем!

Ул чорда яшьләрне татарча көрәш серләренә атказанган тренер Салават Йосыпов өйрәтә иде. Беренче күнегүләрне әтисеннән алган егеткә (булырдайның адымыннан ук билгеле булгандыр) остазы шундук игътибар итте. Күп тә үтми, ул аны Әлмәт җыелма командасына алды. Күңелләрен көнчелек корты кимергән кайбер егетләр Зөлфәткә кырын карый башлады – «любимчик», янәсе. Арадан берсе (кирәк бит!) үпкәсен тренерның үзенә дә әйткән.

– Һе, мин аннан алдарак йөри башладым, дисең инде, ә! Шәләй-вәләй, эленке-салынкы йөрү генә җитми, энем, өйрәнү кирәк, – дигән аңа Салават абыйлары. – Ә син, егылсаң, театрга җыенган кеше шикелле тизрәк өс-башыңны кага башлыйсың. Келәмгә чыккач, тузаннан куркырга түгел, бер пот тоз ашарга кирәк. Остарып җиткәч, командага сине дә алырбыз. Борчылма.

Ә чырыш Зөлфәт, кая гына барсалар да, остазының йөзенә кызыллык китермәде. Шуннан соң аңа Татарстан җыелма командасында бил алышу насыйп булды. Һәм ... Аллаһның рәхмәте – егерме яшьлек егет алтмыш биш килограммга кадәрге авырлыктагы көрәшчеләр арасында республика күләмендә өченче урынны алды!

Салават абыйсы аны дәртләндереп, аркасыннан какты. Тәҗрибәле остаз шәкертенең кимчелекләрен дә күздән ычкындырмаган, күрәсең:

– Көрәш ул, энем, бил алышу гына түгел, ул – сәнгать!

Аңладыңмы, дигән шикелле тренер имән бармагын җиңел генә һавада селкеп алды:

– Киләсе елга тагын да яхшырак әзерләнергә кирәк.

Яхшырак дип әйтү генә ансат. Стипендия алыр өчен аңа бит әле яхшы укырга: зачётларны – вакытында, имтиханнарны «яхшы» билгеләргә тапшырырга да кирәк. Ике куянның койрыгын тоту җинел түгеллеген Зөлфәт үзе генә белә. Андый чакта әнисенең колагына «киртләп» әйткән сүзләре дә уйландыра. «Әллә инде, әллә ...» дигән икеләнү хисләре баш калкыта. Әмма тренировка көннәре җитсә, спорт сарае аны магнит сыман үзенә тарта да ала.

Остазлары кайбер буыны сыекларны: «Энем, бар әле, авылыңа кайтып, берәр җәй көтү көт. Аннан соң килерсең», – дип, кире борганда, Зөлфәтне үз баласы шикелле аркасыннан кагып үсендереп тора. Ничек көрәшне ташлыйсың инде!

Аннары… Ә аннары кеше гомерендә хыялый һәм кабатланмас яшьлек еллары да бар бит әле. Ә ул синең кем булуыңа карамастан, үзенекен итә. Егет бул да, юктан да кызык табып чыркылдашкан кызларга ничек игътибар итмисең инде!

Ә Азнакай кызы белән алар очраклы гына таныштылар. Зөлфәт күнегүләрдән соң биреләсе зачётлары, имтиханнары турында уйлана-уйлана ишеккә якынлашты. Тизрәк тулай торакка кайтып, шуларга тотынырга иде исәбе. Ул арада гимнастика залыннан атылып чыккан кыз да, кабаланып, ишеккә ташланды. Икесенең дә алданрак чыгасы килде дә, ишек катында аларның иңбашлары бәрелеште.

– Свиданиегә ашыксаң, инде соңга калдың. Сәгатеңә күз сал! – диде кыз төксе генә.

– Юк. Минем срочно зачётларга әзерләнәсем бар.

– Ә-ә, булачак академик! – диде кыз, бу юлы көлемсерәп.

Зөлфәт кызның ирониясен колагы янынннан гына үткәреп җибәрде:

– Гафу итегез! Ялгыш кына инде.

Кызга Әлмәтнең икенче читенә кайтасы. Аңа соңгы троллейбуска өлгерергә кирәк. Бәлки инде соңга да калгандыр. Мизгел эчендә аның күңелен фаразлар дулкыны айкап узды. Укып та йөри, спорт белән дә шөгыльләнә. Димәк, начар егет түгел! Ә бәлки машинасы да бардыр!

– Егет, син машина беләнме әллә? Троллейбуслар туктагандыр инде. Мине бистәгә илтеп куй әле, – диде ул урамга чыккач, сынаулы карашын егеткә төбәп.

Зөлфәтнең йөрәген кыенсыну катыш үкенечле уйлар ташкыны чеметтереп узды. Хәзерге заманда егет кешенең машинасы булырга тиештер анысы. Авылдан килеп укый гына башлаган егетнең каян килеп машинасы булсын инде?! Кыз алдында аңа уңайсыз булып китте. Шулай да сер бирәсе килмәде:

– Миңа дигән машинаның рудасын Урал тавыннан чыгарып кына йөриләр шул әле. Ну, диплом алган көнгә әзер булачак, диделәр. Әйдә алайса, мин сине такси белән озатып куям.

Ярый әле, Зөлфәтнең кесә төбендә икенче көнгә исәпләнгән акчасы бар иде.

Нәфис гимнастика түгәрәгенә йөрүче Гүзәл белән алар әнә шулай танышып киттеләр һәм... әйтмичә дә булмый, шул көннән башлап, спорт сараеның тарту көче дә бермә-бер артты!

Зөлфәт яшьлек кайнарлыгы белән күнегүләрне тагын да тырышыбрак дәвам итте. Тәҗрибәле көрәшчеләрнең техникасын, алымнарын өйрәнде, хәтеренә сеңдерде. Келәмдә, кем әйтмешли, чиләк-чиләк тир түкте. Тозын аерсаң, (Салават абыйсының яраткан сүзе!) бер пот кына чыкмас иде! Нәтиҗәдә ул Татарстан беренчелегендә финалга чыгып, икенче урынны яулады! Ә икенче елда инде аңа тиңнәр табылмады. Ул барлык көндәшләрен дә чиста җиңеп, республика чемпионы исемен алды! Шул ук елда Россия

беренчелегендә икенче урынга чыкты. Аңа спорт мастеры дигән мактаулы исем бирелде.

Татарча көрәш буенча Муса Җәлил призына уздырыла торган мәртәбәле ярышларда Зөлфәт шул елларда батыр калды!

Җыеп кына әйткәндә, ул алтмыш биш килограммга кадәрге авырлыктагы көрәшчеләр арасында республика күләмендә ике мәртәбә көмеш медаль алды. Ике тапкыр Татарстан чемпионы булды.

Сокланырлык уңышка ирешкән Зөлфәткә карата, «кечкенә дә, төш кенә» дигән мәкаль суйган да каплаган инде! Танылган көрәшче бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яши. Сөеклесе Гүзәл белән өч кыз, дүрт малай үстерә!

* * *

Ә-ә-ә, әйе! Безнең, авызын йомарга да онытып, әтисенең көрәшен күзәткән Булат та бар бит әле. Тиресен текмәгән, әнисен куандырып ул да егет булып килә. Төпчеген дә укытырга, һөнәрле итәргә кирәк. Әтисенең фатихасы белән көрәшкә кереп киткән, соңыннан баш-аягы белән чумган егет Тойгелде урта мәктәбен тәмамлау белән «кая барырга икән» дип, баш ватып тормады: Әлмәт физкультура һәм спорт техникумына укырга керде. Ул да Салават абыйлары кул астында көрәш серләренә өйрәнде. Иренмәде, ялкауланмады. Келәмгә беренче булып чыкты, көрәш залыннан иң ахырдан китте. Дәрт иткән – морадына җиткән, ди. Булат спорт дөньясында әкияттәге батыр сыман «ай үсәсен көн үсте». Баш әйләнерлек тизлек белән бер-бер артлы югары үрләр яулады. Җитмеш биш килограммга кадәрге авырлыктагы көрәшчеләр арасында 2004 елда Татарстан чемпионы булды. Россия беренчелегендә икенче урынга чыкты. Спорт остасы исемен алды. Абыйсы укыган институтны тәмамлап, ихътисадчы дипломы алырга да өлгерде.

Ике улымны да көрәшче итә алсам дип хыялланган әтиләре Зөлфәтнең көрәштәге беренче уңышларына куанган булса, улларының уңышына хәзер әниләренең куанычы куенына сыймады! Их, әтиләре дә исән булса! Энҗенең күңелен юксыну хисе телгәләп узды.

2005 елда, Казанның меңъеллык юбилее уңаеннан, башкалабызда билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионаты уздырылды. Анда планетаның кырык ике иленнән иң көчле көрәшчеләр җыелды. Төркия, Иран, Үзбәкстан, Кытай һәм Япониядән дә көрәшчеләр бар иде. Кыскасы, санап бетергесез! Хәтта тешләре белән күзләре генә елтырап торган, чуен кебек кап-кара тәнле Африка көрәшчеләре дә килгән иде. Төшеңә керсә, куркып уянырсың. Беләк мускуллары да, ай-яй, хәтәр! Буар еландай уйнаклап тора.

Җанатарлар арасында Булатның тренеры, дуслары, туганнныары... Әнисе утыра. Җаваплылык бизмәнгә салып кына үлчәрлек түгел. Булат келәмгә чыкканда, алар сулышларын кысып, тын алырга да куркып утыралар. Өметләр акланырмы? Булат әлегә көндәшләрен бер-бер артлы җиңеп бара. Алда тагын үзбәк, таҗик егетләре белән бил алышасы бар. Ә аларның көрәшендә аяк чалу хәрәмләшү саналмый, рөхсәт ителә. Салават абыйлары юкка гына «көрәш ул – сәнгать» дими инде. Монда беләк мускулларыңны гына түгел, башыңны да эшләтергә кирәк. Әтисенең: «Тизлек! Җитезлек!» – дигән сүзләре дә Булатның бүгенгедәй хәтерендә. Аяк чалырга омтылган көрәшченең гәүдә авырлыгы да, җирдәге терәге дә сыңар аягында кала.

Шул мизгелне җитезлек белән файдалана алсаң, җиңү – синеке! Ә уяулык дигәнен бер секундка да югалтырга ярамый.

Менә келәмдә хәлиткеч минутлар якынлашты. Булат монгол көрәшчесе белән финалга чыкты. Бу – соңгы алыш. Монда кемнең кем икәне күренәчәк. Монгол егете килде-китте генә көрәшче түгел, үз иленең чемпионы! Байтак тартыштылар. Берсенең дә бил бирәсе, җиңеләсе килми иде. Тәнәфес игълан иттеләр. Булат монгол егете сыман көрәшчеләр өчен куелган эскәмиягә утырмады, келәмнән чыгып, яшел чирәмгә чүгәләде. Шешә борыныннан гына берничә йотым су эчте дә аякларын сузып җибәрде. Шуны гына көткәндәй, каяндыр үләннәр арасыннан килеп чыккан кырмыска җәһәт кенә аның аягына үрмәләп менде. Егетне дәртләндергәндәй, аяк йөзен кытыклап, әрле-бирле йөренә башлады. Теле булса, мөгаен, нәрсәдер әйткән дә булыр иде...

Туган туфрак куәт өстәдеме, ахыр чиктә, Булат монгол егетен селтәп, сыртына салды!

Бу минутларда җанатарларның шатлыгын тасвирлау өчен сүзләр дә, язар өчен кәгазь дә җитмәс иде. Барысы да дәррәү аягүрә басты. Кемдер котырып кул чабарга тотынды. Кемдер йодрыкларын һавада селки-селки тыпырдый башлады. Кемдер бөтенләй таныш түгел кешене кочаклап үпте. Трибунада утырган җитәкчеләр, мәртәбәле кунаклар да, ихтыярсыз, аягүрә бастылар. Дөньяларын онытып кул чабарга, бер-берсенең кулларын кысарга тотындылар. Тамаша инде, чын тамаша! Сирәк була торган ихлас тамаша иде бу.

Шулай итеп, Булат бу мәртәбәле дөньякүләм бәйгедә үз үлчәвендәге көрәшчеләрнең барысын да җиңеп, егерме биш яшендә Дөнья чемпионы исемен яулады. Бу – татар көрәшчеләре арасында иң зур казаныш!

Бу урында, үзеннән-үзе, күренекле шагыйрь Зөлфәтнең:

Томырылдык көрәш уртасына
Сабан туе атлары сыман.
Безнең мәйдан – шаулы планета,
Без көрәшче халык затыннан! –

дигән шигъри юллары хәтердә яңара. Әйтерсең, шагыйрь йөрәге якташларының планета шаулатып, мәйдан тотасын, татар данын еракларга таратасын алдан ук фаразлаган...

## Эпилог

...Үз әхлак кодексы белән яшәүче мөслимлеләргә рәхмәт. Район үзәгендәге бер урамга данлыклы көрәшче Булат Вәлиев исемен биргәннәр.

Зат – затка, тилчә – тамырга, ди. Киләчәктә келәмгә Вәлиев фамилияле көрәшчеләр чыкса, белеп торыгыз: алар Сәет батыр токымнары булыр!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез Фәтхулла Абдуллинга сиксән биш яшь тула. Без аны гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, исәнлек-саулык, әле алга таба да милләттәшләрен шатландырып, гүзәл әсәрләр иҗат итүен телибез!*



*Абдулҗан Мухтарҗан улы Азнабакиев – уйгыр шагыйре. Ул 1986 елның 5 декабрендә Казакъстан Республикасының Алма-Ата өлкәсе Енбекшиказакъ районы Гайрәт авылында дөньяга килә. Мәктәптән соң Абай исемендәге Казакъ милли педагогика университетын тәмамлый. 2013 елда ул Уйгыр яшьләре фестивале, ә 2017 елда Турган Тохтамов исемендәге әдәби бәйге лауреаты була. Шул ук елны Евразия Язучылар берлегенең Истанбул шәһәрендә узган Беренче төрки яшь язучылар фестивалендә катнаша.*

*Абдулҗан – «Пәрвәз» уйгыр җыр башкаручылары җәмгыяте әгъзасы, җыр текстлары, «Йөрәк язым» («Кәлбим баһари»), «Яшьлек лирикалары», «Йөрәк альбомы» исемле шигырь җыентыклары авторы.*

*Бүгенге көндә ул «Гунчә»(чәчәк бөресе, бутон) журналының баш мөхәррир урынбасары, «Уйгыр авазы» газетасы хәбәрчесе һәм Алма-Ата шәһәрендә мәктәптә укытучы булып эшли.*

*Иҗатына килгәндә, ул – шәркый стильдәге фәлсәфи лирика һәм мәхәббәт лирикасы белән игътибарны җәлеп итә, аеруча гомернең узуы, язмыш һәм бәхет төшенчәләре хакында уйлануларын образларга төреп, укучысына җиткерүгә сокландыра.*

Абдулҗан
Азнабакиев

# САЛКЫН ҺАВА, ТУЛГАН АЙЛЫ ЙОЛДЫЗЛЫ ТӨН...

***

Кальбем гүя тулып таша галәмемнән,
Бүген янә сердәш булдым каләм белән.
Чишелешсез сорауларга җавап эзләп,
Чуарладым кәгазь битен берәм-берәм.

Камчы очы сыман безне бу яшәеш
Талпындырып ала кайчак йә сикертә.
Тәкъдир гүя миңа үзе картлык өсти,
Ә борчулар чәчләремә чал йөгертә.

Караң шактый минем бәхетем кичектерде
Үч иткәндәй тәкатьсезлек өчен гүя.
Әйтерсең лә, тәкъдир шулай үчекләде,
Башкаларны ак бәхеткә күмә-күмә.

***

Салкын һава, тулган айлы йолдызлы төн.
Берьялгызым шушы төнне сердәш иттем.
Бу гомремнең юк-барыннан тәмам туеп,
Күңелем тулып, күзләремнең яшен түктем:

– Тәкъдир безгә янә күпме дәрт-гамь өстәр,
Өеп куеп тормышның вак мәшәкатен?
Башкалардай булмаса да, дөньялыкның
Бераз гына
Күрербезме хөр бәхетен, әй милләтем?!

## Яшьлек җыры

Бакча гөлем, хыял күгем – яшьлегем.
Киләчәккә өмет белән баккан чак.
Хыяллардан канат куеп иңнәргә
Илһам сазын уйнап, җырлап яткан чак.

Гүзәл чорым, сүнмәс җырым – яшьлегем,
Мин ул – сине мәңге сөяр гашыйгың!
Яшьлек дәртем, көч-гайрәтем ташыр мәл,
Тәвәккәллек төкәнмәс чор – яшь чорым.

Мәхәббәтем, гамьсезлегем – яшьлегем,
Гыйшык каләм алдырган мәл кулыма.
Дуслар белән тәгәрәшеп үскән чак,
Җиңелмәс чак – киртә торса юлымда.

Гүзәл язым, шат авазым – яшьлегем.
Гыйлем алып, бүген иркен яшимен.
Чал өрсә дә, чәчкә гомер җилләре,
Күңелем һаман синдә калган, яшь минем.

***

Офык – сәхнә,
Күктәге ай – софит.
Ә йолдызлар – гүя төсле көй.
Ак болытлар – сәхнә бизәлеше,
Күзләремне назлап иркәли.

Җил – җыр суза,
Дәрья дулкыннары
Биеп ала бердәм нотада.
Йокламаучы бака-чикерткәләр –
Көй чыгарып, җырлап утыра.

Ә дирижёр –
Зәңгәр күгем – чиксезлекнең үзе.
Мин агачлар белән – тамашачы,
Чәбәклим кул.
Табигатьнең игезе – Тәкъдиребез,
Ул – Режиссёр.

## Тәүге эйфория

Йөзләреңне тулган айга мин охшатсам,
Гафу итсен мине күкнең мәләкләре.
Синең мөлдер күзләреңә диңгез бакса –
Аның суы шунда сеңеп бетмәгәе.

Баткан кояш көнбатыштан үзе кайтыр,
Сине төнгә калдырырга көнләшүдән.
Урыныннан кузгалмаучы мәгърур тау да
Тайчынмас күк, артларыңнан иярүдән.

Көн яшьләрен яшерергә тырышачак,
Ә йолдызлар сөю тулы моңын түгәр.
Сәфәр чыксаң, юл рәнҗер һәм автобусың
Син китмәсен өчен соңга калып килер.

Гашыйк Мәҗнүн кабат туган дисәләр дә,
Ләйләсеннән башкага ул җыр җырламас.
Бер шигырьне ике шагыйрь язмаган күк
Миннән артык сине һичкем сөя алмас.

***

Гүзәллекнең барчасы,
Җаным, синдә икән лә –
Кызганмаган табигать
Үз тылсымын өргәндә.

Миңа дигән пакь сөю,
Дөрли-дөрли янганмы?
Кояшның бар җылысын
Йөрәгеңә салганмы?

Язгы гөлем, яшьлегем,
Сөмбел чәчкәйләреңне
Дәрья дулкыннарында
Әниең тараганмы?

Иелеп, су эчкәндә,
Синең мөлдер күзләрдән
Карашын алалмыйча,
Чишмә үбеп калганмы?

## Синсез яшәү мөмкин түгел

Күзләреңнән гүя чиксез йолдыз бага,
Ә кулларың иркә җилдәй тарый чәчем.
Сагынуың күккә аһәң булып аша
Йөзең балкый тулган айны хәтерләтеп.

Чәчәкләрнең хуш исеннән исерәм мин,
Шатлыгымнан былбыл булып сайрый күңел.
Бураннарга урап юлла сөю сүзең!
Мәҗнүн көе синсез яшәү мөмкин түгел.

Йөрәк сөю ширбәтеннән туенсынга,
Җан сөйгәнем, ярым булып кил яныма.
Биш көнлек бу хәятымның сыңар көнен
Аерылышып корбан итмә, зая кылма!

*Уйгыр теленнән* **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре*

# ТАТАРСТАННАН – ДӨНЬЯ ФӘНЕ КИҢЛЕКЛӘРЕНӘ



«Казан утлары» журналында галимнәр хакында сәхифәбезне башлап җибәргәндә, без Татарстаннан читтә яшәүче, гыйлем мәйданында танылган милләттәшләребезнең казанышлары белән таныштыру максаты куйган идек. Бүгенге язмабызның герое – татарстанлы, әмма аның фәнни ачышлары Татарстаннан һәм Россиядән читтә дә билгеле. Алай гына да түгел – шул ачышлар нигезендә чит илләрдә заводлар төзелә, технологияләр сафка баса. Болар барысы да – республикабызның абруен ныгытуга хезмәт итә.

Сүзебез – академик (1991), Углеводород чималы фәнни-тикшеренү институты («ВНИИУС» АҖ) директоры (1985), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (2006–2014), техник фәннәр докторы (1984), профессор (1990), Татарстан Республикасының атказанган химигы (1990), Фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясе лауреаты (1998), Ислам дөньясы фәннәр академиясе академигы (2007), Фән һәм техника буенча Россия Хөкүмәте премиясе лауреаты (2005), Россиянең мактаулы нефтехимигы (2002) һәм башка бик күп исем-дәрәҗәләргә лаек Әхмәт Мазһар улы Мазһаров турында.

Әхмәт Мазһар улы 1943 елның 1 гыйнварында Татарстанның Балтач районы Сасна авылында туган. Дөрес, төп чыгышлары моннан түгел – бабасы Мирхафиз Кайбелев Пенза өлкәсенең Качкару (Кутеевка) авылыннан атаклы Кышкар мәдрәсәсенә дини белем алырга килеп төпләнеп калган. Күрәсең, яшь мулланың акыллы, тәртипле, гыйлемле булуын күргәннәр: Казан артында яшәп калырга, халыкка дин хезмәте күрсәтеп, белем нуры таратып яшәргә дип, тирә-яктагы иң зур авыл, сукно (постау) мануфактуралары, эре сәүдәгәрләре белән дан тоткан Саснага аны Гомәр бай Якупов чакырган була. Шулай итеп, Сөләйман – Габделмәҗит – Җамалетдин Кайбелевларның нәсел шәҗәрәсен имам Мирхафиз татар иле – Татарстан белән бәйләгән. 1889 елны монда туып, Кышкар мәдрәсәсендә укыган, Шода һәм Сасна авылларында мөгаллимлек иткән улы Мазһар муллалыкны дәвам итәр дип фаразлаган ул. Әмма заманнар үзгәргән, инкыйлаб тирә-якта абруйлы, исемле, гыйлемле муллаларны да, аларның гаиләләрен дә «дошман» лагерена чыгарган.

Шунысы гыйбрәтле: репрессия тегермәнен узса да, Мазһар мулла гаиләсе иман белән яшәүдән ваз кичмәгән. Совет дәверендә дә авылдашлары Мазһар белән Рәкыйганың – мулла белән абыстай булуын онытмаган: вәгазь һәм дога укырга да чакырганнар, киңәшкә дә килгәннәр, бәхәсле мәсьәләләрне чишкәндә дә ярдәм сораганнар. Әти кеше өч баласына да гыйлемгә омтылышның мөһимлеген сеңдерә килгән. Мәктәптә бик яхшы укыган, спорт белән шөгыльләнгән Әхмәт, җидееллык

Сасна мәктәбен тәмамлап, 8 сыйныфка Балтач урта мәктәбенә, рус сыйныфына укырга йөри башлаган, монда техник фәннәр белән кызыксынып киткән. Шуңа да, аттестат алуга, Казан химия-технология институтына укырга кергән.

Институтта үзен алдынгы укучы, көчле спортчы (чаңгы һәм байдаркада йөзү) итеп таныта ул. 1964 елда институтны тәмамлагач, сәнәгать-җитештерү өлкәсен сайлый – Куйбышев синтетик спирт заводына эшкә урнаша һәм өч елда цех начальнигы урынбасары була. Әмма көннәрдән бер көнне заводка Мәскәү профессоры Н.Н.Лебедев килү яшь белгечнең тормышын тамырдан үзгәртә. Нефть химиясе өлкәсендә танылган галимнәрдән булган Николай Николаевич аны үзенә аспирантурага чакыра. Шулай итеп, 1967 елда егет Д.И.Менделеев исемендәге Мәскәү химия-технология институтына аспирантурага укырга керә.

Николай Николаевич Лебедев (1917–1989) – химия фәннәре докторы, профессор, Д.И.Менделеев исемендәге Мәскәү химия-технология институтының төп органик һәм нефтехимик синтез технологияләре кафедрасы мөдире, СССР Дәүләт премиясе лауреаты – аспиранты өчен чын мәгънәсендә Остазга әйләнә. Ә.М. Мазһаровның 1970 елны яклаган кандидатлык диссертациясе материаллары ук инде гамәли файдаланырга лаек дип табыла һәм Рубежан химия заводына кулланылышка тәкъдим ителә. Совет фәнендә дә сирәк күренеш була бу.

1972 елда фәннәр кандидаты булып, Казанга әйләнеп кайткан Әхмәт Мазһаров шушы белемнәрне, тәҗрибәне Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү институтына («ВНИИУС») алып килә, анда углеводородлы чималны күкерттән чистарту лабораториясенә нигез сала. Шушы лаборатория газ конденсатын һәм нефтьне – күкертле водородтан һәм меркаптаннардан, пычрак суларны күкертле кушылмалардан чистарту технологияләре; бензин, авиакеросин, җиңел углеводород чималын меркаптаннан аеру технологияләре белән танылa да инде.

1970 еллар – Татарстанда нефть чыгаруның елдан-ел арта барган вакытлары. Әмма Татарстанда гына түгел, Әстерхан, Оренбург, Казакъстан кебек төбәкләрдәге гаять зур нефть һәм газ ятмаларында табыла торган чимал – күкертле кушылмаларга бай. Углеводород чималын эзләү, чыгару, читкә озату белән шөгыльләнүче предприятиеләр өчен төп куркыныч фактор булып эш барышында экосферага чыга торган күкертле кушылмалар белән тирә-як мохитне пычрату тора.

Ә.М.Мазһаровның Казанга кайткач башлаган хезмәтләре шушы мәсьәләгә – күкертле кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый, алар нефть һәм газны чистарту өчен яңа ысуллар булдыруга хезмәт итә. Башлап, үзенең беренче аспиранты В.А.Фомин белән берлектә Ә.М.Мазһаров меркаптаннарның үзлекләрен өйрәнүгә керешә. Үткәрелгән тикшеренүләр нәтиҗәсендә инде 1974 елны Новокуйбышевск комбинатында пентанны меркаптаннан аеру җайланмасы төзелә. Аның артыннан – ААҖ «Салаватнефтеоргсинтез», Куйбышев НПЗсы һ.б. урыннарда шундый чистарту җайланмалары эшләтеп җибәрелә. Әйтик, «Салаватнефтеоргсинтез»дагы җайланма Оренбург төбәгендә табылган барлык җиңел углеводородларны чистартырга мөмкинлек бирә. Әлеге җайланмалар өчен эшләнгән ИВКАЗ катализаторлары шул замандагы чит ил аналогларыннан нәтиҗәлерәк булып чыга! Шул рәвешле, ВНИИУС дөньяда беренче булып нефтьне күкертле водородтан һәм меркаптаннардан аеруда нәтиҗәле ДМС-1 җайланмасын һәм ИВКАЗ катализаторларын сафка бастыра.

1991 елда, институт өчен шактый катлаулы бер чорда, коллектив Ә.М.Мазһаровны директор итеп сайлый. Ил җимерелгән, тормыш күнегелгән юлыннан чыгып, сайлау алдында калган бу дәвердә икътисади һөҗүмнәрнең берсе фәнни институтларга ясала. Гамәли институтлар финанс ярдәменнән өзелә: алар таралып, ябылып бетәләр. 1995 елны ВНИИУСта да фәнни эшчәнлекне дәүләт бюджетыннан финанслау туктатыла. Белгечләр саны 2 тапкырга кыскартыла. Институт җитәкчелеге «Нишләргә?» дигән сорау алдында кала.

Мондый шартларда фәнни коллектив булып сакланып калу юлын сайлаганда, галимнәргә эш хакы түләү өчен финанс чыганагы эзләү мәҗбүрияте алга килеп баса. Институт директоры Ә.М.Мазһаров углеводород чималын чистарту җайланмаларын гамәлгә куюны киңәйтү өчен мәйданнар эзли. Россия һәм Казакъстан, Беларусь, Литва, Болгария белән ике арада хезмәттәшлек җепләре сузыла: Казан технологияләре чит төбәкләргә китә, Татарстан галимнәре үзләренең хезмәт җимешләрен камилләштерү мөмкинлеге ала.

1993 елны Ә.М.Мазһаровның нефтьне меркаптаннан чистарту технологияләре белән Американың танылган «Шеврон» компаниясе кызыксына башлый. Компания бу технологияне бер ай дәвамында сыный, аннары Казакъстан Республикасындагы Тенгиз нефть ятмалары өчен махсус пилот җайланма төзергә тәкъдим ясала. Өч ай дигәндә сафка баскан җайланма үзенең, чыннан да, нәтиҗәлелеген күрсәтә. 100 еллык тарихы булган «Шеврон», шулай итеп, беренче тапкыр Россиядән технология сатып ала – елына 4әр миллион тонна нефть чистарта торган ике завод төзү турында карар кабул ителә. Алар 1995 һәм 1996 елларны эшләтеп җибәрелә. Моның сәбәбе исә бик гади: Казан тәкъдим иткән технология, чыннан да, үзенең гадилеге, җиңеллеге, экологик зыянсызлыгы һәм зур чыгымнар таләп итмәве белән дөньяда кулланыла торган билгеле технологияләрдән аерылып тора.

Әлбәттә, әлеге технология, беренче чиратта, Татарстан нефть химиясенә хезмәт итә. «Татнефть» белән берлектә, Татарстанда чыгарыла торган авыр нефтьләрне табылган урында, промыселда чистарту өчен Ә.М. Мазһаров җитәкчелегендә югары күкертле карбон нефтенең составы, үзлекләре фундаменталь тикшерелә һәм яңа оригиналь ДМС-1МА җайланмасы уйлап табыла. Елына 2,0 млн. тонна егәрлеге булган әлеге җайланма «Нурлатнефть» нефть-газ табу идарәсендә төзелә һәм 2005 елдан уңышлы эшләп китә. Әлеге хезмәте – дөньяда беренче булып нефтьне күкертле водородтан һәм меркаптаннардан чистарту технологиясен эшләгәне өчен Ә.М. Мазһаровка һәм аның хезмәттәшләре-фикердәшләренә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелә (1998).

Хәзерге вакытта Мазһаров технологиясе нигезендә нефтьне, бензинны, газларны чистарту буенча илебездә 40тан артык промышленность җайланмасы эшли. Шундый ике җайланма Болгариядә урнаштырылган. Тикшеренүләр нәтиҗәләре Англия, Дания, Канада, Италия, Швеция, Финляндия, Төркия, Марокко, Казакъстан һ.б. ил химиклары арасында да зур кызыксыну уята. Уйлап табу патентларының бишесе – АКШта, берсе Германиядә кулланыла. Әмма иң актив хезмәттәшлек – Иран Республикасына туры килә.

1990 еллар ахырында Ә.М.Мазһаровның өч лицензиясен Иран сатып ала һәм шулар нигезендә Иранда 20 нефть чистарту җайланмасы төзү турында килешү имзалана. Шуларның бишесе 2009 елда Харк утравында сафка баса. 2018 елда Фарсы култыгындагы Ассалуйе шәһәре янында елына 800 тонна одорант (С3-С4 меркаптаннар) җитештерә алырлык ДМД-2 «Одорант» җайланмасы эшли башлый. Ул Иранны чит илләрдән ел саен 4 млн. долларлык одорант сатып алудан азат итә. Хәзерге вакытта җайланманың көчен елына 2000 тонна одарант җитештерерлек итеп үзгәртеп көйләү эше башкарыла. Шунысын да әйтергә кирәк: аның 1000 тоннасы – Россия өчен җитештереләчәк.

2000 елның сентябрендә «Бид Боланд» заводында ДМД-2К технологияләре буенча бутанны күкертле кушылмалардан һәм ДМД-3 технологияләре буенча пентан фракцияләрне чистартучы 2 зур җайланма сафка баса.

2022 елның апрелендә Иранның Көньяк Парс төбәгендәге газ ятмалары чыгару урынында  елына 4 млн. тонна газоконденсатны меркаптаннардан тирәнтен чистарту җайланмасы (ДМС-3) эшләтеп җибәрелә. 2023-2024 елларда Иранда шундый ук тагын ике җайланманы Россиянең «ВО «Промсырьеимпорт» АҖ (Мәскәү) катнашында төзү планлаштырыла.

2021 елның 13 июлендә исә, Иранның Aztin Azma Mehr компаниясе белән

берлектә Бушерда нефтьне һәм нефть продуктларын меркаптаннардан чистарту өчен ИВКАЗ катализаторларын җитештерү линиясе сафка баса. ИВКАЗ – биредә элегрәк кулланылышта булган UOP, Axens, Merichem кебек фирмаларның катализаторларын алмаштыра.

2006 елны Татарстан Фәннәр академиясенең президенты итеп сайлангач, Ә.М.Мазһаров оешмадагы ике юнәлешкә аеруча зур игътибар бирә. Аның беренчесе – академик институтларны ныгыту, аларга үз урыннарын, Россиядә беркемнең дә эш юнәлешен кабатламаган фәнни темаларын табарга мөмкинлек бирү. Күрәсең, үзе озак еллар институт директоры булып эшләүче Ә.М.Мазһаров моның аякка басып барган Фәннәр академиясе өчен гаять мөһим булуын яхшы аңлаган. Икенчесе – чит илләр фәнни институтлары, академияләре, гыйльми үзәкләре белән багланышларны үстерү. Нәтиҗәләрне күрәләр: 2002 елны Ә.М.Мазһаров Ислам дөньясы фәннәр академиясе (IAS) академигы итеп сайлана. 2008 елда Казанда IASның XVIII конференциясе үткәрелә: дөньяның 48 иленнән килгән галимнәр Татарстандагы академик фән, технологияләр белән якыннан танышу һәм эшлекле элемтәләр урнаштыру мөмкинлеге ала.

Бу чорда Татарстан Фәннәр академиясендә күп кенә уртак фәнни проектларга нигез салына, алар тормышка ашырыла. Шул исәптән, чит илләрдә, чит җирләрдә сибелеп яшәүче татарларны өйрәнү, материалларны фәнни әйләнешкә кертү, татар галимнәрен берләштерү максатында матур эш-гамәлләр башкарыла. Иран темасына кергәнбез икән, бер генә мисал китерәсе килә: Ә.М.Мазһаров 2013 елның декабрендә Иран ягы акчасына бер төркем галимнәр: тел, әдәбият, халык иҗаты, сәнгать, борынгы кульязмаларны өйрәнү белән шөгыльләнүче белгечләрне әлеге илдә яшәүче татарлар тормышын-мәдәниятен өйрәнергә җибәрүне оештыра. Гөлестан провинциясендәге татарлар күпләп яши торган Кече Көмештәпә (татарлар иң башта шушы авылга килеп утырганнар дип исәпләнә), Олы Көмештәпә, Чабаклы, Хуҗанәфәс, Каракиле, Татар Гөлия (Шәһри Татар), Татар Суфлә (Түбән Татар), Бәндәр Төрекмән, Гурган, Гомбаде-Кабус, Карасу, Ак камыш кебек торак урыннарында булып, галимнәр монда татарларның 500-600 еллар элек үк күченә башлаганлыгын ачыклый. Монда яшәүчеләр үзләрен ике төркемгә: «су татарларына» (Каспий ягыннан күчеп килүчеләр) һәм «кыр татарларына» (күчмәннәр) аералар. Дөрес, 1230–1243 елларда монда килеп чыккан «кара татарлар» да, 1917 ел инкыйлабыннан соң, 1920–1930 елларда биредә мәрхәмәтле урын тапканнар да, хәтта Бөек Ватан сугышыннан соң килеп төпләнгәннәр дә аз түгел. Татарлар – мәктәп-мәдрәсәләр корып, газеталар чыгарып, үз тарихларын өйрәнеп яшиләр. Мондагы татарларның нигездә руханилар, гыйлемле кешеләр, фән һәм сәнгать әһелләре булуы халкыбызга хас этник сыйфатларга ачыклык кертә. Әлеге экспедициядә урнашкан бәйләнешләр бүген дә дәвам итә. Иранда яшәүче милләттәшләребез үзләренең тормышы турында мәгълүматларны Академиядәге «Мирасханә»гә җибәреп торалар.

Билгеле, чит илләр белән хезмәттәшлек итү, бигрәк тә – читтә заводлар, җайланмалар эшләтеп җибәрү галимнәрдән зур хезмәт, тырышлык һәм гыйльми фикернең дөнья фәненнән алдарак баруын, алдынгырак булуын таләп итә. Нәкъ шушы сыйфатлары Ә.М.Мазһаровка Иран нефть химиясенә зур өлеш кертергә юл ача. Шул ук вакытта, Татарстан фәне өчен Иран нефть ятмалары – технологияләрне камилләштерү мәйданына әйләнә. Болардан тыш, галимнең инглиз, немец телләрен белүен, татар теле аша фарсы телен үзләштерүен әйтергә кирәк. Бу очракта «Телләр белү – илләр ачар» дигән халык әйтеме күңелгә килә.

Җәй башында Иранга командировкасыннан Ә.М.Мазһаров фарсы телендә үзе хакында язылган китап алып кайта. Ирандагы нефть сәнагатен үстерүгә керткән өлешен күздә тотып, олы ихтирам билгесе буларак, фәнни эшчәнлеге һәм кешелек сыйфатлары хакында китап нәшер иткәннәр икән. Әлбәттә, мондый бүләк – сирәк

галимнәргә, чит дәүләтләргә, чит кавемнәргә игелекле хезмәт күрсәтә алган кешеләргә генә эләгә.

Чит илләр белән генә түгел, туган ягы белән элемтәләре нык Ә.М.Мазһаровның. Туган авылы Саснада мәчет салдыру, асфальт юл эшләү, зиратны төзекләндерү кебек гамәлләрдә аның өлеше зур була. Бүген Саснаның күркәм мәчете – «Мазһар мулла мәчете» дип атала, Аллаһ йорты урнашкан төп урам исә – Академик Мазһаров исемен йөртә. Мәктәптә дә аның исеме телләрдән төшми. 2000 елдан бирле Сасна мәктәбендә алдынгы укучылар арасында конкурс үткәрелеп, Әхмәт Мазһаров исемендәге 3 стипендия бирелә: физика-математика белән химия-биологияне иң яхшы үзләштерүчегә һәм иң көчле чаңгычыга. Димәк, Татарстанны чит җирләрдә танытырлык яшь галимнәр үсүенә дә өмет бар дигән сүз.

Үзен олы юлга чыгарган Балтач урта мәктәбендә исә, 2012 елдан бирле ике елга бер тапкыр «Фәнгә адымнар» дип аталган фәнни-гамәли конференция – «Академик Мазһаров укулары» оештырыла. 8 юнәлештә: математика, химия, физика-астрономия, география-икътисад, биология, техник иҗат, мәгълүмати технологияләр, туган як тарихы буенча җиңүчеләргә өчәр диплом һәм һәр юнәлештә беренчелекне алган укучыга Мазһаровтан истәлек бүләге тапшырыла.

М.Ломоносовның канатлы гыйбарәгә әйләнгән гомумбилгеле сүзләре бар: «Үз илендә танылган кеше генә дөньяны яулый ала». Чыннан да, шулай бит! Әхмәт Мазһар улы Мазһаров үз туган җирендә, үз Татарстанында ирешкән нәтиҗәләр – дөнья фәненә барып ирешә, дөнья сәнәгатендә кулланыла. Туган җире, Татарстаны исә, үз галименең уңышлары белән горурлана.

Татар тарихын, мәдәниятен, сәнгатен яхшы белүче, татар телле галим Әхмәт Мазһар улы хатыны Әлфия ханым (КХТИ доценты) белән ике кыз үстерәләр. Кызлары Казанда татар мәктәбен тәмамлыйлар, алты телдә сөйләшәләр. Бүген олысы София Лос-Анжелес шәһәрендә яши, 2018–2020 елларда шушы шәһәрнең мәшһүр университетына татар теле укытучысы итеп чакырыла. Кече кызлары Наилә Австриядәге Total компаниясендә хезмәт куя. Алар да чит җирләрдә татар булып, үз үрнәкләре белән татар мәктәбенең юлларны кисмәвен, киресенчә, бүгенге дөньяда һәр фикерле, акыллы, тырыш кешегә барлык мөмкинлекләр дә бар икәнлекне исбатлап яшиләр.

Без дә, журнал укучылары исеменнән, бу көннәрдә 80 яшен тутыручы, әмма киләчәккә зур планнар корып, якындагы елларда дөньяда төзеләчәк – җайланмаларын билгеләп куйган, күпсанлы укучылары-шәкертләре белән бергә көн саен шушы киләчәкне якынайту өчен хезмәт куючы Әхмәт Мазһар улы Мазһаровны юбилее белән ихластан котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, барлык теләк-ниятләренең тормышка ашуын телибез.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# ШӘРЫК ШАГЫЙРЬЛӘРЕ*

### Җәләлетдин Руми[1]

Җәләлетдин Руми суфи шагыйрьләрнең иң даһиларыннан хисапланса да, җаиз[2]. Унөченче гасыр милади, җиденче гасыр һиҗридә Анатолиядәге сәлҗүк хөкемдарларының тәхет гяһе[3] булган Конья шәһәрендә торган. Аның Руми ләкабе[4] шуннан килә. Нәсел ягыннан ул чып-чын төрек була торып, шигырьләрен фарсыча язган. Шуңа күрә дә фарсы шагыйрьләреннән хисапланып, иран әдәбиятында шәрәфле урын тота. Ул башта сәлҗүк солтанының сараенда сарай галиме монасибында булса да, гомеренең ахырына таба дөньяны куеп, дәрвишлеккә бирелгән. Мәүләви тарикатен төзүче Җәләлетдин Румидыр. Аның әсәрләреннән мәшһүррәкләре – «Диван»ы белән «Мәснәви»е. Бу әсәрләрнең беренчесе хисси шигырьләрдән мөрәккаб[5]. «Мәснәви»дә нәсер һәм шигырь белән язылган мәсәлләр, гыйбрәтле хикәяләр катыш; шуның өстәвенә ул тәсауф фәлсәфәсе белән дә тулы. Шагыйрьнең бу әсәрләреннән башка робагыйлары да мәшһүрдер.

***

Кердем бакчага
Көннәрдән бер көн;
Теләдем өзәргә
Гөлләрдән бер гөл.
Курка идем тик
Бакчачыдан мин;
Йөрдем яшеренеп
Читтән-читтән мин.

Бакчачы кинәт
Каршыма килде;
Ягымлы көлеп,
Ул миңа, диде:
«Бер генә чәчәк –
Нәрсә ул миңа;
Бөтен бакчамны
Багышлыйм сиңа».

***

Газаплары миңа рәхәт булып күренә тәмугның
Әгәр дә бергә булсаң син минем белән, гүзәлем.
Чәчәкле бакчага охшар иде зиндан да хәтта,
Әгәр дә анда булсаң син минем белән, гүзәлем.
Чәчәклек күк булып күренә миңа комлы сусыз юл,
Әгәр шул юлда булсаң син минем белән, гүзәлем.
Бөтен дөнья гөле булсын тирәмдә – мин бәхетсез,
Әгәр дә булмасаң шунда, минем тиңсез гүзәлем.

[1] Мәүлана Җәләлетдин Мөхәммәд Руми (1207–1273) – XIII гасыр фарсы шагыйре, суфи, иҗаты төрки халыклар әдәбияты үсешенә дә гаять зур йогынты ясаган.
[2] Җаиз – ярый торган.
[3] Гяһ – урын.
[4] Ләкаб – кушамат.
[5] Мөрәккаб – тупланган.

* Гали Рәхим. Шәрык шагыйрьләре. Казан: Электро-типография «Милләт», 1919.

*Ахыры. Башы узган санда.*

***

Мәхәббәт ялкыны итсә тәкатьсез,
Тынычланмак теләп бер аз заманга,
Күтәрәм дә кадәчне тик, гакылны
Телимен мин гарык кылмага[6] анда.
Ләкин һәйһат! Теләсәм дә ни чаклы,
Насыйп булмый сине, җанкай, онытмак;
Торасың шул күз алдымда һаман син
Шәрабымны теләгәндә дә йотмак.

***

Маил кылуы күңелнең башкаларга
Вакытлы ул; Сөямен мин һаман да;
Кыласың шул канәгать яндырып шәм
Кичен, күктә кояшың булмаганда.

***

Беләм, дустым, телисең син йөрәгемне һәм алтын;
Ләкин юкка өмид итмә, биралмыйм мин берен дә.
Үзең уйла: табарсыңмы тишек янчыктан алтын!
Гашыйкмын мин, йөрәгем дә минем юк шул җирендә.

***

Миңа тормыш язык синсез, гүзәл яр,
Бу дөньяда ничек синсез торырмын?
Тирәклеккә һич охшамас бу тормыш;
Үләрмен мин, кибәрмен дә корырмын.

## Гомәр Хәйям[7]

Гомәр Хәйям шагыйрьлеге белән ни кадәр шөһрәт тоткан булса, бөек бер фән галиме булуы җәһәтеннән дә шул кадәр үк мәшһүрдер. Ул заманының (унберенче милади – бишенче гасыр һиҗри) иң олуг риязият[8] галимнәреннән булып, сәлҗук солтаны Мәликшаһ хозурында Нишапур шәһәрендә, гыйлем мәхәббә булган шул патша тарафыннан тәэссис ителгән рәсадханәне[9] идарә итеп торган. Аның гыйлем әл-җәбр[10] һәм гыйлем хәяттән язган әсәрләрен Европа галимнәре әле хәзердә дә тәкъдир итәләр. Моның өстенә, Гомәр Хәйям бер мөтәфәккыйр[11] – философ булу җәһәтеннән дә танылган. Аның робагыйларын Иран халкы телдә тәсбих урынына йөртә, әле дә булса халык җырлары урынында җырлый. Гомәр Хәйямнең шигырьләре, бер яктан, дөньяның кабахәтлеген, җәфа һәм газап учагы булуын, тормышның мәгънәсезлеген алга сөреп, шагыйрьнең дөньядан бизгәнен, тормыштан туйганын изһар итсәләр, икенче тарафтан, без аларда тулы дөньяви тормышка чакыру, җисмани рәхәт, тәләззезгә[12] өндәү табабыз; хәмергә, хатын-кыз гыйшкына мәдех вә сәналәр укыганын күрәбез. Гомәр Хәйям үзе хосусый тормышында риязат чигеп гомер итсә дә, картлык көненә кадәр шул рухта язудан туктамаган.

---

[6] Гарык кылу – батыру.
[7] Гыясетдин Әбүлфатих Гомәр ибне Ибраһим әл-Хәйям Нишапури (1048–1131) – мәшһүр фарсы телле шагыйрь, математик, астроном, философ, табиб.
[8] Риязият – математика.
[9] Рәсадханә – обсерватория.
[10] Гыйлем әл-җәбр – алгебра.
[11] Мөтәфәккыйр – фикер иясе.
[12] Тәләззез – ләззәт.

***

Килдем дөньяга – булмады файда,
Аңарга һич тә минем туганнан;
Үләрмен – ләкин бу фани дөнья
Нә шөһрәт, нә дан казанмас аннан.
Һичбер адәмнән ишетмәдем мин,
Гомерләр үтте – белә алмыйм һаман:
Ник тудым, тордым, газап чиктем мин?
Ни өчен китәм инде дөньядан?

***

Бөтен дөнья ляшә[13] бит ул, кирәксез ул
Бикяр бөтен укып, белеп, аңлаганың;
Бар сөйләгән сүзләрең дә кирәксез бит;
Биһудә[14] һәм дә ялган бар тыңлаганың.
Алачыгыңда[15] утырып син фикерләдең –
Бушка синең бөтен уйлаган уйларың.
Әбәдия[16] мәкыясендә ляшә бит ул –
Биһудә син бөтен дөньяны буйладың.

***

Ябылды яшьлегемнең пакь китабы,
Укылды ахырына тик, инде бетте.
Тагын да инде килмәскә булып һич
Бәхетле һәм дә шат яз көнем үтте.
Һамайун кош[17] «җүләр яшьлек» аталган
Очып китте төшәр-төшмәс һавадан;
«Килеп җиттем» дияргә өлгермәде,
Сәмаләргә[18] рәван[19] булды яңадан.

***

Буем зифа – гүя сәрви агачы,
Таза яшьлек таша миннән ташу күк.
Гүя мин бакчада үскән кызыл гөл;
Теләү белән рухым кайный, күңел ут.
Ләкин уйла! Нигә соң мондый күркәм
Вә ялкынлы яраткан мине санигъ[20] –
Җир астында ятып чермәк өченме?
Җавап бир син, әйтә алсаң мине канигъ[21].

***

Без туганчы бит һаман да
Зыр итеп торган җиһан;
Без үлеп аннан китәрбез
Һичбер эз калдырмыйчан.

[13] Ляшә – үләксә.
[14] Биһудә – буш, файдасыз.
[15] Алачык – татарча сүз. Кечкенә йорт (хижина) мәгънәсендә. Алачак дигән сүз белән саташтырылмасын (Г.Р. искәрмәсе).
[16] Әбәдия – мәңгелек.
[17] Һамайун – һомай кошы, бәхет кошы.
[18] Сәма – күк.
[19] Рәван – китүче.
[20] Санигъ – бар кылучы.
[21] Канигъ – барына риза булучы.

Элеккеге күк әйләнер ул
Итмәенче һич касыйрар[22];
Без череп туфрак булырбыз –
Бер зыян килмәс аңар.

***

Мөкаддәрдә[23] язылганга сонып буй,
Минем белән сиңа хәтле дә һәр көн
Куркытып зыр итеп торган юлында
Алышкан якты көн белән кара төн.
Киңәш, дустым, сиңа: йөргән чагыңда
Онытма, сакланып бас; ихтималга
Гүзәлләрдән берәүнең күз-бәбәген
Үтәсеңдер тузан дип таптый-таптый.

***

Ләззәтен бел дөньяның син, аз гомернең рәхәтен
Тапмый калма бер сәгатьлек бу сәфәрдә, дускаем!
Дөньялыкның рәхәте бит бер дәкыйка, бер сулыш;
Форсатыңны тик качырма син, хозур кыл, дускаем!

***

Диләр безгә, ки җәннәт багларында
Гүзәл хур кызларын безләр кочарбыз.
Оҗмах чишмәсенең без буйларында
Күбекләнгән шәраб һәм бал эчәрбез.
Әгәр бу сүз дөрес булса, әйлә дус:
«Тәгалә» оҗмахында кылса рөхсәт –
Ярамас нигә бу фани галәмдә
Шәраб эчсәң, гүзәлләрне без үпсәк?

***

Эчәрмен дә үләрмен һич җәфасыз,
Һәм исерек хәлдә гүргә мин керермен.
Череп бетсә дә гәүдәм, мин кабердән
Борынга тәмле ис тик китерермен.
Килерләр бик күп исерекләр, ерактан
Шәраб исен сизеп, ошбу кабергә;
Сулагачтын шул исне мәшат[24] булырлар,
Биһуш хәлдә аварлар  шунда бергә.

***

Кайчан кем мин үлеп күзләр йомылса,
Ачылмаска соңыннан инде һич тә,
Утыртмагыз гүремнең өстенә таш,
Мине тотсын диеп инсаннар истә.
Череп балчыкка әверелгәч кенә тик
Шәраб белән изеп кирпеч ясарсыз
Да хуш исле хәмер тулган савытның
Тик авызын сез шуның белән ябарсыз.

[22] Касыйрар – кимлек.
[23] Мөкаддәр – язмыш, тәкъдир.
[24] Мәшат – шат, бәхетле.

## Тәкълид

Гамьсез үтте яшьлегемнең бер-бер артлы көннәре,
Тормышымның кырларында җилләр искән күк булып.
Бирми рәхәт, бирми ләззәт гыйш-гыйшрәт төннәре:
Тиз китәрмен бу җиһаннан мәңгелеккә юк булып.

## Тәкълид

Телимен мин югалтырга үземне
Гашыйк белән томанлатып күземне.
Ни хәтле генә яшерсәм дә йөземне,
Насыйп булмый, югалталмыйм үземне.

## Сәгъди[25]

Шәех Сәгъдинең ислам шәркында шөһрәте Хафизныкыннан артык булмаса, ким түгел. Хафизның да, Сәгъдинең дә исемнәренә тагылып йөртелә торган «шәех» ләкабе аларның суфилардан булуларын күрсәтә. Бер яктан, алар шагыйрь булсалар, икенче яктан, мөтәсуфилар. Сәгъдинең дә ватаны, Хафизныкы күк, Шираз өлкәсе. Ләкин ул, үзеннән йөз ел соң килгән ватандашы Хафиз шикелле, туган илендә рәхәт гомер кичерә алмаган. Гомере буенча явыз тәкъдир аны бер илдән икенче илгә ташлаган. Ул Һиндстанда да булган, Сүриягә дә барып чыккан; хәтта бер заманны Әһил Сәлип гаскәренә әсир дә төшкән. Шулай итеп, Сәгъди картлык көнендә генә ватаны Ширазга кайтырга муафикъ булган. Хиссият бабында шәех Сәгъди үзенең әсәрләрендә Хафиз кадәрле үк «хөррият» күрсәтми; аларда тәзһиб[26] әхлакка күбрәк урын бирелгән. Сәгъдинең әсәрләре башлыча «Гөлстан» һәм «Бостан»нан ике китапка җыелган. «Бостан» бөтенләй шигырь белән язылып, бу китапта шагыйрьнең касыйдәләре, газәлләре, робагыйлары дәреҗ ителгән. «Гөлестан» исә күбрәк нәсер белән язылып, төрле гыйбрәтле вак хикәяләрдән тора. Шигырьләр бу китапта берәмтекләп кенә сибелгәннәр. Үткен тел, кискен һөҗү Сәгъди каләменең хасәсеннәндер[27].

## Касыйдә[28]

Гомерлеккә кол итмәсен сине, дус,
Ватаның һәм кара кашлы матур яр:
Җир өсте бик киң ул, һич тә чиге юк,
Һәм аз түгел бу дөньяда матурлар.

Азмы дөньяда, кара син, ал яңак?
Азмы йөзләр охшаган гөлчәчәккә?
Урманнарда яшел тирәк азмы соң?
Бакчалар соң батмаганмы чәчәккә?

Бусагаңнан китә алмыйсың, тавык күк,
Нигә чаклы тәкъдиреңә түзәрсең!

[25] Мөслих әд-Дин Әбу Мөхәммәд Абдулла ибн Мөшәрриф ибн Мөслих ибн Мөшәрриф (1200/1219-1292 – Сәгъди тәхәллүсе белән иҗат иткән күренекле фарсы шагыйре, философ. Аның «Бостан» поэмасы дөньяның иң мәшһүр 100 китабы исемлегенә керә.

[26] Тәзһиб – алтынга манылган.

[27] Хасә – үзенчәлек.

[28] Сәгъдинең бу касыйдәсен бераз кыскартып тәрҗемә итеп, тәҗрибә өчен төрек шагыйре Мөхәммәдәмин яза торган «төрек вәзене» кулландым. Мөтәрҗим (Г.Р.искәрмәсе).

Кул селек тә йортыңа син, чык та кит:
Күгәрчендәй иркендә бит гизәрсең.

Сандугачтай мәфтүн тик очып йөр әйләнеп,
Гафил булып сазлыктагы чеЛәндәй
Утырма син үз гыйшкыңа бәйләнеп.

Төрле халык арасында кайнашып,
Кайда рәхәт, кайда шатлык – шунда бул.
Кальбеңне син әсирлеккә бирмә һич:
Кайда гыйшык булса – кайгы шунда ул.

Ефәк – асыл көмешләргә сокланып,
Ашыкма син акылыңнан язарга;
Онытма, дус, тот исеңдә һәрвакыт:
Ефәкләрнең исәбе юк базарда.

Кырда йөргән аргамакка сал күзең:
Нинди уйный; көр күңелле, шат үзе.
Үгез исә тегермәнгә җигелгән;
Нинди зәбун һәм  сукырланган күзе.

Иркендәге бер-бер кемсә теләрме!
Кул-аягы богауланып куярга!
Гамьсезләргә мөмкинме соң, дусларым,
Гамьсезлектән, тынычлыктан туярга!

Сөйгәнеңнең колы булсаң да әгәр,
Кыйммәтеңне белми бит ул, би вафа.
Күңелеңнең тик җуясың бәясен,
Мәхәббәтеңнән тик чигәсең син җәфа.

Бәхетлеләр ярларын тик төннәрдә
Үбеп-кочып гыйш-гыйшрәт итәләр;
Иртәгесен ташлыйлар да аларны
Тыныч кына юлларына китәләр.

Бал-шикәрдән татлы, нәфис мивәләр,
Яткан вакыт өелешеп табында
Зәүкым кебек ачы җимеш агачын
Берәү-берәү үстерерме багында?

Гыйшык тозагына ләккән адәми
Тиң күрәм мин арканлаган әсиргә;
Атлы дошман сөйри аны артыннан,
Бер тора ул, егыла тагын да җиргә.

Гомерең буе татып килгән җәфаны
Аз дәвам иткән тәләззез капламый;
Иртә белән баш авыртудан сине
Төнге мәҗлеснең хозуры сакламый.

Үзең төсле бер кешегә кол итү
Ихтыярны һәм гакылны, күңелне
Мәҗүсиләр төсле ялган тәңрегә,
Сынымнарга табыну кебек түгелме!

Һичбер вакыт син гакылыңның тезгенен
Бирә күрмә дәртләреңнең кулына.
Хикмәт белән күзе ачылган кешегә
Рәи[29] түгел керү гыйшык юлына.

Гашыйкларның хәлен бик аңлыйм инде,
Котылгачтын «гыйшык» дигән аудан мин.
Бер мәртәбә елан чаккан кешедәй,
Куркам инде юлда яткан баудан мин.

***

Минем күзләремә нурлар сибәсең син йөзеңнән,
Синең белән миңа төннәрдә төн түгел, була көн.
Әгәр ташлап мине мәхрүм итәр булсаң үзеңнән,
Аермасыз булыр шул чак кояшлы көн, кара төн.

***

Суның чын кыйммәтен белмәк теләсәң син әгәр дә,
Көеп янган кызу сахрада юлчыдан сорап бел.
Ничек инде суның кадрен белерсең син, әйа дус,
Ташып аккан фөрьяд нәһре[30] буенда гына торып гел?

***

Әгәр булсаң бөтен җир йөзенә шаһ,
Хаким итсәң дә хәтта син җиһанга.
Фикер иткел: озайтырга кадереме
Хисапланган көнеңне син бер азга?

***

Син уйлама ки карчыкны теләмәс дип ашарга
Гаһед[31] биргәч, җимешләрне ашамаска түзәргә.
Тешен бик кайраса да, шул насыйп булмас аңарга:
Үрелсә да, кулы кыска, буе җитмәс өзәргә.

***

Яшь кызлар күк фазыйләт[32] чәчәк ата
Бакчаларда исле гөлчәчәк.
Гомре генә аның тик кыска шул,
Күп тә тормый шиңеп бетәчәк.
Адәмнең дә буе-сыны зифа,
Сыгылмалы биек нарат күк.
Көчле яшьлек белән мактанырга
Туры килми ләкин аңар күп.

[29] Рәи – файда.
[30] Нәһер – елга.
[31] Гаһед – сүз, ант.
[32] Фазыйләт – яхшылык.

## Хакани[33]

Хакани беренче дәрәҗә мәшһүрләрдән түгел. Ул милади 41 нче, һиҗри алтынчы гасырда Азәрбайҗанның Ширван аталган өлкәсендә (хәзерге шәркый Кавказиядә) Ширван шәһәренең сараенда «сарай шагыйре» булып торып, күбрәк мәдехнамәләр язу белән шөгыльләнгән.

***

Хәсрәтле, горур яшьлекнең уты
Йөрәгемдә янып яткан чагында,
Күбәләктәй очып йөрде фырылдап
Кызу рухым кызу ялкын янында.
Менә инде ул ут сүнде дә бетте;
Күбәләк тә көеп, янды, югалды.
Аларның янган урынында – ва вәйлә[34]!–
Суык көлдән бүтән инде ни калды?

## Җами[35]

Җами соңгырак заманның иң истигъдадлы шагыйрьләреннән. Ул Тамерлан балалары хакимият сөргәндә (51 нче гасыр милади – 9 нчы һиҗридә) аларның пайтәхете «Һират» шәһәрендә туып, шунда яшәгән. Әдәбиятның һәрбер кыйсемендә мәһарәт сахибе[36] булган.

Синең аткан угың килде дә керде
Йөрәккә... инде мәҗрух мин, бетәмен.
Алай да мин һаман өзмим өмидне:
Килер, угын алырга диеп көтәмен....

## Рабиндранат Тагор[37]

Һинд шагыйре Рабиндранат Тагор хәзерге шәрык шагыйрьләренең иң шөһрәтлеләреннән. Ул – үзенең Һиндстанында гына түгел, бөтен Европада танылган кеше. Аның әсәрләре бөтен Европа телләренә тәрҗемә кылынган. Берничә ел элек ул һәр елны иң кыйммәтле әдәби әсәр язган әдипкә бирелә торган мәшһүр Нобель премиясен алу шәрәфенә дә наил булган иде. Тагор үзе – бенгалияле һинду (брахмани), ул Англиядә Оксфорд дарелфөнүнендә укып, камил Европа тәрбиясе алган бер кеше. Ләкин Европада уку аның шәрык рухына катрә кадәр тәэсир итмәгән. Кирәк язган әсәрләрендә, кирәк гади тормышта ул там мәгънәсе белән һиндле. Аның Европада шөһрәт казануының бер сәбәбе үзенең табигый истигъдады булса, икенче сәбәбе шиксез әсәрләренең үзенә бер төрле, күпне күреп өйрәнгән Европалы өчен өр-яңа бер әйбер булуыдыр. Тагорның шигырьләре – күбрәк хисси шигырьләр. Алар баштанаяк үзенә бер төрле нәфасәт нечкә тойгылар белән сугарылганнар. Аларда европалыда булуы мөмкин булмаган, Һиндстанның кызу кояшы тәэсирендә генә инсанда пәйда була торган ялкынлы, атышлы хиссият бар. Монда тәкъдир ителгән берничә шигырь аның «Бакчачы» нам шигырь мәҗмугасыннан алынып, русча аркылы нәсер белән

[33] Афзаледдин Бадил Ибраһим ибн Али Хакани Ширвани (1120-1199) – күренекле азәрбайҗан шагыйре, философ.
[34] Вайлә – үкенеч.
[35] Нуреддин Габдеррахман ибн Әхмәд Җами (1414-1492) – фарсы телле шагыйрь, суфи шәйх, философ, аның иҗаты фарсы классик поэзиясен йомгаклап куя дип санала.
[36] Мәһарәт сахибе – осталык иясе.
[37] Рабиндранат Тагор (Тхакур) (1861-1941) – һинд шагыйре, композитор, рәссам, иҗтимагый эшлекле. Иҗаты 1913 елда Нобель премиясенә лаек була.

тәрҗемә ителделәр. Тагор әсәрләрен һинд-бенгалия телендә яза. Күп әйберләрен ул үзе инглиз теленә тәрҗемә кыйлган. Монда китерелгән берничә шигырь генә, әлбәттә, аның әдиплек характерын тәмам ачып бирә алмыйлар. Ул – бик әтрафлы язучы; аның хисси шигырьләре булганы шикелле, дини-фәлсәфи рухтагы шигырьләре дә, хикәяләре, театрга махсус әсәрләре дә бар. Түбәндәге шигырьләр минем хосусый зәүкыма карап кына сайланды.

***

Әйт миңа, җаным, сөйлә миңа: ни турысында җырлыйдыр идең син? Төн караңгы. Йолдызлар болыт араларына качканнар. Җилнең генә тик агач араларында аһ итеп сулаганы ишетелә.

Мин чәчләремне сүтеп, таратып җибәрермен. Күк ябынчам мине кара төн төсле эретер.

Мин синең башыңны күкрәгемә кысып, йөрәгеңнең сөйләгән татлы сүзләрен тыңлармын. Юк, мин синең йөзеңә күтәрелеп карамам; күземне йомармын да бары тик синең йөрәгеңне генә тыңлармын.

Сөйләр сүзләрең беткәч, без тик кенә сөйләшми генә утырырбыз. Агачлар гына тик караңгыда үзара шыпыртлап серләшерләр.

Төн агарыр, көн яктырыр... Без сүзсез генә бер-беребезнең күзенә карарбыз да, аерылышып икебез ике якка китәрбез...

Әйт миңа, җаным, сөйлә миңа: ни турысында җырлыйдыр идең син?

***

Әй, гүзәл хатын, син Тәңренең генә сәнгате түгел; сине син итүдә ирләрнең дә катнашы бар. Аның өчен алар сине һәрвакыт үз йөрәкләрендәге матурлык белән зиннәтлиләр.

Шагыйрьләр сине алтыннан тукылган шигырьләре белән киендерәләр, рәссамнәр синең матурлыгыңны мәңгелеккә калдыралар.

Сине бизәп, матурлап, тагы да кыйммәтлерәк итәр өчен диңгез – үзенең энҗеләрен, җир – үзенең алтынын, бакча чәчәкләрен бирә.

Ирләрнең сиңа маиле дә синең яшьлегеңне төрләндерә. Чынлап та, син яртылаш «хатын» булсаң, яртылаш хыялдан тукылгансың.

***

Су кирәк булган чагында, су савытыңны күтәр дә минем күлгә генә кил син.

Күлнең суы синең аякларыңны кочар да колагыңа үзенең яшерен серләрен сөйләр.

Күрәмсең, яңгыр болытларының күләгәләре яр кырыендагы сары ком өстеннән чабалар; каракучкыл болытлар, нәкъ синең күгелҗем күзләрең өстенә төшкән кара чәчләрең төсле, урман өсләрендә асылынып торалар...

Синең аяк авазың миңа күптән таныш инде: аны ишетүгә, минем йөрәгем тибәргә тотына...

Су кирәк була икән сиңа, зинһар, су савытыңны ал да кил тизрәк минем күл буена.

Әгәр синең буш вакытың булса, буш кувшиныңны суда йөздереп, тик кенә, уйсыз гына су буенда утырасың килсә, ул чагында да минем күл буена кил син.

Күрәмсең, яр буе ямь-яшел чирәм белән капланган, үлән арасында үскән чәчәкләрнең исәбе дә юк.

Уйлар, сагышлар, ояларыннан очкан кошлар шикелле, синең күзләреңнән очарлар; онытылырсың... бөркәнчегең дә башыңнан җиргә төшәр...

Буш вакытыңны тик кенә утырып уздырасың килсә, кил син, кил минем күл буена.

Уйный-уйный аргач, су коенасың килә икән – минем күлгә кил.

Сине эреткән зәңгәр ком өстендә ятканда, күлнең зәңгәр суы синең тәнеңне эртер.

Дулкыннар аяк очларына басып, урлап синең ачык муеныңны үбәрләр, колагыңа шыпырт сүзләр сөйләрләр...

Су коенырга теләгән чагыңда кил син, кил минем күлгә.

Әгәр гакылыңны югалтып, тормыштан бизеп, үлем кочагына атылырга теләсәң, ул вакытта да минем күл кырыена кил син.

Суы салкын аның, төбе чиксез тирән, төпсез йокы төсле караңгы төбе.

Аның астында төн дә, көн дә бер; камил занлык хөкем сөрә анда...

Үлем дәрьясына талырга теләгәндә дә минем күл буена гына кил син.

***

Әйт, минем сөеклем, дөресме? Дөресме болар барысы?

Минем күзләремнән атылган яшеннәргә каршы синең күкрәгеңдәге кара болытлар гөлдерәп җавап бирәме?

Дөресме, җаным: беренче мәхәббәтнең яңа ачылып килә торган чәчәкләре күк татлымы минем иреннәрем? Тәнемнән яз исләре аңкып торуы дөресме?

Минем аяк басуыма җир өсте думбра күк матур авазлар бирәме?

Мине күргәч төн дә шатлыгыннан елап, күзләреннән чык тамчыларын тамыза түгелме? Таң яктысы да мине кочаклагач кына үзен бәхетле саный түгелме?

Синең гыйшкыңның гасырлар буенча мине эзләве, чынлап та, хакмы?

Син мине очраткач, минем тел тибрәтеп әйткән сүзләремдә, минем иреннәремдә, күзләремдә, бөдрә чәчләремдә синең гасырлар буе асраган хыялың үзенең соңгы рәхәтен табып тынычлавы дөресме?

Минем маңгаемда мәңгелекнең серле мөһере басылган булуы, тәхкыйк, чынмы?

Әйт миңа, сөеклем, дөресме болар барысы да?

***

Һәр көнне ике бертуган кыз, суга барышлый шушы турыдан узганда, көлеп узалар. Көн саен берәүнең, агач артына яшеренеп, үзләренең үткәнен көтеп торганын сизгәннәр, ахры, алар.

Һәрвакыт ике бертуган кыз, шушы турыга җиткәч, бер-берсе белән ни хактадыр пышылдаша башлыйлар. Агач арасында качып торган кешенең серен белгәннәр, ахры, алар.

Һәрвакыт шушы турыга җиткәч, аларның кувшиннары кылая да сулары түгелә. Агач артына поскан кешенең йөрәге, үзләрен күргәч, ныграк типкәнен сизгәннәр, ахры, алар.

Ике бертуган кыз, бер турыдан узганда, бер-берсенә карыйлар да көләләр. Үзләренең көлүләре, вак-вак атлап йөгергән аяклары агач артында торган кешенең башындагы бөтен уйларын чуалтканын белгәннәр, ахры, алар.

***

Төндә бер ялгызым сөеклем белән күрешергә барганда, шундый тын, шундый тын...

Агач яфраклары да җилгә җилбердәмиләр, кошлар да сайрамый; урамның ике ягында йортлар шып-шыпырт тезелешеп торалар.

Аяк атлаган саен тубыгымдагы беләзекләр шылтырыйлар да, шул тавышка үз-үземә оялам.

Балконда төнлә ялгыз утырып, сөеклемнең аяк авазын көткәндә, шундый тын, шундый тын...

Яфраклар селкенмиләр, елганың да суы нәкъ йоклаган сакчының тезләре өстендәге ялан кылыч күк шомарып ялтырый.

Йөрәгем генә минем шашкан төсле дөп-дөп тибә. Ничек туктатырга инде аны.

Сөйгәнем килеп, яныма утыргач, бөтен тәнем минем калтыранырга тотына. Күзләрем йомыла. Башларым әйләнә.

Шул чакта йолдызларны болыт каплый да, төн тагы да караңгыланган күк була.

Минем йөрәгем генә тик караңгыда кыйммәтле асыл таш кук яна, күкрәгем аркылы ялтырый. Белмим, ничек яшерергә инде аны...

***

Яшь шаһзадә безнең йорт алдыннан үтеп китәчәк бит, анам – ничек бүген эш эшләргә кулым барсын соң минем?

Әйт әле, чәчләремне ничек итеп ясыйм? Нинди күлмәкләремне киим соң, ә?

Гаҗәпләнеп карама син миңа, анам!

Бик яхшы беләм мин, әлбәттә, ул минем тәрәзәмә күзен дә салмас, күз ачып йомганчы күз алдыннан югалып, курай тавышлары гына әкренләнә-әкренләнә ерактан елаган төсле ишетелерләр.

Алай да яшь шаһзадә безнең йорт алдыннан үтәчәк, анам; шуның өчен мин үземнең иң һәйбәт киемнәремне киярмен.

Шул вакытта йөземнән пәрдәмне ачтым да, муенымдагы якут муенсамны салып, аның узачак юлы өстенә, җиргә ыргыттым мин.

Гаҗәпләнеп карама син миңа, анам?

Бик яхшы беләдер идем мин, әлбәттә, ул минем муенсамны җирдән алмады. Якутлар арбаның тәгәрмәче астында тапталып, кызыл кан табы төсле җирдә ятып калдылар. Калсыннар! Минем аларны кемгә бүләк иткәнем берәүгә дә мәгълүм түгел бит!

Алай да яшь шаһзадә безнең йорт алдыннан узганда күкрәгемдәге кыйммәтле җәүһәремне аның аяк астына ташлап калдым шул мин.

***

Беренче таң кошлары белән бергә уянып, сүтелгән чәчләрем өстеннән чәчәк кыршавы киеп ачык тәрәзә төбенә утырган идем.

Иртәнге алсу томан эчендә урамнан яшь бер юлчы узып барадыр иде.

Муенына энҗе тезмәсе аскан, башына кигән чәчәк кыршавы алтын таҗга охшашлы иде. Минем ишегем төбендә туктап, «кайда ул?» дип сорады.

Ни уйлап «ул – мин; мин монда, яшь юлчы!» дияргә кодрәтем җитмәде.

Эңгер-меңгер вакыты иде. Мин өйгә китеп, чәчемне үреп утырадыр идем. Батып бара торган кояшның яктысында яшь юлчы килеп, минем ишегем төбендә туктады. Атлары ак күбеккә баткан, үзенең дә киемнәре тузанлы иде. Арган тавыш белән: «Кайда ул?» – диде.

Ни оят! «Ул – мин; мин монда, арган юлчы!» – дияргә кодрәтем җитмәде.

Менә язгы тын бүлмәдә кандил яна. Акрын гына искән җил биткә бәрелә. Тутыем үзенең читлегендә тынып йоклый.

Минем изүем тавис кошының түше төсле зәңгәр, ябынчам язгы яшь чирәм күк яшел.

Тәрәзә төбендә утырам да бушап калган урамга карыйм. Бөтен төн буенча авыз эчемнән һаман бер сүзне тәкрарлыйм: «Мин идем – ул, өмиден өзгән юлчы, мин идем», – дим.

***

Әй, җырчы, кич якынлашып, синең чәчләреңне көмешләндерә бит.

Уйга калып нәрсә тыңлыйсың син, киләчәктәге тормышның тавышын түгелме?

Кич булды инде, – ди җырчы, – вакытның соңлыгына карамый, мин һаман тыңлыйм: ихтимал, соң булса да, авылдан берәү-берәү чакырыр әле мине.

Ихтимал, ике адашкан яшь йөрәк очрар миңа, ихтимал, янып торган ике пар күз авыр тынлыкны кисеп, үзләре урынына сүз сөйләтер өчен миннән җыр сорарлар дип, көтәм.

Әгәр дә мин, тормыш диңгезенең корабында утырып, үлем хакында уйга калсам, кем аларга дәртле җыр җырлап бирер соң?

Кичке йолдыз батып бара. Суның ары ягында ягылган ут сүнәр-сүнмәс ялтырый.

Ташландык йортның ишегалдында, эреп бара торган айның яктысында чайкалган үреләр.

Әгәр дә мин үлемнән качып өемә бикләнсәм, шул вакытта монда, төн уздырып, караңгылыкның серле авазларын тыңлар өчен, төнен үзенең йортын ташлап киткән бер-бер юлчы килә калса, кем аның колагына хәятның серләре хакында шыпыртлап сөйләр соң?

Чәчем көмешләнсә, ни булган?

Мин һаман да үзебезнең авылның иң яшьләре шикелле үк яшь, иң картлары күк үк карт бит.

Берәүгә садә вә сөйкемле елмаю бирелгән, берәүгә исә хәйләкәрләрчә кысылган күзләр бирелгән.

Берәүгә көн яктысында да чишмә күк ага торган яшьләр бирелгән, берәүгә төннәрдә генә коела торган яшерен яшьләр бирелгән.

Мин аларның һәммәсенә дә кирәк, шуның өчен миңа киләчәгем турысында уйларга вакыт да юк.

Чәчемә чал кергәнгә карама, мин аларның һәммәсенә яшьтәш, һәммәсенә бертигез кардәш бит.

***

Әй син, исереклектә тиңдәше булмаган, гакылсыз адәм?

Ишекләреңне шар ачык куеп бөтен халык алдында башыңны җүләрлеккә салганда;

Гакылыңа телеңне чыгарып күрсәтеп, бер төн эчендә янчыгыңда булган бар байлыгыңны җилгә очырганда;

Ташландык сукмаклардан йөреп, ярамас нәрсәләр белән үзеңне әвәрә кылганда;

Кафияне дә, мәгънәне дә аяк астына салып таптаганда;

Ишкәгеңне сындырып, җилкәнеңне давыл иркенә тапшырганда,

Мин синең белән, иптәш!

Барырмын, эчәрмен! Чәнчелеп китсен дөньясы!

Моңарчы, тынычлык сөя торган, гакыллы күршеләремнең мәҗлесендә бөтен төннәремне, көннәремне юкка уздырдым инде мин.

Күпне белгәнгә чәчләрем агарды; бертуктаусыз саклык белән як-ягыма карый-карый, күзләрем тонды инде минем.

Еллар буена мин төрле нәрсәләр җыеп, тау-тау өйдем.

Әйдә, таптыйк шуларны хәзер, өсләренә менеп биик тә җилгә очырыйк.

Чөнки белемнең иң югары ноктасы эчүдә генә икәнен беләм бит мин. Шулай булгач, чәнчелеп китсен дөньясы!

Әйдә, мине кимерә торган шөбһәләр югалсын да, мин өмидсезләнеп юлдан чыгыйм.

Әйдә, җүләрлек давылы минем көймәмне очырып алып китсен.

Бөтен дөнья эшчән, истигъдадлы, мөхтәрәм затлар белән тиң тулы бит.

Аларның кайберләре алдан баралар, кайберләре исә вәкарь белән генә арттан өстерәлеп киләләр.

Әйдә, юллары уң булсын, бәхетле булсыннар; тик мин генә дивана шикелле эшлексез, файдасыз булыйм.

Чөнки мин дөньядагы бөтен эшләрнең ахыры нигә тукталганын бик яхшы беләм бит – тик эчүгә генә инде, шулай булгач, чәнчелеп китсен дөньясы!

Ихтирамга мөстахикъ кеше булу хокукыннан ваз кичкәнлегемә ант итәм мин!

Үземнең галәмнәргә махсус вәкаремнән дә, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар булуы хакындагы мөлахазәләремнән дә мәңгегә аерылам инде мин.

Актык тамчы яшь белән бергә, күз яше тулган хәсрәтләр касәсен ватам да, җиләктәй кызыл шәрабның күбегенә шатлыгымны батырып, аның йоклаган рухын уятам мин.

Тәрбияле гражданлык мөһерен парча-парча кылам да мөкатдәс бер нәзер әйтәм: эчәргә.

Димәк, чәнчелеп китсен дөньясы!

***

Ни өчен син мине оялтырга теләгән төсле карыйсың?

Мин җырчы булып килмәдем бит синең каршыңа.

Мин болай гына, бер сәгатькә генә синең бакчаңның читәне янына туктаган идем.

Ни өчен инде син мине оялтырга теләгән төсле карыйсың?

Мин синең бакчаңнан гөлләр дә, җимешләр дә өзмәдем.

Мин тик әдәп белән генә юл кырыендагы агач астына ышыкланган идем. Шулай туктап ял итәргә һәрбер юлаучы хаклы бит соң?

Мин синең бакчаңнан гөлләр өзмәдем бит.

Мин арган идем. Яңгыр да тамчылый башлады.

Бөгелә-сыгыла торган бамбук камышлары арасында җил үкерергә тотынды.

Күл йөзендә, сугыш мәйданындагы качкан гаскәрләр күк, болытлар чабалар иде.

Юл озын булганга, минем аякларым арган иде шул.

Белмим, син мине кем дип белгәнсеңдер; белмим, кемне көткәнсеңдер.

Яшеннең уклары синең күзләреңне камаштырган иде.

Мине күрер дип уйламаган идем шул мин сине.

Көннең ахыры якынлашты: яңгыр да туктап китте.

Мин синең бакчаң янындагы агач астыннан китәм инде хәзер.

Караңгылык та төште бит; ишегеңне яп инде син: мин дә акрын гына юлыма китәрмен.

Көннең ахыры якынлашты бит инде...

***

Синең сөальле күз карашың моңлы. Ай югарыдан карап, диңгез төбен үлчәргә теләгән төсле, ул да минем зиһенемдәге ригаятьле[38].

Мин үземнең тормышымны бер каринәдән[39] икенче каринәгә кадәр синең күз алдыңа ачып салдым инде; һичбер әйбер яшермәдем, качырмадым. Шуның өчен дә шул син мине аңламыйсың.

Әгәр дә ул кыйммәтле җәүһәр булса, мин аны йөзгә ватып, муенса ясар идем дә синең муеныңа асар идем.

Әгәр дә ул кечкенә генә касә төсле чәчәк булса, мин аны сабыннан өзәр идем дә синең чәчеңне шуның белән бизәр идем.

Ләкин йөрәк кенә шул ул, минем сөеклем. Кырыйлары кайда да аның, төбе кайда?

Син аның падишаһы булсаң да, мәхлукатеңнең[40] чикләрен белмисең әле.

Әгәр дә ул күз ачып йомганчы уза торган ләззәт булса, елмаеп чәчәк атар иде дә, син аны аз вакытка булса да күреп калыр идең.

Әгәр дә ул хәсрәт булса, саф күз яше булып агар иде дә, сүзсез генә аның иң тирән серләре ачылыр иде.

Ләкин мәхәббәт шул ул, минем сөеклем.

Аның рәхәтләре дә, хәсрәтләре дә чиксез, байлыгы–ярлылыгы да ниһаясез шул.

Ул сиңа хәятың күк якын булса да, гомердә дә син аны аңлый алмассың.

[38] Ригаятьле – игътибарлы.
[39] Каринә – билгесез нәрсәне аңлауга ярдәм итә торган билге, «җеп очы».
[40] Мәхлүкат – җан иясе.

***

Кулың кулымда. Күзләребез бер-берсенә гарык булганнар[41]... Безнең йөрәкләребез хакындагы кыйсса шулай дип башлана.

Язгы төн ай яктысына күмелгән; һавада татлы кына исе аңкый; минем кураем ташланган килеш җирдә ята; синең дә үрә башлаган чәчәк кыршавың үрелеп бетмәгән килеш ыргытылган.

Безнең арабыздагы мәхәббәт эчендәге бер җыр шикелле садә.

Синең зәгъферан төсендәге бөркәнчегең минем күзләремне исертә.

Синең хәят биргән ясмин чәчәкләрең минем йөрәгем өстендә калтыранып тәсбих итәләр.

Бу бер уен: якынлашу, яңадан ераклашу, ачылу вә яңадан яшеренүдән гыйбарәт булган уен; елмаю, җиңелчә куркыну һәм файдасыз татлы көрәш.

Безнең арабыздагы мәхәббәт иң гади бер җыр шикелле садә.

Күз алдыбызда булган нәрсәләрдән башка һичбер сер дә юк безнең өчен; мәхаль[42] булган әйберләргә өметләнү дә юк; шуңар күрә якты өмидләр артына яшеренгән кара күләгәләр дә юк; караңгылык дөньясы үзе дә юк хәтта!

Безнең арабыздагы мәхәббәт иң гади бер җыр шикелле садә.

Сүзләрне онытып мәңге тынлык дөньясына талмыйбыз без; өмид итү мөмкин булмаган нәрсәләрне алу нияте белән кулларыбызны бушлыкка сузмыйбыз; тик үзебез биреп, үзебез ала торган әйберләр белән генә канәгатьләнәбез.

Газап шәрабы түгелмәсен өчен, тәләззез бабында актык чиккә килеп җитмибез без.

Безнең арабыздагы мәхәббәт иң гади бер җыр шикелле садә.

***

Син су буендагы сукмак буйлап, су тутырган кувшиныңны бөереңә терәгән килеш барадыр идең.

Ник соң син миңа таба әйләндең дә җилбердәгән ябынчаң аркылы күз салдың?

Караңгыда ялтырап киткән шул караш, кешене калтырандырып, су өсләрен шадраландырып күләгәле су буйларыннан исә торган җил күк, миңа килеп бәрелде.

Кичләрдә күз ачып йомганчы бер ачык тәрәзәдән кереп, икенчесеннән очып чыгып китә торган төн кошы төсле очып килде ул.

Син тау артларына яшеренгән йолдыз төсле каплангансың. Мин исә – йолдызга мохтаҗ булган юлаучы.

Ник кенә соң син су тутырган кувшиныңны бөереңә терәгән килеш су буендагы сукмак буйлап барганда туктадың да ябынчаң аркылы күз салдың инде миңа?

***

Ул һәр көнне килә дә, яңадан кире китә.

Дустым, син аның янына бар да чәчемә кадаган чәчәгемне бир аңар.

Әгәр дә ул синнән «кем җибәрде аны?» дип сораса, үтенәм синнән, аңар минем исемемне атый күрмә. Ул бит һәр көнне килә дә яңадан кайтып китә.

Ул әнә һәрвакыт шул агачның астында утырырга ярата.

Дустым, ул утырачак урынга яфраклар, чәчәкләр түшәп куйсана.

Аның күзләре кайгылы; шул күзләре минем дә йөрәгемне кайгыга батыралар.

Барыбер ул күңелендә ни булганын әйтмәс, ул бит бары килә дә яңадан кайтып китә.

---

[41] Гарык булган – баткан.
[42] Мәхаль – билгесез.

***

Синең өчен генә булган бөтен яшерен сүзләремне әйтергә хыял итәм мин. Ләкин кыймыйм, көләрсең дип куркам шул.

Шуның өчен дә мин үз-үземнән көлгән булып, мәзаж[43] арасында гына серләремне ачам сиңа.

Моның сәбәпле, никтер газап чиксәм дә, синең көлүеңнән куркып шулай итәргә мәҗбүр мин.

Синең өчен генә булган бөтен хак сүзләремне әйтергә хыял итәм мин. Ләкин кыймыйм, ышанмассың дип куркам шул.

Шуның өчен мин аларны ялган белән эретәм дә, уйлаганымның киресен сөйлим, җан газабы минем өчен һич шәйдә булмаган төсле кыланам.

Сүзсез генә синең янында булырга телим мин. Ләкин кыймыйм, йөрәгем мине тоттырыр дип куркам шул.

Шуның өчен дә мин синең алдыңда юк сүзләр сөйлим, бертуктаусыз такылдыйм.

Мин синнән ераклашырга телим. Ләкин кыймыйм, минем куркаклыгымны күрерсең дип куркам.

Шуның өчен дә мин башымны югары күтәрәм дә илтифатсыз гына син булган җиргә керәм.

***

Гашыйк мин сиңа, сөеклем. Кичерсана минем гыйшкымны.

Мин юлдан адашып, тозакка эләккән кош күк тотылганмын инде.

Йөрәгем калтыранып киткәч, аны каплап торган пәрдә ачылды да, ул ялангач калды. Аны үзеңнең кызгануың белән капла да, минем гыйшкымны кичер инде син.

Әгәр дә мине сөя алмасаң син, кичерсана минем хәсрәтемне.

Кырын карый күрмә миңа, мин үземнең почмагыма керермен дә шунда караңгыда тик кенә утырырмын.

Карама миңа, сөеклем, кичер минем хәсрәтемне.

Әгәр син мине сөясең икән, сөеклем, кичер минем шатлыгымны.

Бәхетемнең ташуы йөрәгемне агызып алып киткән чакта үз-үземне онытуымнан көлмә син.

Тәхеткә менеп, Аллаһы төсле гыйшкымның төн хакимияте коты белән мине идарә итә башлагач, мин сине рәхмәтемнән мәхрүм итмәм. Шулай да инде, сөеклем, син минем олуглыгым алдында башыңны и дә гафу ит минем шатлыгымны.

***

Әй минем якты хыялымның күгенә кичкырын
Алланып, алтынланып нурлы болыттай йөзүче!
Мин сине тик мәхәббәтемнең нурлары белән генә
Төрле-төрле төскә кертеп күп шәкелләр алдырам.
Әй минем очсыз-кырыйсыз төшләремнең хуҗасы,
Син миңа булдың бөтенләйгә, гомерлеккә миңа!
Йөзләреңдә нурлана бит гөл чәчәктәй алланып,
Утлы маилем яктысында алланып, ялкынланып,
Әй минем җырлар кырында соң уракны урганчы,
Кичке җырлар басуында соң башаклар җыючы!
Ник синең бу ал-кызыл иреннәреңдә мондый тәм!
Хәсрәтемнең тиң шәрабыннан алар татлы-ачы!
Әй минем сахра кеби киң төшләремнең хуҗасы,

[43] Мәҗаз – киная.

Син миңа булдың бөтенләйгә, гомерлеккә миңа!
Мин төшендем, дәртләремне нәкъ заман күк каплады.
Мәгъшукамның нурлы җәтмәсе белән чолгап кына
Мин сине тоттым, тозакка бит төшердем мин сине.
Әй минем син, нурлы рөэямда[44] икамә итүче[45],
Син миңа булдың бөтенләйгә, гомерлеккә миңа!

***

Күңелеңнән генә серләреңне эчеңдә яшереп саклама, дускаем! Миңа гына сер итеп кенә сөйлә син аларны.

Син елмайсаң, шыпыртын гына әйт миңа; әйткән сүзләреңне, хәтта, минем колакларым да ишетмәс, бары тик йөрәгем генә ишетер.

Төн караңгы; йорт тәфазыл[46]; кош оялары да йокыга талганнар.

Елмайган хәлдә, күз яшьләреңне тыеп, татлы оялу һәм йөрәк сызлавы белән син эч серләреңне чиш миңа, дустым!

***

«Кил безнең якка, яшь егет, әйт безгә дөресен – нидән синең күзләреңдәге бу шашкынлык?»

«Кормагәннән ясалган, ниндидер шәраб эчкән идем мин; шуннан минем күзләремдәге шашкынлык».

«Оят түгелме соң?»

«Булса ни! Берәү беләкле була. Берәү беркатлы, берәү сакчыл була. Көлеп карый торган күзләр була. Елап карый торган күзләр дә була. Ә минем күзләремдә исә бары тик шашкынлык».

«Яшь егет, ник син агач күләгәсендә хәрәкәтсез басып торасың?»

«Йөрәгем авыр булганга аякларым ардылар, шулай күләгәдә тик кенә басып торам мин».

«Оят түгелме соң?»

«Булса ни! Берәү алга китә, берәү артка кала, бер кеше иректе, кайберәүләр богауда, – минем исә, йөрәгем артык авыр булганга, аякларым чак кына күтәреп торалар аны».

***

Мин синең чәчәгеңне өздем, әй, дөнья!

Мин аны күкрәгемә кыскан идем, чәнечкесе йөрәгемә кадалды.

Көн үтеп караңгы булгач, чәчәк шиңгән, бары авырту гына калган иде.

Синең гаҗәеп хуш исле чәчәкләрең бик күп булыр әле, әй дөнья!

Ләкин минем чәчәкләр өзәр чагым узды инде. Караңгы төнемдә минем гөлчәчәгем юк, тик авырту гына калды инде.

***

Мин аның кулларын кулыма алып күкрәгемә басам; мин аның гүзәллеге белән кочагымны тутырырга телим: ал йөзендәге елмаюны үбеп алып китәргә, күзләрем белән кара күзләрен тәмам эчеп бетерергә телим.

Аһ, ләкин мөмкинме? Кем күкнең зәңгәрлеген аерып алырга кадыйр соң?

Мин аның гүзәллеген кулымда тотып калырга телим; ләкин ул ычкынып кача да минем кулымда тик тән генә кала. Алданган, арган хәлдә кире чигенәм.

Тик җан гына якын килә ала торган чәчәкләргә ничек итеп фанә тән кагыла алсын соң?

[44] Рөэя – төш.
[45] Икамә итү – яшәү.
[46] Тәфазыл – өстенрәк, уңайрак.

***

Чыраг тиң сүнде?

Җилдән саклар өчен ябынчам белән каплаган идем мин аны, шуңарга сүнде шул ул.

Чәчәк ник шиңде?

Комсыз мәхәббәт белән күкрәгемә кыскан идем мин аны, шуңарга шиңде шул ул.

Чишмә ник гөрләвеннән туктады?

Үземә хезмәт иттерер өчен бөяп куйган идем мин аны, шуңарга тынды шул ул.

Думбраның кылы ни өчен өзелде?

Көченнән тыш булган авазлар чыгарырга теләгән идем мин аннан, шуңарга өзелде шул ул.

***

Шашкан адәм бар нәрсәне алтынга әйләндерә торган ташны эзли иде.

Кояшка янган тәне шәүлә күк арык, тузгыган чәчләре тузанлы, иреннәре дә нәкъ йөрәге төсле йомылган: күзләре утлы кортлар күк ялтырый иде.

Очсыз-кырыйсыз диңгез аның каршында үкерә, дулкыннар бертуктаусыз диңгез төбендә яшерелгән хәзинәләр хакында сөйлиләр. Үзләренең сүзләрен аңлый алмаган наданнан көләләр иде.

Бәлки ул инде эзләгәнен табудан өмиден дә өзгәндер. Ләкин ял итү турысында уйлап та бакмый, һаман эзли дә эзли, чөнки аның бөтен тормышы инде шул эзләүдән генә гыйбарәт булып калган иде.

Шулай ук диңгез дә бит һәрвакыт кагылырга кодрәте җитмәгән нәрсәгә таба омтыла, кулларын күккә суза.

Шулай ук йолдызлар да бит, мәңгегә җитү мөмкин булмаган нәрсәгә ашкынып, бертуктаусыз дәверләр буенча әйләнәләр.

Нәкъ шулай ук буш диңгез буенда чәчләре тузанга манчылган дивана да бертуктаусыз гизә, бөтен нәрсәне алтынга әйләндерә торган ташны эзли иде.

Көннәрдән бер көнне малай аны күреп: «Карале, билгә бәйләгән бу алтын чылбырны кайдан алдың син?» – дип сорады.

Дивана сикереп китте, караса, чынлап та, билендәге тимер чылбыры алтынга әверелгән икән. Бу төш түгел, чын иде. Бары тик аның алтынга әйләнгәнен күрми генә калган икән ул.

Вә хашия[47] генә башын селекте: ничек соң ул, үзе дә белмичә, эзләгәнен тапкан?

Очраган бер ташны алып билендәге чылбырга тидереп, нәтиҗәсен карамастан ыргытып ташлауны ул гадәт иткән иде инде. Шулай итеп ул бөтен әйберен алтынга әверелдерә торган ташны табар-тапмас югалткан иде.

Мәгъриптә кояш баеп бара: һава алтынга манчылган.

Дивана адәм яңадан үзенең эзләре буенча кире кайтып эзләргә тотынды. Көче беткән, йөрәге сүнгән, тамырыннан кубып егылган агач күк билен бөкрәйткән килеш, үзе һаман эзли дә эзли иде.

*Басмага* **Дания ЗАҺИДУЛЛИНА** *әзерләде***.**

[47] Вә хашия – кырыйга.

# МӘХКӘМӘИ ШӘРГЫЯНЕҢ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

## Яңа оешманың татарча исеме турында

1788 елның 22 сентябрендә Уфада дини идарә ачу турындагы Указда яңа институт «Духовное собрание магометанского закона» дип атала. Империя хакимияте Таврия өлкәсенә кергән кырым татарлары һәм нугайлар өчен дини идарә төзү турында 1794 елны фикер алыша башлагач (*Мусульманское духовенство Таврической губернии в конце XIX века: рапорт В.В. Вашкевича: сборник документов / Сост., авт. предисл., прим. и сокр., сост. указ. И.К.Загидуллин. Казань, 2016. С.33*), аларны аеру мәсьәләсе атамаларына губерна исеме кертү юлы белән хәл ителә. 1796 ел Указында тиздән ачылачак дип тәкрарланган бу яңа институт соңарып, 1831 елны гына «Таврическое магометанское духовное правление» исеме белән оештырыла. «Духовное собрание магометанского закона» исеме «Оренбургское магометанское духовное собрание» дип үзгәртелә, ә аның рәисен «Оренбург мөфтие» дип атый башлыйлар. «Полное собрание законов Российской империи» исемле кануннар җыентыгында бу хакта махсус Указ очратмадык. Димәк, әлеге гамәл дини идарә буйсынган үзәк империя структурасы кысаларында башкарылган. Рәсми исем 1917 елга – рус самодержавиесе җимерелгәнчегә кадәр саклана.

Шулай итеп, губерна исеменә бәйләп «Оренбургское духовное собрание магометанского закона» дип язасы урынга, чынлыкта оешмага өр-яңа исем бирелә: «Оренбургское магометанское духовное собрание». Турыдан-туры татарчага тәрҗемә итсәк: «Оренбург мөселман дини / рухани җыены».

Эш шунда: беренче исем яңа оешманы төзү турындагы Нигезләмәдә беркетелгән пунктны күздә тотып язылган. Анда яңа оешманың Уфа наместничествосы идарәсе буйсынуында торуы, хокукый статусы урта дәрәҗәдәге суд оешмаларыныкына тиң булуы хакында язылган *(Материалы по истории Башкирии. Том V. / Сост. Ф.Демидова. Под ред. С.М.Васильева. М., 1960. С.563, 2 нче маддә)*. «Духовное собрание магометанского закона» исеме яңа оешманың коллегиаль булганын һәм шәригать – ислам кануннары – буенча эшләячәген белдерә.

Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов, Россия чиновнигы буларак, югарыда аталган Нигезләмәдә язылган урта дәрәҗәдәге суд оешмасы дигәнне күздә тотып, дини идарәне тәүге тапкыр татарча «Мәхкәмәи шәргыя» (шәригать суды) дип атаган. Соңрак русча рәсми исеменә «Оренбургское» сүзе (губерна исеме) өстәлгәч, «Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя (Орынбургыя)» буларак яки элеккечә кыскартып язылган.

XIX йөз – XX гасыр башында русча текстларда һәм рәсми кәгазьләрдә «Оренбургское магометанское духовное собрание» дип язылган. Исем үзгәрү белән яңа дини оешма атамасында мәхк+әмә мәгънәсе калмавы татар тарихчыларын кыен хәлгә куйган. Шул сәбәпле оешма төрле исемнәр белән атап йөртелгән: русча вариантын кулланудан һәм исемен русчадан турыдан-туры тәрҗемә кылудан тыш, аңа яңа исемнәргә кадәр кушылган.

Ш.Мәрҗани «Духовное собрание магометанского закона» исемен «Мөхәммәд дине җәмгыяте идарәсе» дип тәрҗемә иткән. Соңрак чорга карата «Ислам дине җәмгыяте»

дигән вариант әйткән *(Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан, 1989. 209 б.),* ләкин даими рәвештә аңа карата «*Дини идарә*» атамасын кулланган *(Шунда ук, 210, 211, 213, 217 б.).*

Р.Фәхретдин төзегән һәм Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан расланган «Сборник циркуляров и иных руководящих распоряжений по округу Оренбургского магометанского духовного собрания. 1841–1901 гг.» (Уфа, 1902) җыентыгының татарча өлешендә аның исеме «Җәмгыяте шәргыя Орынбургия» дип аталган. 1908–1910, 1916-1917 елларда басылган рәсми матбагасы исеме «Мәгълүмате Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургия» дип куелган. Журналның рәсми бүлегендә исә төрле вариантлар очрый: «Духовный собрание», «Собрание», «Җәмгыяте шәргыя Оренбургия» (*Мәгълүмате Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургия. 1908. №6. 104 б.)* һ.б. Ризаэддин казый 1898 елда бастырган «Танзимат» китабының тышына, шулай ук, «Мәхкәмәи шәргыя Орынбургиә» дип куйган.

Р.Фәхретдин «*Диния нәзарәте*» дигән исемне тәүге тапкыр үзенең мәшһүр биобиблиографик «Асар» хезмәтенең 1901 елда басылган беренче том, икенче өлешендә куллана *(Фәхретдин Ризаэддин. Асар. Беренче том. Казан, 2006. 51 б.)*. Ул 1905 елда, казый булган чакта язган «Тәрҗемәи хәлем»дә исә берәр тапкыр «Оренбург Җәмгыяте исламия мәхкамәсе» һәм «Оренбург Дини Идарәсе», «Җәмгыяте шәргыя» *(Фәхретдин Ризаэтдин. Тәрҗемәи хәлем // Фәхретдин Ризаэддин: Фәнни-биографик җыентык – Ризаэддин Фахретдинов: Научно-биографический сборник. Казан, 1999. 29, 30 б.),* мәгънәдәш сүзләр буларак, ике тапкыр «Оренбург Дине мөхәммәди мәхкамәсе» *(Шунда ук. 30, 31 б.)*, шулай ук берәр тапкыр «Мәхкамә» һәм «Нәзарәт» дигән вариантларны ала *(Шунда ук. 37 б.)*. 1905 елны үзе язган дини идарә уставы проектында дини идарәне «Мәхкәмәи исламия» дип исемли һәм текстта мәгънәдәш сүз сыйфатында «Собрание» сүзен файдалана. Шушы кәгазь буенча төзелеп, Уфа корылтае тарафыннан кабул ителгән һәм русчага тәрҗемә ителгән документтагы атамасын Муса Бигиев татарчага «Баш идарә» һәм «Рухани идарә» дип тәрҗемә итә (*Җарулла Муса. Исляхат әсаслары. Пг., 1917. 113, 114, 117* б.*)*.

Фәхретдин 1908 елны басылган «Мәнасыйбы диния» (Дини вазифалар) китабында «Собрание» сүзен куш җәяләр эченә алып, «Идарәи шәргыя» *(Фәхретдин Ризаэддин. Мәнасыйбы диния // Фәхреддин Ризаэддин. Дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан, 2011. 271 б.)* дип атый, икенче бер урында «Шәргыя исламия Оренбургия» дип яза *(Шунда ук. 275 б.)*.

Г.-Р.Ибраһим 1895 елны «Чулпан йолдызы»нда «Духовное собрание магометанского закона»ны «Рухани шәригате мөхәммәдия җәмгыяте» дип, кыскартып, «Җәмгыяте исламия мәхкәмәсе» *(Ибраһим Габдерәшит. Чулпан йолдызы // Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык /төз. М.Госманов, Ф.Галимуллин. Казан, 2011. 44, 58 б.)* рәвешендә яза. Аның исемен, нигездә, «Мәхкәмәи шәргыя» яки «Мәхкәмә» (Духовный собрание) (*Шунда ук. 45 б.* ) дип атаса да, урыны-урыны белән «Собрание», «Собрание Мәхкәмәсе», «Духовный собрание» *(Шунда ук. 45, 50, 56, 57, 64, 65, 66, 67 бб.)* вариантларын да куллана. 1905 елны төзегән Дини идарә уставы проектында «Мәхкәмәи шәргыя» терминын өстен күрә *(Загидуллин И.К. Уфимский курултай 1905 года. Казань, 2018. С. 272)*, 1906 елны язылган «Автономия яки идарәи мохтарият» исемле китабында, күрәсең, «Асар»га ияреп, «Диния нәзарәте» сүзен куллана *(Галимуллин Ф. XX гасыр башында татар милли хәрәкәте һәм Габдерәшит Ибраһим «Автономия»се // Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төз. М.Госманов, Ф.Галимуллин. Казан, 2011. 301-302 б.)*.

Хәзерге тарихи әдәбиятта һәм вакытлы матбугатта, шулай ук Р.Фәхретдин һәм Ш.Мәрҗани хезмәтләре йогынтысында «Дини идарә», «Диния нәзарәте» кебек вариантлар кулланылышта йөри. Без бу институтны, нигездә, «Мәхкәмәи шәргыя» дип атыйбыз.

## Яңа оешма күзәтүендәге дини институтлар саны

Дини оешма турында Нигезләмә Екатерина II тарафыннан расланмаса да, чынлыкта аның пунктлары кулланылган. Моны тормыш үзе таләп иткән.

Нигезләмәдә әйтелгән очраклар буенча мөселманнар рус чиновниклары янына ярдәм яки аңлатма сорап килгәндә, алар Оренбург мөфтиенә «төртеп» күрсәткәннәр.

Мәхкәмәи шәргыянең беренче еллардагы эшчәнлеге авылларда рухани хезмәтен башкаручы абызларга имтихан уздырып, аларның статусларын рәсмиләштерүдән гыйбарәт була.

1792 елдан биредә эшләүче мөселманнарга ислам бәйрәме көннәрендә ял итү хокукы бирелә. 1893 елны Мәхкәмәи шәргыя әгъзалары Казан губернасы руханилары арасыннан өч елга сайлана дип төгәлләштерелә.

1797 елны Уфа наместничествосы Оренбург губернасы итеп үзгәртелү сәбәпле, Мәхкәмәи шәргыя, башка дәүләт оешмалары белән бергә, Оренбургка күченә, 1802 елның ахырында –1803 елның башында кире Уфага кайта (*Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII-XIX вв. Уфа, 1996. С. 25)*.

Мәхкәмәи шәргыя коллегиаль оешма булып, аның утырышларында кимендә өч кеше катнашканда кабул ителгән карар гына канун көче алган. Муллалар һәм мөселманнардан хатлар һәм гаризалар туган телләрендә язылган, тикшерелгән мәсьәләләр һәм карарлар Мәхкәмәи шәргыя журналына русча теркәлгән, җаваплар шулай ук русча җибәрелгән. 1906 елдан башлап, мөфти кушуы буенча, журналлар алып бару тукталган, алар урынына кыска резолюцияләр язу тәртибе кертелгән.

Мәхәллә руханиларына инструкцияләр исә, муллаларның русча белмәүләрен яки начар белүләрен исәпкә алып, русча һәм татарча адресланган.

Административ институт буларак, 1796 елга кадәр аның өстеннән күзәтү Уфа наместничество идарәсе, 1796-1865 елларда Оренбург губерна идарәсе карамагында булып, Оренбург губернасыннан 1865 елда Уфа губернасы аерылып чыккач, Уфа губерна идарәсе хозурына күчкән. Шулай ук, 1865–1881 елларда, Оренбург генерал-губернаторы Н.А.Крыжановский күзәтчелек иткән.

Дини институт буларак, аны империя үзәге күзәткән. 1803 елдан аны Синод обер-прокуроры кенәз А.И. Голицын күз уңында тоткан. 1810 елдан Мәхкәмәи шәргыя Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Чит диннәр эшләре буенча баш идарәгә буйсындырылган. Баш идарә, үз чиратында, 1817 елны яңа оешкан Дин һәм мәгариф эшләре министрлыгы составына кертелә. 1824–1831 елларда мөстәкыйль идарә булып яшәгәннән соң, 1832 елдан башлап, Эчке эшләр министрлыгы составында Чит диннәр эшләре департаменты кебек эшли башлый. Департамент беркадәр вакыт (1880 елның 6 августыннан 1881 елның 16 мартына кадәр) мөстәкыйль структура булып торганнан соң, кабат Эчке эшләр министрлыгына буйсындырыла *(Азаматов Д.Д. Күрс. хезмәт. 30, 31 б.*).

Рәсми рәвештә Мәхкәмәи шәргыя округына, Таврия өлкәсеннән кала, барлык җирләр дә керә дип тәгаенләнә. 1788 елдан соң Россия үзенә кушкан мөселман халыклары яшәгән төбәкләр моңа кертелмәгән. 1867 елны элекке Кече, Урта һәм Олы җөзләргә тупланган казакълар аның карамагыннан алынган, ә Әстерхан губернасы җирләрендә яшәгән Бөкәй Урдасы казакъларының дини планда аңа буйсынуы сакланган. Формаль рәвештә аның күзәтүендә дип Кубань, Терск өлкәләре, Ставрополь губернасы саналган. Димәк, яңа институт хәзерге татар һәм башкортларның мәхәллә руханиларын күзәткән *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007. С.6)*.

Мәхкәмәи шәргыянең эш масштабын аның карамагында булган дини институтлар һәм мөселманнар саны аша күзалларга мөмкин. 1833 елны Мәхкәмәи шәргыя карамагында 3133 мәчет һәм гыйбадәт йорты, 68 ахун, 100 хатыйб, 1792 имам, 1164

мулла, 343 мөхтәсиб һәм 439 мөдәррис булган (*Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007. С.143)*. Алар халыкка аң-белем, дини һәм әхлак тәрбиясе биргәннәр, укыту системасын үз кулларында тотканнар.

1868 елны Идел, Урал, Себер һәм Үзәк Россиядә һәммәсе 2,1 млн мөселман, 6,5 мең рухани һәм 4 меңнән артык мәхәллә теркәлә. 1889 елга мәхәлләләр саны 4254кә җитә. Руханилар арасында 65 ахун, 2734 хатыйб, 2621 имам һәм мөдәррис, 1783 мөәзин исәпләнә *(Загидуллин И.К. Татарское национальное движение в 1860–1905 гг.. Казань, 2014. С.39)*.

XIX гасырның икенче яртысы – XX йөз башында хакимият тарафыннан яки махсус ташламалар биреп, хакимиятнең изүеннән качып яки җир җитмәүдән, урбанизация, модернизация йогынтысында ерак төбәкләргә үзләре яисә Столыпин аграр реформасы кысаларында күченү, шулай ук хәрби хезмәтне тәмамлагач, татар солдатларының ерак шәһәрләрдә яшәп калып, анда мәхәлләләр теркәүләр – болар барысы да Мәхкәмәи шәргыя округын киңәюгә алып барган. Аның округына кермәгән торак пунктларында оешкан мәхәлләләрнең муллалары да имтихан бирергә Уфага килгәннәр, ата-бабалары кебек Мәхкәмәи шәргыягә буйсынырга теләк белдергәннәр. Әйтик, Дала губерналарындагы шәһәр татар җәмгыятьләре яки Көнчыгыш губерналарның Варшава, Киев, Харьков кебек калаларында оешкан мәхәлләләр барысы да аерым «нокталар» рәвешендә (бу төбәкләр, шулай ук литва татарлары, Таврия мөселман рухани идарәсе округына кергән. – *И.З.*) Мәхкәмәи шәргыя күзәтүендә яшәгәннәр.

Шул рәвешле, 1911 елга Мәхкәмәи шәргыя округына Россиянең 84 губернасы, 5 өлкәсе, 6 градоначальник институты булган шәһәрләр кергән; 4572276 мөселман 5771 рәсми теркәлгән мәхәллә кысаларында дини тормышларын оештырган. Алар белән 3946 имам-хатыйб, 3691 имам, 691 мулла, 3885 мөәзин җитәкчелек иткән (*Фархшатов М. Мусульманское духовенство // Ислам на территории бывшей Российской империи: энциклопедический словарь / сост. и отв. ред. С. М. Прозоров. М., 2006. Т. 1. С. 288, 289, 292).*

## Мәхкәмәи шәргыя – дини-мәдәни автономия үзәге

Дәүләт оешмасы буларак ачылган Мәхкәмәи шәргыя акрынлап чын мәгънәсендә Идел, Урал һәм Көнбатыш Себер төбәге дин әһелләренең мәнфәгатьләрен хакимият алдында яклаучы институтка әверелә. Оешкач та, ул мөселманча тормыш рәвешенә бәйле мәсьәләләр белән шөгыльләнә башлый, аларны рәсми рәвештә теркәү акрынлап үзәк «фатихасы» белән башкарыла: теократик хөкүмәт, күбәеп барган мәчетләр, дин әһелләре, мәктәпләр, илдәге башка оешмалар өстеннән урнаштырылган контрольне Мәхкәмәи шәргыя аша үзәкләштерергә омтылып, аның хокукларын киңәйтә. Әйтик, 1801 елдан башлап, губерна идарәләре яңа мәчет төзергә яисә яңа мәхәллә теркәргә рөхсәт алу кебек эшләрне Мәхкәмәи шәргыя белән килештереп башкару тәртибе урнаша, 1811 елдан муллалар гаилә мөнәсәбәтләренә караган мәсьәләләрне шәригать буенча тикшерү һәм карар чыгару хокукы ала. Хакимият таләбе белән, православие руханиларының приходтагы кешеләрнең гражданлык актларын язып бару вазифасы муллаларга да йөкләнә. 1829 елдан башлап, мулла 50 тиен түләп, икешәр данә типография ысулы белән бастырылган метрикә дәфтәрләре алган һәм аларга мәхәлләдәге туган, үлгән, никахлашкан, аерылышкан кешеләрне теркәгән. Ел тәмамлангач, бу документның бер данәсе Мәхкәмәи шәргыя архивына җибәрелгән. Нәтиҗәдә Мәхкәмәи шәргыя мөселманнарның санын теркәүче статистика оешмасы, аларның гражданлык актлары саклана торган архив һәм гаилә хәле, туган елы һ.б. шуның ише сораулар белән мөрәҗәгать итүчеләргә белешмә бирә торган нотариат оешмасы буларак та таныла.

1826 һәм 1836 елгы Указлар нигезендә мөселманнарның мирасын бүлү шәригать

кануннары буенча тормышка ашырылуын империя кануннары таный башлый, һәм аларны Мәхкәмәи шәргыя күзәтеп тора, дөресрәге, шикаять килсә, тикшерү оештыра.

1830 елны муллалар карамагына балаларның әти-әниләренә буйсынмау очракларын тикшерү дә һәм аларны вәгазьләү хокукы да бирелгән. Бу мәсьәләләр буенча килгән шикаятьләрне дә Дини идарә тикшергән һәм карарлар чыгарган.

Бер үк вакытта хөкүмәт, Мәхкәмәи шәргыя, мөфти белән килештереп, шәригатькә туры килми торган дәүләт кануннарын да кертә. Әйтик, 1830 елны үлгән кешеләрне өч көн үткәч кенә җирләү турында, 1835 елны гаилә корырга теләүче ир-атларның яшен – 18, кызларныкын 16 яшькә кадәр арттыру канун көчен ала *(Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в период правления Николая I // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.6. Казань, 2013. С. 465-473)*. Шуңа күрә Мәхкәмәи шәргыя үз эшчәнлеген шәригать кануннарын дәүләт рөхсәт иткән кадәр кулланып һәм, алардан тыш, дәүләт кануннарына нигезләнеп кора.

Мәхкәмәи шәргыя дип аталса да, чынлыкта ул, мөселман илләрендәге шәригать мәхкәмәләре кебек, тикшерүгә шаһитларны, гаепләнүчене һәм зыян күрүчене чакырып, карар чыгару кебек эшләр башкармый, фәкать шикаятьләр, гаризалар кабул итә, аларны, урында өйрәнү максатында, төбәктәге берәр ахунга яки гыйлемле һәм гаделлеге белән танылган имамга юллап, үзе читтән күзәтеп тора, бюрократик оешма буларак, күп очракларда килгән хатларны, карар кабул итү өчен, губерна идарәсенә адреслый һәм тикшерү нәтиҗәсен соратып ала (*Гарипова Р. Р. Политика брака и развода у мусульман Волго-Уральского региона в имперской России конца XIX – начала XX века // Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья: сб. ст. Казань, 2011. Вып. 2. С. 174*). Шунысын да әйтеп узу мөһим: Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыя округына кергән төбәкләрдә мөселманнарга карата шәригать буенча җәза куллану тыела, җинаятьчеләргә җәза билгеләү – дәүләт мәхкәмәләре, ә вак канун бозулар волость идарәсе мәхкәмәсе карамагына бирелә.

Шулай итеп, XIX гасырның беренче яртысында, бигрәк тә дәүләт белән император Николай I идарә иткән дәвердә, хөкүмәт барлык оешмаларның да вәкаләтләрен, вазифаларын төгәлләштерә, төрле инструкцияләр кабул итә, Мәхкәмәи шәргыяның хокуклары ачыклана, ә 1857 елны, ниһаять, беренче уставы раслана. Уставта аның вәкаләтләре бик кыска языла.

Хөкүмәт чиновниклары 1910 елда Мәхкәмәи шәргыянең кәгазьләрен тикшереп, аның түбәндәге вазифаларын саныйлар:

• рухани дәрәҗәсе бирү өчен имтихан алу;
• руханиларның эшчәнлеген күзәтү һәм тәртип бозучыларга карата җәза чарасы куллану;
• мәчетләр төзү, ремонтлау, руханиларны билгеләү мәсьәләләрендә катнашу;
• метрикә кенәгәләрен алып баруны оештыру, күзәтү;

руханилар өстеннән түбәндәге мәсьәләләр буенча язылган шикаятьләрне тикшерү:

а) гыйбадәт кылу, дини ритуалларны үтәү тәртибен бозу;

б) никах һәм аерылышу актларын башкару кагыйдәләрен төгәл үтәмәү;

в) хосусый милекне яки мирас итеп бирелгән милекне бүлгәндә эшләнгән хилафлыклар;

г) балаларның әти-әниләренә буйсынмавы мәсьәләләре буенча карарларда җитешсезлекләр;

д) гаилә тугрылыгын бозган очракта кабул ителгән карарлар;

е) метрикә кенәгәләре өчен, мөселман никах салымы һәм башка максатларда җыелган акчаларны тиешенчә сакламау;

ж) мәчет һәм уку йортлары милке белән идарә итүдә кимчелекләр;

з) мөселманлыкка чыккан кешеләрне үз мәхәлләсенә алу очраклары;

и) мөселманнарны бер мәхәлләдән икенчесенә күчерү *(Загидуллин И.К. Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. С.44-45)*.

1874 елны Идел һәм Урал төбәкләрендә мәктәп-мәдрәсәләр Халык мәгарифе карамагына тапшырылгач, мөселман уку йортларын күзәтү Мәхкәмәи шәргыя карамагыннан алына.

1889 елны Мәхкәмәи шәргыягә басылачак дини китапларга экспертиза уздыру хокукы бирелә.

Кайбер дәүләт органнары мөрәҗәгате нигезендә Мәхкәмәи шәргыя Мәкәрҗә (1817 елдан Түбән Новгород), Эрбет һ.б. төбәк ярминкәләренә – вакытлы муллалар, мәчетләре булса, вакытлы мөәзин дә билгеләгән. 1870 елдан соң мөселманнар укый торган гимназияләрдә ислам дине нигезләрен өйрәтүче рухани да мөфти белән килештереп эшкә билгеләнгән. Коры җир гаскәрләрендә, Балтыйк һәм Кара диңгез флотларында, 1908 елдан башлап, биш хәрби округта берәр хәрби мулла, 1904-1905 еллардагы Рус-япон сугышы, 1914 елдан Беренче бөтендөнья сугышы вакытында хәрби муллалар да Мәхкәмәи шәргыя тарафыннан расланган.

Мәхкәмәи шәргыя император, аның хатыны һәм тәхет варисының туган һәм аларның исемнәренә тәңгәл килгән христиан изгеләре көннәрендә, шулай ук император тәхеткә утырган көнне, Романовлар хөрмәтенә мәҗбүри җәмәгать намазлары уздыруны күзәткән, хакимият бу чараны уздырмаган мулланы эшеннән алган; шул рәвешле дини-патриотик тәрбия алып барылган. Үзәк яки төбәк хакимият вәкилләре мөрәҗәгать иткәндә, идарә аларның карарларын татарчага тәрҗемә итеп руханиларга һәм мәхәллә халкына җиткерүне оештырган. Йогышлы авыруларга каршы көрәш кагыйдәләрен тәрҗемә иттереп тарату, аларны үтәүне тәэмин итүне муллаларга йөкләү, ил күләмендә төрле иганәчелек чараларына мөселманнарны тарту кебек эшләр белән дә шөгыльләнгәннәр. Бу чаралар барысы, ахыр чиктә, төрки телле һәм гореф-гадәтле, мөселман менталитетлы татар һәм башкортларны рус идарә системасына кертү, аларда императорга һәм Ватанга хөрмәт, кануннарга буйсыну хисе тәрбияләү өчен оештырылган.

Мөфти кәнәфиенә күпчелеге хөкүмәт тәкъдиме белән утырган һәм тормышын яңа вазифага багышлап, милләт гаме белән яши башлаган шәхесләр олы тормыш сынавын узганнар. Бер яктан, империя структуралары, икенче яктан, традицион мөселман җәмгыяте арасында мөнәсәбәтләрне көйләүче, хакимият кушканны тормышка ашыручы да булып, дин кардәшләренең көндәлек тормышында хокукый планда тотрыклылыкны тәэмин итү, мәгарифне, мәдәниятне үстерү өчен шартлар тудыру юнәлешендә мөфтиләр Мөхәммәтҗан Хөсәенов (1788–1824), Габдессәлам Габдерәхимов (1825–1840), Габделвахит Сөләйманов (1840–1862), Сәлимгәрәй Тәфкилев (1865–1885), Мөхәммәдьяр Солтанов (1886–1915), Мөхәммәтсафа Баязитов (1915–1917) булдыра алган кадәр хезмәт куйганнар.

Шулай итеп, 1789 елдан башлап, Россия империясе хакимиятенең мөселман руханилары белән хезмәттәшлек итүе билгеле дәрәҗәдә системалы төс алган: Идел-Урал төбәгендә, Көнбатыш Себердә һәм үзәк губерналарда Россия кануннары кысаларында мөселманнарның дини һәм мәдәни ихтыяҗлары канәгатьләндергән автономия формалаша. Бу автономия хакимият күзәтүендә, рәисе император тарафыннан билгеләнгән, өч әгъзасы (казыйлар) эчке эшләр министры тарафыннан расланган дәүләт оешмасы кул астында рәсмиләшә.

Инде билгеләп үтелгәнчә, Мәхкәмәи шәргыя акрынлап руханиларны, дини ритуаллар башкаруны, гаилә мөнәсәбәтләрен күзәтүне, нотариат, мирас бүлү, мәхкамә вәкаләтләрен үзендә туплау хисабына ныгый. 1857 елны дәүләт тарафыннан Мәхкәмәи шәргыянең Уставын раслау Россия империясендә татарларның һәм башкортларның уртак дини-мәдәни автономиясен тануга тиң вакыйга була.

Мәхкәмәи шәргыянең йогынтысы арту берничә объектив фактор белән аңлатыла.

Беренчедән, татар дворяннары, нигездә, Уфа губернасында тупланганлыктан, аларның земство оешмалары аркылы мөселманнарга йогынтысы шушы төбәк белән чикләнә. Күчемсез милек цензы булу һәм русча камил белү таләп ителгәнлектән, башка

губерналардагы земстволарда татар сәүдәгәрләре дә, крестьяннары да, гласныйлар буларак, актив роль уйный алмаганнар.

Икенчедән, Идел-Урал төбәгендә һәм Көнбатыш Себердә көн күргән мөселманнарның башка йогынты ясарлык модерн оешмалары булмый. Билгеле булганча, татарлар 1905 елдан гына газеталар һәм журналлар бастыру хокукын ала, шул ук елны Россиядә легаль партияләр оештырырга рөхсәт бирелә. Шәһәрләрдә яшәүчеләренең саннары аз булу сәбәпле, мөселман иганәчелек һәм мәдәни-мәгърифәтчел иҗтимагый оешмаларының саны зур булмаган.

Өченчедән, татарлар һәм башкортлар яшәгән җирләр илнең аграр төбәкләре булып, күпчелек мөселманнар консерватив рухлы һәм һәр яңалыкка шикләнеп караган йомык игенче җәмгыятьләрендә яшәгәннәр. Авыл мәхәлләләрендә иң зур йогынтыга Мәхкәмәи шәргыядә имтихан биреп, муллалыкка билгеләнү хокукы алган руханилар ия булган. Алар, XIX гасырның соңгы өч дистә елында дәүләт үзләренең хокукларын кыса башлагач, бердәнбер яклаучылары Мәхкәмәи шәргыя икәнен аңлаганнар һәм дини идарәгә карата карашларын уңай якка үзгәрткәннәр. Чыннан да Мәхкәмәи шәргыя еш гына, дини-мәдәни автономиянең җитәкчесе буларак, руханиларның һәм мөселманнарның дини хокукларын яклап империя структуралары белән язышa һәм кайбер уңышларга да ирешә.

Р.Фәхретдин дә Мәхкәмәи шәргыя оешу мөселманнар өчен файдалы гамәл иде, аның ислам институтларына тәэсире яхшы булып, дин тоту өлкәсендә «күп иркенлек мәйдан алып, мәктәп вә мәдрәсәләр күбәйгән», дип белдерә (*Фәхреддин Ризаэтдин. Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре //Фәхретдин Ризаэддин. Дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма хезмәтләр. Казан, 2011. 177-178 б.*).

Мөселман руханиларының үз-үзләрен тотышларын һәм мөселман җәмгыятьләренең дини тормышын күзәтү өчен оештырылган дәүләт оешмасының шундый яңа сыйфатта чыгыш ясый башлавы кайбер чиновникларны борчуга сала. Беренче булып Мәхкәмәи шәргыяне дәүләт өчен файдасыз институт дип хөкүмәткә 1870 елны Оренбург генерал-губернаторы Н.А.Крыжановский яза *(Россия дәүләт тарих архивы, 821 ф., 8 тасв., 611 с.б., 45 кгз. арты, 48-48 кгз. арты).*

1872 елны Уфа губернаторы С.П.Ушаков аны ябу муллаларны һәм мөселманнарны берләштереп торуны туктату өчен кирәк дип ассызыклый (*Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. Ч. 1. Аграрный вопрос и крестьянское движение 50 – 70-х годов XIX в. М.; Л., 1936.* С. 212).


Империя хөкүмәте мондый кискен тәкъдимнәрне кабул итми, чөнки мөселманнар Россия дәүләтенә карата лояль, хәерхаһ позициядә булалар. Мондый уңай мөнәсәбәт, беренче чиратта, Мәхкәмәи шәргыянең тырыш һәм максатчан эшчәнлеге нәтиҗәсе дип санала.

Модернизация чорында Россиядә күпсанлы социаль тетрәнүләр күзәтелә. 1860–1870 елларда хөкүмәтнең либерал реформалары, хакимияттәге кризислар, Рус-япон сугышында хурлыклы җиңелү, 1905–1907 елгы инкыйлаб һәм илдәге демократик үзгәрешләр, Дәүләт Думасы эшли башлау һәм реакцион сәясәт еллары мөселман җәмгыятенә дә зур йогынты ясаган, мәгарифтә, китап бастыруда, иҗтимагый хәрәкәттә һ.б. өлкәләрдә тирән үзгәрешләргә сәбәп булган. Бу вакыйгалардан Мәхкәмәи шәргыя дә читтә кала алмаган, яңалыклар аңа да тәэсир иткән. Нәкъ шушы елларда Мәхкәмәи шәргыянең җәдиди рухлы рәисе һәм казыйлары төрле дәрәҗәдәге әһәмиятле мәсьәләләргә багышлаган иҗтимагый чаралар уздырып, җәдитчелек хәрәкәте көчәюгә өлеш керткәннәр.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

*Әхмәт Ерикәйнең тууына – 120 ел*

# ТАТАР ҖЫРЫ МЕНӘ ШУНДЫЙ БУЛА...



Татар әдәбиятының иң үзенчәлекле шагыйрьләреннән берсе Әхмәт Ерикәйнең (Әхмәт Фазыл улы Ерикиев) исемен ишетүгә күңелдә иң әүвәл аның сүзләренә язылган җырлар яңара. Шигырьләрнең ритмик төзелеше, эчке аһәңе үзеннән-үзе музыка сорап тора. Татарстан радиосы фондында саклана торган язмаларны барлап карасаң, шул чорда бер генә композитор да аның әсәрләренә мөрәҗәгать итмичә калмагандыр кебек тоела. Гомумән, сугыштан соңгы еллардан башлап, бүгенге көнебезгә кадәр бер генә концертны да Әхмәт Ерикәй җырларыннан башка күз алдына китереп булмый. «Шауласын, гөрләсен безнең җыр», «Комсомолка Гөлсара», «Гармун» (Җ.Фәйзи музыкасы), «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Тагын килер язлар», «Тын бакчада», «Туган ил» (М.Мозаффаров музыкасы), «Лирик җыр» (Ф.Яруллин музыкасы), «Батыр егеткә», «Айлы төн» (З.Хәбибуллин музыкасы), «Кәккүк» (С.Габәши музыкасы) «Бибисара» (С.Сәйдәшев музыкасы), халык көйләренә язылган «Алсу», «Минзәлә» кебек җырлар әле дә өлкәнрәк буын укучыларыбызның күңел түрендәдер.

Ә инде сугыштан соңгы унъеллыклар дәвамында музыкага салынган «Сиңа» (З.Хәбибуллин музыкасы), «Сипкелле диләр мине» (М.Мозаффаров музыкасы), «Көтәм сине» (С.Садыйкова музыкасы), «Бик күрәсем килә» (Р.Яхин музыкасы), «Онытырга мөмкин түгел» (Х.Вәлиуллин музыкасы), «Сиреньнәр хуш исләр тарата» (Н.Җиһанов музыкасы), «Кил, иркәм, гармун уйнарга», «Күңелгә шулай тоела» (Ә.Фәттах музыкасы), «Идел буе каеннары» (И.Шакиров музыкасы), «Сөясеңме дип ник сорыйсың», «Эзләдем, бәгърем, сине» (С.Хәбибуллин музыкасы), «Яшьлегемә кайтыр идем» (И.Якупов музыкасы), «Юллар» (Л.Айтуганов музыкасы), «Җәйнең матур аяз таңнарында» (Ф.Әхмәдиев музыкасы) һәм башка күп кенә җырларны без бүгенге яшь җырчыларыбызның концертларында еш ишетәбез.

Мавыктыргыч-маҗарави тормыш юлы үткән, Бөек Ватан сугышында утлар-сулар кичкән шушы олпат шәхеснең, татар шигъриятендә җыр жанрының классик үрнәкләрен булдырган күренекле шагыйрьнең юбилеен ни рәвешчә билгеләп үтик, дигәндә, әлбәттә, без аның әнә шул онытылмас җырларын хәтердә яңартырга тиешбездер. Шуңа күрә дә журнал укучылар игътибарына аның шигырьләренә язылган җырлардан төзелгән концерт тәкъдим ителә.

*Мостафа Ногманның тууына – 110 ел*

# МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЯШЬЛЕК ШАГЫЙРЕ



Киң катлау укучыларга шагыйрь һәм тел галиме Мостафа Ногман (1912–1976) иң элек милләттәшләребез яратып тыңлый торган популяр җырлар авторы буларак билгеле. Татарстан радиосы фондындагы язмаларына күз салсак, без әлеге җырларның заманнан-заманга күчеп, күңелдән-күңелгә тапшырылып барган үлемсез әсәрләр булуын күрәбез. Әлеге язмаларның иң әүвәлгеләре 1953 елга карый. «Онытa алмыйм», «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Бөдрә таллар», «Салагыш болыннары», «Гел синең хакта», «Ул гына аңлар кебек», «Киек казлар китә», «Ә кайда соң минем мәхәббәтем», «Сагыну җыры», «Ак җилкән» кебек җыр текстларын Рөстәм Яхин, Сара Садыйкова кебек шул заманның иң затлы композиторлары көйгә салган, әлеге җырлар һәм романслар дистәләрчә җырчының репертуарына кергән. Әле бүген дә Мостафа Ногман шигырьләренә иҗат ителгән җырларның концертларда, радио эфирларында тынып торганы юк.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган аудиоязмада әдипнең шәхесе дә, иҗаты һәм гыйльми эшчәнлеге дә шактый ук тулы булып ачыла. Тапшыру 1992 елда Мостафа Ногманның тууына 80 ел тулу уңаеннан әзерләнгән булган һәм анда күренекле галимебез Нил Юзиев, язучы Мөхәммәт Мәһдиев, җырчылар Фәридә Кудашева һәм Мөнирә Булатова, танылган галим һәм педагог Җәмил Зәйнуллин үзләренең фикерләре һәм истәлекләре белән уртаклашканнар.

«Күңелдә ул һаман да яшь булып, мәһабәт гәүдәле матур ир булып, күңеле һәрвакыт җыр һәм музыка белән тулы яшьлек һәм мәхәббәт шагыйре булып гәүдәләнә, – дип башлый Нил Юзиев үзенең истәлекләрен. – Мостафа, кешенең һәр адымы мәхәббәт уты белән яктыртыла, дип, бик дөрес яза. Бу сүзләр аның үзенә дә, бөтен тормыш юлына да бик тә туры килеп тора. Ул гомере буе мәхәббәт уты белән янып яшәде, картаймаска тырышып көн итте. Ленин районындагы Химиклар сарае яныннан үзе эшләгән университетка ул җәяүләп йөрергә ярата иде. Еш кына мине дә үзе белән бергәләп кайтырга дәшә иде. Кышын ял көннәрендә чаңгы белән Тирән күлгә, Аккош күлләренә бара иде. Кайткач хозурланып, яңа туган шигъри хисләре белән уртаклаша иде. Олыгая барса да, һәрчак үзен яшьләрчә тойды, ничә яшьтә икәнен тирә-юньдәгеләргә белгертмәве дә, туган көннәрен билгеләп үтәргә яратмавы да, юбилейларын уздырмавы да әнә шул яшьлектән аерылырга теләмәү хисе белән бәйле иде булса кирәк. Аңлы рәвештә ул үзен картаюдан саклый, йөрәгендә мәхәббәт утының сүнүеннән курка иде...»

Хәер, без тапшыруның эчтәлеген тулысынча сөйләп чыгуны максат итеп куймыйк, укучыларыбызның үз ихтыярына калдырыйк. Әйткәнебезчә, биредә милләтебезнең биш олпат шәхесе катнаша. Аларның газиз тавышларын ишетү күңелләрдә рәхәт бер сагыш уятыр, дип уйлыйбыз.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# АЛТЫН ТӨБӘГЕНДӘГЕ АЛТЫН КЕШЕЛӘР

*Аларның максаты уртак: Татарстаннан читтә яшәсәләр дә, балаларына, оныкларына ана телләрен өйрәтү, ата-бабаларының рухи-мәдәни мирасын калдыру. Бүген без Свердловск өлкәсендә кунакта.*

## Оясында ни күрсә...

Халыкта «Балаңны тәрбияләмә, үзеңне тәрбиялә, ул барыбер үзеңә охшаячак» дигән гыйбарә йөри. Березовский шәһәрендә көн итүче милләттәшләребез дә моны яхшы аңлый. Ноябрь уртасында шәһәрнең 5 нче гимназиясендә «Милли ишегалды» дип аталган чара да шул максаттан үткәрелде. Җиде йөздән артык гимназистлар хозурына татар халкы яшәеше белән бәйле күренешләр, илкүләм билгеле «Курай» ансамбле чыгышы тәкъдим ителде.

– Әле күптән түгел генә укучыларны үзебезнең көнкүреш, милли гореф-гадәтләребез белән таныштырган идек кебек. Баксаң, укучылар белән тәүге очрашудан соң инде өч дистә елдан артык вакыт үтеп киткән икән, – ди Березовскийдагы татар-башкорт җәмгыяте җитәкчесе Фрида Насретдинова, шәһәрдә милли хәрәкәт җанланып киткән чорны искә төшереп.

Фрида ханым үзе тумышы белән Башкортстанның Тәтешле районы Аксәет авылыннан. Югары белемне Казанның финанс-икътисад институтында ала, хезмәт юлын Арча сөт комбинатында башлый ул. Әмма, кияүгә чыгып, туган ягына – Нефтекамскига күченеп кайткан яшь белгечне язмыш җилләре Свердловск өлкәсенә алып китә. Биредә дә ул сайлаган һөнәренә тугры кала – башта Россиядә бердәнбер прецизион эретмәләр заводында, ә 1993 елдан соң яңа оешкан медицина иминиятләштерү фондында бухгалтер булып эшли. Инде лаеклы ялда булуына карамастан, бүген дә җаваплы вазифада ул – Березовскийда яшәүче милләттәшләребезне бердәм йодрыкка туплап тора.

– Хәзерге заманда үгет-нәсыйхәт белән генә туган телне өйрәнүгә кызыксыну уятып булмый, бигрәк тә үсеп килүче буын яңалыкка интерактив чаралар, уен аша тартыла. Гимназиядә үткән чара да – моның ачык мисалы, – ди Фрида Фәрит кызы.

Халкыбызның сый-нигъмәтләреннән авыз итү, костюмнарын тотып карау, эш кораллары аша һөнәрчелек белән танышу укучылар күңеленә аеруча хуш килгән. «Инде күбесенең әти-әниләре дә ишетеп кенә белгән иләк, орчык-каба, бишекне күрсәткәндә, бигрәк тә Сабантуй күренешен яктырткан чүлмәк вату, капчык киеп сикерү уеннарын уйнаган чакта аларның күзләре янып торды», – ди Фрида ханым. Балалар да җавапсыз калмаган: абый-апаларына сәләтләрен күрсәтеп, халкыбызның җыр-биюләрен башкарган.

Шул ук максатны күздә тотып, активистлар Сабантуйга бүләк җыюга да күбрәк яшьләрне җәлеп итәргә тырыша. Гореф-гадәтләрне барлау белән беррәттән, аларны киләчәк буынга тапшыра алырлык алмашчылар тәрбияләү дә мөһим бүгенге заманда.

## Берлек кайда – көч шунда

Теләсә нинди идеяне дә тормышка ашырып була дигән фикердә Березовскийда яшәүче милләттәшләребез. Ә алар бирегә илнең төрле почмакларыннан җыелган. Без аралашканнары Татарстан, Башкортстан республикаларыннан, Пермь краеннан күчеп төпләнгәннәр.

– Һәр эштә иң мөһиме – бер уй белән янып йөрүче кулдашларың булу, – ди Фрида Фәритовна. Иҗтимагый хәрәкәткә кушылган һәркемнең үз юнәлеше бар икән. – Бу эшне аерым бер кеше генә башкара дигән сүз түгел. Күмәкләшеп эшлибез.

Мәсәлән, укучылар белән очрашуда гына түгел, өлкә күләмендә, шәһәрдә уза торган һәр чараның йөзек кашы булган «Курай» милли коллективына нигез салынган елны



*Татарлар килә! Березовский татарлары!*

хәтерләмиләр дә инде биредә. Ә менә 2009 елда ансамбльне Илнур Хәмидуллин җитәкли башлагач, аңа яңа сулыш өргәндәй була. Татарстанның Балтач районы Куныр авылында туып-үскән егет, Казан мәдәният институтын тәмамлаганнан соң, тормыш иптәше Зөлфиянең туган ягы Свердловск өлкәсенә юл тота. Һөнәрле кайда да югалмый инде. Берсе – хор-дирижёрлык, икенчесе оркестр бүлеген тәмамлаган яшь белгечләрне Березовский җирлеге, бигрәк тә андагы мәдәният бүлеге колач җәеп каршы ала.

– Икебез дә бер үк уку йортын тәмамладык. Тормышка, иҗатка карашыбыз уртак. Мин шәһәрдә эшләсәм, Зөлфия күрше Югары Пышма шәһәрендә иҗат итә. Бәйрәм-фестивальләрдә очрашабыз, бәйге-ярышларда «бил алышабыз», – ди Илнур әфәнде. – Шулай да баян кирәк чакта пышмалылар белән дә сәхнәгә чыккалыйм. Арада көндәшлек юк, төп максатыбыз – милләттәшләребезне берләштерү, иҗат аша туган телебезне, мәдәниятне саклап калу. Тарихи Ватаныбыздан читтә булганда, бу – иң мөһиме.

Иҗат кешеләренең балалары, гадәттә, сәхнәдә үсә. Зөлфия ханым белән ике кыз һәм бер ул тәрбиялиләр. «Мәктәптә күбрәк рус телендә сөйләшәләр, өйдә татарча аралашырга тырышабыз. Аңласалар да, мохит булмагач, кыенракка туры килә инде яшьләргә, – ди ата кеше. – Шундый чакларда җыр һәм бию ярдәмгә килә. Кечкенәдән халык музыка уен кораллары, җырлар, гомумән, мәдәниятебез белән танышып үсәләр».

Әле менә узган ел мәктәп яшендәге балалар өчен «Тамчы» ансамбле оештырганнар. Ансамбльгә әлегә даими рәвештә 5-6 бала гына йөрсә дә, проектның нәтиҗәле булачагына ышана җитәкче. «Җырлар аша ана телебезнең матурлыгын күрсәтәбез, традицияләребезне өйрәнергә җирлек тудырабыз», – ди ул.

Шунысы да игътибарга лаек: илнең төрле почмакларыннан бәхет эзләп килгән төрле милләт вәкилләрен үзенә сыендырган Березовскийда һәркемгә ихтирам белән карыйлар. «Башкалар алдында дәрәҗәне төшереп булмый. Һәр чыгышыбыз белән тамашачыга аерым бер идеяне җиткерәсебез килә. Шуңа күрә халкыбызның иң матур әсәрләрен тәкъдим итеп, шулар аша татар сәнгатенә юл ачарга омтылабыз. Җырларны 2-3 тавышка җырлавыбыз да чыгышларыбызга яңа төсмер өсти», – ди Илнур әфәнде.

Тырышулары да бушка китми артистларның. Моны ирешкән уңышлары да раслап тора. Әле күптән түгел үзешчән коллективлар арасында үткәрелгән «Милләтләр бердәмлеге» («Единство наций») фестивалендә 2 нче урынга лаек булганнар. Татар җырларын башкаручыларның «Урал сандугачы», «Яраткан моңнар» төбәкара бәйгеләрендә дә «Курай»лылар ел саен беренчеләр рәтендә.

– Эчәр суыбыз, ашар ризыгыбыз шунда булган, кендек каны тамган җирләрдән еракта яшәргә язган инде. Шөкер, әти-әниләрем исән-сау. Җай чыкканда, Татарстанга кайтабыз, ешрак әти-әниләр, гаиләләре белән энеләрем кунакка килә, – ди Илнур әфәнде. – Шәһәр

җитәкчелеге дә, иганәчеләр дә ярдәм кулы сузып тора, бер гозеребезне дә кире каккannары юк. Музыка мәктәбе, яшьләр үзәге, китапханә белән үзара ярдәмләшеп яшибез. Читтән килүчеләр дә сокланып китә.

– Шуңа да игътибар итәргә кирәк, – дип, сүзгә Фрида Фәритовна кушыла. – «Курай»га йөрүчеләребезнең дүртесе генә лаеклы ялда, башкаларының төп эш урыны бар. Шулай да җай чыккан саен репетициягә киләләр, кирәк чакта ярдәм итәләр.

Әңгәмәдәшләремнән ансамбльнең исеме җисеменә туры киләме соң дип кызыксынам. Халкыбызның онытылып бара торган җырларын күп очракта баянга кушылып җырласалар да, араларында курай тартучы Вадим Мостафин да бар икән. Иҗат белән эшне бергә үреп бару Вадим үскән гаиләдән киләдер, мөгаен. Җәен 83 яшен тутырган әтисе Мөдәррис ага да соңгы җиде ел дәвамында «Курай»лылар белән бергә җырлап йөри. «Тормышының күп өлешен шахтада үткәргән булуына карамастан, сулышы әйбәт, рәхәтләнеп җырлый – андыйлар сирәк», – диләр аның хакында хезмәттәшләре. Моннан берничә ел элек тормыш иптәшен җирләгән Мөдәррис ага үзе дә ансамбльгә рәхмәтле. «Яшәвемә бер ямь бирдегез, сезнең янда яшәреп киттем», – ди ул.

## «Үз тамырларыңны онытма»

Илнур әфәнденең авылдашы – Гөлсия ханым Гарипова җитәкчелегендә булдырылган проект әнә шулай дип атала. Кияүгә чыгып, монда килеп төпләнгәненә дә егерме елдан артык вакыт узып киткән инде. Әле туган ягында яшәгәндә үк мәдәният йортында эшләү тәҗрибәсе булган Гөлсия Равил кызы, бирегә килгәч тә, үзәк китапханәгә эшкә урнаша. Бүгенге көндә өлкән китапханәче булып эшли.

Фикердәшләр бер-берсен әллә кайдан эзләп таба. Гөлсия һәм Фрида ханымнарның да юллары бик тиз кисешә.

– «Үз тамырларыңны онытма» проекты шәһәребездә яшәүче милләттәшләр белән бергәләп эшләү, ана телебезне, гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклау, балаларыбызга җиткерү максатында булдырылды. Мин килен булып төшкәндә, китапханәдә бер генә татар китабы да, гәҗит-журналы да юк иде. Шөкер, бүгенге көндә «Казан утлары», «Сөембикә», «Идел» журналларын яздырабыз, аларны сорап укучыларыбыз да шактый. Шулай ук Татарстан китап нәшрияты белән тыгыз элемтәдә эшлибез. Ел саен киштәләребез яңа, матур эчтәлекле татар китаплары белән тулыланып тора, – ди туган ягы белән ныклы дуслык җепләре булдырган Гөлсия ханым.

Һәрчак яңалыкка омтылган, шулар аша яшьләрдә уку культурасы тәрбияләргә тырышкан Гөлсия ханымның уңышлары да шактый. Шундыйларның берсе – ТАССР төзелүнең 100 еллыгына багышлап, китапханәчеләр арасында оештырылган өлкәкүләм бәйгедә катнашып, «Туган як серләре» проекты белән җиңүчеләр рәтенә керүе.

Хезмәттәшләре белән бер максат өчен тырышулары да бушка китмәгән – ун миллионлык грант хисабына китапханәгә заманча ремонт ясалган. Укучыларны яңа китаплар, татар әдипләре белән таныштыру өчен төрле чаралар үткәрелү традициягә кергән инде: бу җәһәттән күргәзмә-презентацияләр, җай булганда, шагыйрь-язучылар белән очрашулар да оештырыла. Балаларга онлайн форматта әкиятләр укуны да уңышлы алым дип саныйлар биредә. Г.Тукай, М.Җәлилнең туган көннәренә атап оештырылган рәсем һәм шигырь бәйгеләре, төрле әдәби чаралар да еш уздырыла. Шунысы куанычлы: әлеге чараларда төрле милләт вәкилләре катнаша. Активист ханымнар фикеренчә, бу балалар һәм яшьләр арасында ана телләрен өйрәнү белән беррәттән, башка милләт мәдәниятенә ихтирам хисе тәрбияләү өчен дә бик мөһим.

– Соңгы елларда Татарстаннан читтә урнашкан төбәкләрдә дә халкыбызның гореф-гадәтләренә, традицияләренә игътибар арта, – дип, сүзгә кушыла бүгенге көндә шәһәр администрациясе карамагындагы Иҗтимагый палата депутаты Фрида ханым. – Бу исә үсеп килүче буынга үз тамырларын өйрәнергә этәргеч булып тора. Моның өчен шәһәр җитәкчелеге, иганәчеләргә зур рәхмәтлебез.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк: Гөлсия ханым тормыш иптәше Марс әфәнде белән ике кыз үстергәннәр. Алсу һәм Айгөл саф татар телендә сөйләшә. Милли җанлы әти-әнисенә охшап, шәһәр, өлкә күләмендә үткәрелгән чараларда катнашып, чыныгу алган кызларның берсе Казанда табиб һөнәрен үзләштерә, икенчесе Екатеринбургның И.И. Ползунов исемендәге көллиятендә белем ала.

– Туган яклар бик сагындыра, – ди Гөлсия ханым. – Анда кайтуны бик дулкынланып көтеп алам. Авылдашым Илнур белән бер өлкәдә хезмәт итүебез исә шул сагынуны вакытлыча булса да басып торырга ярдәм итә.

## Уртак омтылыш

Татар халкын Сабантуйсыз күз алдына китереп булмый. Аны хәзер чит илләрдә дә, хәтта океан аръягында да зурлап оештыралар. Милләттәшләребез күпләп яшәгән Березовскийда исә ул быел утыз икенче тапкыр оештырылган.

– Шөкер, башлап җибәргән чордагы кебек кул сузып йөргән чаклар артта калды. Егетләрем хәзер: «Оештыру – синнән, финанс ягын үзебез хәл итәбез», – дип елмая Фрида ханым. Егетләр дигәндә, ул мәчет каршында төзелгән Попечительләр советын күз алдында тота. Рәисләре Фәрит Миннәхмәт улы Нәбиуллин белән берлектә алар шәһәр халкын, бигрәк тә милләттәшләре мәнфәгатьләрен кайгыртып яши. Татар-башкорт иҗтимагый хәрәкәтенә булышлык күрсәтә, мәдәният чараларын, спорт ярышларын игътибарсыз калдырмый. Шул рәвешле күпмилләтле илнең бердәмлеген ныгытуга зур өлеш кертә.

Мәчет дигәннән, моннан 13 ел элек ишекләрен ачкан мәчеттә тумышы белән Свердловск өлкәсенең Каменск-Уральский шәһәреннән имам Рәдифулла хәзрәт Гиндуллин эшли. Мәчет карамагындагы шимбә-якшәмбе мәктәпләрендә теләгән һәркем – олылар да, балалар да татар телен йә гарәп графикасын өйрәнә яисә дини белем ала.

Милләттәшләребезнең һәрберсе иҗтимагый хәрәкәт эшенә үзеннән өлеш кертергә тырыша. Кемдер матди яктан булыша, икенчеләре оештыру эшендә башлап йөри. Тумышлары белән Башкортстаннан булган Рида һәм Нәҗип Хәйдәршиннар шундыйлардан.

– Без күчеп килгәндә, Березовский кечкенә генә бер бистә иде әле. Хәзер әнә нинди матур шәһәргә әйләнде. Ул чакта монда татарлар яши дип тә уйламый идем. Ә менә гомер бәйрәмемне шәһәрдә популяр булган «Кристалл» ресторанында үткәрәсем килде. Нәкъ шул ук көнне анда татар-башкорт җәмгыяте матур бер чара уздыра иде, – дип искә ала Рида ханым үзенең милли хәрәкәткә кушылып киткән чакларын.

Шул вакыт эчендә башкарган эшләре дә шактый булган инде. Милли бәйрәмнәр белән беррәттән, иганәчеләр ярдәмендә Өлкәннәр көненә бүләкләр тарату оештырылган. Гомер буе шахтада эшләгән әби-бабайларның күңелен күрер өчен барлыкка килгән чара оештыручылар өчен дә бер савaплы эш булып тора. Мәүлет аенда җыелган садакаларга хәрби хезмәткә киткән якташларына кирәк-яраклар алып җибәргәннәр.

– Рух ягыннан да, физик яктан да көчле буын тәрбияләнә Березовскийда, – ди шәһәрдә милли көрәш түгәрәген ачып җибәргән Пермь өлкәсе Янапай авылы егете Фәрит Миннәхмәтов. – Моның өчен барлык шартлар да тудырылган.

Бүгенге көндә спорт мастерлыгына кандидат, беренче разрядка ия спортчылар тәрбияләгән тренерның планнары зурдан. Самбо, тхэквондо, дзюдо кебек спорт төрләре белән беррәттән татарча көрәш белән шөгыльләнүче егетләрне дә чемпионнар рәтендә күрер өчен тырыша ул. Ниятенә ирешер өчен тылы нык – тормыш иптәше Гөлчирә ханым һәр эшендә таянычы булып тора.

Гомумән алганда, Березовский шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез ныклы кулларда. Венера-Рәзиф Рияновлар, Гөлназ-Олег Фасиховлар, Рушания-Марат Янгировлар турында да алга таба язарбыз әле. Җир астына төшеп, шахталарда эшләп, алтын белән очрашмасалар да, аларның һәрберсен алтынга тиңләп була. Тарихи Ватаннарыннан читтә гомер кичерсәләр дә, берләшеп, уртак максатлар белән яши алар. Бердәм булгач, ниятләренә ирешәләр дә!

**Ландыш НӘСЫЙХОВА**

# 2022 елда «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр исемлеге


**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЛАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №6

«Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. №10

**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНА – 100 ЕЛ**

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары Ассамблеясе рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шамил Садыйков котлаулары. №5

**БЕЗНЕ КОТЛЫЙЛАР:**

Азәрбайҗан Республикасының халык шагыйре Әкбәр Гошалы, Казакъстан Республикасының «Касым» журналының баш мөхәррире Серик Сагынтай, Кыргыз Республикасы Язучылар берлегенең «Ала-Тоо» журналы баш мөхәррире Маркабай Ааматов, Башкортстан Республикасы «Агыйдел» журналының баш мөхәррире Мөнир Кунафин, Башкортстан Республикасы «Шоңкар» журналының баш мөхәррире Айгиз Баймөхәммәтов, Чувашия Республикасының халык шагыйре Юрий Семендер, Кырым Республикасы «Йолдыз» журналының баш мөхәррире Диләвәр Осман, Кабарда-Балкар Республикасы «Мәңге-Тау» журналының баш мөхәррире Әскәр Додуев, Калмыкия Республикасының халык шагыйре Эрдни Эльдышев, Саха (Якутия) Республикасы «Чолбон» журналының баш мөхәррире Гаврил Андросов, «Литературная газета»ның баш мөхәррире Максим Замшев. №5

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Г а л и у л л и н Р. Рухи ЙӨЗебез. №5

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ә м и р х а н Ф. Чәчәкләр китерегез миңа! *Нәсер*. №5

Ә м и р х а н о в М. Ататуш. *Бәян*. №6

Ә х м ә т г а л и е в а А. Кайтаваз. *Хикәя*. №5

Б ә й р ә м о в а Ф. Сирень чәчәге. *Хикәя*. №5

Г а л и В. Соңгы сәфәр. *Бәян*. №6

Г а л и е в М. Хыянәткә – кыямәт. *Эссе*. №5

Г а л и у л л и н Р. Хикәяләр. №2

Г а ф ф а р Ә. Карачкылар. *Хикәя*. №5

Г ы й л ә җ е в А. Йәгез, бер дога! *Роман-хатирәдән өзек*. №5

Г ы й м а л т д и н о в Ф. Буа. *Роман*. №№1-3

Г ы й м а т д и н о в а Н. «Сатлыкҗан». *Хикәя*. №5

Г ы й м а т д и н о в а Н. «Юаш». *Повесть*. №12

Е н и к и Ә. Кем җырлады? *Хикәя*. №5

И к с а н о в а И. Матәм. *Хикәя*. №4

К а м а л Ш. Курай тавышы. *Хикәя*. №5

К а р а К. Биек бәхет таулары. *Повесть*. №4

К ә б и р о в М. Тик син генә. *Повесть*. №№11-12

К ә р и м о в а Н. Изге ат. *Хикәя*. №7

К у т у й Г. Тапшырылмаган хатлар. *Повестьтан өзек*. №5

М ә һ д и е в М. Бәхилләшү. *Повестьтан өзек.* №5

М ө х ә м м ә т ш и н Р. Лаләләр. *Хикәя*. №1

С а б ы р Р. Фәхрине үтереп ташладылар... *Роман*. №№9-10

С ә г ъ д и Р. Әлмирәнең хәтере ачыла. *Роман*. №№11-12

С ә л и м Р. Агыйделнең бу ягында. *Хикәя*. №10

У с м а н о в а Р. Ярлыкану бәхете. *Повесть*. №3

Ф ә т т а х Н. Тәнкыйтьче. *Сатира-юмор*. №5

Х а р и с о в а Н. Үтте инде. *Повесть*. №4

Х ә к и м З. Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?.. *Роман*. №№7-8

Х ә л и м А. Моң кайтты. *Повесть*. №1

Х ә м з и н А. Кабул итәсезме?.. *Роман-фарс*. №9

Ш а һ и е в Р. Гайшә-Фатыйма. *Повесть*. №6

Ш ә м с и С. Әшрәф баба хөҗрәсендә. *Хикәя*. №8

Ю н ы с о в а А. Мәк чәчәге. *Бәян*. №8

**ШИГЪРИЯТ**

А ш и р о в И. Без бу җирнең бары кунаклары. *Шигырьләр*. №12

Ә х м ә т җ а н о в а С. Дәлилләрбез. *Шигырь*. №3

Ә х м ә т җ а н о в а С. Исән килеш исемлектән төшмик. *Шигырьләр*. №4

Б а к и р о в М. Җаным әрнер яшәп туймаганга... *Шигырьләр*. №4

Б а т т а л о в а Г. Айсыз авыл. *Поэма*. №8

Б ә ш ә р Р. Учларымда гөлләр үстердем мин... *Шигырьләр*. №11

Б ә ш и р о в а З. Безнең юл. *Шигырь*. №5

Б и е к т а у л ы И. Кан сагышы. *Шигырьләр*. №2

В ә л и е в Р. Мин бәхетле – ил бәхетле булса... *Шигырьләр*. №1

Г а з и з о в Р. Туган илем – болыннарың таҗы. *Шигырьләр*. №4

Г ы й б а д у л л и н а Л. Иңнәремдә көн талпынып куйды... *Шигырьләр*. №3

Г ы й б а д у л л и н а Л. Ут сагында. *Шигырь*. №5

Г ы й б а д у л л и н а Л. Гали Рәхим. *Поэма (Гали Рәхимнең тууына – 130 ел)*. №11

Г ы й з з ә т у л л и н а Ф. Ком бураны. *Поэма*. №9

Г ы й л ә җ е в Ф. Үз хәлеңне җитә чамалау... *Шигырьләр*. №6

Җ ә л и л о в а Г. Табылсын якуты вакытның... *Шигырьләр*. №1

Җ и һ а н г и р о в а Ш. Үз балаңа мирас итеп калдыр телең... *Шигырьләр*. №6

З ә й д у л л а Р. Гел яхшыга юрасын тик кошлар... *Шигырьләр*. №1

З ө л к а р н ә й Л. Гөрләгән сулар. *Йөз елдан соң мәрсия*. №4

З ө л ф ә т. Яшәр безнең журналыбыз. *Шигырь*. №5

И с м ә г ы й л е в а Ф. Ник яңара җанда шушы моң? *Шигырьләр*. №7

К о р б а н Р. Казан. *Поэма*. №6

К ы я м о в И. Мин – бары тик гади кеше генә... *Шигырьләр*. №3

М а н с у р о в З. Бәгырьдәге гамьнәр төенләнә... *Шигырьләр*. №7

М и р з а М. Мәңгелек юлында. *Поэма-кыйсса*. №7

М ө х ә м м ә т ш и н Р. Бары купты күк гөмбәзе... *Шигырьләр*. №12

Н и з а м и Р. Күтәрелдек без дә түбәннән. *Шигырьләр*. №8

Р а х м а н Р. Идел буе – минем йортым ул. *Шигырьләр*. №9

С а б и р о в а Г. Мин аклык эзлимен җиһаннан... *Шигырьләр*. №6

С а ф и н Ф. Бәхетлеләр үз илендә яши... *Шигырьләр*. №3

С а ф и н а Н. Мәңгелек белән элемтә. *Шигырьләр*. №1

С ә л а х Р. Вакыт ага... көзге яңгыр булып... *Шигырьләр*. №10

С и т д ы й к о в а Ә. Мин кыяда басып торам... *Шигырьләр*. №10

С о л т а н Ф. Сал хәсрәтен тирән дәрьяга... *Шигырьләр*. №9

С у ф и я н о в А. Хак Тәгалә безне җанлы иткән... *Шигырьләр*. №10

Ф ә т т а х о в а Л. Вакыт күк тарала хәятнең өннәре... *Шигырьләр*. №10

Ф ә т х и Л. Ут капканда чыгып йөрәгеңнән... *Шигырьләр*. №2

Х а р и с Р. Татар кычытканы. *Поэма*. №2

Х ә й р у л л и н Д. Гел тәгәрәп торыр кояшы да... *Шигырьләр*. №12

Х ө с ә е н о в а Э. Мин сиңа ошарга тырышмам. *Шигырьләр*. №3

Ш ә р и п о в Р. Тормыштан да олы бернәрсә юк... *Шигырьләр*. №2

Ш ә р и ф у л л и н а Э. Сугыш кырларыннан мин кайтсам?.. *Шигырьләр*. №6

Ш и р м ә н Х. Кулъязмалар – тормыш көзгесе... *Шигырьләр*. №7

Я к у п о в а С. Күңел галәмендә һич тынгы юк... *Шигырьләр*. №8

Я н с у а р Л. Мин сүзләрне җылы сөткә манам... *Шигырьләр*. №11

**ЮБИЛЕЙ САНЫНА КЕРГӘН ШИГЫРЬЛӘР**

Тукай Г., Дәрдемәнд, Рәмиев С., Сүнчәләй С., Гафури М., Бабич Ш., Думави Н. *шигырьләре*. №5

Такташ Һ., Туфан Х., Исәнбәт Н., Фәйзи Ә., Нәҗми К., Баттал С. *шигырьләре*. №5

Җәлил М., Кәрим Ф., Алиш А.,

Дәүли Н., Мөдәррис Ш., Мөҗәй Х., Баян Н. *шигырьләре*. №5

Хәким С., Нәҗми Н., Арсланов Н., Кәрим М., Нури З., Маннур Ш., Давыдов Ә., Мансур З., Кудаш С., Гәрәй Р. *шигырьләре*. №5

Юзеев И., Афзал Г., Галиев Ш., Баян Ә., Атнабаев Ә., Әхмәтҗанов Р., Сөләйманова С., Зәйнашева Г., Булатова К., Шабаев М., Кәримов М. *шигырьләре*. №5

Яруллин Ф., Фәйзуллин Р., Харис Р., Гаташ Р., Әхмәтҗан Р., Рәхим Г., Гәрәева С., Мингалим Р., Хәлим А., Рәшит Ә., Гыйззәтуллина Ф., Шәфигуллин Ф., Сибгатуллин К., Насыйбуллин З. *шигырьләре*. №5

Әгъләм М., Зөлфәт, Сафин Ф., Миңнуллин Р., Әюп Х., Вәлиев Р., Гамбәр Н., Шагыйрьҗан Л., Мансуров З., Садә Г., Низами Р. *шигырьләре*. №5

Зәйдулла Р., Зөлкарнәй Л., Морат Г., Корбан Р., Рахман Р., Лерон Л., Акмал Н., Әмәк Ф., Мирза М., Җамалетдинова Ф., Иксанова И., Сафина Н., Сөләйман Җ. *шигырьләре*. №5

Аймәт Р., Кәбиров М., Янсуар Л., Суфиянов А., Шәех Л., Миңнуллина Й., Батталова Г., Сәлах Р., Мөхәммәтшин Р., Ибраһим Б., Гыйләҗев Ф. *шигырьләре*. №5

**ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ**

Гыйләҗев М. Соңгы мираж. *Ике бүлектән торган романтик кыйсса*. №4

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Ильюп О. Ялган кояш күзне чагылдыра... *Шигырьләр*. (*Ф.Гыйләҗевнең кереш сүзе белән)* №11

Низамова Л. Тиле. *Хикәя*. №3

Равилова Л. Балакошлар инде белми хөрлек төсен. *Шигырьләр*. №9

Хафизов И. Хикәяләр. №8

Яруллина Ф. Өмет тама җанны куандырып... *Шигырьләр*. №4

**«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ**

Абдуллин Ф. Сәет батыр токымнары. *Повесть*. №12

Әбүдәрова Л. Кара каплан. *Хикәя*. №9

Әхмәтгалиева А. Без барабыз, ул килмәс... *Повесть*. №10

Гафиятов А. Чуен аю. *Документаль хикәя*. №9

Гыйбадуллина Л. Кара батыр. *Документаль повесть*. №7

Гыйльманов Г. Батыр асты. *Хикәя*. №8

Гыймаев З. Көрәшче. *Хикәя*. №6

Гыйматдинова Н. Остаз. *Документаль повесть*. №3

Исмәгыйлев Х. Беренче Сабантуй. *Хикәя*. №2

Корбан Р. Соңгы Сабантуй. *Хикәя*. №1

Низами Р. Келәмдә очрашу. *Хикәя*. №4

Хан А. Потап. *Хикәя*. №11

**ЕРАКТАГЫ УТЛАР**

Бәдретдинов Х. Кер син миңа төннең уртасында... *Шигырьләр*. №9

Корбан Р. Таныш булыгыз: Нижгар шагыйрьләре. №9

Рамазанов Р. Хәтер буйлап кайтам егет чакка. *Шигырьләр. (Р. Корбан тәрҗемәләре)*.

**КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ**

Аджиев Б. Йөрәк таныла тибеше белән... *Дүртьюллыклар. (Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №2

Азнабакиев А. Салкын һава, тулган айлы йолдызлы төн... *Шигырьләр*. №12

Акбаев Ә. Белгәнемне язам манып канга... *Шигырьләр. (З. Хәким тәрҗемәләре).* №8

Беппаев М. Тауларым – минем очар кошларым... *Шигырьләр. (Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №1

Додуев Ә. Җәһәннәм белән куркытма мине... *Шигырьләр. (Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №1

Зумакулова Т. Сез килегез миңа кунак булып... *Шигырьләр. (Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №1

Исхаков В. Дуслар. *Хикәя (Р. Корбан тәрҗемәсе)*. №9

Курудимова М. Алда ни көтәсен кем белгән... *Шигырьләр (Ф. Гыйләҗев тәрҗемәләре)*. №11

Лугинов Н. Һуннар бәяны. *(Ф. Җамалетдинова тәрҗемәсе)*. №6

Мәүләнов С. Җырлы Казан. Бер сәхифә тарихы. *(Кереш сүз авторы һәм казакъчадан тәрҗемә итүче – Л. Хәмидуллин)*. №7

Өмәруглы Я. Хикәяләр. (*Төрекчәдән З. Москау, К. Мукашева, Р. Корбан тәрҗемәләре)*. №10

Сарманбетов А. Дөнья киң ул, әгәр күңел киң булса... *Шигырьләр (Л. Шәех тәрҗемәләре)*. №4

**ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ**

Абдуллина Ф., Әхмәдиева Д., Гыймадиева Р., Гыйниятов Г., Ибраһимова Г., Сабирҗанов Р., Сәгыева А., Сибгатуллина М., Хәкимуллина З. *шигырьләре*. №1

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Әбүдәрова Л. Донкихотлар ничек үлә? *(Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» романына бәяләмә)*. №11

Галимуллин Ф. Яшьлеккә гашыйк әдип *(Рәфкать Кәрамигә – 80 яшь)*. №2

Галитзуллина Л. Хикәя җегәре *(Айдар Хәлимгә – 80 яшь)*. №1

Галиуллин Т. Хисчән фикерле шагыйрь *(Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында уйланулар)*. №№10-11

Заһидуллина Д. Дөньяны бары тик яхшы якка үзгәртүче *(Разил Вәлиевкә – 75 яшь)*. №1

Заһидуллина Д. Татар әдәбияты ни хәлдә? *(Әдәби әсәрләр бәйгесеннән соң уйланулар)*. №4

Ибраһимов Г. Яңа әсәрләр. №5

Мансуров З. Ваемлы йөрәк авазы *(Ркаил Зәйдуллага – 60 яшь)*. №1

Морат Г. «Шөгарә» сүрәсе өмет уята. №11

Рахмани Р. Замана шагыйре *(Рафис Корбанга – 65 яшь)*. №2

Рахмани Р. Чын шагыйрь... Һаман да шагыйрь! №3

Шәмсутова А. Йөрәге – тоташ сөюдән, күңеле җырдан тора *(Галимҗан Гыйльманга – 65 яшь)*. №2

**ФӘН**

Заһидуллина Д. Чикләрне тоташтыручы. №3

Заһидуллина Д. Татар тарихыннан энҗе эзләүче галимә. №6

Сәфәров Р. Тел – мәдәниятнең таҗы, сүзлек исә – телнең таҗы *(Алты томлы аңлатмалы сүзлек басылып чыгу уңаеннан)*. №7

Шамилоглы Ю. Минем тормыш тарихым. №3

**ТАРИХ**

Заһидуллина Д. Калын журнал. №5

Хәмидуллин Л. Сөембикә шәҗәрәсенә өстәмәләр. №11

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Исхакый Г. Безнең хәлләр. №5

Юныс Р. Референдум: халык «әйе» диде. №5

**СӘНГАТЬ**

Арсланов Г.: «Кулыңнан килсә, кешегә ярдәм ит!» *Әңгәмәдәш – Хәбибуллина А.* №11

Әхмәтгалиева А. Абагалар чәчәк атса... №4

Миңнуллин Т. «Әлдермештән Әлмәндәр». №5

Сафиуллин Ю. Әлки әллә әллүкиме? №1

**«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП**

Ибраһимов И. Еракка китеп карап. №4

Кәримов К. Йөзгә-йөз. №1

Нуриев В. Кыска юлның дәвамы яки мәңгелек сер. № 3

Хәмзин А. Синдә тудым... №2

**«КАЗАН УТЛАРЫ» – МИНЕМ ЯЗМЫШЫМДА**

Галимуллин Ф. Сүз сәнгате маягы. №2

Галиуллин Т. «Казан утлары» – татарның «визит карточкасы». №3

Имамов В.100 еллык әдәбият бакчасы. №5

Садриев Ф. Иҗат казаны. №1

Хөснияр З. Татар утлары. №5

Шәрифуллина Э. «Бу бит – академик басма!..» №4

**ЮБИЛЕЙЛАР**

ХАРИС ХӘЗРӘТ САЛИХҖАНГА – 95 ЯШЬ

«Дин белән фән тора...». *Әңгәмәдәш – Әбүдәрова Л.* №8

РИФАТ СВЕРИГИНГА – 90 ЯШЬ

Корбан Р. Картаюны белмәс картлач. №8

ЮНЫС САФИУЛЛИНГА – 75 ЯШЬ

Галимуллин Ф. Аны Мәскәү таныган. №10

ЛӘИС ЗӨЛКАРНӘЙГӘ – 60 ЯШЬ

Г а т а ш Р. Яралы хәтер, милли сүз китабы. №4

РИФӘ РАХМАНГА – 60 ЯШЬ

Г а й н у л л и н а Г. «Чорлар туа үз җырчысы белән». №9

**ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР**

*(Сәхифәне Н ә с и м А к м а л алып бара)*

МӨХӘММӘДЬЯРНЫҢ ТУУЫНА – 525 ЕЛ

Аңламас акылсыз, ассаң да дарга... №7

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

Безнең көннәрне дә язган әдип. №3

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

Ул кабызган утлар сүнмәс алар... №9

БАРИ РӘХМӘТНЕҢ ТУУЫНА – 125 ЕЛ

Могҗиза тудырган әдип. №6

ӘХМӘТ ЕРИКӘЙНЕҢ ТУУЫНА –120 ЕЛ

Татар җыры менә шундый була... №12

ГАЛИ ХУҖИНЫҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Бүген дә уйланып укырлык. №10

МОСТАФА НОГМАННЫН ТУУЫНА – 110 ЕЛ

Мәхәббәт һәм яшьлек шагыйре. №12

ЗӨЛӘЙХА ХИСМӘТУЛЛИНАНЫҢ ТУУЫНА – 100 ЕЛ

Җырчыларның моң әнкәсе. №11

РӨСТӘМ МИНГАЛИМНЕҢ ТУУЫНА – 85 ЕЛ

«Кайда сез, ирләр?» дигән иде... №8

ӘХМӘТ ГАДЕЛНЕҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Милләт гаме аны шагыйрь иткән. №2

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

Без яратмый, җирдә кем яратсын?! №2

«БАШМАГЫМ» МУЗЫКАЛЬ КОМЕДИЯСЕ ПРЕМЬЕРАСЫНА – 80 ЕЛ

Мәңге тузмый торган «башмак». №3

ШАГЫЙРЬ ЗӨЛФӘТНЕҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Аны әле һаман яраталар. №1

ӘМИР МӘХМҮДОВНЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Рухы белән ул көрәшче иде. №6

НАИС ГАМБӘРНЕҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Олпат мөхәррирләр затыннан. №8

ДАНИЯ ГАЙНЕТДИНОВАГА – 70 ЯШЬ

Балаларның якын дусты. №1

ХӘЙДӘР ГАЙНЕТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА – 70 ЕЛ

Юксындырып искә төшә... №11

Алтмыш – алтын чор башы *(Ләис Зөлкарнәй, Йолдыз Шәрәпова, Лилия Садриева, Сания Әхмәтҗанова)*. №4

**ХӘТЕР**

А х у н о в Г. Әдәби мәккәбез яшәсен! №5

Ә п с ә л ә м о в Г. «Совет әдәбияты» журналы турында солдат хатлары. №5

Б ә ш и р о в Г. «Якты тәрәзәләр». №5

Г ы й л ә җ е в А. Журналны татар яшәтә. №5

Е н и к и Ә. «Безнең юл» – «Казан утлары». №5

К а ш ш а ф Г. Нигез ташларын салганда. №5

Н у р и З. Журнал өчен, журнал белән. №5

Р а с и х А. Әдәбият мәйданына юл ачучы. №5

С и р а җ е т д и н о в Ш. Бабалар җиренә тартылу. №10

Ф ә й з у л л и н Р. Журналның үз архивын булдырыйк. №5

Ф ә й з у л л и н Р. 50 ел узгач. №5

Х а р и с Р. Урманче һәм Такташ. *Истәлек*. №8

Х ө с н и Ф. Аның яктысында. №5

Ш а м о в А. Журналның бер нөсхәсе. №5

Ю з е е в И. Журналыбыз турында. №5

Ю с у п о в Р. Бакчачы, галим һәм язучы *(Фарсель Зыятдиновның туууына – 85 ел)*. №6

Хатларда – өлкәннәр сүзе *(Хатлар Р.Гаташ архивыннан алынды)*. №5

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Б ә д р е т д и н о в Р. Хатирәләрне барлаганда *(әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловның «Озын гомерем хатирәләре» (икенче кисәк) исемле китабы чыгуы уңаеннан)*. №8

Г а й н у л л и н а Г. Фәнни сүзем – саф тылсымым... №2

И б р а һ и м о в М. «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар». №4

И б р а һ и м о в М. «Һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас». №9

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ЧИТ ТЕЛЛӘРДӘ**

З ә й д у л л а Р. Хикәянең дәвамы бар. №10

С и б г а т у л л и н а Ә. Төркиягә Казан күчтәнәче. №10

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ – ТӘРҖЕМӘДӘ**

С и б г а т у л л и н а Ә. Маҗара тәрҗемәсе яки тәрҗемә маҗаралары. №2

**ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ҺӘМ ЗАМАН**

Г ә р ә е в а - А к ч у р а А. Айнелхәят һәм аның хатирәләре. №9

К у н т а й Ш. Бер заманнар юллары Анадолудан кичкән татар хатыннары... №9

С а н а й Р. Кызыл Россиядә бер төрек хатыны. *Романнан өзекләр*. №9

**ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ – 1100 ЕЛ**

З а һ и д у л л и н И. Идел-Чулман төбәгендә ислам дине: Идел буе Болгар дәүләте. №1; 922 елда Багдад хәлифе әл-мөкътадирдән килгән илчелек. №2; Алтын Урда дәүләтендә ислам мәдәнияте. №3; XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урдада ислам дине институтлары. №4; Казан ханлыгында ислам дине. №№6-7; И. XVI гасырның икенче яртысы – XVIII йөзнең уртасында Идел-Урал төбәгендә ислам дине. №№8-10; Мәхкәмәи шәргыя оешу. №11; Мәхкәмәи шәргыянең вәкаләтләре. №12

**ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН**

Бакый Урманче хатирәләре *(З. Мөхәммәтшинның кереш сүзе белән)*. №№3-4

М ө х ә м м ә т ш и н З. Рәссамның шигъри иҗаты. №2

Р ә х и м Г. Шәрык шагыйрьләре *(Д.Заһидуллинаның кереш сүзе белән)*. №№11-12

У р м а н ч е Б. Шигырьләр. №2

**МИЛЛИЯТ**

Ш ә р и ф у л л и н а Э. Күренекле мәгърифәтченең җан авазы. №9

**МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗ**

З а һ и д у л л и н а Д. Гомер бүләк итүче галим. №7

З а һ и д у л л и н а Д. Татар фәне – Кыргызстанда. №8

З а һ и д у л л и н а Д. Татарстаннан – дөнья фәне киңлекләренә. №12

**ЗАМАНДАШЫБЫЗ**

Н ә с ы й х о в а Л. Нәфис затның көчле җилкәсе... №3

Н ә с ы й х о в а Л. Хөрлек сүздә түгел, йөрәктә. №4

Н ә с ы й х о в а Л. Бердәмлекне көч итүче ханым. №8

Н ә с ы й х о в а Л. Олы юлның... узылганы. №9

Н ә с ы й х о в а Л. Алтын төбәгендәге алтын кешеләр. №12

**БЕР ЮБИЛЕЙ ТАРИХЫ**

Л е р о н Л. Тукайның йөз еллыгын үткәргәндә. №4

**«АК ҖИЛКӘН»**

Г ы й л е м х а н о в Р. Бәләкәй Риман. №9

**БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ**

Г ы й м а д и е в А. Киләчәктән килгән малай. *Үсмерләр өчен повесть.* №7

**УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ**

Ш ә р ә п о в М. Шигырьләр. №2

**ПЕЧӘН БАЗАРЫ**

А р и ф у л л и н Р. Әрем бирсәм дә – риза. *Шигырьләр*. №7

Б ә д р и е в Д. Сәяхәтче чебеннәр. *Юмористик хикәя*. №10

К ә р и м о в К. Мин дә булдым... *Юмористик хикәя.* №5

М ө д ә р р и с о в а Х. Сайлау. *Юмористик хикәя.* №8

Х ә й р у л л и н И. Юмористик хикәяләр. №9

Ш ә р ә п о в а Й. Чиратсызлар чираты. №4

**ШАЯН СӘХИФӘ**

М а н с у р о в З. Уены-чыны бергә. №9

Х ә к и м З. Уйлар уйнавы. №5

**КАЙТАВАЗ**

С а ф и н а Н. Күп нокталар ни турында сөйли? №4

Фотоархив: Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиевкә – 85 яшь. *Сәхифәне Н.Шәйдуллина әзерләде.* №1

Юбилейга барышлый: фотоархив. №2,3,4

Фотоархив: юбилей мизгелләре. №6

Фотоархив: Лирон Хәмидуллинга – 90 яшь. №11

2022 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. №1

«Казан утлары» архивыннан. №№1-9. *Сәхифәне Р.Фәйзуллин алып бара.*

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12. *Сәхифәне В.Нуриев алып бара.*

Яңа китаплар. №№2,3,6,9,11. *Сәхифәне Г.Морат алып бара.*

## ЯЗУЧЫЛАР – ЧАЛЛЫДА

Чаллыда татар әдәбияты көннәре булып узды. Казаннан кайткан бер төркем әдипләр Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендәге каләмдәшләре белән бергә шәһәрнең төрле мәктәпләрендә, шул исәптән Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназиядә укучылар белән очраштылар. Татар әдәбияты көннәре кысаларында Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдуллага 60 яшь тулуга багышланган «Син кара Шагыйрь күзенә...» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Кичәдә ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм ТРда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Татарстанның халык шагыйрьләре Зиннур Мансуров, Газинур Морат, Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, язучы-прозаик Рөстәм Галиуллин, шагыйрь, прозаик Рүзәл Мөхәмmәтшин, җырчылар Азат Тимершәех, Равил Галиев, Гөлдания Хәйруллина, Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театрлары артистлары һ.б. катнашты. Кичәне артистлар Илфат Әскәров белән Энже Шиһапова алып барды.

## КАНДАЛЫЙНЫҢ ТУУЫНА – 225 ЕЛ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында мәшһүр татар шагыйре Габделҗаббар Кандалыйның тууына 225 ел тулуга багышланган «Якутлар табыладыр вакыт белән» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Мәдәният министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Айрат Фәйзрахманов, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов, Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, режиссёр, актёр Раушан Шәриф, Мәскәүдән шагыйрә, прозаик Лилия Агадуллина, җырчылар Рафис Хөснетдинов, Альбина Кинҗалиева, Г.Кариев театры артистлары һ.б. катнашты. Кичәне артист Фәнис Кәлимуллин алып барды.

* * *

Мәскәүдәге Татар мәдәнияте үзәгендә XIX гасыр татар шагыйре Габделҗаббар Кандалыйның рус телендәге шигырьләр җыентыгын тәкъдим иттеләр. Шигырьләрне шагыйрә һәм прозаик Лилия Агадуллина тәрҗемә иткән. Кичәдә чыгыш ясаган язучы, «Татарский мир» газетасының баш мөхәррире Ринат Мөхәммәдиев (китапны нәшер итүдә ул да катнашкан) татар әдәбиятын үстерүгә гаять зур өлеш керткән Кандалыйның күләгәдә калуын, иҗатын пропагандалау зарурлыгын искәртте.

## ХУҖА БӘДИГЫЙГА БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Г.Тукайның әдәби музеенда «Тукай фатихасы белән» дигән әдәби-музыкаль кичә узды. Ул шагыйрь, тәнкыйтьче, галим, фольклорчы, тәрҗемәче Хуҗа Бәдигыйның тууына 135 ел тулуга багышланган иде. Чарада Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, КФУ галимнәре, Г.Тукайның әдәби музее хезмәткәрләре, Бәдигыйның Санкт-Петербург, Казан, Яшел Үзәндә яшәүче туганнары катнашты һәм чыгыш ясады.

## МӘСКӘҮДӘ ЧЫККАН КИТАПЛАР

Мәскәүдәге Берләшкән гуманитар нәшрияттә (ОГИ) Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби тәрҗемә үзәге әзерләгән «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе» һәм Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» китаплары рус телендә басылып чыкты.

## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Күптән түгел Төркиянең «Һәҗә» нәшриятында (Анкара) Фатиһ Кутлу тәрҗемәсендә «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» җыентыгы дөнья күргән иде. Төркиянең «Һәҗә» әдәби-нәфис журналында

исә татар шигърияте тәкъдим ителде. Шигырьләрне дә төрекчәгә Фатиһ Кутлу тәрҗемә иткән. Журналда Фатиһ Кутлуның кереш сүзе, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән әңгәмәсе, 20 татар шагыйренең берәр шигыре, авторлар турында кыскача мәгълүмат урын алган.

### КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

ТР Милли китапханәсендә шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның «Мәңгелек юлында» дип исемләнгән китабын тәкъдим итү булды. Китапка авторның трагик артист Мохтар Мутин турындагы шигъри әсәре, «Хәбибҗамал», «Мәңгелек юлында» поэмалары һәм «Адәм баласы» шигырьләр циклы кергән. Чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире Ленар Шәех, әдәбият галимнәре Дания Заһидуллина, Нурфия Йосыпова, Миләүшә Хәбетдинова, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, язучы, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов һ.б. чыгыш ясады. Мөхәммәт Мирза Мохтар Мутин шәхесе турында, аңа багышланган әсәренең язылу тарихы турында сөйләде. Кичәдә автор үзе һәм аның укучылары шигырьләр, әсәрләрдән өзекләр укыдылар.

* * *

Буа татар дәүләт драма театрында һәм Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылы мәдәният йортында драматург, прозаик Рәдиф Сәгъдинең Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Алло, кем әле бу?!» китабын тәкъдим итү кичәләре булып узды. Бу чараларда авторның каләмдәшләре дә катнашты. Буада – Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары Рифат Җамал (ул Түбән Бәрәскәгә дә кайтты), «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан, Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, бүлек мөхәррире Ленар Гобәйдуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, Татарстанның халык артисты Илгизәр Хәсәнов чыгыш ясадылар. Кичәләрнең икесендә дә төп рольләрнең берсен Рәдиф Сәгъди башкарган «Корыч» нәфис фильмы да күрсәтелде.

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы утырышы булды. Анда язучы Заһид Мәхмүдигә исән чагында тапшырылып өлгермәгән «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исемен бирү турындагы таныклык гаиләсенә ирештерелде. Аны хатыны Рәшидә Мәхмүтова белән улы Фәнис Камал кабул итеп алды. Утырышта соңгы вакытта башкарылган эшләргә хисап ясалды. Берлекнең Әдәби тәрҗемә үзәге эшчәнлеге турында сөйләшү булды. Мөнир Вафин, Гомәр Даутов, Людмила Уфимцева Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

### СӘФӘРЛӘР

«Мәдәни җомга» газетасының, «Безнең мирас» һәм «Казан утлары» журналларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин һәм «Татар-информ» журналисты Зилә Мөбәрәкшина Башкортстанда сәфәрдә булды. Балтач районының Үзәк китапханәсендә язучы Аида Хәйртдинованың «Кышкы юл озын иде» китабын тәкъдим итүгә багышланган «Үз юлымнан барам» кичәсе оештырылды. Ул «Казан утлары» журналы редакциясе әзерләгән уналтынчы кесә китабы булып басылып чыккан иде. Шулай ук Борай, Нуриман, Мишкә районнарында, Уфа шәһәрләрендә милләттәшләр белән очрашулар узды.

* * *

«Казан утлары» журналының бүлек мөхәррирләре Рафис Корбан белән Фәнил Гыйләҗев Түбән Новгород өлкәсендәге Кызыл Октябрь районы Олы Рбишча һәм Уразовка авылларында булып, мәктәп укучылары һәм китапханәчеләр белән очраштылар. Аларга «Казан утлары»ның 100 еллык тарихы турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар. 250 бала укый торган Олы Рбишча мәктәбенә һәм район Үзәк китапханәсенә журналның быелгы саннарын, юбилеена багышлап чыгарылган фотоальбом һәм китаплар бүләк иттеләр.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, ТР Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы **Рәшит Сүнәев** теоретик физика өлкәсендә югары нәтиҗәләргә ирешкән өчен Германия физика җәмгыятенең иң югары бүләге – Макс Планк медале белән бүләкләнде.

* * *

Татарстанның халык шагыйре **Рәдиф Гаташ** «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орден медале, язучы, җәмәгать эшлеклесе **Роза Туфитуллова** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Бүләкләрне аларга Казан Кремлендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Р.САГДИ «Альмира»; повести М.КАБИРОВА «Только ты», Н.ГИМАТДИНОВОЙ «Кроткий»; стихи Р.МУХАМЕТШИНА, Д.ХАЙРУЛЛИНА, И.АШИРОВА.*
*Литературный конкурс «Майдан – для батыров!»: повесть Ф.АБДУЛЛИНА «Потомки Саид-батыра»*
*«Литература родственных народов»: стихи А.АЗНАБАКИЕВА в переводе с уйгурского языка Ф.ГИЛЯЗОВА.*
*«Соплеменник»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Бриллианты эпохи»: стихи восточных поэтов в переводе Г.РАХИМА. Публикацию к печати подготовила Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статья к 120-летию А.ЕРИКЕЯ и статья к 110-летию М.НУГМАНА. Рубрику ведет Н.АКМАЛ.*
*«Современники»: статья Л.НАСЫХОВОЙ.*
*Список произведений, напечатанных в 2022 году в журнале «Казан утлары».*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На нашей обложке: IT-парк имени Башира Рамеева. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by R.SAGDI «Almira»; stories by M.KABIROV «Only you», N.GIMATDINOVA «The Meek»; poems by R.MUKHAMETSHIN, D.KHAIRULLIN, I.ASHIROV.*
*Literary competition «Maidan is for batyrs!»: story by F.ABDULLIN «Descendants of Said-batyr».*
*«Literature of kindred peoples»: poems by A.AZNABAKIEV translated from the Uighur language by F.GILYAZOV.*
*«Tribeman»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Diamonds of the Epoch»: poems by Oriental Poets translated by G.RAKHIM. The publication was prepared by D.ZAGIDULLINA.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Priceless voices»: article dedicated to the 120th anniversary of A.ERIKEY and article to the 110th anniversary of M.NUGMAN.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*«Contemporaries»: article by L.NASIKHOVA.*
*List of works published in 2022 in «Kazan Utlary» magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Bashir Rameev IT-Park. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк. *И.АБРАМОВА фотосы.*